# казан утлары

2
ФЕВРАЛЬ-1976

# ПАРТИЯГӘ

Киләчәккә штурм ясаганда,
Ашкынулар җаннан ташканда,
Могҗизага әверелеп, күше
Җирдән Айга — күккә ашканда,
Кирәк безгә акыл — тиңсез акыл!
Кирәк безгә куәт,
                    көч,
                      терәк!
Әмма гади көчтән
                    йөз, мең тапкыр
Ул булырга тиеш көчлерәк!
Андый көч бар!
                Андый акыл да бар!
Көч һәм акыл
                ул — син, Партия!
Син — горурлык,
                    син — ышаныч булдың.
Безнең туры юл син, Партия!
Син үзең дә ышан, таян безгә!
Без изгелек яклы кешеләр.
Коммунистларың без!
                    Хәзер инде
Миллионнар — безнең ишеләр.
Сиңа килә халкым — эндәшергә,
Киңәшергә кирәк чагында.
Син — часовой.
                Басып торасың син
Тынычлык һәм хаклык сагында.
Синең идеяләр,
                йөрәк кебек,
Күкрәкләрдә мәңге тибәчәк.
Синнән тора Бөек Бәхет чоры,
Синнән тора Бөек Киләчәк!

РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН.

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

2

ФЕВРАЛЬ
1976

## Бу санда

Г. РӘХИМ. Зур адымнар. Шигырь . . . . . . 3
А. РАСИХ. Айлы төннәр. Роман . . . . . . . 4
Х. ХӨСНУЛЛИН. Республикам. Шигырьләр . . . 79
Р. МИНГАЛИМОВ. Самолетлар оча. Хикәя . . . 85

МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

Мусага — безнең чәчәкләр:
С. ХӘКИМ. Ләгънәтләнгән ачы һәм каргалган . . 95
А. СУЮНЧЕВ. Кырык үлемне җиңгән ил җырчысы 96
З. НУРИ. Әйтә күңел . . . . . . . . . . . 97
С. ДАНИЛОВ. Солдат-шагыйрьнең горур карашы. 98
Р. ГӘРӘЙ. Иләрәкләрдә Муса җырлары . . . . 98
М. ЛУКОНИН. Халык улы . . . . . . . . . 100
С. МӘҮЛЕНОВ. Туганыбыз Муса . . . . . . . 101
Я. УХСАЙ. Дустым турында . . . . . . . . 103
Н. НӘҖМИ. Заман легендасы . . . . . . . . 103
О. ШЕСТИНСКИЙ. Үлемсезлек . . . . . . . . 105
Ә. СИНЕГУЛОВ. Уникаль бүләк . . . . . . . 106
Ә. МӘХМҮДОВ. Муса Җәлилнең сугышка кадәрге иҗатында эстетик идеалның формалашуы 107
К. АБДРАЗАКОВ. Муса Җәлил Саратов өлкәсендә . . . . . . . . . . . . . . . . 116
К. КАМБАРОВ. Каһарман шагыйрьгә һәйкәл . . 119
И. ЗӘБИРОВ. Үзбәк әдәбияты һәм Муса Җәлил . 123
С. АКБИЕВ. Муса Җәлил һәм Дагстан . . . . . 128
Х. КАЗАКОВ. Муса рәсемен ясаганда . . . . . 133
И. КУДИНОВ. «Шагыйрь Муса Җәлилов бу...» . 135

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . 145
Ж. МИНДУБАЕВ. Алга карап, еракны күреп . . 147

ПУБЛИЦИСТИКА

Ш. ХАММАТОВ. Бишьеллык һәм публицистика . 155

ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ 90 ЕЛЛЫГЫНА

И. НУРУЛЛИН. Тукай . . . . . . . . . . . 165

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

**Ш. ГАЛИЕВ.** **Үз итеп.** Шигырьләр . . . . . . 178

УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

**Хатлардан юллар** . . . . . . . . . . . . . . . 181

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 188

**Б. МУЛЮКОВ** көе, **Ә. ДАВЫДОВ** сүзләре. **Яшә, Партия** . . . . . . . . . . . . . . . . . 192

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 4/XI-1975 ел. Басарга кул куелды 12/I-1976 ел. ПФ 07009. Кәгазь форматы 70×108[1]/[16]. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91344 экз. Заказ Я-435. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

«Казан утлары», 1976 ел.

## Гәрәй Рәхим

### Зур адымнар

КПССның XXV съезды ачылуга

Илдә КамАЗ, илдә төзелеш,
Илдә хезмәт, илдә хәрәкәт.
Торгынлыклар безгә ят нәрсә —
Хәрәкәттә безнең бәрәкәт.

Зур эшләрдән күчеп зур эшкә
Бишьеллыклар адымы белән,
Коммунизм дигән яктыга
Атлап бара илем бер эздән.

Ильич сызган шушы ак эзне
Тирәнәйтә халкым тагын да.
Без корабыз һәрбер нигезне
Бөтен союз масштабында.

Нигезләрдә күпме милләтнең
Якты йөзе, нуры чагыла.
Партиянең һәрбер эндәше,
Һәрбер сүзе тулы чагыла.

Съездлардан күчеп съездга
Зур адымнар атлый илдәшләр.
Безгә карап Ильич елмая:
— Дөрес юлдан... дөрес, иптәшләр!

**Атилла Расих**

# АЙЛЫ ТӨННӘР

РОМАН

Хөсәен Ямашев турындагы әсәрнең икенче китабы

## 1



Көзге ачы җил йомры дүңгәләкләрне дала буйлап тәгәрәтә. Алар ниндидер күз күрмәгән куркак җанварлар кебек җан-фәрманга йөгерешәләр. Алла белсен, нинди язмыш көтә аларны?! Кайларга җитеп туктарлар алар? Кайда булыр ул дүңгәләкләрнең тернәкләнеп, җирлек табып урнашып калулары. Әллә бу иксез-чиксез даладагы сукыр сәяхәт бер дә тукталмасмы, яисә, юлда ниндидер киртәләр очрап, орлыклар шытмаслык ярлы, ташлы җирдә үлемгә дучар ителерләрме алар?

Поезд Сырт станциясен дә узды. Әллә кайчаннан бирле һич аерылмастан юлчыларны озатып килгән Самар елгасы да, сул якка борылып, дала чиксезлекләренә китеп адашты. Озакламый Оренбур каршыларга тиеш Фәрхетдинне. Күп дигәндә бер сәгатьлек юл калды. Тәмам үзәк-бәгырьләргә үтеп йончыткан сәфәр шунда тәмам булачак. Шунда Фәрхетдин эзләп йөргән бәхетенә ирешер. Әйе, алла боерса, язган булса...

Ул, поезд тәрәзәсеннән дала киңлекләрендә дуамал чабышкан дүңгәләкләрне күзәтә-күзәтә, үзе турында уйланды. Аны да бит рәхимсез язмыш, дүңгәләкләрне йөгерткән көзге җил кебек, ил буйлап әллә кай җәһәннәмнәргә кадәр әйдәп алып бара.

Көтмәгәндә поезд, бөтен тирә-юньне буш тимер мичкәләрнекедәй гөрелтегә күмеп, күпер аша узды. Артта Сакмар елгасы калды. Тиздән Оренбур каласының корылмалары, йортлары, чиркәү-мәчетләре мираждай калкып алга килеп басты. Пычрак, тынчу вагон эчендә ыгы-зыгы купты. Котсыз, килбәтсез киемле тынгысыз пассажирлар юл әйберләрен барлый, капчыкларын биштәрләп аркаларына аса башладылар.

Менә ул Оренбур станциясе! Түбәсе күкләргә ашкан мәһабәт вокзал бинасы янына поезд кычкыртып, авыр пошкыра-пошкыра, пар бөркеп килеп туктады. Вагоннардан дәррәү пассажирлар төшә башлады. Фәрхетдин дә, кешеләргә этенә-төртенә, пассажирлар агымына ияреп, поездан төште. Билетын аста баскыч янында авызыннан аракы исе аңкытып торган кондукторга сузды. Алда әлеге соры вокзал бинасы игътибарны үзенә тарта иде. Ул ят, шыксыз, ничектер күңелне өшеткеч моңсулык күләгәсендә калдыра. Ә артта маневр паровозларының ачы сызгыртуы үкереп елау тавышын хәтерләтеп күңелне әрнетә. Туган илдән еракта ят җирләргә беренче аяк басу белән Фәрхетдиннең бөтен барлыгын авыр юксыну тойгысы биләп алды, башы әйләнеп китте, күрәсең, монысы озак вакытлар поездда килүдәндер, яисә ризыкның такы-токы булуыннандыр...

Ләкин бары хәрәкәттә — бәрәкәт, башка бернинди дә чара юк. Фәрхетдин, тәвәкәлләп, халык кайнаган перрон буенча вокзал ишегенә таба юнәлде. Нияте, берәрсеннән әйбәтләп сорашып, мондагы хәл-әхвәлләрне белгәннән соң, эшкә керешү иде. Хәер, ул моңарчы да сорашмады, кызыксынмады түгел. Нәдердә дә, Казанда да белдекле ил агайлары аңа күп төрле киңәш бирделәр. Шулай ук юлда да Оренбур хәлләрен аңлатучылар аз очрамады. Әле шушы елның башында гына Ташкент тимер юлы салынып беткән, ул Урта Азия белән Россияне тоташтыра торган юл икән. Инде килеп Оренбур турында сүз кузгатсаң, бу шәһәр ике якны биләүче шул юл уртасында тора, анда зур-зур тимер юл мастерскойлары гөрләп эшкә керешкән чак икән хәзер. Менә шул мәгълүматлар билгеле булды Фәрхетдингә. Әмма болар гына аз. Аңа монда яшәүче кешенең, ачысын-төчесен үзе һәр даим татып торучы кешенең, аның сүзе кирәк.

Фәрхетдин сасы ис аңкып торган зал эченә килеп кергәч, башта кемгә барып сүз кушарга белмичә югалыбрак калды, аннан соң гына, берәр татар агай-эненең очравын теләп, тирә-юньдәге тавышларга колак салып йөри башлады. Чыннан да, күп тә узмады, колакка татарча әйтелгән сүз чалынып киткәндәй булды. Бер яшь тавыш:

— Бүген дә апайны каршы алырга насыйп булманы, — диде. Фәрхетдин, барлык игътибарын җыеп, тавыш килгән якка таба атлады.

Ике кеше сөйләшеп торалар иде. Берсе, буйчанрагы, кара драп пальтодан, башына эшләпә кигән, анысы Фәрхетдингә арты белән басып тора. Ә «булманы» дип сәер итеп әйтүчесе исә мамык эчле иске бишмәт, койрыклы төлке бүрек кигән яшь чырайлы бер егет иде. Аның кысыграк күзләре, игътибарны җәлеп иткән сәер шивәсе, хәтта бүреге һәм тез астыннан бау белән буып бәйләгән тула кунычлы күн сапкан итекләре дә татар кешесе булмавын, тәгаен башкорт икәнлеген күрсәтеп тора иде. Чибәр киемлесе нидер әйтте. Фәрхетдин сагая төште һәм «пересадкада утыра алмагандыр» дигән сүзләрне ишетеп алды. Гаҗәп таныш иде бу кешенең тавышы. Салмак, тоныграк, ләкин ягымлы бер тавыш. Фәрхетдин якынлаша төшеп, аның йөзен күрергә тырышты. Әйтерсең теге үзе дә Фәрхетдиннең ниятен сизенде, кинәт борылып егеткә карап алды. Хөсәен Ямашев иде бу. Фәрхетдин аны тану белән телен йоткандай өнсез торды. Ниһаять, «Хөсәен абый» дип кычкырганын үзе дә сизми калды.

Фәрхетдинне Оренбур вокзалында очратуына Хөсәеннең дә гаҗәпсенүе егетнекеннән ким түгел иде, әлбәттә. Ләкин ул, гадәтенчә, тойгыларын туган минутында ук сиздерергә ашыкмады, бары куе кара кашларын сирпеп көлемсерәде дә:

— Фәрхетдин ич бу! — диде.

— Бәй! Фәрхетдин шул, Хөсәен абый, шул үзе!

— Ничек болай? Кайдан?

— Илдән килеш. Сезне шушында очратырмын дип һич кенә дә

уйламаган идем, Хөсәен абый. Исәнлек-саулыкмы? Сез дә бу якларга килеп чыккансыз икән...

Фәрхетдин күрешергә дип ашыгып кулларын сузды. Хөсәен аның каты, кытыршы кулларын тоткан килеш үзенең инде хәзер Оренбур кешесе булырга җыенуын, менә шушы поезд белән Хәдичә дә килеп төшәргә тиешлеген, ләкин ни сәбәптәндер килеп җитмәвен әйтте. Шул ук арада аның күзләренә Фәрхетдиннең йөзендәге күптәнге таныш чырайны үзгәрткән тирән яра эзләре дә чагылып узды. Яра элек шактый чибәр булган битне ямьсезләтеп маңгай турысыннан уң як буйлап иякә таба төшкән иде. Хөсәеннең әле моны беренче тапкыр күрүе. Фәрхетдиннең күзләрендә дә хәзер Хөсәенгә таныш булган элекке, балаларча беркатлы ышаныч белән карау юк иде кебек, карашы да ничектер нурсыз, өметсез.

— Эш эзләпме? Ачлыктан котылу нияте беләнме? — дип сорады Хөсәен.

— И Хөсәен абый, ризык бәндәне шулай йөретә икән инде ул!..

— Начармы Нәдердә? Семья хәлләре ничегрәк соң?

— Ачлык анда, Хөсәен абый. Чимиягә падмуга булмасмы дип чыгу инде өйдән...

— Нишләп Хафазаңны да ияртмәдең соң?

— Әле үзеңә акча ничек җүнәттең диген, Хөсәен абый. Аннан тагы... Хафаза буйга узды бит. Менә исән-сау гына котылсын инде. Бәлкем сабый үз ризыгы белән дөньяга килер. Гомер булып, урнашып китә алсам, белмәссең, бәлкем алдырырмын да.

Хөсәен Фәрхетдиннең өс-башына карап алды. Егетнең өстендә шул ук ситсы тышлы тузган бишмәт, башында каешланып беткән кырпусыз бүрек, аягында баш сапкан күн итек. Егетнең битләрен куе төк баскан, юл азабы бик кыйммәткә төшкәнлеге аның саргайган йөзеннән үк күренеп тора иде.

Хөсәен анык бер карарга килеп:

— Әйдәле, чыгыйк әле бу тынчу урыннан,— диде.

— Безнең ат монауда гына,— дип өстәде башкорт егете. Алар вокзал аша халык дәрьясын кичеп шәһәр ягындагы мәйданга чыктылар. Мәйдан аркылы узып, атлар бәйләү өчен махсус ясалган озын бүрәнә киртә янында әрҗәле арбага җигелгән колынлы туры бия янында тукталдылар.

Башкорт егете атны борып алга чыгарды да Хөсәеннән: «Китәбезме?» дип сорады. Хөсәен Фәрхетдингә мөрәҗәгать итте:

— Фәрхетдин! Мин үзем дә әле фатирга урнашып өлгермәдем, вакытлыча бер белешемдә торам. Тик шулай да мин сине калдырып китә алмыйм, әйдә, безнең белән, бер җаен табарбыз, синең бит барып төшәр урының да юктыр?

— Барып төшәр урыным юк, Хөсәен абый. Алай да мин сезнең белән китә алмыйм. Ник дисәгез, миңа һич тә вакыт әрәм итәргә ярамый. Бүген үк тимер юл мастерскоена барып эш белешергә кирәк. Шулай куштылар.

— Һинең һөнәр бармы һоң? — дип сорады башкорт егете.

— Бар. Мин тимерчелектә эшләгән кеше, чүкеч сугып торучы.

— О, улайһа була,— диде башкорт егете, көнләшкәндәй Фәрхетдингә кызыгып карап.— Улайһа һин, туган, хәзер үк мастерской канторына бар да эшеңне көйлә, аларның казармаларына урнашырга тырыш, инде бер дә булмаһа, минем янга килерһен.

Башкорт егете Фәрхетдингә үзен ничек эзләп табарга кирәклеген аңлата башлады.

Бары да җайланды булса кирәк. Хөсәеннең чырае яктырып китте. Алай да әле ул арбага менеп утыргач, Фәрхетдингә акча чыгарып бирүне кирәк тапты. Фәрхетдин үзенә сузылган акчага карап бераз уйланып

торды, аннан көрсенеп: «Акчаны алам, Хөсәен абый. Башка чарам юк,— диде,— Әҗәткә алып торам».

— Мин бит сиңа сәдака бирмим. Хәлеңне аңлыйм,— диде Хөсәен.— Минем белән алай кыланып сөйләшмә. Исеңдә тот: әгәр урнаша алмасаң, я берәр уңайсызлык килеп чыкса, мине эзләп тап. Мин Неплюев урамында Тимерша Соловьев йортында булырмын. Инде өйдә булмыйм икән, көтеп торырсың, — шулай дип, ул Фәрхетдингә кулын сузды.— Ярый, аңлаштык булса кирәк.— Ат кузгалыр алдыннан гына ул, исенә төшереп, тагы берничә сүз әйтүне кирәк тапты: — Синең Хафазаңны, әти-әниеңне узган кышта Нәдердә күрдем. Аларның кадерен белергә кирәк. Бик әйбәт, сөйкемле кешеләр.

— Сезнең хәл белешергә керүегез турында миңа әйткәннәр иде, Хөсәен абый. Эзләп табып керүегез өчен бик зур рәхмәт инде.

— Мин ул вакыт Уфага киткәнче атнадан артык вакыт Әлмәттә яттым. Буш арада шыпырт кына һәм бик нык сакланып авылларга да чыгып кергәләдем.

— Барысы да аңлашыла, Хөсәен абый, — диде Фәрхетдин күз кысып. Хөсәен, аңа игътибар итмәстән, йөзендәге җитдилеген җуймаган хәлдә, сүзен дәвам иттерде:

— Менә шулай, Фәрхетдин, әгәр эшең уңмаса, әйткәннәрне онытма. Башта Чынбулатны эзләп тап, аннан мине.

— Мине белмәгән кеше юктыр мастерскойда, — диде Чынбулат һавалана төшеп,— такелажник Чынбулат — башкирский князь дисәң, бөтәһелә белә.

Ул ак тешләрен күрсәтеп кеткелдәп көлеп җибәрде.

— Тагы бер сорау бирим әле, Хөсәен абый. Фатыймабикә апа, Нәкыя исәннәрме соң?

— Алардан хат алып тордык. Исән-саулар иде, Фәрхетдин. Рәхмәт.

— Мин больницада яткан чакта бик тә ярдәм иттеләр, үз балалары кебек тәрбияләделәр. Бик зур рәхмәт инде аларга...

Фәрхетдиннең, күрәсең, авыр көннәре исенә төшүдәндер, күзләре яшьләнеп китте. Ул читкәрәк карап: — Ярар, сау-сәламәт булыгыз, — диде.— Сезне күргәч, Хозыр Ильясны күргән кебек булдым. Бөтенләй рәхәт булып китте.

Хөсәен елмаеп Фәрхетдингә кул болгады. Ат кузгалып китте.

Фәрхетдин колынлы туры бия җигелгән әрҗәле арба тыкрыктан борылып күздән югалганчы карап торды да, биштәрләп тагылган капчыгын аркасына рәтләбрәк салып, кире вокзал бинасына таба юнәлде.

Хөсәен исә, баштагы минутларында бу көтелмәгән очрашуга сәерсенеп, Фәрхетдин һәм аның язмышы турында уйланып барды. Шулай шул, ул Әлмәттә чагында, ялган паспорт юнәтү мөмкинлеген көткән арада, тик ятмады, мунчада җилем басмада прокламацияләр басып, ышанычлы кешеләргә өләште. Нәдердә чагында ул Фәрхетдиннең өенә кереп чыгудан тыела алмады. Аварга торган черегән салам түбәле өйдә хәерчелек каршы алды аны. Авыру карт, дөнья баскан, кипшенеп беткән бәләкәй карчык, яшьлек гүзәллеге авыр хезмәттән вакытсыз сулган яшь килен.

Килен чыннан да уңган, акыллы иде. Ул Хөсәеннең Фәрхетдин турында сөйләгәннәрен зур сабырлык белән тыңлап утырды. Фәрхетдингә ярдәм итүчеләр бар, ул озакламый терeләчәк дигәч, чын күңеленнән Хөсәенгә рәхмәтләр укыды. Хөсәен аларга авыр вакытларда үзенең сеңелесе Хәдичәбикәгә мөрәҗәгать итәргә кушты.

Бу тынчу өйдә үпкә чире белән интегүчегә генә түгел, сәламәт кешегә дә сулыш алулары читен иде...

Әле атта Оренбур урамнарыннан узган арада Хөсәен шул күренешләрне күз алдыннан кичерде. Аннан аның күңелен әле һаман ят тоелган, ияләшеп бетмәгән шәһәрнең сәер, үзенчәлекле манзарасы үзенә

тартып алды. Биредәге халык артык чуар, төрле милләт вәкилләреннән тора. Вокзалга якын гына булган күпер аша чыгып озак та китмәделәр — килбәтсез сузан дөяләргә йөк салып Бохара якларыннан ук килүче сәүдәгәрләр кәрваны очрады. Алар күздән югалу белән урам очында кулына камчы тоткан бер җайдак күренде. Киемнәренә караганда, бусы башкорт һәм атының шабыр күбеккә батуына игътибар итсәң, бик ерактан килүче икәнлеген чамалап булыр иде.

Көтмәгәндә тоткарланып торырга туры килде. Юлда очраган аркылы урамны тутырып, казакъ көтүчеләре меңләгән сарык әйдәп уздылар. Монда сарыкларның бакырышуы аркасында бер-береңне ишетерлек тә түгел. Хөсәен белән Чынбулат тукталып юл ачылганын көткән арада ым кагып кына аңлашырга мәҗбүр булдылар.

Шулай да юлда очраган күпчелек кеше руслар һәм татарлар иде. Еш-еш хәрбиләр, аерата казачилар очрый.

Петр патша заманында диярлек нигез ташы салынган бу шәһәргә рус дәүләте җирле халыкларны тәмам буйсындырганчы кирмән-крепость хезмәтен үтәргә туры килгән. Ул Азия халыкларын богауда тоту өчен салынган форпостларның берсе булган.

Бераздан Кәрвансарай мәчетенең биек ак манарасы күренде. Халык акчасына салынган бу гүзәл архитектура ансамбле менә алтмыш ел инде Оренбур каласын бизәп, үзен иҗат иткән кешегә истәлек булып тора.

Хөсәеннең уйлары тагы алда торган мөһим эшләренә әйләнеп кайтты. Бүген ул большевик дусты Галимҗан Сәйфетдинев белән беренче тапкыр иркенләп сөйләшеп утырачак. Барысы да, әле вокзалга Тимершалар атында түгел, ә Галимҗан белән бәйләнеш йөртүче башкорт егете Чынбулат белән баруы да Сәйфетдинев белән аулакта очрашу өчен эшләнгән эш иде. Хәдичә килгән хәлдә Чынбулат очрашу урынын күрсәтергә һәм очрашу иртәгәге көнгә кичектерелергә тиеш иде.

— Галимҗанның хәлләре ничегрәк соң? Нигә үзе вокзалга килергә итмәде? — дип сорады ул Чынбулаттан.

— Һаулыгы ярыйсы аның, Хөсәен агай. Төшә алмавының сәбәбен аңлайсыздыр инде. Ул бит монда сөрелеп килгән кеше. Бу арада әле аның артыннан бик хәтәр күзәтә башланылар.

— Шулай икән, — дип куйды Хөсәен.. — Алайса, халык арасында бөтенләй була алмыйдыр инде ул?

Чынбулат тешләрен агартып елмаеп куйды.

— Булмай дип әйтеп булмай. Җаен таба. Тик бу һаклануы һездән өсен булды инде. Менә бүген дә бит без аның квартираһына тукталмайбыз. Һөйләшенгән урын бар. Менә шушы атның хуҗасы. Шунда керербез. Галимҗан агай һезде шунда көтә.

Хөсәен Уфада чакны Галимҗан Сәйфетдиневтән: «Я үзем очратырмын, я ышанычлы кеше җибәрермен», дигән хат алган иде. Әле шуны хәтерләде ул. Эчтән генә көлемсерәп: «Дөнья бабай егетне өйрәтә, конспирациягә хөрмәт күрсәтә башлаган», дип куйды.

Шәһәрнең үзәк урамнарын узгач, алар озак та бармадылар, бер катлы таш өй янәшәсендәге капка алдына килеп туктадылар. Чынбулат йөгереп кереп капканы ачты, атны ишегалдына алып кереп туара ук башлады. Хөсәен өйгә керергә җыенганда болдырда Галимҗан Сәйфетдиневнең төз, мәһабәт гәүдәсе күренде. Алар кочаклашып күрештеләр.

Өй эченә майда кызган суган исе һәм Галимҗан тарткан тәмәке исе тулган иде. Ялгызак хатыннарның өенә хас барлык җиһаз-дирбия тәртиптә, пакь, чиста. Тәрәзә төпләрендә тамчылы гөлләр, акшарлы стеналарда портретлар, сурәтләр.

— Сал киемнәреңне, өеңә кайтып кергән кебек бул,— диде Галимҗан, — бу безнең иң ышанычлы явка урыны.

Алар чишенеп кечкенә як бүлмәдән өстәл тирәсенә артсыз утыргыч-

ларга утырыштылар. Хөсәен бүлмә эчен тагы бер тапкыр күздән кичерде.

Гөл ярата, ахры, хуҗабикә, чөнки тәрәзә янындагы өстәл өстендә дә гөл чүлмәкләре тора иде. Стенадагы барлык сурәттән исә — атлы казаклар. Күрәсең, хуҗалар нәсел-нәсәпләре белән атлы казаклардыр. Аларның мыеклары бөтеренке, үзләре я папаха, я бескозырька кигән, бик һаваланып, башны күккә чөеп төшкәннәр.

Кинәт бүлмә ишеге ачылды да, Чынбулатның башы күренде.

— Мин китәем инде, алайһа, минем башка кирәгем юктыр ич?

— Нигә ашыгасың? — диде Галимҗан. — Хәзер чәй була, чәйләп китәрсең.

— Юк, сменага барасым бар. Атны эчердем, бесән салдым, — диде Чынбулат.

— Рәхмәт. Мена шушы өйне исеңдә тот инде, туган. Ашыгыч йомышлар була калса...

— Бәй, беләм инде, Галимҗан агай.

Чынбулат саубуллашып күздән югалу белән, Галимҗан, мин сине хуҗа хатын белән таныштырыйм әле дип, бүлмәдән чыгып китте.

Бераздан ул олыгая башлаган бер рус хатыны ияртеп керде. Тышкы кыяфәтеннән үк бу гади казачканың дөнья мәшәкатен күп татыганлыгын белергә булыр иде. Чыннан да, танышу белән үк ул үзенең хәзер бик авыр көннәр кичерүен, чөнки бердәнбер улының җәй башында гына суга батып үлүен сөйләп алды. Хуҗабикә Анфиса Петровнаның улы унҗиденче казачий полкта хезмәт иткән. Мәгълүм булганча, приказ үтәүдән баш тарткан өчен бу полк таратылган. Чөнки ул полкта хезмәт итүче казаклар революцион хәрәкәтне бастырудан баш тартканнар. Анфиса Петровнаның улы исә шул фетнәне башлап йөрүчеләрдән булса да, вакытсыз үлем аркасында, ул хәлләрне башыннан кичермәгән.

— Бераз төшенәм,— диде Хөсәен,— димәк, әлеге таркатылган ундүртенче һәм унҗиденче казачий полклар вакыйгасының кәсафәте сезнең семьяга тимәсә дә, сез зур бәхетсезлеккә таргансыз икән.

Хуҗабикә хәзер үзенең бөтенләй ялгыз калуын, киленнең, баласын ияртеп, Иләккә әтиләренә кайтып китүен сөйләде.

— Хәзер инде мин менә сезнең белән. Булмады, буласы да юк, әгәр үзебез каһарманлык күрсәтмәсәк. Безнең атлы казакларның нахакка халыкны суюларына гомерем буена рәнҗеп яшәдем. Инде дә артык тәкатем калмады, егетләр, — диде ул, ничектер кырысланып.

«Акыллы, ышанычлы хатын, — дип уйланды Хөсәен, — менә шундый квартирга урнашырга кирәк. Тимершаларда озакка калып булмас».

Анфиса Петровна, Хөсәеннең ни уйлап утыруын сизенгәндәй, Хәдичә белән кызыксынды. Килгәч тә таныштыруын үтенде. Аннан өстәлгә шаулап торган самавар һәм чәй кирәк-яраклары китереп куйды да, иркенләп сөйләшегез, дип чыгып китте.

Дуслар утыргычларын өстәл тирәсенә якынрак тарттылар. Галимҗан, каты итеп чәй ясагач, Хөсәенгә текәлде.

— Эш болай тора, — диде Хөсәен, барын да аңлап, — РСДРПның Урал өлкә комитеты татар телендә газета чыгарырга кирәк дигән карар кабул итте. Иван Адамович Саммер, Уфага килгәч, бу мәсьәләдә ярдәм итте. Ул хәзер ЦК члены, шул газета өчен партия кассасыннан биш йөз сум акча бирергә кушты.

— Биш йөз сум, — диде Галимҗан елмаеп. — Витте анда безгә каршы көрәшергә тиешле газетага алты йөз мең сум бирергә кушкан.

— Борчылма, — диде Хөсәен, — безнең биш йөз сумга төшереп чыгарган газетабыз аның алты йөз меңлегеннән көчлерәк булачак. Иң мөһиме эшне белеп оештыруда: төрле шәһәрләрдән хәбәрләр, информацияләр өзелми килеп торсын. Газета легаль. Анда РСДРП органы дигән сүз булмаячак. Ләкин без татар телендә большевистик идеяләрне

пропагандаларбыз. Тегеләрнең аңына барып җиткәнче, без байтак эшләр башкарырга тиеш, Галимҗан.

Хөсәен хәзерлек йөзеннән үзенең Чиләбе, Троицк, Камышлы, Әстерхан, Самара, Баку белән бәйләнешкә кереп, анда ышанычлы кешеләр булдыруын сөйләп алды.

— Казанга Коләхметовка да, башка кайбер иптәшләргә дә яздым. Гафур хатны алу белән, чын күңелдән шатлануын, ярдәм итү вәгъдәсен белдереп, телеграм сукты. Инде эш менә монда, димәк, бездә. — Хөсәен әйткәннәрен ишарәләр белән шәрехләде дә чәен эчә-эчә, аратирә кишер пирогыннан җитешеп, сүзен дәвам иттерде:— Уфада газета чыгару мөмкинлеге бөтенләй бетте. Фиргавеннәр артык эзәрлекли башладылар. Шуңа күрә һәр җәһәттән иң муафыйк урын дип Оренбур сайланды.

— Монда татар матбагалары да, Фатих Кәрими, Тимершалар да...— дип кыстырды Галимҗан.

— Син дә монда,— дип өстәде Хөсәен елмая төшеп.

— Рәхмәт илтифатыңа, — диде Галимҗан, ни өчендер ачы елмаеп,— мин партия члены, сөргендә булсам да, булмасам да, минем эшлисе гамәлем ачык.

Алар тынып тагы чәй белән булыштылар. Хөсәен бушаган чынаягын яңадан Галимҗанга сузды.

— Син ничек уйлыйсың, газетага рөхсәт алу катлауланмасмы?

— Җиңел булмас. Шулай да мөмкин дип уйлыйм. Монда кулай нашир һәм мөхәррир табу мөһим. Ә синең белән минем рәсми мөхәррир була алуыбыз турында сүз булмаска тиеш.

— Дөрес әйтәсең, мин дә шундый ук караштa торам. Нашир мәсьәләсендә Тимерша Соловьев ризалык бирде бирүен. Аңа килеп төшүем бушка китмәде.

Галимҗан бераз вакыт уйланып торды, куе кара чәчләрен сыпыргалады.

— Җиңелчәрәк фикерле кеше, әлбәттә,— дип куйды.— Әмма батырлыкка батыр, усаллык та җитәрлек үзендә. Мин учительскаядан ук беләм аны.

— Ни әйтсәң дә безнең бергә укыган шәрик. Ит югында үпкә дә тансык.

— Дөрес,— диде Галимҗан куәтләп.— Син дөрес төзәгәнсең угынны. Төзәгәнсең дә, аткансың да. Әлхасыйл, бер атуда ике куянны үтергәнсең. Тимершаның Фатих Кәрими кияве икәнлеген дә истә тоткансың, дип әйтүем. Чөнки матбага мәсьәләсе бар бит әле.

— Менә шул шул,— диде Хөсәен җанланып.— Ә инде мәсләк, юнәлеш ягыннан җайларбыз дип уйлыйм. Аңлатырбыз. Аннан, минемчә, ул чыгарып яткан «Чүкеч» журналы, анда басылган материаллар миндә, мәсәлән, якты өметләр уята.

— Шакир Мөхәммәдов белән дуслык җепләрен булдырырга кирәк!

— Мөхәммәдовмы? «Карчыга»мы? Ниндирәк кеше ул?

— Ул миллионер Хөсәеновларда конторщик булып хезмәт итә. Мәгәр гаҗәп батыр демократ.

— Мин «Карчыга» журналының беренче номерын Уфада чакны укыдым. Аның мөхәррире белән танышу теләге миндә шул ук минутта туган иде ул чак.

— Монда безгә ярдәм итәрдәй кешеләрдән тагы Закир Рәмиев бар. Бай. Алтын прискаларының хуҗасы. Ләкин сабыр ит. Ул бик акыллы кеше. Либерал һәм, әйтүләренә караганда, матур әдәбиятны ифрат ярата.

— Беләм. Мәшһүр «Вакыт» газетасының хуҗаларыннан берсе.

Дуслар сүзне бу очракта ниндирәк рәвештә алып барырга кирәклеге турында фикер алыштылар. Соңыннан Хөсәен эшләнәсе эшләрнең ни-

дән торганлыгын аныклап, Галимҗан башкарырга тиешлеләрен әйткәч, газетага рөхсәт алу белән үзенең Уральск шәһәренә барып кайтачагын белдерде.

— Төшенәм, — диде Галимҗан, — дөрес эшлисең. Анда сиңа Камил Мотыйгый белән танышып, аның белән дә бәйләнешкә керергә кирәк.

— Минем Уральскида газета өчен ышанычлы кешеләр булдырасым килә. Хәбәрләр дә җибәреп торсыннар, газета да таратсыннар, кирәк икән иганә дә җыйсыннар.

— Кыскасы, агентлар...

— Анда, укып белүемчә, бик сәләхиятле, хәтта талантлы дип әйтер идем, яшьләр бар. Мәсәлән, Тукаев имзасы белән шигырьләрен «Әлгасрел җәдит»тә бастыручы бер шагыйрьне бик яратып укыйм мин. Просто феномен!

— Әйе, әйе, бар андый кеше. Миңа да ошый ул. Инде тагы бер киңәш бар. Сиңа «Простор» газетасының идарәсендә булырга кирәк. Беләсеңдер, ул социал-демократик юнәлештәге легаль газета, рус телендә, биредә чыга.

— Беләм, укып барам.

— Бүлдермә. Хикмәт шунда: аларның газета эшен алып баруда тәҗрибәләре зур. Мәсәлән, газетаның хакыйкый редакторы нәкъ синең хәлдәге яшеренеп йөрүче кеше. Ә рәсми редактор булып аның хатыны Афиногенова Антонина Васильевна исәпләнә. Алар белән тиз арада сиңа танышып киңәш-табыш итү фарыз эш, туган.

— Бу бик әйбәт фикер, Галимҗан.

— Хәдичә ханым кайчаннарга килеп җитәргә тиеш?

— Телеграммасына караганда, бүген килергә тиеш иде. Поезд көн аралаш, димәк, берсекөнгә, я аннан ары...

Бераз тынып торганнан соң Хөсәен үзе сорау бирде:

— Ә синең тормышлар ничегрәк? Сашаң үзең беләнме? Ничек яшисез?

Сорау Галимҗанга ошап җитмәде, ахры. Шуңа күрә ул башта сүзне икенчегә борырга да чамалаган иде, ләкин ахырда Хөсәен кебек якын кешесеннән яшеренеп торуны кирәк санамады.

— Саша — меньшевичка, мин — большевик. Партия җыелышында икебез ике фракциядә, бәхәсләшәбез. Өйгә кайткач, эш турында сүз башланса, тагын бәхәсләшәбез. Ә төн килеп караңгы төшкәч, икебез бер түшәккә ятып йоклыйбыз, — диде.

Хөсәен хәзер шундый мәнсез сорау бирүенә үзе дә уңайсызланып, башын чайкап куйды.

— Аңлый алмыйм, ничек яшәргә буладыр шулай?

— Алла диген, Хөсәен, башыңа төшкәч, яшисең икән ул. — Галимҗан бераз тынып торды да: — Яратам мин аны, ул да мине ярата. Аны бит бирегә сөрмәделәр. Ул үзе синсез яши алмыйм дип килде, — диде.

— Нихәл итәсең, эш шулай тора икән, — яшәгез, — диде Хөсәен. — Бу артык интим һәм артык шәхси мәсьәлә. Андый сорау бирүем өчен мине кичер. Безнең арада бернинди дә сер була алмый дигән кагыйдәдән чыгып кына...

— Сүз уңаенда әйтим, монда меньшевиклар да, большевиклар да бер оешмада. Сиңа да көрәшкә әзер булып торырга кирәк.

— Нәрсә, әллә меньшевиклар бездән көчлерәкме монда?

— Юк, — диде Галимҗан һавалана төшеп, — безнең аларга биреш-кән юк әле!

Алар тагы бирелеп булачак газета, аның бүлекләре, эшкә ниндирәк кешеләрне тарту турында сөйләшә башладылар. Әңгәмә төн уртасына кадәр дәвам итте. Шәһәр тынгач, башта Галимҗан, аннан Хөсәен, Анфиса Петровна белән саубуллашып, чыгып киттеләр.

## 2

Хәдичә иреннән «кил» дигән телеграмманы түземсезлек белән көтте. Дөресен генә әйткәндә, аны бу билгесезлек тәмам туйдырган иде инде. Туган йорт — Чистай белән бәйләнеш чикләнде, мөнәсәбәтләр суынды. Бу хәл Хәдичәнең качып киткән революционер ире артыннан сәфәр чыгуы аркасында булды. Ләкин ул шул кадәресен дә сизде: туган-тумача булмаган чит шәһәрдә яшәү Хәдичәне Хөсәенгә тагы да якынайта төште. Хәзер инде Хәдичә үзен Хөсәеннән башка яши алырмын дип башына да китерми. Бу хәл исә билгесезлекне тагы да авырайта төште.

Ниһаять, октябрь аеның яңгырлы шыксыз бер көнендә зарыгып көтелгән телеграмма килде. Анда юлга чыгу турында хәбәр җибәрү өчен адрес та бар иде. Димәк квартир табылган. Аннан шул ук телеграммада Хәдичәне ат белән каршы алачаклары, кар төшкәнлеге, җылырак киенеп килергә кирәклеге дә язылган иде.

Әйберләрнең бер өлеше багаж итеп җибәрелгән иде инде. Хәдичә тиз арада калган нәрсәләрне күршеләр булышлыгы белән ящикларга, чыпта капларга тутырды һәм шул ук тәмам туган шикелле булып киткән күрше Касыйм Дәүләткилдеевләр семьясы ярдәмендә багажның барысын да диярлек Оренбурга озатып, үзе дә өч көннән соң юлга чыкты. Нәкъ өч тәүлек тулып дүртенчегә киткәндә ул дала елгасы Җаек белән Сакмар кушылган җирдәге Оренбурга килеп төште.

Гаҗәпсенүенә каршы, аны Хөсәен үзе каршы алмады. Станциягә Хәдичәне каршы алырга чанасына колынлы туры бия җиккән башкорт егете төшкән иде. Егет Хәдичәгә булдыра алган кадер-хөрмәтне күрсәтте күрсәтүен, әйбер күтәртмәде, артлы чананың мул итеп печән салынган иң җайлы җиренә утыртты. Алай да Хәдичә шомланды, Хөсәен турында сорамый булдырмады.

— Хөсәен агай ашыгыч эш менән китте,— диде Чынбулат.

— Ничек китте, кайда китте?

— Ашыгыч эш чыккан булһа кирәк,— диде Чынбулат.

Ул Хәдичәгә карап алды да аны тынычландыру теләге белән:

— Кайгырмагыз, апай, — диде, — ул озакламый кайтыр. Сезне квартирагызда бик әйбәт каршылаячаклар. Квартир хуҗагыз Анфиса Петровна марҗа бик тә әйбәт хатын, аның белән сезгә начар булмас. Әле Хөсәен агай узган атнада гына күсте.

Чыннан да, Хәдичәне яңа квартирада Анфиса Петровна үз кызын каршылагандай хөрмәт күрсәтеп кабул итте. Әйберләрне урнаштырырга булышты, юынганда җылы су коеп торды, тәмле кәбестә шулпасы белән сыйлады, чәй эчергәч, ятып ял итеп алу өчен күпертеп урын җәеп бирде. Ләкин юлда Хәдичә никадәр арып-алҗып бетмәсен, тиз генә йоклап китә алмады. Әлбәттә, Хөсәеннең үзен каршы ала алмавы аның өчен бик табигый бер хәл иде. Хәдичә бу шәһәрдә узачак тормышы турында уйланды. Монда бөтен нәрсә ят, чит әле. Бу Анфиса Петровна бик ягымлы, яхшы күренә күренүен, ләкин Уфадагы Касыйм Дәүләткилдеевләр кебек үз булып китә алырмы? Ни әйтсәң дә, аның үз дине, үз гореф-гадәте бар.

Хәдичә әле һаман поездда тирбәлеп килгәндәй хис итә үзен. Бөтен тирә-юнь бер көйгә чайкала, барысы да хәрәкәттә кебек. Ниһаять, ул шулай тирбәлә-тирбәлә йокыга талды. Ә уянып киткәндә, аның янында елмаеп Хөсәен басып тора иде.

Ул, иелеп, Хәдичәнең битеннән, аннары иреннәреннән үбеп алды.

— Нихәл, исән-сау килеп җиттеңме?

Хәдичә бер сүз дә дәшмәстән күзләрен җемелдәтеп, ирен күрүгә чиксез куанган хәлдә, бераз карап ятты. Аннан:

— Ай-яй, нык сагынгансың икән син мине, Хөсәенкәем! — диде.

— Гафу ит,— диде Хөсәен, хатынының үпкәләүдән дә бигрәк шаяртып сөйләгәннәрен аңлап. — Синнән телеграм килеп төшкәндә иптәшләр белән очрашу вакыты турында сөйләшенгән иде инде. Мин берни дә эшли алмадым, Хәдичәкәй.

— Тагы башландымыни инде?

Башланды. Оренбурда татар-башкорт эшчеләре шактый күп. Алар белән моңарчы беркем дә шөгыльләнмәгән. Менә Галимҗан килгәч кенә бераз җан керә башлаган бу эшкә. Әмма, үзең аңлыйсың, Галимҗан өзлексез күзәтү астында яши, аңа авыр. Шуңа күрә аңа булышмыйча мөмкин түгел.

— Алар ничек яшиләр соң? — диде Хәдичә, Галимҗанны хәтерләп. Ул аны күреп белә иде.— Аның хатыны да биредә кебек. Александра Михайловнамы әле?

— Әйе, Александра Михайловна. Яшиләр, сөргендәгечә. — Хөсәен кәефләнеп көлеп куйды. — Биредә партийный группа гына. Бер үк группада большевиклар да, меньшевиклар да. Шуңа күрә Галимҗан хатыны белән җыелышларда да бергә була.

— Шулайдыр шул. Син аның хатыны меньшевичка дигән идең бит.

Хәдичә кинәт болай ятуның килешмәвен искәреп: «Абау, ходаем, мин ятам да ятам тагын»,— дип, урыныннан сикереп торды... Ашыкпошык киенә башлады. Тулы, матур ап-ак аякларына оек кигәндә сорап куйды:

— Ә газета мәсьәләсе ничек тора соң, Хөсәен?

— Наширлекне Тимерша Соловьев үз өстенә алырга булды. Күндердем. Ә инде менә мөхәррир турында күп уйлангач, без Галимҗан белән шундый бер фикергә килдек: сиңа мөхәррирә булырга туры килер.

Хәдичә, оек бәйләүләрен рәтләп маташкан хәлдә иелгән килеш, матур коңгырт кара күзләрен тутырып Хөсәенгә текәлде.

— Әйе, әйе, Хәдичәкәем, аптырама,— диде Хөсәен бик җитди рәвештә.— Башка бернинди дә чара юк. Реакция җилләре монда да исми түгел. Сизәм, бик авыр булачак. Мин үз имзамны куйсам, чыга башламас борын газета ябылачак.

Хәдичә бер сүз дәшмәстән киенеп бетте дә урын җыя башлады. Хәзер ул Хөсәенгә арты белән торса да, аның уйлануы сизелә иде.

— Менә шулай,— диде Хөсәен,— газетаның рәсми мөхәррирәсе син буласың. Димәк, аны чыгарырга рөхсәт сорап губернаторга сиңа барырга туры киләчәк. Бу шулай ук бик җитди эш. Монда инде безгә ярдәм күрсәтәчәкләр. Чөнки тиешле декорация дә, кирәкле нәзакәтлелек тә — барысы да булырга тиеш. Губернаторга рөхсәт сорарга барганда диюем...

— Кем ярдәм итәр соң? — дип куйды Хәдичә. Ул эшен тәгаллләп Хөсәенгә таба атлады. Үрелә төшеп аның күзләренә карады. Хөсәен бу минутта бик-бик бәхетле хис итте үзен. Аның Хәдичәсе барысын да аңлаган, ул рәсми мөхәррирә булырга риза иде. Хөсәен аны каты итеп кочты да яңагын аның хушбуй исләре килеп торган күперенке йомшак чәчләренә тидерде.

— Безгә бу эштә биредәге социал-демократлар группасы ярдәм күрсәтәчәк. Хосусән, монда русча чыга торган «Простор» газетасының шундый ук рәсми, ләкин хакыйкый булмаган редакторы Антонина Васильевна Афиногенова ярдәм итәчәк. Иртәгә үк алар белән танышырбыз.

Хөсәен карчыгына газета нинди рәвештә оештырылачагы турында сөйли башлады. Боларның барысы да Хәдичәгә асылда күптән мәгълүм нәрсәләр иде инде. Ул Хөсәеннең менә ничә елдан бирле инде татар телендә большевистик газета чыгарырга хыялланып йөрүен белә. Ләкин шулай да ул ирен игътибар белән тыңлады. Чөнки бу сүз инде

чынбарлыкка иң якын торганы, мондагы хәл-әхвәлне искә алып сөйләнгән сүз иде.

Икенче көнне алар «Простор» газетасы урнашкан бер катлы таш зур йортта булдылар. Шул ук көнне кичен Хәдичәгә күн чемонданга салып затлы киемнәр һәм кыйммәтле бизәнү әйберләре китерделәр. Тәгаен болар барысы да ниндидер бай татар хатынының әйберләре иде. Хәдичә никадәр генә кызыксынмасын — сорашырга базмады, ә Хөсәен исә, күрәсең, әйтүне кирәк тапмады. Әйберләр китерүче олы гына яшьләрдәге татар абзые Хөсәенгә:

— Иртәгә сәгать уннар тирәсендә ат булыр,— диде.

Хөсәен бик мәгънәле итеп Хәдичәгә карады. Димәк, сүз губернаторга бару турында бара дип уйлады Хәдичә. Һәм бу дөресеннән дә шулай иде.

Иртәгесен Хәдичә көзге янында ярым шәрә килеш киемнәр үлчәп маташканда, бүлмәгә рөхсәт сорап кемдер үтте. Хәдичә борылып карау белән керүчене танып көлеп җибәрде. Хөсәен үзе белән Антонина Васильевна Афиногенованы ияртеп кергән иде. Башта артык җитди күренгән бу пенснеле, каратутлы ханым беренче күрешүдә үк Хәдичәнең хөрмәтен яулап алды. Антонина Васильевна, җылыда парланып киткән күзлек пыялаларын сөртә-сөртә, Хәдичәнең яңа киемнәрен күздән кичерде дә үзенең киңәшләрен бирә башлады.

— Сезнең ирегез Хөсәен Минһаҗетдинович белән дә, Галимҗан Сәйфетдинев белән дә без ирем белән бергәләп озак-озак сөйләшкәннән соң килдек бу фикергә. Сез мине акыл сата дип гаепләмәгез, болар барысы да минем баштан кичкән хәлләр...

— Андый сүзнең кирәге юк, Антонина Васильевна. Мин үзем дә губернатор резиденциясенә сезне күрми торып барырга җыенганым юк. Бу вазифалар минем башыма шул кадәр кӧтелмәгән рәвештә килеп төште, сездәй ярдәм кулы сузучы булмаса, мөгаен, мин башкарып та чыга алмам.

Антонина Васильевна губернатор белән сөйләшкәндә Хәдичәгә үзен ничек тотарга кирәклеген өйрәтә башлады. Аннан соң алар бер сәгатькә якын көзге алдында кайнаштылар. Хәдичә танымаслык булып үзгәрде. Күпермә иңбашлы, затлы алсу-шәмәхә күлмәк, кат-кат итеп тагылган энҗе муенса, башта шундый ук кыйммәтле энҗеле калфак, бармаклардагы киң алтын балдаклар, кыйммәтле ташлы йөзекләр аны тәмам башка кеше итте.

Хәдичә кашларына сөрмә тарткач, соңгы тапкыр көзгегә карады да тыела алмыйча бүлмәне яңгыратып көлеп җибәрде.

— Ходаем, купчиханың ниндие генә булам икән әле үзем!

— Шулай кирәк тә,— диде Антонина Васильевна җитди рәвештә.— Сез ул мәлгунь губернаторның күз явын алырга тиешсез.

Ул арада капка янына резин көпчәкле, өсте ябык фаэтон да килеп туктады. Хәдичә шәл бөркәнеп, мех якалы җиңел тунны өстенә киде дә, тиешле язуларын һәм документларын тагы бер тапкыр барлап, ишеккә таба атлады. Бусагага житкәч, борылып, үзен озатучыларга карады.

— Шүрлим бераз...

— Бернинди шүрләү булырга тиеш түгел. Өмет бары синдә генә, Хәдичәкәй, — диде Хөсәен.

— Кыюрак, кыюрак, күгәрченем,— диде Антонина Васильевна дәртләндереп.

Хәдичә бер мизгел тукталып торды да катгый адымнар белән өйдән чыгып китте. Хөсәен, Антонина Васильевна һәм Анфиса Петровна аңа фаэтонга утырырга булыштылар. Кучер үз эшен яхшы белә иде. Хәдичә аны күрү белән таныды. Кичә киемнәр китергән кеше иде ул. Аның дилбегәне күтәрә башлавы булды — сәлектәй, ак бәкәлле кара аргамак эре адымнар белән юыртып китеп тә барды.

Хәдичә губернатор янына ничек керәчәген,ниләр әйтәчәген һәм үзен ничегрәк тотачагын юл буенча күңеленнән тәкрарлап барды. Әле кичә генә кар явып тора иде, бүген исә эретә, юллар тагы лыжырдаган. Юртакның тояк асларыннан балчык чәчри, күлдәвекләрне кичкәндә тәгәрмәчләр тирә-юньгә су сиптерәләр, ләкин ат, аңа-моңа карамастан, кызулаганнан-кызулый бара. Капка яннарындагы һәм тротуарлардагы кешеләр борылып туктапып карап калалар, якынрактагылары исә ашыгып читкә тайпыла.

Бик тиз арада губернатор урнашкан Кәрвансарайга килеп җиттеләр. Хәдичә, сакчылы капка янындагы будкага кереп, эчкә узарга рөхсәт алды. Озакламый губернатор резиденциясенә якынлаштылар. Парадный ишегалдына туктау белән кучер елдам гына төшеп, фаэтонның ишеген ачты, Хәдичәгә төшәргә булышты.

Губернаторның иркен, тын приемныенда Хәдичәдән башка чират көтеп тагы ике кеше утыра иде. Берсе — биле бөрмәле кара киемнән, картуздан, сары сакаллы юан рус — итче булырга охшый, икенчесе — картлыктан бөкрәйгән, бәлтерәйгән, киемнәренә караганда, югары сословие эһеле — бер карчык иде.

Хәдичә иркен бүлмәнең аргы очында зур өстәл янында утырган чиновникка үзенең кем икәнлеген һәм нинди максат белән губернатор янына аудиенциягә килгәнлеген әйтте, язуларын, документларын күрсәтте. Чиновник көмеш кысалы күзлек кигән, пеләш башлы, агарган мыеклы бер кеше иде. Хәдичәгә юньләп карамады да. Аның прошениесен, документларын күздән кичерде дә, папкадагы кәгазьгә нидер төрткәләгәннән соң, аякка басты һәм вәкарь саклап ашыкмыйча гына губернатор кабинетының калын, зур җиз тоткалы ишегенә таба юнәлде.

Ул әйләнеп чыкканчы һәм «көтегез» дигәнче, Хәдичә йөрәгенең еш-еш, хәтта бераз авырттырып тибүен тоеп торды.

Кинәт сискәндереп, ишек өстендәге кыңгырау чылтырады. Әле генә губернатор яныннан чыккан казачий формадагы мәһабәт полковник урынына биле бөрмәле кием кигән теге юан итче кереп китте.

— Өске киемнәрне салырга рөхсәтме? — дип сорады Хәдичә, ишек янындагы аяклы күчермә элгечкә ымлап.

— Рәхим итегез, мадам,— диде чиновник, бу юлы да башын күтәрмичә генә. Хәдичә өстен чишенеп көзге алдында үзен тәртипкә китерде. Тагы тетрәнеп көтә башлады. Иң мөһиме — каушап калмау, тыныч, гамьсез булып күренү. Әз генә куркуга бирелсәм дә, бөтен эшне бозачакмын, дип уйланды ул.

Ниһаять, итче дә, карчык та губернатор бүлмәсеннән әйләнеп чыктылар. Тагы кыңгырау чылтырады. Тагы умыртка сөяге буйлап дәһшәт чиркәнчеге йөгерде. Хәдичә барлык батырлыгын җыеп, үзен кулга алды. Чиновникның: «Керегез, мадам», дигәнен дә көтмәстән, җиз тоткалы авыр ишеккә таба юнәлде. Губернаторның яландай иркен кабинетына кергәндә, Хәдичә шулай да йөзенә гамьсезрәк һәм бераз җилкуаррак бай хатын кыяфәте чыгара алды.

Күрәсең, аның әчтәлеген, формасын җиткереп, коллиграфия шартларын да төгәл үтәп язган үтенечен губернатор укып чыккан иде инде. Тәхеттәй зур креслосында аерата кечкенә булып күренгән, бакенбардлы бәләкәй карт шул үзе иде инде. Ул бик сынап, җансыз бер караш белән Хәдичәне күзеннән кичерде дә коры гына:

— Утырыгыз, госпожа Ямашева,— диде.— Димәк, сез мөселман халкын агарту максаты белән газета чыгармакчы буласыз?

— Әйе, галиҗәнаб, мин, патша әгъзам хәзрәтләренең 17 нче октябрь манифесты шартларыннан файдаланып, бөек Россиянең мөселман подданныйларын, ялгыш юл сайламасыннар өчен, газета аша тәрбияләмәкче булам.

— Сезнең мөмкинлекләрегез бармы соң моңа, мадам?

— Галиҗәнаб минем югары катлау вәкиле икәнлегемне беләдер. Мин бернинди партиядә дә әгъза түгел. Минемчә, иң мөһиме бирелә акча.

Губернаторның йөзендә елмаюга охшаш бер хәрәкәт булып алды. Ул Хәдичәнең бизәнгән битенә һәм яртылаш ачык тулы ак күкрәкләренә дә күз ташлап алгалады. Ләкин җитдилеген югалтмады. Ниһаять, тамак кырды да бакенбардларына үрмәләгән ак куе мыек чылгыйларын сыпыргалады. Аның күзләрендә уенчак ялтырау күренеп китте.

— Иң мөһиме акча дисез инде сез, мадам?

Хәдичә җавап урынына ярарга тырышкандай чак кына елмая төште. Күрәсең, бу шактый урынлы килеп чыкты. Губернаторның теле ачыла башлады:

— Бу араларда миңа шундый ук үтенеч белән керүчеләр байтак булды, — диде ул, — тик, мадам, хәзер бит инде газета белән шаяру вакытлары узды. Уен бетте, җитәр! Шулай түгелме?

Хәдичәнең йөрәге «жу» итеп китте, башына ниндидер кайнар, авыр дулкын күтәрелгәндәй булды. Ләкин ул бу юлы да югалып калмады, теләсә нинди хәйләләргә барып булса да, губернаторның рөхсәтенә ирешергә тырышып утырды.

Губернатор, мыек чылгыйларын тагын сыпырып җибәреп, Хәдичәнең күкрәк-түш турыларына тагы бер артык исе китмәгәндәй күз сирпеп алгач, сүзен дәвам иттерде:

— Мин сезнең мөселман телендә газета чыгарырга үтенеп язган гаризагызны төпченеп тикшерү өчен кабул итәм, мадам, — диде. — Ышанам, сезнең хезмәтегез безнең империя политикасына лояль булыр. Шулай бит?

— Минем газетам,— диде Хәдичә, тигез матур тешләрен күрсәтеп елмайган хәлдә, — империя политикасын шәрехләп, төшендереп бирүне һәм халыкны агартып, ялгыш юлга кереп китүдән кисәтүне үзенә бурыч итеп куя.

— Ә хатын-кыз мәсьәләсендә нинди караштa сез? Эмансипацияме?

— Хатын-кызларны да гүзәлрәк итәчәк бу газета, — диде Хәдичә, беркатлы булып кыланып.— Алар өчен иң кирәк нәрсә: эчке һәм тышкы матурлык.

Губернатор мыек астыннан гына елмайды да үтенечкә нидер язып Хәдичәгә мөрәҗәгать итте:

— Сезне артык тоткарламыйм, мадам. Юлыгызда булыгыз.

— Димәк...

— Якын көннәрдә хәл ителер, мадам.

Хәдичә бераз югала төшеп урыныннан кузгалды. Карт төлке хәйләкәр иде. Шулай да Хәдичәнең өстеннән тау төшкәндәй булды. Ул бөтен тойгы җепләре аша нигездә мәсьәләнең уңай хәл кылынганын аңлады. Җәһәт кенә аякка басты да, җиңелчә реверанс ясап, губернаторга баш иде.

— Рәхмәт сезгә!

Ишеккә җитәрәк ул тагы бер кабат борылып карады. Губернатор, агарган куе кашлары астында ялтыраган соры күзләрен текәп, һаман аны күзәтә иде әле. Хәдичә елмаеп тагы баш иде, тагы реверанс ясады да кабинеттан чыгып китте. Ул өйгә кайтып кергәндә тәмам хәлдән тайган иде. Хөсәен аңа киемнәрен салырга булышты. Барысын да бәйнәбәйнә сөйләткәннән соң аның йөзендә елмаю балкыды. Ул бик канәгать иде. Димәк, иртәгә Уральскига китәргә була...

Хөсәен Уральскига зур өметләр баглап юл тотты. Урта Россиядәге төрки телләрнең берсе булган татар телендә чыгачак газета башка тугандаш халыкларда да үзенә теләктәшлек, терәк булдырыр дип ышана иде ул. Уфа, Оренбур һәм Троицк мәдрәсәләрендә укып мәгърифәткә омтылучы казакъ, башкорт шәкертләрен ул күрмәде түгел. Димәк, газета татар телендә чыкса да, аның большевизм идеяләрен шул татар белән аралашкан шәкертләр аша башка төрки телле халыклар арасында да тарату мөмкинлеге булачак. Ләкин Хөсәеннең бу җитди эшне үз агышына гына куясы килми иде, аны оештырырга кирәк иде, шул халыклар арасында ышанычлы дуслар табып, аларга таянып, газетаны укучы күңеленә үтеп керерлек итеп чыгарасы иде.



Әле борынгы казакъ далаларындагы казачий шәһәрләрнең берсе булган, төрки халыклар арасында Җаек дип, русча Уральск дип аталган шәһәргә ул шул теләкләрен гамәлгә ашыру өчен, юл никадәр авыр булса да, барырга булды. Кышкы суыклар башланган иде инде. Егерме чакрым саен ат алыштырып, ямщик атларында Иләк аша барды ул. Хөсәен Уральскига буш кул белән китмәде, әлбәттә. Әле Уфадан ук казакъның алдынгы либераль карашлы кешеләреннән Әбелхәер Әбелмамбетовның Уральскида торганлыгын яхшы белә иде. Оренбурга килгәч, моны анykларга һәм хәтта ул казакъның адресын белергә мөмкинлек туды.

Уральскига килеп төшеп «Казан» кунакханәсенә урнашу белән Хөсәен Әбелмамбетовның өен эзләп китте. Ул өйне табып ишек шакыганда, эңгер башланып, вакыт кичкә таба авышкан иде инде. Ишек шакуга хуҗа үзе чыкты. Хуҗа иңбашына ярым хәрби френч салган, җитү чәчле, сирәк кенә кара мыеклы, егерме бишләр тирәсендәге бер кеше иде.

— Исәнмесез, мөмкинме керергә? — диде Хөсәен.

— О, рәхим итегез,— диде хуҗа һәм шундук Хөсәенгә чишенергә ымлап пальтоны чөйгә элде. Аннары, үзе алдан юл күрсәтеп, әле һаман берни дә сорашмаган хәлдә, кунакны эчкә алып кереп китте. Квартир берничә бүлмәдән тора, һәм шунысы Хөсәеннең хәтеренә сеңеп калды: аларның кайберләре саф казакъ стилендә җиһазланган иде: идәнгә палас яки киез җәелгән, стена буендагы эреле-ваклы сандыклар берсе өстенә берсе куелган; стеналарга да шулай ук келәмнәр элеңгән, ә идәндә, стена буендагы буш урыннарда, көрпә һәм мендәрләр ята.

Әбелмамбетов казакъка хас кунакчыллык белән Хөсәенне түр бүлмәгә — Европа стилендә җиһазланган, кызыл агачтан ясалган язу өстәле, яшел хәтфә белән тышланган кәнәфи һәм утыргычлар куелган бүлмәгә алып керде. Хуҗа бу якларда үз халкын якларга омтылучан бердәнбер укымышлы адвокат иде, күрәсең, шактый хәлле кеше.

— Утырың, әфәнде, — диде ул, аннары ярым татарча, ярым казакъча, рус сүзләрен дә бик мул кыстырып сораша башлады: — Сездәрде кем дип беләек? Кандай җомыс?

— Ялгышмасам, мин адвокат Әбелхәер Әбелмамбетов өендә хуҗаның үзе белән очраштым, — диде Хөсәен. — Шулаймы?

— Ай-бай, тугры гой,— диде хуҗа.

Хөсәен үзе турында шактый тулы итеп сөйләп бирде.

— Йомышым шул,— диде,— мөселман телендә Оренбурда легаль, ләкин бик сул, дөресен генә әйткәндә, прогрессив идеяләрне пропагандаларга тиеш булган газета чыгарырга җыенабыз. Бу газетаны бер татар халкы гына түгел, башка кардәш төрки милләтләр дә укып файда күрер дип ышанасы килә. Иң мөһиме шул: казакъ халкының тормышы, аның аһ-зары турында бер даими корреспондентка мохтаҗбыз.

— Газета казакъ халкы турында да хәбәрләр биреп барачак, дидегезме?

— Әлбәттә.

— Ой-бай, — дип куйды тагы Әбелхәер кәефләнеп, — күктән төшкән бәхет гой бу!

Хөсәеннең дә күңеле күтәрелеп китте. Әбелмамбетов кунагы алдына, өстәлгә, географик карта китереп салды. Анда Азиянең борын-борыннан казакъ халкы биләгән җирләре төшерелгән иде.

— Карасаңызчы бу харитага, — диде ул. — Осы җирләремезне колонистлар басып алыпты. Правительство безнең якка бик күп переселенец күчерәде. Инде бу керемет хәл талас-ызгышларга китерде. Хәзер казакъ мән переселенец руслар, хахоллар арасында каты низаг туды гой. Берсен-берсе җәберләп, берсенең малын икенчесе куып китеп, зур дау кубады.

Әбелхәер үзенә ничә ыруг вәкилләре ярдәм сорап килүен, ләкин эшне берничек тә югары инстанцияләргә җибәреп булмавын, җирле власть вәкилләре, теләсә нинди юллар табып, җирле халыкны гаепле итеп калдыруларын, нәтиҗәдә казакъ халкының җирсезлектән, ачлыктан кырыла баруын ачынып сөйли башлады.

— Хөкүмәтнең ул политикасын без фаш итәргә тиеш,— диде Хөсәен. — Без андый материалны бастырып чыгару өчен барлык көчне куячакбыз, тик сез безгә материал әзерләүдә һәм, газетада басылгач, аны казакъ халкына җиткерүдә булышлык күрсәтегез. Сез ризамы, Әбелхәер туган?

— Миннән эш калмас, мин сезгә сүз бирәм, — диде Әбелмамбетов. Хөсәен аңа бәйләнеш тоту өчен берничә адрес бирде.

— Шуның белән минем йомышым үтәлде, рәхмәт. Әгәр рөхсәт итсәгез, мин бәлки тагы бер сугылырмын әле,— диде Хөсәен. Хуҗа, адресларны язып алгач, урыныннан торды. — Миңа китәргә рөхсәт итегез.

Әбелхәернең гаҗәпләнүдән кысык күзләре зур булып ачылды:

— Ой-бай, сондай алыстан килгән кунак — кымыздан авыз итмичә китәргә тиешме? Казакъта андый гадәт юк гой!

Хуҗа Хөсәенне, ай-ваена карамастан, икенче бүлмәгә алып чыкты. Анда ашъяулык җәелгән, зур агач җамаякка кымыз салынган, табынга майда кызарып пешкән бавырсак сибелгән, агач аяклар куелган иде. Хуҗа Хөсәенгә түргә узарга кушты. Аяк бөкләп көрпәгә утырыштылар, тиз арада җиз комган, ләгән, сөлге тотып бүлмәгә бер яшь кыз керде. Ләгәнне Хөсәен алдына куеп, комганнан су коерга әзерләнде кыз.

— Бу минем туган сеңелем булады, — диде Әбелхәер, кызга ымлап. — Ә бу агаң нугайның олы адамнарыннан берсе булат.

Кызның күзләре уттай көйрәп тора, күрәсең, үзе дә үтә чая нәрсә иде. Хөсәен кулын юган арада аңа карап алды. Берәр шаян сүз әйтергә ымсынды, мәгәр тыелды: белмәссең, чит халык гореф-гадәтләре ничектер бит. Хуҗа савыттагы кымызны бер мәл агач чүмеч белән болгатып утырды, аннары иплән кенә сары агач җамаякларга сала башлады.

Казакъның кымызы җилле иде. Бу инде Казан кымызы да, хәтта Уфа кымызы да түгел. Хөсәен, кымыз эчә-эчә, эшләнәчәк эшләре турында уйланып утырды. Бу кунакчыл Әбелхәернең кымызыннан авыз итми китү аны рәнҗетү булыр иде шул. Ул тәмләп, иркенләп сүзгә керешкән хуҗаны бүлдермәде, игътибар белән тыңлый башлады.

Казакъ исә үз халкына хас рәвештә җанлы һәм күңелле итеп, тапкыр мәкальләр, тәгъбирләр кыстырып, күргән-белгәннәре, казакъ халкының бүгенге тормышы турында сөйләде. Үзе Оренбурда, аннан Петербурда укыган кеше икән. Хәлле семьяда туу аркасында шундый бәхеткә ирешкән. Ләкин Петербурда алдынгы студентлар сүзенә дә колак салгалаган бу. Һәм нәтиҗәдә үзе дә шактый җитлеккән демократ-

ка әйләнеп кайткан. Ләкин Әбелмамбетов Хөсәен белгәннәрне үзләштермәгән әле. Ул милли азатлыкка сыйнфый изелүдән котылмыйча торып та ирешергә була дигән фикердә иде. Хөсәен, сүз җаен туры китереп, мәсьәләгә үзенең карашын әйтте. Яңадан теге казакъ җырләренә күчерелгән руслар, украинлылар турында хәтерләп:

— Әгәр дә рус һәм украин алпавытларының җирен ярлы крестьянга бирсәң, бу низагны хәл итеп булыр иде, — диде. — Ләкин патша хөкүмәте моңа бармый, аңа милләтләрне талаштыру кулай, ул шуның исәбенә халыкны революцион эшеннән читкә бора, элекке тәртипләрне саклап калу юлын карый.

— Дөрес гой,— диде Әбелхәер, бераз уйлангач.

Хөсәенгә кузгалырга күптән вакыт иде инде. Әгәр вакыты калса, иртәгә кереп чыгачагын тагы бер кабат әйтеп, ул урыныннан торды. Аяклар ойый төшкән, күптән болай аяк бөкләп утырган юк шул.

— Мин сезгә, Әбелхәер туган, зур өметләр баглыйм,— диде ул китәр алдыннан, хуҗаның кулын кысып. — Без уртак эш башкарабыз.

— Егет сүзе бер булады, диме нугай? — диде хуҗа, елмая төшеп.— Вот осындай!

Хөсәеннең барырга тиешле икенче урыны Камил Мотыйгый өе иде. Караңгы төшкән булса да, ул аны бүген үк күрергә тиеш. Теге көнне Галимҗан, тәгаен шуны күрәсең киләдер, дип, дөрес әйткән иде. Камил Мотыйгый үзе яшь кенә булса да, Хөсәеннең ишетүенчә, дөньяны күп күргән, әле моннан өч ел гына элек Каһирә университетын бетереп кайткан һәм, барыннан да элек, мөхәррир буларак, үзе бастырган журнал һәм газеталардагы хөр фикерлелеге белән Хөсәеннең игътибарын җәлеп иткән, кызыксынуын көннән-көн арттырган бер кеше иде. Ни генә булмасын, ул бишенче ел башында ук татар телендәге беренче журнал «Әлгасрел-җәдит»не чыгарды, шулай ук татар телендәге беренче сатирик «Уклар» исемле журналны бастыра башлады.

Әлбәттә, Камил Төхфәтуллинның ниндидер эзлекле юлдан баручы, үз мәсләгендә нык торучы зат булуы исбат ителмәде ителүен. «Әлгасрел-җәдит»нең беренче санында бик күп урын Хөсәен өнәмәгән авторларга бирелгән иде. Ләкин тора-бара журнал үзенең демократик йөзен шактый ачык күрсәтә башлады.

Мондый кешене күрү, аның белән дуслык беркетү, мөмкин булса, аңардан файдалану — яшь газетчы Хөсәенгә бик тә кирәкле максат иде.

...Хөсәенне Төхфәтуллиннарның ике катлы шактый зур өендә ак катыргы якалы күлмәктән һәм европача костюмлы, ә костюм өстеннән әле, борынгы рус алпавытлары шикелле, эре-эре чәчәкле ефәк халат кигән яшь, бик төз сынлы, җитез хәрәкәтле, мәһабәт бер кеше каршы алды. Ул Хөсәен яшьләрендә, егерме биш-егерме алтылар тирәсендә генә күренә. Камилнең җиту кара чәченә, сызылып киткән мыегына, кырын салып кына кигән кара хәтфә кәләпүшенә һәм купшы өс киемнәренә карап, бу кеше корьәнхафиз һәм мөхәррир булудан да бигрәк данлыклы артисттыр дип уйларлык иде. Хәлбуки, шәһәрнең соңгы елларда шактый нык күтәрелгән мөхәррир Камил Мотыйгый шул үзе иде.

Ул Хөсәенне бер дә мөкиббән китмичә генә каршылады. Хәтта әле эрерәк тә кыланды булса кирәк. Һәрхәлдә, Хөсәенгә шулай тоелды. Хөсәен үзенең исемен әйткәч тә ул артык үзгәрмичә: «Беләм, беләм ишеткәнем бар сезнең турыда», — диде.

...Иркен залда алар икесе ике кәнәфигә утырдылар.

— Сезне бу якларга нинди йомыш ташлады? — диде Камил.

— Мин, Камил әфәнде, Оренбурда үзебезчә газета чыгарырга җыенам.

— Ничек Оренбурда? Сез анда да барып җиттегезмени әле? Сезне Уфада дигәннәр иде бит. Афәрин! Өлгер үзегез, ә! Я, ничек соң,

социал-демократлар хәрәкәтен тиешенчә күтәреп буламы? Иярүчеләр артамы? Сез бит инде шуларның башында торучылардан.

Камил бик әтәчләнеп сөйләшә иде. Җитмәсә, баланың шуклыгын гафу иткәндәй, ул Хөсәеннең иңбашына сугып көлеп тә куйды.

— Ярый, бик әйбәт, хәзер модада инде ул.

Хөсәеннең ачуы килде.

— Сез дә социал-демократик рухтагы мәкаләләрне модага ияреп бастырмагансыздыр бит?

— Кайда?

— Әйтик, «Әлгасрел-җәдит»тә.

Камил, кәнәфи аркасына сөялгән килеш, башын артка ташлап рәхәт бер көлү белән бүлмәне яңгыратып алды.

— Инде мине дә модага иярүче кеше дисәләр!..

— Уйларга мөмкин, Камил әфәнде. Чөнки сез «Әлгасрел-җәдит»нең беренче санында бик рәхәтләнеп дин һәм милләтчелек идеологларына урын бирдегез. Ә аннан соң шул ук газетада бөтенләй башка юнәлештәге әйберләр дә басыла башлады.

— Газета ич ул! Демократия дибез икән, анда, минемчә, Хөсәен әфәнде, тегесе дә, бусы да басыла ала. Бәхәс кирәк, бәхәстә туа дөреслек!

— Кемгәдер хезмәт итәргә тиештер бит ул газета?! Аннан, Камил әфәнде, демократия максат түгел бит, ул чара. Шулай түгелмени?

Камил кәнәфи култыксасын бармаклары белән гасабиланып тыпырдатып куйды.

— Минә шул чара ярдәмендә дөреслек туа. Ярар, бәхәсләшмик, һәркемнең мәсьәләгә үз карашы бар, — диде ул. — Димәк, сез газета чыгарырга булдыгыз, Хөсәен әфәнде?

Хөсәен «бу эш тә хәзер бик модада» дигән сүзләрне көтте, ләкин Камил анысын әйтмәде.

— Сез газета чыгарырга булгансыз, ә акчагыз бармы соң? Ул ташып торамы? — диде.

Хөсәен җавап бирергә өлгермәде, Камил үзе элеп алды.

— Минә мин шул газета, журнал бастырам дип йөри торгач, хәзер бөтенләй бөлдем, beлəсегез килсә, Хөсәен әфәнде. Егерме мең сумга барлык байлыгымны сатып, хәтта хатынымның приданнарын да шуңа кертеп матбага сатып алдым. Казаннан хәрефләр китерттем. Нәтиҗә шул булды: «Уралец»ны яптылар. Карагруһлар газетасы «Бәянелхак» хатын-кыз хөрлеге өчен көрәшкәнгә мине хәтта хөкемгә тартты. Инде үзебездәге «Уральский листок» минем өстемнән төрле пычрак ялалар белән чыкты. Минә нәрсә бит ул безнең заманда газета чыгару, әфәндем! Сез боларның барысын да аңлый торгансыздыр ич?!

— Барысын да аңлыйм, Камил әфәнде, — диде Хөсәен. Ул Камилнең авыр хәлен чамалап белә иде. Бүген булмаса иртәгә бу һавалы каһарман газета-журнал эшен ташларга мәҗбүр итeләчәк. Һәм моның сәбәбе, иң беренче чиратта, демократия өчен көннән-көн авырая барган шартлар булса, икенчедән, монда Камилнең дуамаллыгы, кайбер очракта гамьсезрәк кыйланып ордым-бәрдемгә, авантюрага исәп тотуында иде. Кыскасы, ул акылдан бигрәк хис, тойгы колы иде. Ә мондый кеше, бик файдалы эшләр эшләп ташлау белән бергә, зур чатаклыклар ясаудан да азат түгел. Әйе, татар дөньясына үзенең файдалы эшләре белән танылган, хәтта социал-демократик идеяләрне таратуда эш күрсәткән газета-журналлар сүнү-бетү алдында тора. Бу хәл исә Хөсәен газетасының кирәклеген арттыра гына төшә, аның җаваплылыгы да, кирәге дә соң дәрәҗәдә зур бүген. Тирәнлек һәм эзлеклелек җитмәгән, йөзләре җитәрлек ачылмаган вакытлы матбугат диңгезендә, әлбәттә, большевистик газета гына укучыга дөрес юнәлеш бирә алачак. Ләкин аны чыгару җиңел булмаячак.

Хөсәен шулар турында уйлап алды һәм үзенең үтенечен аңлатты.
— Мин сезгә, Камил әфәнде, үтенеч белән килдем.
— Акча сорасагыз, акча юк,— диде Камил өзеп.
— Юк, акча түгел, — диде Хөсәен елмаеп. — Миңа сезнең киңәшләрегез кирәк.
— Ә монысын эшләргә була, — диде Камил һәм, гадәтенчә озын, озак итеп, сүзгә тыгылырга һич ирек бирмичә, ничегрәк эшне башларга һәм ничек итеп газетага язылуны оештырырга кирәклеген сөйләп китте. Соңыннан исенә төшеп: — Туктагыз әле, гафу итегез, сезнең тукталган урыныгыз бармы соң? Сез ач түгелме? — дип сорады.
— Рәхмәт, мин ач түгел.
— Бүген бездә куначаксыз.
— Рәхмәт, мин «Казан» кунакханәсеннән номер алдым. Аннары минем, йоклар вакыт житкәнче, Габдулла әфәндене дә күрәсем килгән иде.
— Кайсы Габдулланы? Алар бит байтак безнең Уральскида.
— Әлбәттә, Тукаевны. Ул бит көндезләрен эштә була торгандыр. Мин аны сезнең матбагада эшли дип ишеттем.
Камилнең кәефе кырыла төште.
— Ул беркайда да эшләми. Сез аны үзегез тукталган «Казан» миһманханәсеннән таба аласыз.
Хөсәен бу ике кеше арасында нидер булганлыгын шунда ук чамалады, ләкин төпченергә базмады.
— Миңа, иң яхшысы, алайса, кунакханәгә кире кайту,— диде.
— Ихтыярыгыз, Хөсәен әфәнде,— диде Камил. Алар икесе дә саубуллашу өчен аягүрә бастылар. Хөсәен Камилнең чыраеннан, күз карашыннан ук мөхәррирнең бик авыр вакытына туры килүен аңлады. Камил сер сынатучылардан түгел иде, күрәсең, ләкин шулай да эчтәге кичерешләр сизелмимени ул!..

## 4

Фәрхетдиннең юлы уңды. Килеп төшкән көнне үк эш табылды. Моңарчы тимерчелектә эшләгән бер рус егетенең кызган тимер очкыны тиеп күзе пешкән икән, шуның урынына бастырдылар.
Елдан артык кулына чүкеч алганы юк иде. Фәрхетдиннең «кәҗә майлары» чыкты, хәлдән таеп, үләм, егылам дигән минутлары булды, мәгәр сер сынатмады, — сменаны исән-аман уздырды.
Әйтергә кирәк, тимерче дә яхшы кеше булып чыкты. Фәрхетдиннең хәлен аңлады булса кирәк, җикеренмәде, сүгенмәде, чүкеч сугып торучысының житешсезлекләренә түзде.
Тимер юл мастерское зур иде бирелә. Тимерчелектә генә дә ун учак бар иде. Корымга каткан ярым караңгы бу җәһәннәм базыдай остаханәдә бертуктаусыз тимер чыңы, осталарның кычкырынуы, чүкеч сугучыларның ухылдавы һәм тимергә кувалда белән дөп-дөп суккан тавышлар ишетелеп тора. Мондагы күн алъяпкычлы, йөзләре күмер тузанына каралып беткән кешеләр дини әкиятләрдәге тәмуг зобанилары сыман күренә. Корымлы йөзләр буйлап тир ага, күзләрне әчеттерә, буш ара булган саен кешеләр почмакта торган агач кисмәккә чабалар, кружка тутырып су эчәләр. Юньләп тәмәке көйрәтеп алырга да вакыт юк. Шулай да Фәрхетдин шат иде, аңа биредәге җәһәннәм газаплары да көтеп алынган куанычлы бер бәйрәм булып тоелды.
Бер атна эшләгәч тә аңа туксан ике тиен акча бирделәр. Фәрхетдин мастерской мунчасында юынып, арурак күлмәкләрен киеп, шатлыгын уртаклашу өчен, такелажник Чынбулат өйрәтүе буенча, Хөсәеннәр квартирына китте.

Хәдичә аны күреп хәйран калды. Бүлмәгә узарга, чишенергә кушты. Фәрхетдин Хөсәеннәрнең нинди эш башкарып йөрүен белә иде инде. Ул шушы узган бер ел эчендә шактый катлаулы һәм гыйбрәтле сабаклар алырга өлгерде. Шуңа күрә хәзер Хәдичәнең «безнең бүлмәгә кер» дип, бер рус кешесе өендәге бүлмәгә чакыруына да аптырамады.

— Бәй, Хөсәен абыйны кайткандыр дип уйлаган идем ич мин,— диде ул.

— Хөсәен абыең, читтә шул әле,— диде Хәдичә.

— Беләм, миңа Чынбулат әйткән иде.

— Чынбулат? Кем соң ул?

— Бәй, сезне ат белән каршы алдым, китереп куйдым, диде ич ул.

Хәдичә исенә төшереп көлеп куйды.

— Син шулай дуслар да табып өлгердеңмени инде?

— Ул бит безнең мастерскойда эшли.

Алар өстәл тирәсенә утырыштылар.

Фәрхетдин Хәдичәгә үзенең башыннан кичкәннәрне сөйләп китте. Авылга нинди газаплар кичереп кайтуын, өйдә үзен нинди күңелсезлекләр көткәнлеген әйтте.

— Рәхмәт сезгә, Хәдичә апа, анау вакытны больницага килеп хәл белешеп тормасагыз, юлыма ризык бирмәсәгез, мин әле бәлкем кайтып та житә алмаган булыр идем.

— Яраң төзәлдеме соң инде? — дип сорады Хәдичә.

— Анысы аллага шөкер, барысы да ямалды.

— Ярый инде, шунысына шөкер ит, гомерлек гарип булып калуың да бар иде ич.

— Их, Хәдичә апа, Хәдичә апа! Ул яралар мине гарипләндермәде, киресенчә, гариплектән коткарды.

Хәдичә көлеп куйды.

— Ничек инде ул алай?

— Шулай, акны карадан аера башладым. Хөсәен абыйның, маллымөлкәтле кеше малаеның, болай йөрүенә шакката идем. Пычак миңа барысын да аңлатты. Дөрес эшли Хөсәен абый. Мин аның эше өчен хәзер, Хәдичә апа жаныем, күкрәгемнән йөрәгемне йолкып алып бирергә риза.

— Синең ярдәмең дә, Фәрхетдин, Хөсәен абыеңа озакламый бик кирәк булыр әле, — диде Хәдичә.

Фәрхетдиннең йөзе алсуланып китте.

— Нинди ярдәм кирәк — барысын да эшлим, Хәдичә апа!

— Абыең озакламый Оренбурда газета чыгара башлаячак. Менә шул газетаны таратуда аңа ярдәм күрсәтә аласың син.

— Ах, — дип куйды Фәрхетдин, — урысча укый-яза белмим шул!

— Газета бит урысча түгел, үзебезчә, татарча.

— Бәй, андый нәмәрсә дә бармыни? Үзебезнең телдә, син, мин аңлый алырлыкмы? Һа! Авылда шулай бер гәзит тапканнар да атайлар миңа килгәннәр. Яле, Фәрхетдин, син бераз сукалыйсың, шәһәрләрдә йөреп шомарган син, укып бир әле шул гәзитне, мөселманча булса кирәк, дип, шуны миңа китереп тоттырдылар. Менә, билләһи, Хәдичә апа, тирләппешеп чыктым, ике сүзен бергә кушып укый алмадым шуның. Үзебезнең хәрефләр белән язылган, үзе әллә нәмәрсә телендә. Мин әйтәм, бу гәзитне мулла абзый гына укыса укый алыр, миннән булмый, мин әйтәм. Их, син, диләр, мәдрәсәгә дүрт кыш буе йөрүең корысын, диләр. Шулай оятка калдым.

— Нинди газета иде соң, исеме ничек? — дип сорады көлемсерәп тыңлаган Хәдичә.

— Әллә торжагунмы, төржоманмы шунда.

— «Тәржеман», — дип төзәтте Хәдичә. — Юк, безнең «Урал» андый телдә язылмаячак.

— Алай булса инде эш икенчерәк формалы икән.
— Ләкин сиңа, Фәрхетдин, әгәр дә абыеңа ярдәм итәргә алынасың икән, мин баштан ук аяк киенеп куюыңны теләр идем.
— Ничек итеп, Хәдичә апа?
— Менә, әйтик, син эшләгән мастерскойда татар-башкорт эшчеләре күпме? Алар үзебезчә чыгачак, эшчеләр кайгысын кайгыртачак газетага ничегрәк карарлар икән? Чыкса, сатып алырлармы, укырлармы, таратырга булышырлармы? Шуны белешергә кирәк.
— Аңлыйм,— диде җитдиләнеп Фәрхетдин.— Күргәлим, күргәлим, мастерскойда безнең ят кешеләр дә булгалый. Мин инде, Хөсәен абый кебегрәкләрдер болар, дип уйлап куям. Тик миңа әле аның турында сүз катарга ярамый. Мин бит әле бөтенләй яңа кеше.
— Алайса, сөйләштек, — диде Хәдичә.
Ул җентекләп Фәрхетдиннең йөзен күздән кичерде. Егет бер ел эчендә бөтенләй олыгаеп киткән. Казандагы канлы вакыйгаларның истәлеге булып аның уң яңагында кызгылт яра эзләре җөйләнеп тора. Хәдичә Фәрхетдиннең больницада яткан көннәрен хәтерләде.
— Сөйләштек, Хәдичә апа, — диде Фәрхетдин, — мин әкрен-әкрен сораша, белешә башлармын.
— Тик моны бик оста, сиздермичә генә эшләргә кирәк, Фәрхетдин, юкса, абыеңа да, үзеңә дә зыян килүе бар.
— Анысын да төшенәм,— диде Фәрхетдин. Сүз Фәрхетдиннең хатынына һәм әнисенә күчте: — Алла боерса, әз генә тернәкләнсәм, саманнан өй салам да Хафазаны да, әти-әнине дә монда китертәм,— диде Фәрхетдин. — Монда бик җиңел генә итеп балчыктан өй әмәллиләр икән. Әйтәм ич, өй салам, аннан бәләкәй генә гармун алам. Гомер буе шул нәмәрсә турында хыялланам инде.
Алар чәй эчәргә утырдылар.
— Үзегез Уфада ничек яшәдегез соң? — дип сорады Фәрхетдин.
— Яшәдек, — диде Хәдичә, — абыең иртәдән кара төнгәчә эшләп йөрде. Мин аңа булыштым... булдыра алганча. Дөресен әйтәм, җиңел булмады, Фәрхетдин. Кайчагында тәүлекләр буе аның кайтканын көтеп утырырга туры килә иде.
— Ярый әле, балагыз юк,— дип куйды Фәрхетдин, аны-моны уйламыйча. Хәдичә күңелсезләнеп читкә борылгач кына, ул үзенең кирәксез сүз әйтеп ташлавын аңлады. Ләкин соң иде инде.
— Юк шул, юк шул,— диде пошынып Хәдичә.— Әгәр ул булган булса, бәлки барысы да бөтенләй башкача юл алыр иде.
Фәрхетдин сүзне бу турыда куертмас өчен үзенең эшләү шартлары, тору шартлары турында сөйләп китте.
— Монда да миндәй эшчеләр өчен казарма бар икән. Зур, шыксыз бер барак инде. Шыгырдавык караватым бар. Мине шул төне буе җырлап юата. Монда да акчаны бездәгедән артык бирмиләр, тик акча ризыкка аз китә монда. Безнең Казан губернасына караганда бу якларда ашау әйберсе очсызрак. Җир күп.
Алар шулай тыныч кына гәпләшеп утырдылар.
— Хөсәен абый кайчан кайта соң? — дип сорады Фәрхетдин.
— Бер-ике көннән...

## 5

Бу минутларда Хөсәен Уральск шәһәренең «Казан» гостиницасында, аның икенче катындагы җиденче бүлмә ишеге төбендә басып тора иде. Ишекне шакыганчы ул бераз икеләнеп торды, чөнки вакыт шактый соң бит, кешене борчу булмасмы? Ләкин Хөсәеннең башка чарасы да юк иде, ул иртәгә иртәнге якта ук юлга чыгарга тиеш.
Хөсәеннең сак кына шакуына шунда ук эчтән яңгыраулы яшь тавыш русча:

— Рөхсәт, керегез, — диде.

Хөсәен ишекне ачты. Абажурлы лампа бүлмәнең түре ягындагы өстәл янында утырган җитү чәчле егеткә һәм аның алдындагы кәгазьләргә генә яктысын төшерә иде. Ике якта ике тимер карават. Сул яктагысында кемдер йоклап ята, ә өстәл янындагы егет исә нидер язып утыра. Өстәлдә китап, газета һәм журналлар таралып ята.

Хөсәен әчкә таба бер-ике атлады да бүлмәнең тарлыгыннан каушый төшкәндәй туктап калды. Ул арада егет язуын тәмамлап аягүрә басты, лампаның кәгазь абажурын күтәреп, Хөсәеннең йөзенә яктылык төшерде. «Тукай бу» дигән фикер узды Хөсәеннең башыннан.

Җитди генә итеп егетне татарча сәламләде.

Тукай кәгазь абажурны бөтенләй алып ташлады да:

— Гафу үтенәм, мин сезне доктор дип уйладым, — диде.

— Миңа Габдулла Тукаев әфәнде кирәк иде.

— Тукаев әфәнде без булабыз, рәхим итегез, — диде хуҗа беркадәр ирония белән.— Сезне кем дип белик?

— Мин Хөсәен Ямашев дигән кеше булам.

Тукай игътибар белән, бу юлы һич иронияле, Хөсәенне тагы бер тапкыр күзеннән кичерде.

Габдулланың өстендә кыек якалы кара күлмәк, билендә зәңгәр ефәк пута. Аның сынап карый торган коңгырт-кара күзләре, хәрәкәтчән нечкә кашлары, нык кысылган матур иреннәре һәм тулы ак йөзе игътибарны җәлеп итәрлек үзенчәлекле иде. Кызыгы тагы шунда: аның кыю, җор булуы Хөсәеннең күңелендә туган беренче тойгыны, бала сымак нәрсә, бик яшь икән бу, дигән тойгыны шунда ук юкка чыгарып ташлады.

— Бик әйбәт,— диде Тукай, Хөсәенне сынап күздән кичергәннән соң, — мин сезнең турыда кемнәндер ишеткән идем. Рәхим итегез, узыгыз, утырыгыз. Мондый очрашу уңае белән зур лампаны да яндырырга ярый, — диде ул һәм, Хөсәен буш караватянындагы артсыз урындыкка урнашкан арада, утыргычка басып асылмалы лампаны да кабызып өлгерде. Бүлмә эче ялт итеп балкып китте.

— Сез дә безнең миһманханәгә урнаштыгызмы? — диде ул, утыргычында басып торган килеш.

— Әйе, мин унынчы номерда.

Хөсәен, игътибарын җигә төшеп, караватта яткан шадрарак йөзле кешегә карап алды.

— Без сезнең авыру иптәшегезгә комачау ясамабызмы соң?

— Нәүм базарында инде ул,— диде Тукай, утыргычтан идәнгә төшеп,— мин аңа кайнар чәй белән солицилка биргән идем. Ә чакырткан докторның килмәведер инде.

Тукай караватта ятучыга күз ташлады һәм бик җитди кыланып, шул ук вакытны ирония белән әйткәнен сиздереп:

— Ул да сезнең кебек революционер,— диде.— Тик бу юлы, соңгы бер операциясе уңышсыз чыгып, полиция кулында харап була язды.

Хөсәен Тукайның мәзәген аңлады, көлемсерәп:

— Нинди операция соң ул? — диде.

— Бу — минем дус егет, Миңлебай Хәйруллин. Первоклассный артист та, корьәнхафиз да ул. Шәкерт чактан бирле дуслар без. Хәзер монда торабыз. Өченче көн токтан да, революциягә хезмәт итим әле дип, көпә-көндез тыелган китаплар сатарга чыгып киткән.

— Ни булып беткән соң?

Тукай көлеп җибәрде.

— Бер генә китабын да сата алмаган, үзен җилтерәтеп частька озатканнар. Китапларын конфисковать иткәннәр. Салкын бүлмәдә куныл

кайтты. Өстеннән материал әзерлиләр. Хәзер инде артист булу турында хыяллана, революционер булу шактый хәвефле һөнәр икән, ди.

— Нигә, ул да ярый, революциягә артист булып та хезмәт күрсәтергә була, — диде Хөсәен көлеп. Аннан алар бер мәл, эшкә күчәргә вакыт дигәндәй, тынып тордылар.

— Мин сезнең иҗатыгыз белән таныш, — диде Хөсәен. — «Әлгасрел-җәдит»тәге әсәрләрегезне дә, «Фикер»дәге һәм «Уклар»дагы әсәрләрегезне дә кызыксынып яратып укып барам. Хәтта үзебезчә язылганнарын яттан да беләм.

— Рәхмәт, — диде Тукай һәм инде дусларча көлеп әйтә куйды: — Шаять, сез Оренбурдан бу комплиментны әйтер өчен генә мине эзләп килмәгәнсездер? Берәр шигыремне укып күрсәтүдер ниятегез. Читтән килгән мөсафир авызыннан әйбәт яңгырый микән минем шигырь? Бик беләсе килә.

Хөсәен дә көлеп куйды.

— Ә шул сүзне әйтү өчен генә булса да килерлек түгелмени? Сез, минемчә, андый сүзгә дә, Габдулла әфәнде, мохтаҗ. Хәер, шигырь дә укып күрсәтәм. — Хөсәен утырган урыннан торды да Тукаевның әле генә «Әлгасрел-җәдит» журналында басылып чыккан «Үземә» исемле шигырен яттан сөйли башлады.

Телим булырга мин инсане гали,
Тели күңелем тәгали биттәвали.
Күңел белән сөям бәхетен татарның,
Күрергә шаһлыгын, тәхетен татарның.
Татар бәхете өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

Хисапсыз күп минем милләткә вәгъдәм,
Кырылмасмы вавы, валлаһе әгъләм?

Габдулланың кашлары җыерылды, күзләрендә моңсулык чагылды. Ул моңарчы кулланган ирония-һөҗүне калдырып, җитди рәвештә сөйләшә башлады. Күрәсең, ул хәзер Хөсәенне уңайсыз бер хәлгә төшерергә тырышуына үзе дә үкенә иде.

— Бик мохтаҗ, Хөсәен әфәнде,— диде,— җылы сүзгә, һәрбер иҗат кешеседәй, мин дә мохтаҗ. Татар шагыйренең хәле аңлатып бетергесез авыр. Мин моны шигърият юлында беренче адымнарымны ясау белән үк аңладым. Минем хәзер эттән күп дошманым. Барлык капкорсак байлар, карагруһ муллалар мине тере килеш ашарга торалар. Хәлбуки, әйтеләсе сүз әйтелә башлады гына әле. Дуэль дәвам итә. Ләкин миңа чигенү юллары юк инде. Менә мондый хәлдә, әлбәттә, үзеңә афәрин дип әйтүче булса, көч-гайрәт артып китә. Ләкин мине дусларымның, поклонникларымның тәхсин дигәннәре генә түгел, аларның тәнкыйть сүзләре дә кызыксындыра. Изге теләк белән әйтелгән тәнкыйть тә ифрат кирәкле шәйдер. Тукай сораулы караш белән Хөсәенгә күзатты. Хөсәен исә аска карабрак көлемсерәде дә бармак битләре белән мыегын сыпыргалап алды. Яшь шагыйрь, тәнкыйть кирәкле шәй, дисә дә, аңа туры сүзле булам дип, башыңа беренче килгән уйларыңны әле иләмичә әйтергә ярамый иде.

— Мин сезнең укучыларыгызның берсе буларак бары кайбер теләкләремне генә әйтә алам, — диде Хөсәен. — Сыйныфлар көрәше инде кызган бу чорда үзең сайлаган мәсләккә эзлекле рәвештә хезмәт итү бик мөһим. Әлбәттә, ул нык күзәтүләр, өйрәнүләр аша килә...

Тукай кинәт кабынып:

— Димәк, сез минем шигырьләремдә бу нәрсә җитми дип уйлыйсыз инде? — диде.

Хөсәен тынып калды. Аның карашы бу минутта «үпкәләмә, кадерле кеше, син үзең теләдең бит» дия сыман иде. Моны шагыйрь дә аңлады, үзен кулга алды. Күрәсең, бер мизгелдә аның күңеленнән эзләнүләре,

ышану һәм шик-шөбһәләре узды һәм ул Хөсәеннең әйткәннәре белән шундук килеште.

— Гафу итегез бүлдерүем өчен, — диде, — сез хаклы, әле минем өчен ачык булмаган нәрсәләр бик күп.

— Инде мин тагы бер теләгемне белдерер идем, Габдулла әфәнде. Ул да булса мәрхүм Каюм Насыйри башлаган бөек эшне дәвам иттерү, язган әсәреңне гади халыкка аңлаешлы итеп язу. Сез бит аны, теләсәгез, бик әйбәт башкарасыз. Ә инде татар халкына мөрәҗәгать итеп:

Җөмлә фикрем кичә-көндез сезгә гаит, милләтем.
Сыйххәтеңдер — сыйххәтем һәм гыйлләтеңдер — гыйлләтем.
Син мөкатдәс мөхтәрәм гыйлдемдә барлык нәрсәдән;
Сатмазым бу кяннатә милләтем, миллиятем.
Бахтиярым, бәндәңи гәр итсәләр нисбәт сәңа;
Гаҗизанә шагыйрең улмакка вардыр ниятем,

— дисез икән, аны халыкның барлык вәкиле дә аңлар микән?

Тукай тагы бер кабынып сүнде. Ләкин шулай да тынычланып әйтте:

— Туган телебез турында, аның тулы хокукларын булдыру турында, әлбәттә, безгә бик нык эшләргә кирәк. Ләкин, Хөсәен әфәнде, әдәбият укучысының моңарчы ниндирәк телдә язылган әсәрләргә гадәтләнгәнен дә онытып булмый, минемчә. Үзебезнең әдәби телебез саф татарча яңгырый торган дәрәҗәдә булмый торып, мондый экспериментлар әле яшәр дип уйлыйм мин.

— Әдәби телебезне тизрәк камилләштерү, халыкка якынайту өчен, иң беренче чиратта, сезнең кебек кешеләр җаваплы, Габдулла әфәнде. Уемча, экспериментлар җитәрлек булды инде.

Тукай кулларын кушырды да, туңып киткән кешедәй башын иеп, бераз вакыт чайкалып утырды. Аннан уйланып:

— Бәлки сез хаклыдыр,— диде. Бүлмә эче кинәт артык тын булып китте. Тукай үзенең нидер әйтүен көткән Хөсәенгә дустанә бер караш ташлады.

Бик тыныч, гади генә итеп:

— Ә сез нинди эшләр белән мәшгуль? Уральскида минем сезнең мәсләктәшләрдән дә дус-ишләрем бар,— диде.— Мин сездәге хәлләрдән дә бераз хәбәрдар.

Хөсәен үзенең иң җитди эше, чыгарылачак газета турында сөйли башлады. Сүз төгәлләнгәч, Тукай:

— Бик җитди эшкә керешкәнсез,— диде.— Димәк, әдәби телебезне булдыру өчен моннан соң сез дә җаваплы.— Тукай өстәлдәге тәртипсезлеккә игътибар итеп, тиз-тиз андагы газета-журналларны урнаштыра башлады. Шул эш арасында:

— Без чыгарып ята торган газет-журналлар ул кадәр сул түгел, алай да цензура бугаздан буа башлады,— диде.— Сезгә бик күп сират күперләре кичәргә туры киләчәк. Сезнең болай да хәлегез җиңел түгелдер.

— Ул эшен бетереп яңадан Хөсәен каршысына килеп утырды.

— Әйтегез әле, Хөсәен әфәнде, нинди сәбәпләр аркасында сез революционерлыкны һөнәр итеп сайладыгыз?

— Һәр һөнәр үзенә кулай бер сәләт сорый, — диде көлеп Хөсәен, — ә кайчагында сәләт һөнәрне... Ә сез шагыйрьлекне ни өчен сайладыгыз соң?

— Ә мин аны сайламадым, ул үзе килде.

Хөсәен кәефләнеп мыегын сыпырып куйды.

— Менә революционерлык та миңа үзе килде. Безнең тирә-ягыбыздагы социаль гаделсезлек шартларында мин башка юл сайлауны тиеш тапмадым.

— Сез хаклы, — диде Тукай уйчанланып.

Сүз илдәге хәлләргә, Казан яклары турысына күчте. Тукай үзенең ятимлектә, кыерсытуда узган балалык елларын хәтерләп сөйли башлады. Хөсәен аны әчке кичерү белән тыңлап: «Чыннан да менә бу кеше халыкның аһ-зарын яхшы белә инде», дип уйланды.

Соңгы вакытлардагы Казан вакыйгаларын искә алдылар. Тукайның Казанны сагынганлыгы сизелеп тора иде.

Сүздән сүз чыгып:

— Әле мине шушы araларда сезнең Оренбурга Фатих Кәрими әфәнде «Вакыт»ка эшкә чакырган иде,— диде Тукай.

— Нәрсә дип җавап бирдегез соң?

— Анда барганчы Казанга китәм мин. Күчеп, бөтенләйгә:

Хөсәен Казанда алдынгы шәкертләрнең «Әлислах» газетасы чыгарырга җыенуларын әйтте.

— Ниһаять, «Әлислах» шәкертләр өчен генә чыгарылган язма газетадан киң мәйданга чыгарга әзерләнә икән! Ярый бу!

— Әлбәттә, ярый... дөрес юнәлеш таба алсалар.

Кинәт шушы урында сүз бүленде. Авыру ыңгыраша башлады. Тукай сикереп торды, иптәше янына барды.

— Ни булды, Миңлебай, кәеф нишли?

— Эчәргә су бир әле, зинһар, Габдуллаҗан.

Тукай, калай чәйнектән агызып, авыруга су эчергәч:

— Бездә кунак бар бит әле, Миңлебай дус,— диде,— Хөсәен Ямашев килгән, бир кулыңны, күреш.

— Менә ничек була икән ул революция өчен хезмәт итүнең нәтиҗәсе,— диде Миңлебай, Хөсәенгә кайнар кулын сузып.— Төне буе зәмһәрир суыгында часть та тоттылар, дуңгызлар. Бер китап та сата алмадым.

— Тыелган китаплар саткан өчен полициядә рәхмәт әйтерләр дип уйлаган идегезмени? — диде Хөсәен.

— Һәрхәлдә, мин аларны бу дәрәҗәдә үк мәрхәмәтсезләр дип уйламаган идем.

Көлешеп алган арада Хәйруллин:

— Доктор килмәдемени? — дип сорады.

— Юк,— диде Габдулла һәм көлкене көчәйтеп өстәде: — ул каһәр синең политический булуыңны сизеп шүрләгәндер. Бер пилюли биримме соң тагы?

— Юк, кирәкми, — диде Миңлебай. Ул бераз гына тынып ятты да мышнап тагы йокыга китте.

— Төне буе йокламаган,— диде Тукай, аны аклаган кебек,— әле бүген өйлә вакытында гына кайтып ауды.

Алар яңадан үзара сүзгә керештеләр. Сүз бу юлы Уфа, Оренбур вакыйгалары турында барды. Соңыннан Габдулла:

— Карагыз әле, мин сезгә хәзер бер яңа шигыремне укып күрсәтәм, — диде, — әле генә табадан төште дип әйтергә була. Ул өстәлдән шигырьнең кулъязмасын тапты да дәртләнеп укырга тотынды.

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап,
Чаптыра атларны кучер суккалап та тарткалап.
Кич иде, шатлык белән нурлар чәчеп ай ялтырый,
Искән әкрен җил белән яфрак, агачлар калтырый.
Һәр тараф тын. Уй миңа тик әллә ни җырлый, укый,
Нәрсәдәндер күз әленгән һәм тәмам баскан йокы.

Тукай шигырен башта кәгазьгә карап укыды, аннан, күрәсең, үзе дә сизмәстән, кәгазеннән аерылды, яттан укый башлады. Ул барлык дөньясын онытып, дәртләнеп, кулларын салмак һәм бик кирәгендә генә хәрәкәтләндереп сөйли иде. Менә ул еш-еш сулый башлады, йөзе алсуланып китте. Тукай башын күтәрә төшеп, уң кулын әкрен генә алга таба сузды. Бу минутта аның яңгыравык тавышы чак кына калтырый башлады.

— Бер тавыш килде колакка, яңгырады бер заман,

— диде ул, аннан кинәт тавышын күтәреп, шигырьне укып бетерде:

«Тор, шәкерт! Җиттек Казанга, алдыбызда бит Казан!»
Бу тавыш бик ачты күңелем, шатлыгымнан җан яна,
«Әйдә, чап, кучер, Казанга! Атларны ку: на! на! на!»

Хөсәен Казанны хәтерләп утырды. Анда узган яшьлеге, мәрхүм әтисе, әнисе, дуслары күз алдыннан узды. Никадәр генә эш белән мавыкма — сагындыра иде шул туган як. Яшь шагыйрь дә бик-бик сагынган иде, күрәсең, балалык көннәре узган якны. Юкса, мондый күңелне җылата, күзләрне дымландыра торган шигырь яза алмас иде. Гәрчә туган ягы аңа рәхәтеннән күбрәк михнәтен генә татыткан булса да...

Вакыт бик соң иде инде. Хөсәен рәхмәт әйтеп урыныннан торды. Тукай Хөсәенне берни белән дә сыйлый алмавы өчен гафу үтенде. Хөсәен үз бүлмәсенә керер алдыннан коридорда үзен озата чыккан Тукайның уйчан күзләренә текәлеп, аны яратып, сокланып кулын кысты.

— Сезнең белән танышуыма мин шат, — диде, — үземә тагы бер әйбәт дус таптым дип уйлыйсым килә. Бәлки бик озаккадыр, бәлки озакка түгелдер, һәрхәлдә, күрешкәнгә кадәр, саубуллашыйк. Мин иртәгә таң белән үк Оренбурга китәчәкмен.

— Мин киләсе язга солдатка каралырга тиеш,— диде Тукай.— Туган якларыма кайтам, ходай насыйп итсә. Мин Оренбурны һәм сезне истән чыгармаячакмын. Хат аша хәбәрләшербез.

Хөсәен иртәгесен Оренбурга кайтып китте. Аның башы Уральск хәлләре, Тукай, Оренбурда эшләнәсе иксез-чиксез эшләр, планнар белән тулы иде. Аның ашкынуы шул кадәр көчле иде ки, атлар артык акрын бара кебек тоелды. Кар баскан моңсу далаларны, сирәк-мирәк очраштыргалаган юлчыларны, дөягә атланган яки җигүле ат белән баручыларны күзәтеп, үз уйларына чумды ул.

## 6

Гафур Коләхметов Хөсәеннән бер-бер артлы ике хат алды. Беренче хатында Хөсәен Уфада РСДРП өлкә комитетының татар телендә легаль газета чыгарырга карар кылуын, моның өчен партия кассасыннан билгеле бер сумма акча җибәрелүен һәм бу эшнең Хөсәенгә тапшырылуын хәбәр иткән иде. Икенчесендә исә инде газета мәсьәләсенең бөтен формаль сыйрат күперләре кичүе, хәзер инде җиң сызганып эшкә керешергә кирәклеге турында язылган иде. Ул «Вакыт» газетасының соңгы санында «Урал» турында игълан басылганлыгын әйткән. Шул ук вакытта Хөсәен Гафурдан һәр төрле ярдәм дә үтенгән иде.

Гафур газета чыгаруның һәм аерата «Урал» кебек сул газета чыгаруның ни дәрәҗәдә авыр нәрсә икәнлеген яхшы аңлый иде. Моның өчен, беренче чиратта, тормышның эчендә кайный торган хәбәрчеләр кирәк, газетага язылу шәп оештырылган булырга тиеш, өстәвенә редакция хезмәткәрләре үз эшләренең осталары булсын.

Ләкин, таш яуса да, дустының, барлык авырлыкларны җиңеп, максатына ирешәчәгенә ышана иде Гафур. Ул ихлас күңелдән шатланды. Соңгы хатын укып чыгу белән Хөсәенне күптән хыялында йөрткән максатка ирешүе белән котлап һәм аңа, һичшиксез, ярдәм итәчәген әйтеп, ашыгыч хат җибәрде.

Башкача була да алмый иде. Социал-демократик идеяләрне вакытлы матбугат аша принципиаль позицияләрдә торып пропагандалау бер Хөсәеннең генә эше түгел, ул соңгы вакытларда бик күп укып, үзенең карашларын чарларга өлгергән, җитлеккән, үскән Гафурның да һәм тагы башка егетләрнең дә бурычы иде.

Гафур, эшне озакка сузмыйча, татарлар яшәгән бик күп шәһәрләргә, андагы таныш-белешләренә, «Урал»ны таратуда, аңа хәбәрләр язуда ярдәм күрсәтүләрен үтенеп, үз исеменнән хатлар язды. Икенче көнне үк берничә нөсхә «Вакыт» газетасы сатып алып, дәрестән соң киңәш-табыш итәргә Шәрифулла абзыйларга китте.

Төпчек улы, күз нуры Гыйззәтулла узган елны ерткычларча үтерелгәннән соң Шәрифулла кайгыдан бөтенләй бетерешеп, картаеп киткән. Ләкин ул шулай да атта эшләвеннән файдаланып, оешманың йомышларын намус белән башкара. Ул, күрәсең, шулай үзенең хәсрәтен баса, нахакка үтерелгән кадерле баласы өчен шул рәвештә үч алгандай, канәгатьләнү хисе тоя иде.

Гафур аларга барып кергәндә, хуҗа үзе эштән кайтмаган иде әле. Аны, Шәрифулла кебек үк, бер ел эчендә картаеп бөтенләй әбигә әверелгән Мәһитап апа каршы алды. Кунакны күрү белән тыела алмыйча елап җибәрде. Узган елларда бирелә дус-ишләр белән бергә уздырган чакларны искә төшерде, бәләкәй улының дәртләнеп, янып-көеп, олыларга ярдәм итеп йөрүләрен сөйләп елады. Гафур сәке читендә хатынның сагыш-хәсрәтен сүзсез генә тыңлап утырды.

Озакламый хуҗа үзе дә кайтты. Аның ишегалдында атын тугарып, камыт-дуга, ыңгырчаклар күтәреп, бәрелә-сугыла өйалдына кергәне ишетелде. Шәрифулла абзыйның сакал-мыек ап-ак иде инде. Ул өйгә керү белән кунакны абайлады, танып та өлгерде.

— Сөбханалла, Гафур учитель килгән ич! Нәрсә, бер-бер важный эш бармы әллә? Исәнме?

— Исән-саумы? Бар шул, Шәрифулла абый, бик важный хәбәр алып килдем.

— Әйдә ашыңны сос,— диде Шәрифулла хатынына, чишенеп комганнан юына башлап.— Аш янында сөйләшербез.

Алар бераздан сәкегә утырып, токмачлы аш чөмерә-чөмерә сүз башладылар.

— Алай икән, — диде Шәрифулла, Хөсәеннең хәзер Оренбурда татар телендә газета чыгарырга җыенганлыгын белеп.— Инде безгә нинди эш кала? Без нишлик?

— Безгә инде, Шәрифулла абый, шул газетаны эшчеләр арасында тарату бурычы кала. Аннан Казан хәбәрләрен җыеп язып торырга да кирәк булыр.

— Нигә, эшлибез аны, гәзитен таратырбыз, хәбәрен җыярбыз, син килештереп язарсың, алла боерса, — диде Шәрифулла. Аннан авыр итеп көрсенеп куйды. — Ах, асыл егетләрне вәйран иттеләр, муеннары асларына килгереләр. Никадәр арысландайларны кырдылар, ничәмә иргегетне кулга алдылар.

— Шулай инде, — диде Гафур уйчанланып, — тик аңа карап елап утырып булмас бит, Шәрифулла абый. Булышырлык та, газета укырлык та кеше табарбыз.

— Анысы шулай, Гафур туган, яшьләр үсеп тора, берсен япсалар, икесе, олылардан гыйбрәт алып, киткәнс урынына басарга тора.

Гафур куен кесәсеннән бер пачка газета тартып чыгарды.

— Менә шуның соңгы битен ачып кара әле, Шәрифулла абый.

Карт, тәрәзә төбендә яткан күзлеген киеп, газета актара башлады.

— Өстимме аш? — диде карчыгы.

— Юк, булды, карыным туйды, — диде Шәрифулла. — Менә шулдыр инде ул, бик зур итеп «Урал» дип язып куйганнар.

— Шул, Шәрифулла абый. Анда игълан басылган, газетага язылу шартлары. Менә шул игъланны мөмкин кадәр күбрәк эшче укысын иде. Аңласыннар, бу тегенди-мондый, без моңарчы күргән газета түгел, бу эшчеләр мәнфәгатен яклый торган, үзебезнең телдә чыга торган бердәнбер газета. Инде тагы бер җыелып утырасы иде бит.

Шәрифулла мәгънәле генә итеп Гафурга карап алды.

— Анау чакларны искә төшерепме?

— Әлбәттә, — диде Гафур. — Яшьләр белән яңа газета турында сөйләшеп утырасы килә. Мин аларга Хөсәеннең миңа язган хатын да укып чыгарга уйлыйм.

— Кайда? — дип сорады Шәрифулла.

Бу сорауга җавапны ансат кына биреп булмый иде. Бер ел эчендә хәлләр бик нык үзгәрде. Фиргавеннәр хәзер котыруның аргы ягына чыктылар.

— Кайда мәслихәт соң, синеңчә? — диде Гафур, һаман уйланып.

Шәрифулла бераз тынып торды да:

— Әйдә, булмаса үзебездә, менә монда,— диде.— Гыйззәтулламның елы тулды бит инде.

Гафур үтерелгән улын искә алуның Шәрифулла өчен ни дәрәҗәдә авыр икәнлеген аңлый иде. Ул көрсенеп баш иде, ризалыгын белгертте.

— Кайчанга? — дип сорады карт ничектер кырыс бер кыяфәттә.

— Мөмкин кадәр тизрәк, озакка сузып булмый. Берсекөнгә. Мәслихәтме?

— Юк, булмый, — диде Шәрифулла кырт кисеп, — хәбәр итеп өлгерә алмыйбыз. Җомга көнгә!

— Булды. Мин риза.

— Ниндирәк кешеләрне чакырабыз инде?

— Иң беренче чиратта, элеккеге таныш-белешләрне. Инде алар янына ышанычлы яңа иптәшләрне дә китерергә кирәк булыр. Бер-берсен белә бит эшче агайне.

Алар шулай сөйләшеп аерылыштылар. Янә өч көн үтеп дүртенче көн киткәч, кичке алтыга барып җитү өчен ашыгып, Гафур Бишбалта ягына Шәрифулла абзыйларга юнәлде.

Узган өч көндә дә ул тик ятмады. Казан газеталары өчен язган мәкаләсен тагы да көчәйтебрәк, бәлки «Урал»га кирәк булыр дип, төзәтеп чыкты. Үзе белән бергә эшләүче укытучы, мәсләктәше Гыйльман Мостафин белән сөйләшеп, Алафузов заводындагы яңалыкларны теркәп бер хәбәр рәвешендә «Урал»га җибәреп торуын үтенде. Үзе Казан мәдрәсәләрендәге яңалыкларны һәм Пороховой заводы хәлләрен күзәтеп баруны өстенә алды. Ниһаять, әле Мәскәүдә укып яткан Фатих Әмирханга хат язды. Алардан «Урал»га төрлечә ярдәм күрсәтүен үтенде. Шул эшләрне башкарган арада сөйләшенгән җомга көн килеп тә җитте.

Шәрифуллалар өенә якынлашкач, ишегалдындагы халыкны күреп Гафур хәйран калды. Аларның кайберсе тәгаен яңа гына сменадан кайткан һәм өенә кереп чыгарга да өлгермәгән әле. Менә хәзер «мулла» килгәнен көтеп тәмәке көйрәтәләр. Гафур, егетләрнең һәрберсе белән исәнләшеп чыккач, өй эченә узды. Аны түр якка чакырдылар. Анда идәнгә җәелгән киездә зур ашъяулык һәм савыт-саба, чәй кирәк-яраклары куелган иде.

— Керә башласыннар, бик озакка сузмабыз, Шәрифулла абый,— диде Гафур.

Килгән кешеләр табын тирәсенә урнаштылар.

Гафур башта игъланны укып чыкты, аннан Хөсәеннең хатын укырга керешге. Килгән эшчеләрнең күпчелеге Хөсәенне күреп яисә ишетеп белә иде. Тын калып, бирелеп тыңладылар. Гафур укыган арада күз кырые белән генә үзен тыңлап утырган кешеләрне күзәтте. Аларның кайберсе таныш, күз күргән кеше. Ләкин шулай да күпчелек яңа буын, яшь буын вәкиле. Алар арасында, күренеп тора, авылдан әле күптән түгел генә килгәннәре дә бар. «Әйе, боларына әле мондагы сүз сәеррәк яңгырый торгандыр. Ә менә теге кеше кем соң? Шундый интеллигент йөз, ә өстендә гади эшче киеме».

Ул кешегә Гафур кергәч тә игътибар иткән иде инде. Бая сорашырга өлгермәде. Тик шулай да сәер. Кем икән ул? Үзе болай таныш та кебек.

Гафур укуын дәвам иттерде. Хат укылгач, башта хатта язылганнарны шәрехләп үзе сөйләде, аннан сорауларга җавап бирә башлады. Гафур игътибар итте: теге интеллигент йөзле кеше бернинди сорау бирмичә тын гына утыруында булды. Сораулар беткәч, Гафур үзе сораша башлады. Чират җиткәч, теге кешегә дә мөрәҗәгать итте:

— Гафу итегез, туган, сезне мин ничектер таныгандай итәм. Сезнең исемегез кем әле?

Әлеге кеше борчулы, өметсез караган күзләрен Гафурга текәп, тыныч кына җавап бирде:

— Җәгъфәр.

Гафур аны тиз генә хәтерли алмады.

— Минем сезнең белән сөйләшәсем бар, бергә кайтырбыз,— диде.

— Яхшы, — диде Җәгъфәр һәм сүзендә торды. Гафур хуҗалар белән саубуллашып өйдән чыкканда, ул аны көтеп капка төбендә тора иде.

— Сезнең юл кайсы якка? — дип сорады Гафур.

— Ә миңа барыбер.

— Алайса, сез мине бераз озата барыгыз. Болайга киттек.

Гафурның ниятләре бик изге иде. Ул бу егеткә шактый җаваплы бер йомыш кушарга җыенган иде. Ләкин, текәлеп йөзенә тагы бер карагач, аның хәтеренә Хөсәен әйткәннәр төште. Ул элекке дусларыннан берсенең соңыннан хаин булып чыгуы турында сөйләгән иде. Аның да исеме Җәгъфәр иде түгелме соң?

— Сез исемегезне Җәгъфәр дидегезме әле? — дип сорады ул.

Җәгъфәр башын аска иебрәк баруында булды.

— Әйе.

— Сез Хөсәен Ямашевны күреп белми идегезме?

— Нигә белмәскә, без хәтта аның белән дуслар да идек. Прокламацияләр бастык.

Гафур сискәнеп, кара күзләрен капылт кына зур итеп ачкан хәлдә, Җәгъфәргә текәлде.

— Сез, димәк, Хөсәенгә каршы чыккан Җәгъфәр буласыз, алайса? Сез безне сатмассызмы соң?

— Минем моңарчы беркемне дә сатканым булмады, миңа юк бәлаләр такмагыз, әфәндем.

Гафур бөтенләй тукталып ук калды.

— Дөресен әйтегез, сезне охранка җибәрдеме?

— Сез бик беркатлы, Гафур әфәнде. Сез мине якыннан белмәгән хәлдә дә кем икәнлегемне чамаладыгыз. Охранкада җүләрләр утырмый бит, нишләп андый даны чыккан кешене сезнең арага җибәрсеннәр?

— Ни өчен килдегез соң безнең мәҗлескә?

— Минем яңа газетаның юнәлешен, максатларын беләсем килде. Бәлки Хөсәенгә минем ярдәмем ярап китәр.

Гафур, Хөсәеннең бу кеше турында сөйләгәннәрен кинәт тулысынча хәтерләп:

— Карагыз әле, безгә, Хөсәеннең дусларына, сезнең, семья арасын бозу теләгеннән чыгып, провокацион хатлар язуыгыз мәгълүм, — диде.

Җәгъфәр Гафурны кискен рәвештә бүлдерде.

— Хатлар түгел, бер хат.

— Бер хат? Бер хат җитмәгәнмени?

— Ул хат бөтенләй башка нәрсәгә бәйләнгән.

— Карагыз аны, мин сезнең кем икәнлегегезне беләм, эшчеләр дә тиздән беләчәк.

— Юк, сез алай итмәячәксез. Сез аңлагыз, мин күп саташу-адашулардан соң яңадан элекке мәсләгемә кайттым. Мин бай хатынымны таш-

ладым, үз иркем белән заводка кара эшче булып урнаштым. Сездә әгәр әз генә булса да инсаният бар икән, сез алай эшләмәячәксез. Сез мине сынагыз, сынагыз, Гафур иптәш, аннан әйтерсез.

Гафур ни әйтергә дә белмәстән бераз тынып торды да, Җәгъфәрдән аерылып, кызу адымнар белән үз юлына китте.

## 7

Галиәсгар Камал, көлемсерәп һәм кара бәрхеттәй күзләрен җемелдәтеп, әйтте:

— Хөсәенгә мең кәррә афәрин. Теләгенә ирешкән, газетасы озын гомерле булсын!..

Ул «Вакыт» газетасын иплэп кенә язу өстәленә куйды да җитди тон белән:

— Без барыбыз да билгеле бер дәрәҗәдә Хөсәен әфәнденең йогынтысын тойган кешеләр,— дип сөйләп китте.— Без аның үзенә шәхсән дә бурычлы, ә инде шундый юнәлештәге газета оештырган өчен тагы бер тапкыр бурычлыбыз. — Аннары Гафурга карап әйтте: — Без аңа әлбәттә ярдәм итәчәкбез.

— Мәсәлән, сез нәрсә эшли алыр идегез? — диде Гафур.

— Иң беренче нәүбәттә, мин газетаны һәм газета приложениеләрен «Мәгариф»тә теттереп сата алам. Шул ярдәм түгелмени?

— Бик зур ярдәм. Аларның хәзер беренче брошюрасы Фатих Кәримими матбагасында басылып ята. Ничек әле исеме? Әйе, Самойловичның «Эшчеләрнең котылуы үзләренең эше булырга тиеш». Гали тәрҗемәсендә.

— Гали? Кем соң ул Гали?

Гафурның йөзенә хәйләле елмаю билгеләре чыкты.

— Белмисезме? Ул үзе инде, Гали батыр булырга тиеш.

— Ә алай икән, — диде Галиәсгар. — Бик яхшы. Мин хат язармын. Чыгу белән миңа җибәрсеннәр ул «Эшчеләрнең... үз эше»н.

— Сез Хөсәенгә хат язмагыз. Ул эшнең сезгә уңайсызлыклар китерүе бар. Мин сезгә арадаш булырмын. Саклану яхшы.

— Анысы дөрес,— диде Галиәсгар килешеп,— бу мәлгунь сатраплар көннән-көн камытны кыса баралар. Менә шулай, Гафур дус. «Мәгариф» көтепханәсенә ким дигәндә бер ике-өч йөз данә җибәрсеннәр. Без аны ничек тә таратырбыз.

Ул кинәт урыныннан торды да житез-житез атлап китап шкафына таба китте. Шкаф өстендә көпшәләп төрелгән кәгазь өеме ята иде. Шуларның берсен алды да Гафурга таба борылып сүтеп җибәрде.

— Күрәсезме?

Бу спектакль афишасы булып чыкты. Гафурның күзләре колач буе кәгазь табагының нәкъ уртасына язылган «Бәхетсез бала» дигән сүзләргә төште. Ул, күзләрен кыса төшеп, сәерсенеп чак кына елмайган хәлдә, укый башлады: — Фәлән-фәлән көнне (әле числосы аныкланмаган иде) приказчиклар клубында һәвәскәр артистлар көче белән «Бәхетсез бала» исемле спектакль куелачак.

— Казанда беренче тапкыр татарча публичный спектакль, — диде Галиәсгар. Аның шатлыгы, горурлыгы йөзенә чыккан иде.

— Бик зур тарихи вакыйга,— диде Гафур,— котлы, мөбарәк булсын! Димәк, куелуы анык инде.

— Күрәсез бит, афишалар язарга керештем инде, димәк, иман камил.

— Үзегез язасыз? Сез художник та икән әле, Галиәсгар әфәнде.

— Барысы да булырга туры килә: автор да, режиссер да, актер да, антрепренер да, рәссам да, афиша язучы да. Инде спектакль куелган

көндә чукмар тотып вышибала вазифасын да башкарырга туры килмәгәе дип торам әле.

Ул үзенең кеткелдәп көлүе белән бөтен бүлмә эчен яңгыратып алды.

— Алдан ук белеп торам. Печән базары әһелләре спектакльне өзәргә тырышачаклар,— диде ул, кинәт җитдиләнеп. Азмыни ул Хафизлар анда! Килегез спектакльгә, һәрхәлдә, декабрь урталарында булыр.

— Килми калмам. Берүзем генә дә түгел, туган-тумачаны, дус-ишне ияртеп. Ә спектакльне өзәргә бирмәбез!

Галиәсгар хәтфә кара күзләрен тутырып сынаулы караш белән Гафурга текәлде.

— Шундый ышанычыгыз бармы? Рәхмәт...

## 8

Хөсәен газета чыгаруга вәгъдә ителгән рөхсәт кәгазен сорап губернатор сараена ике тапкыр барды инде, ләкин ниндидер сәбәпләр аркасында һаман берни әйтми киләләр. Күрәсең, Петербург суза.

Моның ахыры начар булып бетүе дә мөмкин иде. Уен түгел, нидер сизенүләре бар. Провокаторларга, җасусларга, филерларга көннән-көн юл киңрәк ачыла бара бит. Бәлки Хәдичә, каушау аркасында, губернаторны ялгыш аңлагандыр, ә мин барлык дус-ишкә «рөхсәт бирелде» дип хәбәр җибәрдем, дигән хафага төште ул.

Күп эшләр башкарылды: «Американская» дип аталган кунакханәдән редакция өчен бер номер арендага алынды, әле моңарчы «Вакыт»та эшләп килгән тәҗрибәле бер корректор «Урал»га күчәргә ризалык бирде. Кәгазь җитәрлек булдырылды, Кәримовлар типографиясе белән договор төзелде... Кыскасы, газета чыгаруга барысы да әзер иде инде. Халыктан газета файдасына иганә җыюны оештырып җибәределәр. Хөсәен хәзер иртәдән кичкә кадәр газета белән мәшгуль. Иртәнге якта китеп көндезге берләргә генә өйгә кайта, анда да ашап-эчү белән, ялсызнисез, яңадан язу-сызуга керешә. Ә инде кичке биштә тагы редакциягә ашыга, аннан төн урталарында гына кайтып ава.

Уральскидан кайтып кергәндә Хөсәен Хәдичәгә шактый көр, таза булып күренгән иде. Ике-өч көн эчендә егетең суырылып калды, күз төпләре күгәреп чыкты, ютәле ешайды. Аны, әлбәттә, эш кенә изми иде, инде барысы да булды дигәндә, ниндидер билгесез сәбәпләр аркасында, менә шулай газетага рөхсәтнең тоткарлануы, эшнең төртелеп калуы аны тәмам чыгырыннан чыгарды.

Хөсәен үзенә йөкләнгән җаваплылыкның никадәр зур икәнлеген аңлап эш итте. Һәм шуңа күрә дә бу хәлне аерата авыр кичерде. Ул берничә тапкыр РСДРПның Оренбур оешмасы членнары белән киңәште. Губернаторның хөрмәтенә лаеклы, ниндидер бер бай либерал табарга киңәш иттеләр, әгәр дә ул губернаторга бу турыда ымласа, мәсьәлә тиз хәл кылыныр бәлки, диделәр, рөхсәт булмаган тәкъдирдә дә губернатор эшнең хикмәтен, серен аңа сиздерми калмас. Шуннан калганы мәгълүм булыр, диделәр. Ул арада редакциягә Казаннан, Уфадан, Әстерханнан һәм башка урыннардан хатлар да килә башлады. Аларга җавап язарга кирәк, ә инде игътибарга лаеклы хәбәрләр булса, шунда ук аларны газета өчен эшкәртергә дә вакыт. Казаннан Гафур үзенең эшләре турында яза, Хөсәенне тәбрик итә, шатлыгы белән уртаклаша. Әйе, ул шактый эшләр майтарып ташлаган икән. Уфадан килгән хатлар арасында берсе Мәҗит Гафуридан иде. Шулай ук ул да үзенең булдыра алган ярдәмен күрсәтергә сүз бирә, тәбрик итә. Ләкин менә Оренбур губернаторлыгыннан гына берничи дә хәбәр-хәтер юк.

Хөсәен, Галимҗан һәм Хәдичә, озак баш ватканнан соң, алтын прискалары хуҗасы бай Закир Рәмиевкә мөрәҗәгать итәргә булдылар. Бу тәкъдимне Галимҗан ясады.

— Либерал, бик әдәпле кеше, заманында үзе дә газета чыгарырга рөхсәт ала алмыйча интеккән, әдәбиятка гашыйк кеше, — диде.

— Шулай инде, юкса, «Вакыт»ның нашире булмас иде. Тик ул хәзер биредә микән? Рәмиевләрнең бит Орскида да өйләре бар бугай.

— Менә бөтен хикмәт тә шунда шул, ул хәзер биредә. Белмим, озакка мы, юкмы, ләкин миңа аның монда икәнлеген анык әйттеләр.

Хөсәен аягүрә басты да кискен рәвештә өстәлгә учы белән сукты.

— Булды! Бүген үк барам!

...Хөсәенне Закир Рәмиев үзе каршы алды. Ул калын гәүдәле, мәһабәт, күрер күзгә иллеләргә якынлашып килә торган бер ага иде. Кыска гына итеп калдырылган куе кара сакал аның тулы йөзен ике яктан да әйләндереп алган, калын мыегының бөтеренке чылгыйлары йөзен ничектер кырыс, рак итеп күрсәтә. Хөсәен, алгы бүлмәдә чишенеп, хуҗа артыннан, затлы мебельләр белән тулган берничә бүлмә аша хуҗаның эш кабинетына узды.

— Рәхим итегез, утырыгыз, — диде Рәмиев. Хөсәенгә күн тышлы зур, йомшак кәнәфи тәкъдим итте, үзе исә камыштан үрелгән, култыксалы җиңел утыргычын кәнәфи каршысына куеп, шуңа утырды. Сүз башланды. Закир артык туарылмыйча, сабыр, салмак тонда сөйләшә.

— Миңа сезнең Оренбургка килүегез турында әйткәннәр иде, — диде ул. — Мин сезне, килеп чыгар дип, күңелем белән көткән дә идем. Менә юравым раска чыкты. Миңа Фатих әфәнде, безнең хөрмәтле мөхәрриребез, барысын да бәян кылды. Сез татар телендә безнең шәһәрдә яңа газета чыгарырга җыенасыз икән.

— Әйе, Закир әфәнде, шул минем хәзерге мәшгулиятем.

— Исеме ничек?

— «Урал».

Закир бераз уйланып торды. Аннан:

— Бик әйбәт, — диде, — битараф, «беспартийный» исем. Әлбәттә, әгәр сез аны «Пролетарий» яхут «Большевик» дип атаган булсагыз, без, Фатих әфәнде белән, сезгә бернинди дә ярдәм күрсәтә алмаган булыр идек. Газетаның юнәлешен, ниләр язачагын без белеп торабыз. Әйе, әйе. Чөнки Хөсәен Ямашев әфәнденең нинди кыйблага сәҗдә итүе турында күптән хәбәрдарбыз. Тик шулай булса да без сезгә булдыра алган ярдәмне күрсәтергә теләдек. Рәхим итегез, газетагызны безнең матбагада бастырыгыз. Әгәр газетаның тагы кушымталары чыгачак икән, анысын да — шулай ук бездә.

— Рәхмәт, — диде Хөсәен, — рәхмәт, Закир әфәнде. Мин башкача булыр дип уйламаган да идем.

Закир Рәмиев алтын сәгать чылбырын селкетеп алгарак иелде дә елмая төшеп:

— Ни сәбәп соң моңа? Мин сезнең каршыгызда шундый ышанычлы үз кешемени? Мин бит — капиталист, бай. Әллә тышкы кыяфәтем белән мин пролетарий вәкиленә биңзиме?

Хөсәен көлемсери төшеп:

— Юк, сез һич пролетарий вәкиленә охшамагансыз, Закир әфәнде, — диде. — Ләкин мин сезнең нашир икәнлегегезне, газета-журналларга мөкиббән бер кеше икәнегезне беләм. Димәк, сез миңа коллега бу җәһәттән. Ә коллегалар һәр вакыт бер-берен хөрмәт итәргә тиеш. Мин Хөсәеневләрнең бусагасын да атлап кермәс идем. Ә сез...

Закир иркенләп көлә башлады. Аннан һаман әле йөзендәге елмаюын җуймаган хәлдә:

— Сез, Хөсәен әфәнде, ифрат дәрәҗәдә оста дипломат икәнсез,— диде. — Аптырап кала торганнардан түгел. Ә инде мин сезгә, большевикка, ярдәм итәргә телим икән, аның сәбәбе, әлбәттә, безнең коллегалар булуыбыз аркасында гына түгел. Безне берләштерә торган уртак бурычлар мине сезгә ярдәм күрсәтергә мәҗбүр итә. Боларның беренчесе — сезнең татар телендә газета чыгарып, татар баласы өчен тырышуыгыз, ә икенчесе — без фәкыйрегез өнәмәгән рус патшасына каршы күтәрелүегез. Иң мөһиме шулар. Ә хакимият өчен көрәш — анысы аның киләчәк эше. Анда күз күрер әле. Әйе, әйе.

— Әлбәттә, анда күз күрер, — диде Хөсәен, — һәркемнең үз карашы булуы ихтимал. Мин сезгә, Зәкир әфәнде, бер үтенеч белән килдем.

Рәмиевнең йөзе уйчанланды, күрәсең, ул нидер исәпли иде.

— Акчамы? — диде ул, ниһаять. — Мин анысын да ишеттем. Сез халыктан иганә җыясыз икән. Ләкин мин сезнең газетага әллә ни күп бирә алмыйм.

— Анысына да рәхмәт, — диде Хөсәен. — Ләкин тагы бер үтенеч бар.

Ул үзенең бүгенге борчуларын сөйләп бирде дә: — Сез генә ярдәм итсәгез итәсез, чөнки сез минем хәлемне аңлыйсыз һәм сезнең сүзегез үтемле, — диде.

— Яхшы, — диде Рәмиев, уйлануын үзенең акыллы коңгырт күзләрендә чагылдырып, — мин сезгә бу эштә дә ярдәм итәрмен. Һәрхәлдә, кирәкле чиннар белән сезнең газетага рөхсәт мәсьәләсен хәл итү турында сөйләшермен.— Закир сүздән тукталып имән бармагын өскә күтәрде: — Әлбәттә, әгәр сезнең ниятләрегезне алдан ук сизенеп эш итмәгән булсалар... Ә газетагызның нашире — Тимерша әфәнде инде,— диде Закир, сүзне икенчегә күчереп.

— Әйе, Тимерша әфәнде.

— Ул алынып, алынып... Ә мөхәррире сез үзегез, шулаймы?

— Юк, мин түгел, минем җәмәгатем.

Рәмиевнең тулы йөзенә тагы кәефләнеп елмаю билгеләре чыкты.

— Шулайдыр, шулай, башкача булуы мөмкин дә түгел.

Өч көннән соң Тимерша Соловьев губернатор канцеляриясеннән газета чыгарырга рәсми рөхсәт алып кайтты.

Хөсәен ул көнне өйгә кайтып керү белән Хәдичәне кочаклап алды һәм, күзләрен йомган килеш елмаеп, аны күкрәгенә кысып торды. Хәдичә эшнең уңай хәл кылынуын шунда ук төшенде. Шыпырт кына:

— Булдымы? — дип сорады.

— Булды, — диде Хөсәен, якты шат күзләрен бердән ачып. — Тимерша алып кайтты. Просто канцелярский бюрократиягә кереп баткан икән.

— Закир әфәндегә рәхмәт әйтергә кирәк.

— Ул әле алар белән сөйләшергә дә өлгермәгән.

— Димәк, хәзер газета чынлап торып чыгачак? — диде Хәдичә. — Тәбрик итәм, кадерлем. — Ул кулларын Хөсәеннең иңенә салды. Кинәт ишек шакыдылар. Хөсәен читкә китте, Хәдичә өстәлгә кулындагы ашъяулыкны җәяргә керешә. Ишекне тагы бер тапкыр шакыдылар.

— Рәхим итегез.

Ишектә өй хуҗасы Анисифа Петровна күренде. Ул Хөсәенгә пакет сузды.

— Менә, сезнең газетагызга килгән, бер малай китерде.

Конвертка «Х. Ямашевның үзенә генә» дип язылган иде. Күрәсең, шуңа күрә экспедитор китергәндер инде, дип уйланды Хөсәен.

— Кемнән ул, нинди хат? — дип сорады Хәдичә.

— Хәзер әйтермен, — Хөсәен, игътибарын җигеп, бик таныш кул белән язылган адресны укый башлады. Кем җибәргәнлеге конвертка языл-

маган иде. Хөсәен тиз генә конвертны ачты да, хатны чыгарып, аның соңгы юлларына күз ташлады. Йөзе үзгәреп китте. Хәдичә куркынып аңа текәлде.

— Ни булды? Кемнән?

— Кабахәт, — диде Хөсәен, ничектер хәлсезләнеп утыргычка чүкте.— Тагы башлана.

— Нәрсә башлана? Кемнән ул хат? — диде Хәдичә, тәкатьсез калып.

— Хат сиңе «бик хөрмәт итүче» кешедән. Җәгъфәрдән...

— Әстәгъфирулла! Ул дөньяда микәнни әле?..

— Менә укыйк әле язганын, нинди ысуллар кулланып агуын канга җибәрмәкче була икән.

Хөсәен хатның беренче битен әйләндерде дә искитмәүчәнрәк бер тон белән укый башлады.

«Мөхтәрәм Хөсәен дус!

Син бу хатны алу белән, язуымнан мине танып нәфрәтләнү аркасында, тынычлыгыңны җуйгансыңдыр. Мин шулай буласын белгән хәлдә дә сиңа ошбу мәктүпне җибәрергә мәҗбүрмен. Ни өчен язам мин бу хатны? Мин бит синең бер генә сүземә дә зәррә кадәр дә ышанмавыңны, мине җасус, сатлык җан, ренегат дип кенә уйлавыңны ачык беләм ләбаса. Әмма миңа бу эшне башкарырга намусым куша. Мин синең бу хатны ничек каршы алачагыңны юрап белсәм дә язам. Чөнки син минем өчен бердәнбер илаһи, саф вә гали җан. Юк, уйлама, мин бу сүзләрне сиңа ярар өчен язмыйм. Мин синең гамәлеңне беренче адымнарыңнан ук күзалдымнан кичерү вә анда бер генә кара тап та күрмәү нәтиҗәсендә язам. Синдәйләр миндә инсаниятнең язмышына карата ышаныч тудыра. Шуңа күрә мин, тирә-ягымда вәхшәт, гаделсезлек, җаһиллек вә пычраклыкны күргән хәлдә дә, күңел төшенкелегенә бирелмәскә кирәклеген аңладым. Рәхмәт сиңа, Хөсәен. Мин кичә синең дошманың идем, ләкин мин бүген синең дустың. Билгеле, мин элек тә синең дустың идем. Һәрхәлдә, мин үземне сиңа карата дус кеше дип исәпли идем. Ләкин ул дуслык беркатлы, сай дуслык булган икән. Дус булып уйнау, кешегә тәкълид итүдән туган дуслык кына. Чөнки мин ул чакта бик яшь идем шул. Бәлки җисми түгелдер, әмма рухи бик яшь идем. Аннан соң мин эзләнү дәверенә аяк бастым. Бик каты ялгышуларга мөбтәлә булдым. Зур ахмаклыклар ясадым. Тәмам бетә язып калдым. Ләкин мең шөкер язмышыма, бу рус революциясе еллары безне бик күп уйланырга, күп гыйбрәтле хәлләр күрергә мәҗбүр итте. Безнең кеннәрнең һәр ае бер елга торырлык бит, Хөсәен. Менә мин дә җитлектем, тәмам үсеп җиттем. Чөнки мин сине күрдем. Юк, юк, элеккечә түгел, яңача күрдем мин сине, Хөсәен. Синең аша мин бөтен дөньяны күрдем. Менә шул, Хөсәен.

Мин хәзер ялгыз гына яшим. Пычракта, авыр эштә, Алафузов заводында эшлим. Эшчеләр казармасында торам. Кешеләр күргән барлык җәфаны түземлек белән кичерәм. Мин синең газета чыгарырга җыенуыңны күптән белә идем инде. Моңа ирешкәнсең икән. Афәрин! Сиңа мин бу эштә булдыра алган ярдәмнең барысын да эшләрмен. Син аны тиздән үзең дә күрерсең.

Сәламәт бул, кадерле туган. Сиңа ихлас күңелемнән сәламнәр күндерәм. Хәдичә ханымга да миннән күп сәламнәр тапшыр. Теге вакыттагы ахмак эшем өчен аннан да, синнән дә гафу үтенәм. Әлбәттә, синнән хат өмет итмим. Болай да синең вакытың чамалыдыр. Җәгъфәр».

Хөсәен хатны укып чыкты да тынып уйга калды. «Бу нәрсә бу, бик оста итеп яңа тозак корумы, әллә башка берәр хәлме?».

Хатны комод өстенә ташлады да аш алдыннан кулын юарга кухняга чыгып китте. Анда Анфиса Петровна плитә янында маташа иде.

— Әйбәт хатмы, Хөсәен Мингазетдинович? — дип каршылады ул.

Хөсәен көлемсерәде дә:

— Әйбәт булсын иде инде, — диде.
— Нигә, укымадыгызмыни әле?
Хөсәен кулына сабын тоткан килеш тынып торды.
— Укыдым мин аны, Анфиса Петровна, ләкин юньләп берни дә аңлый алмадым.

Анфиса Петровна җилкәсен җыерып куйды да Хөсәен юынган арада рождество бәйрәме турында һәм Оренбурның өр-яңа хәбәрләрен сөйләргә кереште.

Әйбәт квартирга туры килделәр Хөсәеннәр. Кып-кыска арада хуҗабикә белән туганнарча якынаеп беттеләр.

Хөсәен аш вакытында, табышмак хатны бөтенләй күңеленнән чыгарып ташлагандай, сүзне менә борын төбендә генә торган бәйрәмнән башлады.

— Без синең белән, Хәдичәкәй, газетаның беренче саны чыгуын билгеләргә тиеш.

— Әйбәт табын әзерләргә мөмкинлегебез бармы соң безнең, Хөсәен?
— Юк, Хәдичәкәй, безгә расходны бик нык кысарга туры киләчәк.
— Шулай булгач, нинди мәҗлесләр җыю турында сүз алып барып була?
— Ә бәлки без бергәләп... Тимершалар белән, Шакир абыйлар белән?.. — диде Хөсәен, Хәдичәгә сорау белән текәлеп.

Хөсәеннәргә бу турыда күп баш ватарга туры килмәде. Өч көн вакыт үтәр-үтмәс, Шакир Мөхәммәдовлардан чакыру кәгазе килде. Анда «Карчыга» журналының мөхәррире һәм нашире булган язучы — Хөсәенне, хатыны Хәдичә белән, «Танышу вә шәһәребездә яңа газета чыгу мөнәсәбәте белән» оештырылачак мәҗлескә кунакка чакырганнар иде.

Русларның шау-шулы Рождество бәйрәмнәре узган иде инде. Җиденче елның башы, «Урал» газетасының беренче номеры җыелып версткага төшерелгән чак. Күңел күтәренке, күңел коштай җиллепә.

— Менә, — диде Хөсәен, язуны укып чыккач тешләрен җемелдәтеп, — бик изге минутта теләгәнбез икән бер утырышу турында.

Хөсәен дә, Хәдичә дә бу чакырылуга бик шат иделәр. Чөнки аларның Оренбур кешеләре белән мәҗлестәш буларак та танышасылары килә иде. Ә Шакир Мөхәммәдов инде, әгәр табынга Хөсәеннәрне дә чакырган икән, димәк, кунаклары — Хөсәен ишләре, һәрхәлдә, алдынгы кешеләр булырга тиеш. Газетага әйбәт материал тупланды. Баш мәкаләне Хөсәен күптән язып куйган иде инде. Оренбур хәбәрләрен дә Галимҗан әзерләп тиешле тәртипкә китерде. Икенче Думага сайлауларга хәзерлек турында газетаның карашын чагылдырган тәфсилле бер мәкалә язылды. Кыскасы, газетаның беренче саны материалга шактый бай, эчтәлекле, өстәвенә (Хөсәен моныcына аерата зур игътибар бирде) большевистик рухтагы әзлекләлек белән сугарылган иде. Барысы да максатча булды кебек. Алдагы бурычларның хәзер чираттагысы, иң авыры, газета материалын цензура аша һәр даим шома гына, артык кыйналусыз уздыра белү иде. Бусы исә Хөсәенне һаман борчып торды. Чөнки революция китергән цензурасызлык көннәре узып китте. Цензура яңадан үзенең эшен зур тырышлык белән башлады. Мәгълүм булганча, Оренбурның хәзерге баш цензоры либерал булып уйнарга яратса да, тезгенне артык ычкындырырга теләми торган каты куллы, начальствога тугрылыклы бер чиновник иде. Бәхеткә каршы, ул төрки телләрнең берсен дә белми. Аның кул астында эшләүчеләрнең берсе, татар газеталарын тикшереп утыручысы, — руслашкан татар, — отставкадагы полковник Акачуров. Сөйләүләренә караганда, сыйлаганны һәм акча тәрткәнне бик ярата икән. Әлбәттә, әгәр дөрес сүзне укучыга җиткерергә телисең икән, алдагы киртәләрнең һәр җимереген,ватыгын исәпкә алып, файдалана белергә кирәк.

Почтадан газетага язылуның барышын белешеп тордылар. «Урал»ны алдырырга теләүчеләр шактый күренә. Ләкин, кызганычка каршы, аларның күпчелеге бер-ике айга гына язылганнар. Булсын дип уйладылар, монысы да ярап тора, киләчәктә подписчиклар һичшиксез артачак.

...Җомга көнне кичке бишләр тирәсендә Хөсәен белән Хәдичә култыклашып Шакир Мөхәммәдовларга юнәлделәр. Оренбурга килгәч, Хөсәен аларда ике тапкыр булды. Хәдичәнең Шакир Мөхәммәдовлар семьясы белән танышканы юк иде әле. Оренбурда кыш үзенең зәмһәрир суыклары белән барлык гайрәтен күрсәтеп хакимлек итә иде инде. Урамнарны атна-ун көн эчендә кар көртләре басып китте. Җаек белән Сакмар елгалары кушылган яктан ачы җил исә, борынны, иякне, бит очларын чеметтереп ала, җиң, итәк эчләренә һәм чалбар балакларына үтеп керә.

— Абау, бигрәк салкын икән, — диде Хәдичә, урамга чыккач. — Кара, колакларың өшеп төшә бит, колакчынлы бүрегеңне киясең калган, Хөсәен.

— Зарар юк, колак минем хәзер бөтен яңалыкны ишетеп торырга тиеш, аны капларга ярамый, — диде Хөсәен шаяртып.

— Язмыйлар бит Чистайдан, — диде Хәдичә, кинәт пошынып һәм ни өчендер үзенең Чистаен хәтерләп.

— Күңелеңне төшермә, ара якын түгел, — дип тынычландырды аны Хөсәен.

— Кунаклары бик гайбәтчел булмаса ярый инде, минем өстемдәге күлмәгем бик иске модалы.

Хөсәен дәшмәде. Хатыны андый нәрсәләр турында тел күтәрсә, ул дәшми кала яки сүзне икенчегә борырга ашыга иде. Хәлбуки, соңгы вакытларда бу темага әйтелгән сүз еш-еш ишетелә башлады. Ахыры хәерле булсын!

Мәҗлес күңелле узарга тиеш иде. Хөсәен һәм Хәдичә моны Шакир Мөхәммәдовларга барып керү белән һәм инде җыела башлаган кунаклар белән танышкач та аңладылар.

Шакир Мөхәммәдов үзе Буада туып үскән кеше икән. Яшьли ятим калган, ундүрт яше тулар-тулмаста Оренбурга килеп чыккан, байтак вакыт малайлыкта йөргән, зирәклеге аркасында приказчиклыкка үрмәләгән, үзлегеннән укып хисапчы дәрәҗәсенә ирешкән. Бераз эшләгәч, уку теләге белән, ул Мәскәүгә китә. Анда бухгалтерлар курсында укый. Үзе хезмәт иткән рус бае каршында эш сөючәнлеге һәм намуслылыгы аркасында ышаныч казанган. Байның ышанычлысы булып хәтта Харбинда бер ел эшләгән... Аннары яңадан Оренбурга әйләнеп кайткан һәм шактый олыгайгач кына өйләнеп, шушы Оренбурда төпләнеп калган. Хөсәен фәкыйрь гаиләдән чыккан, үзлегеннән укып мөхәррир булу дәрәҗәсенә ирешкән бу сәләтле кешенең әсәрләрен 1901 елларда ук укый башлаган иде. Хәтерендә: аның «Җәһаләт яхут Галиәкбәр агай» исемле повесте аңарда тирән тойгы калдырды. Язучының «Яфрак асты яхут Мәкәрҗә ярминкәсе» дигән әсәрен дә Хөсәен яратып укыган иде. Ләкин Оренбурга килгәнгә кадәр Хөсәеннең бу кешене күргәне булмады. Шакир Мөхәммәдовның хәзер Оренбурда демократик юнәлештәге «Карчыга» исемле сатирик журнал чыгара башлавы аны тагы да якынайта төште. Әлбәттә, әгәр алар арасында бер-берсенә карата тирән хөрмәт булмаса, Шакир Хөсәеннәрне кунакка чакырыр идеме соң?

Күрәсең, ул барысын да аңлаган: Хөсәеннәрнең алдынгы кешеләр белән танышырга теләвен дә, газета чыга башлавын билгеләү кирәклеген дә, хәтта Хөсәеннәрнең кунак җыярлык мөмкинлекләре булмавын да. Рәхмәт аңа.

Хуҗа җыйнак кына гәүдәле, сирәк мыеклы, ябык чырайлы, хәрәкәт-

чән, мәҗлес күрке булырлык мәзәкчел һәм җор телле, җинел сөякле бер кеше иде. Ул кунакларны өстәл тирәсенә утырту белән үк үз авызына каратты. Ә хатыны Сафия шулай ук кечерәк гәүдәле, чибәр, ләкин артык аз сүзле. Ул бик яшь — күрәсең, оялчанлыгы аркасындадыр, сүзгә бик кушылмыйча, кунак сыйлау белән генә мәшгуль иде.

Чакырулы кунаклар җитәрлек булып чыкты. Ак якасына кара бант тагып куйган урта яшьләрдәге озын буйлы, ак чырайлы кешене шәһәребезнең зыялыларыннан, «Вакыт»ка да, «Карчыга»га да язышa торган журналист һәм конторщик Әхмәт Кәбири дип таныштырдылар. Өстенә утырма якалы кәзәки, башына кара хәтфә кәләпүш кигән, тимер кысалы күзлеклесен алдынгы мөгаллимнәребездән Назим Салахов диделәр. Өченчесе «Карчыга» журналының һәвәскәр рәссамы, приказчик Габдулла Мостафин иде. Ул сызылып киткән кара мыеклы, өстендә — кара костюм, кара галстук таккан, кырын салып кигән хәтфә түбәтәйдән. Алар өчесе дә хатыннары белән килгәннәр. Хөсәен кунакларның күпчелеге хуҗаның үзе белән миллионер Хөсәеновларда хезмәт итүче кешеләр икәнен белде. Арада бер яшьрәге генә Петербург студенты иде. Ул политехник институтта укый икән. Хәзергә исә, авыру сәбәпле, Оренбурга ялга кайткан. Куе чәчле, ябык чырайлы, озын буйлы бу егет Әхмәтҗан Дәминев атлы икән. Ул үзенең ярәшкән кызы белән килгән. Хөсәен ирексездән хатын-кызларның бер төрлерәк күлмәк кигәнлекләренә игътибар итте: күпермә иңбашлы, озын бала итәкле. Барысының да башында — энҗеле калфак. Иңбашларында бүртмәле ефәк шәл. Хатыннардан үзенең өс-башы ягыннан студент Дәминев белән килгән Гөлчирә атлы кыз һәм Сөләймановлар гына аерылып торалар иде. Гөлчирәнең башында зур шәмәхә бант, өстендә ак кофта һәм шәмәхә төстәге юбка.

Хөсәеннең Сөләймановларны әле беренче тапкыр гына күрүе. Хәлбуки, Разия ханым турында аның Уфада ук ишеткәне бар иде. Кыз фамилиясе — Котлыярова. Ул Петербургдагы Бестужев курсларының медицина факультетын бетереп, иренең туган шәһәре Оренбурда биш енче елын инде уңышлы эшләүче беренче татар докторы иде. Хөсәенне дә, Хәдичәне дә алар, әлбәттә, бик кызыксындырдылар.

Үзе татар кызы, үзе доктор! Әйтүе генә ансат! Ләкин Разия да, аның ире Рәүф тә, артык кычкырып тормаган европача гади киемнәре кебек, тыйнак, гади, ачык кешеләр булып чыкты. Хөсәен танышу вакытындагы берничә сүздән соң ук моны аңлады. Ул:

— Сез рус интеллигенциясенең югары сфераларында кайнасагыз да, туган телебезне онытмагансыз, — диде.

Разия ханым башта, аптырабрак булса кирәк, соры зур күзләрен киң итеп ачты, аннары ак эре тешләрен күрсәтеп елмаеп куйды.

— Ничек инде Рәүф тә, мин дә телебезне белмичә торып халкыбызга хезмәт итә алыйк. Мәсәлән, врач өчен тел ул кайчак дәвадан да мөһимрәк.

— Бик хак сүз, — диде Хөсәен.

— Без сезнең «Урал»ны дүрт күз белән көтәбез инде, — диде Рәүф өстәп. — «Вакыт»тагы игъланны бик кызыксынып укыдык.

Хуҗа, кунаклар белән таныштырганнан соң, мәҗлестәгеләрнең өстәл тирәсенә утыруларын үтенде.

— Хөрмәт итик, — диде, — Хөсәен әфәнде һәм Хәдичә ханым Уфадан килгән кешеләр. Алар безнең шәһәребезне яратып, сайлап биредә яшәргә күченде. Озакламый, насыйп булса, без кадерле кунакларыбыз чыгарачак «Урал» исемле газета уку бәхетенә ирешербез!

— Беләбез, беләбез, — диеште кунаклар.

Озын өстәл тирәсенә утырыштылар. Озакламый табынга токмачлы тәмле аш китерелде. Шакир кыстап ашаткан арада үзенең башыннан кичкән кызыклы вакыйгалар сөйләргә дә өлгерә иде. Сүз, тәлинкә-кашык тавышларына кушылып, өстәлнең бер очыннан икенчесенә күчеп

йөри башлады. Мөгаллим Назим Салахов Оренбур шәкертләре турында кызыклы гына вакыйгалар сөйләде. Аннары Оренбурдан Казанга әле берничә ай гына элек киткән Сәгыйть Рәмиевне искә алды. Талантлы шагыйрь, юкка безнең шәһәрне ташлап китте дип борчылды.

— Зарар юк, ул Казанда да югалмас. Хәзер «Йолдыз» газетасында эшли, — диде Хөсәен.

Петербургтан кайткан студент Дәминев канлы якшәмбе көннәрендәге вакыйгаларның уртасында диярлек булган икән. Ул шул турыда сөйләп алды. Хөсәен Оренбур турындагы тәэсирләре белән уртаклашты. Газета чыгару мөнәсәбәте белән үзе күргән һәм ишеткән вакыйгалар турында төпченеп сорашты. Аннан Уральскидагы очрашуларын, Габдулла Тукаев белән танышуын хәтерләде. Бусы исә шигърият күгенә кыю рәвештә күтәрелеп барган бер йолдыз турындагы хәбәр булгач, барлык кунакларның игътибарын үзенә тартты. Шулпадан соң табынга зур табак белән итле бәрәңге килде. Аны ашаганнан соң сүзне журналист Әхмәт Кәбири элеп алды. Ул, илдәге тормыш, сәяси, революцион хәрәкәт белән бәйләп, икенче Думага сайлау хәзерлеге турында, беренче Дума вакыйгаларының нечкәлекләре, анда мөселман депутатларының үзләрен тотышын һәм тагы бик күп үзе белгән яңалыкларны әйтергә өлгерде. Сүзгә башкалар да кушыла башлап, гәп кызганнан-кыза барды. Өрек суы эчелгәннән соң әле һаман сүзен дәвам иттергән журналистның хатыны — кара тутлы, тулырак гәүдәле чибәр Зәйнәп ханым — түзмәде, бүлмәне яңгыратып көлде дә:

— И бу ирләр, бергә очрашсалар, шул политикадан башка сүзләре юк, — диде. Ул бераз гына назлана төшеп студент Дәминевкә карап куйды: — Әхмәтҗан! Бирегә килгәндә сезнең кулыгызда мин бер музыка коралы күргән идем, — диде.

— Дөрес, дөрес, — дип элеп алды Шакир. — Җәмәгать, хәзер аш белән чәй арасында сүзне Әхмәтҗанның мандолинасына бирәбез.

Сафия тиз генә алгы бүлмәдән кызыл бантлы елтыр мандолина алып чыкты.

— Ну что ж, — диде Әхмәтҗан, мандолинаны кулында артык исе китмичә генә әйләндергәләп. — Тик өметегезне бик сузмагыз, мин әле өйрәнчек кенә.

Ләкин ул кечелекләнә генә иде. Беренче аккордларны яңгырату белән үк аның әйбәт уйнаячагын белделәр. Бераздан бөтен өй эчен гүзәл көй авазлары биләп алды. Чын мәгънәсендә артист, виртуоз иде бу Дәминев.

— Йа, хозурлыклар! — диде Назим мөгаллим. Тамак кырып Әхмәтҗанга дәште: — Мөмкин булса, яңадан башлагызчы.

Аның ни эшләргә җыенуын аңлаган хатыны, сары чәчле, ак йөзле Нәфисә ханым, оялчан гына елмаеп һәм рәнҗи төшеп, иренә тәнбиһ белән күз ташлады.

— Әгәр кәҗә тавышлары чыккаласа, гафу итәрсез инде, — диде мөгаллим. Ул мандолинага җыры туры килсен өчен чак кына көтте дә көр баритон тавыш белән кычкырып җырлап та җибәрде. Юк, бу башкаручы да кәҗә тавышлары турында тыйнаклык күрсәтеп кенә сөйләнә иде. Ул бераз вакыт ялгыз җырлаганнан соң, аңа хатын-кызлардан журналист Әхмәт Кәбиринең хатыны Зәйнәп кушылды. Бераздан башкалар да җырга иярделәр.

Җыр бөтен нәрсәне оныттырды. Моң, рәхәтлек тудырып, күңелнең нечкә, тибрәнчек урыннарын бер-бер артлы килгән рәхәт җылы дулкыннардай сыйпый, иркәли башлады. Бер җырдан соң икенчесенә күчтеләр. Ял итеп алдылар. Тагы җыр яңгырады. Рәхәт иде музыка дөньясында яшәү. Мондый иркенләп җырларга ярый торган урыннар аз бит әле татар дөньясында!

Бераздан жыр тукталып, өй эче тынып калгач, Шакир Хөсәенгә мөрәҗәгать итте:

— Хөсәен дус, бии беләсезме?

— Нигә, бии белмәсәм дә, бүгенге мәҗлес хөрмәтенә биеп карарга була,— диде ул елмаеп.

Хөсәен бик яхшы итеп декламация укый белә иде. Хәтта аның татар, рус кына түгел, француз, немец һәм инглиз телләрендә язылган шигырьләрне дә яттан сөйләгәне бар иде. Ләкин жырга артык осталыгы булмады. Биюне исә, ничектер, үзеннән-үзе үзләштерде ул. Ире аякка басу белән Хәдичә борчылып аның киемнәрен күздән кичерде. Хөсәен исә ул арада бүлмәнең буш ягына чыгып басты да тукталып калды.

— Нинди көй сезгә? — диде Әхмәтҗан.

— Теләсә нинди, — диде Хөсәен, ялтыравык күзләрен уйнатып. Мандолина чыңнары ишетелү белән ул биеп тә китте. Үзен тамаша итеп утырган кешеләрне дә дәртләндерерлек җиңел, матур итеп бии иде Хөсәен. Аның гәүдәсе — төз, нык, җитез, матур аяклары бию өчен генә яратылгандыр диярсең.

Биюгә оста Гөлчирә туташ түзмәде, сикереп торды да биеп Хөсәен каршысына чыкты. Мактау авазлары ишетеп дәртләнгән халдә, бөтен өй эчен дер селкетеп, алар парлап бии башладылар. Бераздан Мөхәммәдов килеп басты. Ул уң кулын баш артына тидереп, түбәтәйне кырын салган килеш, әкәмәт кызык итеп бии иде. Бүлмә эчендә шатлыклы көлү тавышлары тулды. Кунаклар тактка, ара-тирә дәртле сүз кычкыргалап, кул чабып тордылар.

Шакир кинәт тукталып башын кашып куйды.

— Кунаклар, игътибар! — диде. — Нигәдер минем аяклар начар тыпырдый башлады әле. Чәй эчеп бераз аякларга куәт бирмибезме?

Чәй эчү уен-көлкеле сүзләр белән узды. Вакыт соң иде инде.

Ниһаять, стенадагы күкеле сәгать унберне сукты. Урамда күз ачкысыз буран күтәрелгән иде.

Мәҗлестән кайтышлый җилдән сакланып иренә сыенган Хәдичә күтәренке рух белән:

— Бигрәк күңелле булды! Кунаклар ифрат әйбәт кешеләр икән, — диде.

Хөсәен бераз дәшмичә барды. Аннан:

— Сүз юк, кунаклар да, хуҗалар да бер дигән кешеләр, — диде. — Матур кешеләребез дә күп, гүзәл гореф-гадәтләребез дә бар, тик алар барлык халыкка хезмәт итә алмыйлар. Шунысы күңелне әрнетә...

## 9

Оренбур тимер юл мастерскойларында бәйрәм көннәрендә дә эш тукталмый: күпчелек эшче эшләмәсә дә, һич югында, тимерчелектә ике күрек, ике учак тынмый, сандал йөзен чыңлатулар белән кызган тимерне дөпелдәтүләр көндезен дә, төнлә дә ишетелеп тора.

Бөтен шәһәр руслары Рождество бәйрәмен һәм Яңа елны каршылаганда Фәрхетдиннәр эштә иде. Тимерче Егорыч сул кулындагы келәшчә белән сандалда яткан кызу тимерне каптырган. Уң кулында исә кечкенә чүкеч. Ул, ниндидер бер көй чыгарырга тырышкан кебек, чүкече белән әле сандалга сугып ала, әле кызган тимергә бәреп, Фәрхетдингә кувалда белән кай төшкә тондырырга икәнлеген күрсәтә. Сандал кыңгырау кебек чыңлый, аңа җавап итеп Фәрхетдин кызган тимернең йомшарган тәненә үзенең авыр чүкече белән китереп бәрә. Әлеге көй чың-тип-топ, чың-тип-топ дигән авазлардан тора. Ул арада Егорыч, Фәрхетдинне дәртләндереп, шәп суккан чагында: «Ах, якши, якши!»— дип тә кычкырып куя. Ул татарча бары бер сүз генә белә,

ләкин аны Фәрхетдингә әйтми калмый. Менә ул бераздан чүкечен сандалга түтәсе белән түгел, ә яны белән яткызып сукты. Димәк, чүкечче артык сукмасын. Фәрхетдин, авыр кувалданы сабы белән сандал беркетелгән бүкәнгә сөяп, тирән итеп сулыш алды. Аннары инде алар кызуы сүрелә башлаган тимер кисәген, киң авызлы агач мичкәдәге суга манчып, җир идәнгә ташладылар да бераз ял итү өчен эштән туктадылар. Ни өчендер бу юлы Егорыч гадәтенчә тәмәке төрә башламады, аксый-туксый кирпеч стена буендагы кием шкафлары ягына китте. Барып андагы пинжәк кесәсеннән сәгатен алды, аннан икенче почмакта һаман эле эшләп маташкан яшьрәк тимерчегә кычкырды:

— Степашка! Әйдә, ун минут калган!

Икенче учак янында ялгызы гына эшләүче тимерче шундук эшен туктатты, ул да ашыгып шкаф ягына китте. Бераздан алар Егорыч сандалына бер такта китереп салдылар, аның өстенә газета җәеп, тозлы кыяр, калай җамаяк белән тозлы кәбестә, икмәк куйдылар. Егорыч бик хасиятләп дуңгыз мае кискәләп салды. Фәрхетдин ни дип уйларга да белмичә торган арада, аның үзен дә табынга чакырдылар.

— Яңа ел бит, Фәрхетдин, якши, — диде Егорыч күз кысып, — әнә кисмәк кружкасын ал да якынрак кил. Фәрхетдин үзенчә аңлады, ул башта кисмәк өстендә торган кружкадан тутырып су эчте, аннан аны тагын тутырып тимерчеләргә китереп бирде. Егорыч идәндә торган шешәне алды да андагы аракыны тустаганнарга бүлә башлады. Әче аракы исе борынга керде.

— Юк, миңа кирәкми,— диде Фәрхетдин, үзенә дә салганнарын күреп,— мин эчмим.

— Нишләп?

— Юк, юк, гөнаһ була.

Егорыч көлде дә:

— Яңа ел каршылаганда бернинди гөнаһ булмый ул,— диде.— Ну, нинди эш инде ул, Фәрхетдин?! Тәмәке дә тартмыйсың!..

— Тәмәке дә гөнаһ,— диде Фәрхетдин.

— Кызлар белән йөрмисең!..

— Минем авылда Хафазам бар.

— Инде аракы да эчмим дисең.

— Шулай шул, Егорыч агай, эчмим.

— Син дуңгыз мае да ашамыйсыңдыр әле?

— Ул харам.

— Менә мә,— диде Егорыч.— Алай булгач, безнең компаниянең кызыгы да калмый инде.

— Алдаша ул, — диде Степан, бөдрә чәчен корымлы куллары белән сыпырып. — Баксаң-күрсәң, үзе беренче эчкечедер әле. Кара син аның битендәге яра җөйләренә. Белмәссең, бәлки исереп сугышкандыр.

— Юк, исереп сугышканым юк. Узган ел мине Казанда кыйнадылар. Проломныйда.

— Кем кыйнады?

— Кыйнадылар инде. Тәреләр, патша сурәтләре күтәреп баручылар.

Тимерчеләр бердән җитдиләнеп киттеләр.

— Ни өчен?— дип сорады Егорыч, иелә төшеп.

— Мин анда эшчеләр өчен атта корал ташыган идем. Болар аттан таныдылар да...

Егорыч та, Степан да бер-берсенә бик мәгънәле итеп карашып алды.

— Карале,— диде Егорыч, Фәрхетдиннең беләгенә кулын салып.— Бу сүзеңне башкаларга сөйләп йөрисе булма. Белдеңме?

Фәрхетдин ризалык белгертеп башын иде. Егорыч мөнәсәбәтендә ниндидер үзгәреш тугандай булды. Моңарчы Фәрхетдингә шаярып караган кешеләр аны кинәт тиң күреп сөйләшә башладылар.

Егорыч чалбар кесәсеннән зур чуен сәгатен чыгарды.

— Яңа елга өч минут вакыт калды,— диде ул һәм Фәрхетдингә текәлде:

— Бәлки безнең компания хөрмәтенә әз генә булса да күтәрерсең, якши?

Бер дә эчмәгән кеше түгел иде инде ул Фәрхетдин, байда хезмәт иткәндә дә, фәхешханәдә эшләгәндә дә, балын, сырасын әйткән юк, азмаз аракысыннан да авыз итәргә туры килде. Ничектер мөнәсәбәтләр яхшыга үзгәрергә торганда, осталар каршында суфиланып баш тартып маташу әйбәт түгел иде.

— Ярый алайса, тик әз генә,— диде ул көлемсерәп. Кружканың төбендә генә калдырып, үзенә салынган аракының күбрәк өлешен башка савытларга бүлде.

Учындагы чуен сәгатеннән күзләрен алмыйча ящик өстендә утырган Егорыч:

— Егетләр!— диде тантаналы итеп. — Яңа ел башланды. Әйдә, шуның хөрмәтенә тустаганнарны бушатып куйыйк. Котлы булсын жиденче ел!

Алар чыңлатып савытларын чәкештерделәр дә эчеп җибәрделәр. Бер тын тавышсыз ашап утырганнан соң сүз башланды.

Егорыч та, Степан да читтән килеп бирегә урнашкан кешеләр икән. Фәрхетдин кебек үк, бәхет эзләп килгәннәр. Ләкин Фәрхетдин өчен Егорыч шулай да моңарчы табышмак иде әле: аңардан нәрсәнедер яшереп яши кебек, ул белмәгән ниндидер серләрне белә кебек. Чыннан да, яңа ел башланганның икенче көнендә ул үзе, тәмәке тартырга эштән тукталган арада, кичәге әңгәмәне дәвам иттереп, Фәрхетдиннең юравы дөрес икәнлеген белдерде:

— Ничек син бунтовщикларга корал ташыйсы иттең?— дип сорады.

— Шулай инде,— диде Фәрхетдин сүзнең җеп очын тотып,— шулай туры килде.

— Больницада озак яттыңмы?

— Өч айдан артык.

— Инде икенче андый эшкә тыгылмам дип ант иткәнсеңдер үзең дә?!

Фәрхетдин дәшмәде, каш астыннан гына Егорычка сынаулы бер караш ташлады. Тимерче исә үзе дә аны сынап, һәр хәрәкәтен күзеннән кичерә иде.

— Дөресен әйт, курыкма, сатмам, мин белергә тиеш,— диде ул, ниһаять.

— Дөресе шул, Егорыч агай, әгәр мөмкин булса, гомерем буе корал ташыр идем мин аларга.

Егорыч яктырып китте.

— Молодец! Димәк, безнең ботка пешә икән синең белән.

— Ник алай дисең?

— Чөнки мин сине бер айдан артык инде сыныйм, тырышасың, үзеңчә булса да китаплар укыйсың. Шәп егеткә охшагансың.

Фәрхетдин, ни булса ул дип, әйтергә булды.

— Мин синең күңелеңдә ни ятканын аңлыйм,— диде. — Миңа синдәй кешеләр белән очрашырга туры килде, Егорыч. Миңа үзебезнең телдә чыгачак газетаны таратырга куштылар...

— Газета?— диде аптырап Егорыч.

— Әйе, газета. Үзебезчә, татарча чыгачак ул.

—Ниләр язылачак соң анда?

— Анда халыкның тормышы җиңеләйсен өчен ни эшләргә кирәклеге язылачак.

Егорыч сәерсенеп башын чайкады. Фәрхетдин исә сүзендә дәвам итте:

— Мин депога да, мастерской цехларына да кереп карадым. Тик эш бер-ике татар егете белән сөйләшүдән ары китмәде. Ә инде безнеңчә газета чыга, «язылыгыз» дип белдерү язуы элеп куйган идем, китеп тә өлгермәдем, шундук ертып алдылар. Егорыч, шул чыгачак газетаны татар-башкорт эшчеләре арасында таратырга кирәк.

— Минем бер таныш башкорт егетем бар,— диде Егорыч.

— Син Чынбулатны әйтәсеңме?

Егорыч тагы бер тапкыр сәерсенеп куйды.

— Син каян беләсең аны?

— Мин бирегә килеп төшкәндә, ул вокзалга минем белеш бер кешемне каршыларга төшкән иде. Шунда таныштык.

Ниндидер ят кешеләрнең якынлашуы күренде.

— Ярар,— диде Егорыч,— мин сиңа бераздан әйтермен, ә хәзер минә моны күтәреп учакка салыйк. Аннан шул: телеңне тыярга өйрән. Теге көнне дә Степан алдында сөйләнеп ялгыштың.

Алар икәүләшеп авыр тимер болванканың очын учакта көйрәп торган күмер өеменә тыктылар. Егорыч тиз генә келәшчәсен кулына тотты, озакламый кызып аксыл-сары төскә кергән тимер кисәген әләктереп, сандал йөзенә китереп салды. Фәрхетдин кувалдасын алды.

## 10

Хөсәен мәҗлестән кайткач бер сәгать чамасы гына йоклап алды да торып эшкә утырды. Урамда әле күптән түгел генә котырынган буран инде тынган, тәрәзә бозларына караганда, көн җылынырга чамалый иде. Газетаның беренче саны типографиягә төшерелгән инде. Бүген иртә белән гранкалар килергә тиеш. Ләкин беренче номер артыннан ук икенче санны әзерләп төшерергә кирәк. Ике-өч бөртек кеше хезмәте белән шундый җаваплы газетаны чыгару өчен бар көчеңә тырышмыйча булмый.

Ҡерем аз иде. Еллыкка язылудан курка хәзер халык, чөнки белеп тора: бүген газета килә, ә иртәгә аңа арест салалар. Редакция кешеләренә, матбага эшчеләренә түләргә кирәк, гонорар да җибәрергә кирәк, ул башка газеталарныкыннан ким булмасын. Файдасы аз дип, нашир тәртәгә тибә башламаса ярый инде.

Хөсәен алдына ак кәгазь пачкасы салган, кулына каләмен тоткан, әмма язуга керешмәгән хәлдә, шундый уйлар белән булаша иде. Хәдичә тәмле итеп йоклый әле. Хөсәен урыныннан торды да тавыш чыгармас өчен шыпырт кына басып чүпрәктән суккан тар сузма келәм буенча әрле-бирле йөренгәләргә тотынды. Ничек тә тизрәк, икенче саннан да калдырмыйча, «Дәүләт думасына кемнәрне сайларга» исемле мәкаләне бирергә иде. Хөсәен Ленинның ул мәкаләсен татар укучысына беренче номерда ук җиткерәсе иде. Ләкин моңа мөмкинлек булмады, өлгерә дә алмады. Өстәвенә мәкалә, аның фикеренчә, бик яхшы тәрҗемә ителергә тиеш, димәк, аны берничә кешедән укытырга да, кат-кат төзәтергә дә кирәк булыр әле.

Хөсәен тәрҗемә ителә башланган мәкаләгә текәлде. Уйлары аны еракта калган Казанга алып китте. Ул чакта Хөсәен учительскаяда укый иде. Үзләренә бик еш килеп йөри торган, революцион пропаганда алып баручы университет студенты Кулешадан сорады ул: «Әйтегез әле, минә революционерларның иң көчлесе, иң акыллысы, барысы-

на да житәкче булырлыгы кем хәзер?» — диде. Кулеша: «Ленин»,— дип җавап бирде. Әнә нинди беркатлы сораулар биргән ул чакны Хөсәен! Ә хәзер инде ул Ленинны ерактан ишетеп кенә түгел, басылып чыккан һәрбер әсәрен укып, аны аңлап һәм һәр вакыт аны хуплап белә. Иптәшләреннән ишетеп ул шул бөек өметләр баглаган кешенең тышкы кыяфәтен дә, холкын, табигатен дә ачык күз алдына китереп бастыра ала. Әгәр Хөсәенгә Ленинны күрергә туры килсә, ул, һич ялгышмыйча, аны таныр иде кебек. Ленинны чит илдә күреп кайткан Адоратский аларга Ленин турында байтак мәгълүмат биргән иде. Аннан соң тагы Уфада да Ленинны күргән кешеләр белән сөйләшергә туры килде. Шул җөмләдән берсе меньшевик Әхтәмов булды. Ул Уфага әле күптән түгел генә Харьковтан, ә аннан алдарак Харьковка чит илдән кайткан иде. Женевада яшәгәндә меньшевикларның лидеры Плехановның сәркатибы булып та торган. Әлбәттә, ул Владимир Ильич белән бик еш очрашкан. Әхтәмов белән Хөсәеннең Уфада чакны бик каты бәхәсләшкән вакытлары булды. Ләкин сүз гәрчә политикадан башка темаларга башланса да, Әхтәмов Ленин турында да сөйли иде. Ул, әлбәттә, череп беткән меньшевик, ләкин шулай да Ленин турында сокланып сөйли иде.

Хөсәен газетадагы мәкаләгә карап шуларны хәтерләде. Аннан үзенә: «Житте, эшкә, эшкә!» дип әмер бирде. Барлык башка уйларын башыннан чыгарып ташлап, эшенә чумды.

Көндезге уникеләр тирәсендә генә типографиядән гранкалар килә башлады. Алдан сөйләшү буенча, Хөсәен аларны карап чыкты да шунда ук Хәдичәне цензорга җибәрде.

Бу вакытта Хөсәен редакция бүлмәсендә иде инде. Экспедитор малай чыгып китте, Хөсәен ялгыз калды. Ни әйтер инде цензор? Күп тә үтмәде, коридорда тәмәке тартып торган Галимҗан бүлмәгә керде.

— Киттеме?— диде ул, үзенең кечкенә генә өстәле янына утырып.

— Җибәрдем.

— Бәйләнмәсә ярый инде. Синең редакция исеменнән язган мәкаләң бик хәтәр. Шуның өчен борчылам.

— Анысы шулай, мин сине аңлыйм, Хөсәен. Беренче сүзне эзопча әйтеп булмый. Ләкин шулай да...

Галимҗан әйтәсе сүзен тәгәлләргә өлгермәде, Хөсәен әңгәмәне бөтенләй башка юнәлешкә борып җибәрде.

— Мин синнән һаман сорарга онытам,— диде ул. — Ни сәбәптән сез теге көнне Шакир абыйларга бармадыгыз? Сез дә чакырулы булгансыз икән ич! Соловьевлар да килмәде.

— Тимерша миннән куркып бармагандыр, ә мин Сашадан,— диде Галимҗан.

— Нәрсә, теләмәдеме?

— Теләмәде. Сез анда үз телегездә сөйләшеп утырачаксыз, үзегезчә күңел ачачаксыз, ди. Минем, күзле бүкәндәй, арагызда берни аңламыйча утырасым килми, ди.

Хөсәен әйтелгәннәргә үзенең мөнәсәбәтен сиздермәде.

— Бик күңелле булды,— дип кенә куйды.

Бүлмәгә зур сумка аскан, хәтәр мыеклы почтальон агай килеп керде. Ул озак кына мыштырдап газет-журналларны өстәлгә салды, эш арасында, ярарга тырышып, соңгы хәбәрләр дә сөйләргә өлгерде, аннан сумкасыннан тагы бик күп хат, открыткалар, телеграммалар чыгарды, тиешлесенә Хөсәеннән кул куйдырып, ниһаять, теләгенә ирешеп, ягъни Хөсәеннән «чәйлек» алып, җиңеләеп чыгып китте.

Хатларны, ике өстәлгә бүлеп салып, укырга керештеләр. Укылган һәркайсы тиешле урынына куеп барылды: эшчеләр хәрәкәте, авыл, театр-культура, шәкертләр...

— Тукайдан котлау,— диде Галимҗан, матур чәчәк сурәтләре төшерелгән открытканы Хөсәенгә сузып. Открыткада Тукай кулы белән Яңа ел котлавы язылган. Халыкка чиксез гали хезмәт миссиясендә Хөсәенгә һәм барлык идарә кешеләренә зур уңышлар теләгән.

— Бәлки газетага җибәрербез?— диде Галимҗан.

— Юк, ярамый. Аны хәвеф астына куеп булмый.

Котлаулар арасында Гафурдан да, Галиәсгардән дә, Фатих һәм Мәҗиттән дә газетага һәм аны чыгаручыларга дип атап язганнар бар иде.

Килгән хәбәрләргә караганда, барлык җирдә, дөрләп янмаса да, революцион хәрәкәт һаман көйри әле. Казанда мебельчеләр эш ташлаган, Саратовта тимер юлчылар баш күтәргән, Пензада приказчиклар хуҗалары алдына үзләренең таләпләрен куйганнар. Кызылда Гали Дербышевның биш приказчигы эш ташлап, бөтенләй читкә китеп барган...

Болар өстенә мәдрәсәләрне шәкертләр хәрәкәте тетрәтә, вак һөнәрчеләр, профсоюзларга оешып, заказ бирүче хуҗаларга үзләренең шартларын куялар. Корреспонденция тикшерелеп бетәр-бетмәстә Хәдичә кайтты. Аның йөзе артык борчулы иде.

— Берсенә кул куймады, йөзе кара,— диде. —Тагы бер сугылырсың, сеңелкәй, дигән була.

— Кайсына?— дип сорады Хөсәен куркынып.

— «Редакциядән» дип язылганына.

— Әйттем ич,— диде Галимҗан.

— Үземә барырга туры килә инде, алайса,— диде Хөсәен чәбәләнеп.

— Кайчанга, сәгать ничәгә чакырды соң?— дип сорады ул Хәдичәдән.

— Мин әле тагы бераз уйланырмын, диде ул, вакытын атап әйтмәде.

— Сыйлаганны көтә ул, — диде Галимҗан.

Хөсәен сәерсенеп башын кыйшайтып куйды.

— Исерек ул үзе, авызыннан аракы исе килә,— диде Хәдичә. — Күзләрен тозландырып, сеңелкәй дә сеңелкәй, дип утыра.

Галимҗан тыела алмыйча шаркылдап көлеп җибәрде.

— Сиңа бер штофчик аракы кыстырып барырга туры килә, Хөсәен.

Хәдичә алып кайткан хәбәр әйбәт фал түгел иде. Ярый ла бу цензорның ришвәтчелеге яисә эчкечелеге аркасында гына булса?!

Сәгать бер иде инде. Хөсәен хатларны карап бетерде дә Хәдичә белән көндезге ашка кайтып китте.

Ашап-эчкәч, ул цензорны өркеткән «идарәдән» дигән сүз башын кулына алды. Нинди җаваплар бирергә кирәклеген, инде йомшартмый мөмкин булмаган хәлдә, бу эшне нинди рәвештә башкарырга туры киләчәген уйланды. Сәгать өчтә Хөсәен цензор янында иде инде. Зур корсаклы, олы бәдәнле, агарган чәчен уртадан аерып майлап тараган калмык чырайлы Акачуров Владислав Петрович Хөсәенне шактый сүрән кыяфәт белән каршы алды. Ул, язуларыннан аерылып, пенсне күзлеген салды да шактый саф татарча:

— Мин бит сезнең редакторыгызны чакырдым, — диде.

— Редактор авырып китте, ул миңа үзе исеменнән сөйләшергә кушты.

— Ну, утырыгыз, алайса.

Каршысына Хөсәен утыргач, цензор алтын балдаклы кыска юан бармагын язу өстендә төрткәләп сөйләп китте.

Анынча, баш мәкаләдәгечә эшче сыйныфын патшаны төшерергә өндәү, котырту цензура аша үтә алмый иде.

— Юк, сүз монда Галижанәб патша әгъзам хәзрәтләре турында

бармый. Монда сүз дәүләт турында бара. Болар бөтенләй ике мәгънәдәге нәрсәләр. Патшага бернинди тел тидерү юк монда.

Цензор кысык күзләрен челт-челт йомгалап алды, уйланып торды.

— Я, укып күрсәтегез әле яңадан шушы урынны.

Цензор гарәп хәрефләрен бик начар таный иде, ахры. Бу Хөсәен күңелендә аптырау һәм куану хисе тудырды.

Хөсәен ул күрсәткән абцазны укып чыккач, цензор бик шикләнеп:

— Кайда монда «хөкүмәт» дигән сүз? — дип сорады.

— Менә ич, менә, Владислав Петрович.

Цензор кабаланып өстәл тартмасыннан гарәпчә-русча сүзлек табып алды.

Кайда монда «х», «х» кайда, күрсәтегез!

Хөсәен бармак белән төртеп, «х» хәрефен күрсәткәч, цензор китабына яңадан текәлеп торды. Ниһаять, ул ышанды булса кирәк.

— Ярар, монысы белән килешик. Инде башкаларына күчик,— диде.

Шакир Мөхәммәдовтан да, Фатих Кәримидән дә «безнең цензор әйбәт» дигән сүзләрне ишеткән иде инде Хөсәен. Ул чагында бу казна вәкиленең шәплеге нидән гыйбарәт икәнлеген төшенеп бетмәгән иде. Хәзер аңлады, аның уңай ягы — томаналыгы, наданлыгы икән. Хөсәен: «Әйтәм алар цензорны мактаганда һәр вакыт ничектер серле генә елмаялар иде», — дип уйлады.

Хөсәен белән цензор, Шакир Мөхәммәдов әйтмешли, «борча чүпләп» ике сәгать буе утырдылар. Хөсәенгә бу бәйләнчек цензорны кәкре каенга terәтү өчен барлык тапкырлыгын җигәргә туры килде. Ахырда барысы да җайланды, мәкалә өстенә печать басылды.

Хөсәен, яулыгы белән маңгай тирләрен сөртеп, елмайды да:

— Һай, һай, сез бик тирән сөрәсез икән! Рәхмәт сезгә, цензор әфәнде,— диде. Кесәсеннән сәгатен чыгарып карап алды.— Соң икән инде. Сезнең эш сәгате беткән ләбаса, цензор әфәнде.

— Шулай икән шул.

— Беләсезме, минем бер тәкъдимем бар. Эш сәгатьләре дә беткән, ял итү, ашап алу вакыты да җиткән. Булмаса, безнең газетаның беренче номеры шәрәфенә ресторанга кереп бераз тамак ялгап чыгыйк.

Цензор эре, алтын тешләрен балкытып көлеп куйды.

— Аңлыйм мин сезне. Хәйләкәр кеше сез. Шулай икенче бәйләнмәсен өчен йомшартмакчы буласыз.

— Юкны сөйләмәгез. Һич, һич алай түгел. Безнең газета әле чыга гына башлый, безгә әле бик озак еллар бергә эшләргә туры киләчәк. Ничек инде моны билгеләми уздырырга була?! Сезнең бәйләнчек булуыгыз, дөресен генә әйткәндә, миңа бик ошый. Чөнки сез ярдәм итмәсәгез, газетаның сыйфаты һичшиксез түбән булачак.

Цензор алтын тешләрен күрсәтеп көлә бирде. Хөсәен аның күзләреннән укып белде: ресторанга кереп, бик тә сыйланасы килә иде.

— Без анда озак утырмабыз, — диде Хөсәен дустанә рәвештә. — Сез бәлки җәмагатегез ачуланыр дип борчыласыздыр?

— Ах,— дип куйды цензор,— уговорил таки. Әйдәгез, киттек, алайса.

Хөсәен кесәсендәге барлык акчасын ресторанда калдырып, өенә кайтып кергәндә, Хәдичә бүлмәдә Фәрхетдин белән сөйләшеп утыра иде.

— Кайда йөрдең син? — диде Хәдичә, Хөсәеннең килеш-килбәтенә шаккатып.— Борчылып беттем, Галимҗан да ике тапкыр килеп китте.

— Гуляйть суктырдым, Хәдичәкәй,— диде, Хөсәен авызын җыя алмастан,— цензор белән...

Хәдичә барысын да аңлау белән тынычланып бер көлде. Хөсәеннең бүрегe кыек киелгән, күзләре ялтырап тора иде. Киемнәрен коридорда салды да үз бүлмәсенә узды. Анда Фәрхетдинне күреп, кулларын җәеп җибәрде.

— О, Фәрхетдин! Я, нихәлләр, Фәрхетдин? Син безгә мин өйдә югында гына киләсең. Кара аны! — Аннан ул җитдиләнеп: — Эшли башлагансың икән, — диде. — Ничек соң, эшләр үрлиме?

— Бик әйбәт хәзергә, Хөсәен абый. Җүнле остага туры килдем.

— Шулаймы? Кыерсытмыймы үзеңне?

— Кая кыерсыту, сиңа тизрәк тимерчелек һөнәрен үзләштерергә кирәк, Фәрхетдин, ди. Үзем өйрәтәм, ди, гомергә чүкеч сугучы булып эшләмәссең, ди. Үзебезнең кеше.

— Ничек инде «үзебезнең» кеше?

— Менә синең кебек, ул да большевик.

Хөсәен авызына бармагын тидереп: «Тсс-с»,— диде, аннан көлеп җибәрде.

— Сиңа үзе шулай дип әйттеме? Мин большевик дидеме?

— Әйтте, Хөсәен абый. Анау көнне Хәдичә апа миңа задание биреп җибәргән иде. Мин аның белән шул турыда да киңәштем.

Хөсәен кинәт айнып, җитдиләнеп китте.

— Нинди задание?

Ул сорау белән Хәдичәгә текәлде.

— Менә сез чыгарасы газетаны таратуны оештыр әле, дигән иде Хәдичә апа. Мин бернichә татар эшчесе белән сөйләштем, алар, газиткә түгел, ашарга да җитми әле монда, диделәр дә шуның белән эш бетте. Минемчә, алай барып чыкмый бит. Аларга аңлатырга кирәк, ә аңлату өчен белергә кирәк. Хәдичә апа киңәш иткәч, мин инде хәзер төрле китаплар да укый башладым, Хөсәен абый.

— Туктале, нинди китаплар укыйсың соң син?

— Укыйм инде, төрлесен укыйм, «Бакырган»ын да укыйм, «Кыйсса эль әнбия»се дә бар. Монда көтепханәдән алам. Әле «Дин вә мәгыйшәт» дигән журнал сатып алган идем дә, анысына чуты теш үтми.

— Укырга һәвәслек бар икән, Фәрхетдин, китапларны мин үзем бирермен сиңа! — Хөсәен шкаф өстенә үрелде дә аннан бер брошюра алды.

— Мәле, онытылганчы бирим. Менә бу китап безнең газета укучыларына бушлай җибәрелде. Ә остаң газет тарату турында ниндирәк киңәш бирде соң?

Фәрхетдин, укый белгәнлеген күрсәтергә теләгәндәй, башта кычкырып китапның исемен иҗекләде. Аннан гына җавап кайтарды:

— Сорагач та әйтмәде. Уйлашыйк, диде. Иртәгесен без үзара сөйләштек, ярдәм итми калмабыз, дөресен әйткәнсең, диде. Безнең мастерской бик зур. Анда Егорыч ишеләре тагы бардыр әле.

— Анысы ярый, — диде Хөсәен. — Синең шундый дәртең булгач, Фәрхетдин, мин синең белән ачыктан-ачык сөйләшим инде. Безнең «Урал» газетасы — эшчеләр газетасы...

— Әйе, миңа Хәдичә апа әйтте.

— Ләкин ул бары эшчеләр өчен генә түгел, ул барлык юксыллар, шул җөмләдән авыл фәкыйрьләре өчен дә чыгарыла. Менә син укый беләсең. Газетаны якын-тирәдәге авылларга алып чыгып, андагы татар, башкорт крестьяннарына укып карыйсы иде. Бу эшне башта Чынбулатка тапшырасы иде дә бит, ләкин ул укый да, яза да белми.

— Ә эштән ничегрәк китәргә булыр икән?

— Нигә китмәскә! Ял итәсеңдер ич? Аннан син бит, остам — безнең кеше, дисең.

— Анысы шулай, — диде Фәрхетдин.

Кемдер ишек шакыды.

— Без әле бу турыда аерым бер сөйләшербез, — диде Хөсәен, мәгънәле рәвештә бармак янап. — Керегез!

Ишектә Галимҗан күренде. Ул сораулы караш белән Хөсәенгә текәлде һәм шунда ук, күрәсең, барын да аңлап, ачылып китте.

— Ну, булдымы?
— Булды, котлый аласың!
— Әчми булмады инде? — диде Галимҗан көлемсерәп.
— Булмады, — диде Хөсәен, күзләрен елтыратып. — Никадәр саклансам да булмады, Галимҗан.
— Теге риза-бәхил булдымы соң?
— Булгандыр инде, тик моннан соң редактор үзе килсен, ди. Өстерәп алып чыгып, извозчикка утыртып өенә кайтарып җибәрдем.
— Котлыйм, тәбрик итәм, — диде Галимҗан...

## 11

Галиәсгар Камалның татар театрын, кем әйтмешли, идән астыннан киң мәйданга чыгару нияте алдынгы татар яшьләрен бик нык дәртләндерде, ләкин шул ук вакытта соңгы айларда аерата гайрәт чәчә башлаган фанатик динчеләрне һәм аларның иярченнәрен бу ният зур җәнҗал оештырып, «тар балак, кызыл авызлар»ны мәсхәрәләп, «акылга утыртырга» котырта иде.

Артистларны ни генә көтсә дә, авторның үз кулы белән язган афишалар Казанның Яңа һәм Иске бистә урамнарында эленгән иде инде. Спектакль 22 нче декабрь көнне приказчиклар клубында булачак.

Гафур сүзендә торды. Үз тирәсенә тупланган Пороховой һәм Алафузов эшчеләре арасындагы күз күргән татар яшьләре белән сөйләште. Бу спектакльнең бөтен халык өчен гаять әһәмиятле булуын, нинди генә хәлдә дә өздермәскә, Печән базары әһелләренә обструкциягә юл куймаска кирәклеген әйтте.

Ул клубка тәртип саклау өчен полицейскийлар чакырылуын да белә иде. Ләкин алар тәртип урнаштырудан да бигрәк, тәгаен тәртипне бозуда гына булышлык күрсәтәчәк. Һәрхәлдә, әгәр элеге «әһеле ислам каһарманнары» җәнҗал куптарса, аларның берни дә эшләмәячәге Гафурга ачык иде.

Гафур спектакльне карарга теләүче яшьләргә театрда тәртип сакларга туры киләчәген аңлатты. Билетлар алдан ук алынды. Бу эштә дә йоклап калырга ярамый иде. Берәр мөтагассыйп байгураның билетларны күпләп алып куеп, ертып ташлау ихтималы да бар иде.

22 нче декабрь көнне кичкырын Гафур приказчиклар клубына барырга җыенды. Бу спектакльне шул ук һәвәскәр артистлар башкаруында ул өй шартларында берничә тапкыр караган иде инде. Хәзер иң кызыгы шул: гади публиканың спектакльне ничек каршылавын күзәтү, аңа булган мөнәсәбәтен белү. Спектакльгә барып ул сирәк очрый торган таныш-белеш, дус-иш белән күрешеп, «Урал» турында сөйләшә алачак.

...Гафур приказчиклар клубы тирәсенә җыелган халыкның күплегенә хәйран калды. Тонык кына янган газ фонаре яктылыгында бу төркемнең кемнәрдән торганын аерып белү мөмкин түгел иде. Ләкин Гафур озакламый аңлады: Печән базарындагы көфер почмагы әһелләре иде боларның берише. Алар, спектакльгә халык җыелганчы ук, клубка кереп, артистларны кыйнап чыгарга исәп тотканнар икән. Ләкин спектакльне оештыручылар да, мондый эшнең мөмкинлеген истә тотып, алдан ук чарасын күргәннәр: артистларга ияреп егермеләп егет клубка килгән һәм сакка баскан. Хәзер алар тезелешеп ишек янында торалар, таяклар белән коралланган кадимчеләрне ишеккә якын җибәрмиләр иде. Гафур яшьләр арасыннан берничә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертен, учительская школа укучыларын таныды. Артистларның «арт сабагын укытырга» килүчеләр арасында да танышлар юк түгел иде. Иң

беренче булып кырыктартмачы Хафизны таныды Гафур, аның белән янәшә кулына зур уклау тотып шәмче Гайнетдин, тирече Вәли һәм тагы байтак күз күргән кәфер почмагы «каһарманнары» тора иде. Алар даулашып эчкә керергә телиләр, яшьләрне этә-төртәләр, ләкин шулай да кул күтәрергә кыймыйлар, таякларын артык болгамыйлар иде.

Гафурны сакчы егетләр күрү белән үк таныдылар.

— Әйдәгез, Гафур абый, иртәләгәнсез, — диде бер егет, юл биреп.

— Һөҗүмме? — диде Гафур.

— Алай бик әллә ни кыйрата алмаслар, — диде егет.

— Молодцы, — диде Гафур, — бирешмәгез, егетләр!

Кемдер арттан:

— Ә, тар балак! Шул инде учитель Гафур. Атаманнарының берсе. Урыска сатылган денсез, үләт себергере! — дип калды.

Гафур клуб эченә керде. Сакчы егет, иртәләгәнсез, дисә дә, фойеда халык шактый иде инде. Матур гына буфет оештырып җибәргәннәр. Стена буендагы өстәлләрдә китап саталар. Чибәр кызлар кәрзиннәр күтәреп чәчәкләр сатып йөри. Гафур урталыкка үтеп өлгермәде, аның янына зифа буйлы, чәч толымнарын алга салган, башына энҗеле калфак кадаган берсе килеп җитте:

— Исәнмесез, Гафур абый. Сезнең кулыгыз җиңелдер, бер чәчәк алып җибәрегез әле. Кереме шәкертләр файдасына.

— Бик рәхәтләнеп...— диде Гафур кәефләнеп,— тик шарты шул: чәчәкне үз кулыгыз белән кадыйсыз.

— Рәхим итегез, — диде кыз, — сайлагыз.

Чәчәкләр ясалма иде. Аларны шул ук кызлар бәлки төн йокыларын калдырып, тырышып ясаганнардыр. Гафур кәрзиндәге ак, кызыл роза чәчәкләренә текәлде.

— Кемнең оста куллары эшләгән бу гүзәллекне?

Кыз:

— Үзебез, Гафур абый, — диде дә бик тырышып чәчәк кадарга кереште. Кызның кайнар сулышы, йөзенең якынлыгы Гафурны бераз исертә төште.

— Рәхмәт, — диде Гафур, акча түләп, — кадавыгыз өчен дә, чәчәк ясавыгыз өчен дә рәхмәт.

Тамаша залы ишегеннән Галиәсгар күренде. Ул, юлында очраган танышлары белән исәнләшә-исәнләшә, җитез атлап Гафур янына килде, йомшак кулын сузды. Гафур аның спектакль өчен дулкынлануын беренче җөмләләреннән үк аңлады.

— Тыныч бул, — диде, — барысы да максутча булыр. Яхшы оештыргансыз.

— Китап сату прилавкасы белән таныштыңмы? — дип сорады Галиәсгар.

Гафур анда барып җитмәгән иде әле. Галиәсгар, моны аңлагач, култыгыннан элеп алды да, әйдәле дип, Гафурны шунда таба алып китте.

Өстәлдәге китап, газета һәм журналлар бик пөхтәләп урнаштырылган. Гафурның күзләренә газеталардан: «Казан мөхбире», «Вакыт», журналлардан «Карчыга», «Чүкеч» чагылды. «Дин вә мәгыйшәт» һәм «Бәянелхак»ны күргәч, аның йөзе чытылып китте.

— Ә боларын ни пычагыма сатарга тагы?!

— Шаулама, анысы Потемкин кормалары. Син менә монда кара!

Гафур Галиәсгар күрсәткән ниндидер яшькелт тышлы брошюралар өеменә күз салды. Аларның берсен кулына алып тышындагы язуын укый башлады. Анда: «Урал» китапханәсе. Эшчеләрнең котылуы үзләренең эше булырга тиеш. № 1. Оренбур, Кәримов, Хөсәенов вә ширкәсенең паравуй басмаханәсе», дип язылган иде. Гафур, серле елмаеп, шатлыгын һич яшерә алмыйча, шулай ук үзалдына кәефләнеп торучы Галиәсгаргә текәлде.

— Килдемени? Җибәргән, димәк?
— Менә күргәненчә. Ике йөз данә.
— Ә газета?
— Ул да килер, иншалла.

Гафур биш брошюра алып күкрәк кесәләренә салып куйды, акчаларын сатучы алдына ташлады.

— Әйбәт тәрҗемә иткәннәр,— диде Галиәсгар.
— Сез инде шулай да саграк кыйланыгыз,— диде Гафур.
— Әлбәттә, андый-мондый шикле кеше булса, бу егет брошюраларны өстән аска күчереп куячак.
— Габдулла Тукаевтан мәктүб алдым,— диде Галиәсгар, сүзне башкага күчереп.— Ул безнең Хөсәенгә тәмам гашыйк.
— Мин анысы өчен бик шат.

Фойега халык күпләп керә башлады. Гафур үзе күрергә теләгән танышларын эзли китте.

...Спектакль башланып, публика сәхнәдә барган вакыйгалар эченә чумды дигәндә генә алгы рәтләрдәге бер кеше сикереп урыныннан торды. Ул сәхнәгә лимонад шешәсе ыргытмакчы булды. Ләкин аңа ирек бирмәделәр, кемдер кизәнгән җиреннән тотып калды. Ләкин бу шулай да шау-шуга сәбәп булды. Бәхеткә каршы, артистлар артык каушамадылар, уеннарын дәвам иттерделәр. Теге хулиганны ике егет җилтерәтеп залдан алып чыгып китте.

Урта рәтләрнең берсендә утыручы Гафур ирексездән тирә-юнен сагаеп күзәтә башлады. Спектакльне өзү өчен, мөгаен, бер генә кеше килмәгәндер. Һәм, чыннан да, шулай булып чыкты да. Беренче пәрдә бетәр алдыннан Гафур артында утыручы бер кеше һич урынсызга кычкырып көләргә тотынды. Көлүе көлү булса икән — шамакайларча чыркылдау иде ул. Гафур ачулы күзләрен тутырып артына борылды. Ләкин сүз дәшәргә өлгермәде — теге кешенең янында утыручы Пороховой егете зур көчле кулы белән көлүченең авызын каплады. Шулай да нервылар тетрәнә. Публика үзенең ярсуын көч белән басып кына тынычлык саклый. Пәрдә төшү белән бөтен зал гөж килә башлады.

Күрәсең, яшьләрнең мондый сугышчан бердәмлеге тегеләрне яхшы ук шүрләтә булса кирәк, спектакльне өзәргә артык омтылучы булмады. Хәлбуки, Гафур һаман сагаеп күзәтеп утырды. Яңадан берничә урында обструкция ясарга җыеналар иде.

Икенче антрактта Гафур тәмәке тарту бүлмәсендә карангырак бер почмакта ялгыз гына папирос көйрәтеп торучы кешегә игътибар итте. Гафур аны танырга өлгермәде, әлеге кеше караңгы почмактан чыгып, Гафурга таба үзе атлады.

— Бер генә минутка мөмкинме, Гафур иптәш?

Гафур бу кешене шунда ук таныды. Җәгъфәр иде ул. Әмма хәзер аның өс-башы бөтенләй башкача — бик яңа булмаса да, европача тегелгән костюм, башында кара кәләпүш, аякларында шиблетлар. Җәгъфәрнең күлмәге генә бәйрәмчә түгел иде — утыртма кыек якалы, ефәк билбаулы көрән күлмәк. Ул Гафурны читкәрәк алып китте дә:

— Мин сезнең белән сөйләшергә тиеш,— диде. Аннары, сүзен нидән башларга белмәгәндәй, бераз тотлыгып торды.
— Мин сезне тыңлыйм,— диде Гафур, сагая төшеп.

Җәгъфәрнең күзләрендә ачу чаткылары уйнаклап алды. Һәм батырланып әйтте ул:

— Мин сездән моны көтмәгән идем, Гафур иптәш. Минем турыда гайбәт таратудан нинди тәм табасыздыр?! Моннан бит сезгә асла файда юк.

Гафур һич булмаган эш ишетеп, аптырап калды.

— Аңламыйм сезне. Минем беркем турында да әлегәчә гайбәт сатканым юк. Эшләрем аннан башка да җитәрлек.

— Кем дип уйларга кала соң инде миңа? — диде Җәгъфәр ачыргаланып. — Сез, сез генә беләсез минем үткәнемне. Хәзер тирәмдәге бөтен кеше миңа бүрегә карагандай нәфрәт белән карый. Кайберәүләр ачыктан-ачык артымнан: «Провокатор, сатлык», дип кычкырып калалар.

— Без капчыкта ятмый, Җәгъфәр әфәнде. Мин әйтмәсәм дә, халыкның сизенеп турыда белүе бик ихтимал. Сез әллә кайда түгел, шул ук шәһәрдә яшисез бит. Ә бер тапкыр абруй югалтсаң, аны кайтарып алу җиңел эш түгел. Узгандагы гөнаһларыгыздан ансат кына котылмакчы идегезмени? Алай булмый ул. Әйткәннәрегез ихлас булса, сез теләгегезгә зур сынаулар кичеп кенә ирешә алырсыз.

Җәгъфәр башын аска иеп, үзалдына сөйләгәндәй:

— Миңа бары бер юл гына калды, кайда да булса җәһәннәмгә олагырга, — диде. — Туйдым, арыдым.

— Мондый рух төшенкелеге кичерсәгез, әллә ниләр кыйрата алмассыз дип уйлыйм, әфәндем.— Шулай дип, Гафур китә башлады.

— Гафу итегез, — диде Җәгъфәр, калтыранган бармаклары белән сүнгән папиросын кабыза-кабыза.

Спектакль беткәнче әледән-әле Гафурның күз алдында Җәгъфәрнең чытылган ябык йөзе, җыерылган кашлары һәм рәнҗеп карый торган ачулы күзләре җанланды. Ул кеше кызганыч та, җирәнгеч тә иде.

Спектакль бетте. Гафур өенә кайтып китте. Юлда Пороховой егетләренең бер-берен бүлеп, спектакльдән алган тәэсирләрен уртаклашуы, тамашаның аларны соң дәрәҗәдә тетрәткәнлеге аны бөтенләй башка тойгылар дөньясына алып кереп китте. Күңелдә Җәгъфәр белән очрашудан туган кара болыт таралып юкка чыкты.

## 12

Газетаның беренче саны басылып чыкты. Подписчикларга тизрәк җибәрү өчен редакциянең барлык хезмәткәре төне буе эшләде. Сатарга дигән газета да озатылды. Шулай итеп, эшнең зур өлеше башкарылды. Хәзер инде бу вакыйгага карата булачак реакцияне сабырлык белән көтәргә генә калды.

Кайчандыр Хөсәен татар телендә басылган беренче прокламация халык арасына киткәч шундый ук авыр кичерешләр газабын чиккән иде. Ләкин бу — җилем белән басылган прокламация генә түгел, моны хәтсез киң Россиянең барлык почмагында укыячаклар. Моның тәэсире күп тапкыр көчлерәк булачак. Дүртенче январь көнне эштән кайтып ял иткәндә Хөсәен шулай дип уйланды. Аның кулында авыр хезмәт җимеше булган кадерле нәрсәсе — кечкенә форматта чыккан дүрт полосалы «Урал» газетасы иде. Әгәр Хөсәен хис-тойгыларга бирелүчән кеше булса, хәзер шушы арзанлы кәгазьгә басылган газетаны күкрәгенә кысып торыр иде. Ләкин ул алай итмәде, инде һәрбер җөмләсе күңелгә сеңгән, кабат-кабат укылган газета материалын яңадан тәнкыйть иләгә аша сөзеп укый башлады. Уңышлы күренгән урыннарында ул җан рәхәтлеге тоя, ә кытыршырак булган, я аңлашылмаган төштә эчтән уфтана, йөзен чыта, кашларын җыера иде.

Газета чыгып таралган көнне үк редакциягә аның турындагы төрле фикерләр ишетелә башлады. Әмма болары беренче карлыгачлар гына иде әле. Асылда Оренбурда яшәүче татар интеллигенциясе вәкилләре фикере генә иде, Хөсәен исә түземсезлек белән төп адресатның — гади эшченең, ярлы крестьянның бәя бирүен көтте. Шул максат белән газета таралган көнне үк Оренбур социал-демократлар группасында үзенә якын булган кеше, бюро әгъзасы Леонтьев янына китте. Хәлбуки бу «Җирән» кушаматлы кеше үзе дә, аның мәсләктәшләре дә татар телен-

дәге большевистик газетаның чыгуын дүрт күз белән көтәләр иде. Бу җирле халыклар арасында эшләүне бермә-бер җиңеләйтәчәк, төрки халыклар арасында эш йөртүче егетләрнең кулына тотрыклы, аңлаешлы материал бирәчәк иде. Үзен кызгылт сакал-мыек баскан, беренче карашка революционер булудан да бигрәк вак сәүдәгәр кыяфәтендәге Николай Викторович гадәттәге очрашу урынында, ачыграк итеп әйтсәк, Фельдшерский урамдагы чәйханәдә, Хөсәенне газетаның беренче саны чыгу белән котлады.

— Синең газета аркасында эшләреңнең хәттин ашканлыгын аңлыйбыз без, Хөсәен Мингазетдинович,— диде ул,— синең вакыт юк. Шуңа күрә без, иптәшләр белән киңәшеп, берничә егетне тирә-яктагы авылларга чыгарырга кирәк дигән фикергә килдек. Ләкин безнең авыл белән, аерата татар-башкорт авыллары белән бәйләнеш өзелде. Ике кеше билгеләдек. Берсе аның татарча шәп сөйләшә, әмма икенчесе менә...

— Татар телен белмәгән кешене, әлбәттә, татар телендәге газетаны пропагандалау өчен җибәреп булмый.

— Ә менә башка кеше юк. Меньшевиклар арасыннан җибәрүне мин үзем тиешле санамыйм.

Николай тынып җидер исенә төшерде.

— Хәер, безнең запаста үзеңә мәгълүм Чынбулат бар. Мин үзем аны рәхәтләнеп җибәрер идем. Тик ул укый-яза белми.

Хөсәен уйга калды. Аның газетаны татар, башкорт, казакъ авылларындагы кешеләргә укытасы килә иде. Аларның газета турындагы фикерләрен ишетәсе килә иде. Кемне җибәреп була? Ул «Урал»ның идарә хезмәткәрләрен күңеленнән бөрәм-берәм кичерде. Ләкин алар барысы да моннан эшкә чумган, аларның берәрсен төп эшеннән аеру — киләсе санның вакытында чыгуын тоткарлау булыр иде.

«Фәрхетдин! — дип уйлады Хөсәен, кинәт яктырып. — Сынап карасын әле!»

Хөсәеннең гаҗәпсенүенә каршы, аны Чынбулаттан ишетеп Николай да белә икән:

— Булдыра алырмы соң? — диде ул. — Әле бит Фәрхетдин сыналмаган. Җитмәсә, безнең оешма члены да түгел.

— Мин аны күптән беләм, сыналды ул,— диде Хөсәен.— Аннан мин аны ялгыз үзен генә җибәрү ягында да түгел, аны Чынбулат белән бергә җибәрергә кирәк.

Мәсьәлә шуның белән хәл дә ителде. Хөсәен бүген үк сөйләшеп, егетләрне авылга җибәрү нияте белән өенә кайтып китте.

Урамнарны кар басып киткән иде. Тиздән Гостиный дворга таба юнәлгән бодай төяүле олаулар кәрваны күренде. Юлчы агайлар шактый ерактан киләләр иде, ахры, якалары бәсләнгән, атлары алҗыган, аларның өсләреннән бу бөркелә, үзләрен шулай ук бәс басып киткән.

Хөсәен чаттан борылды, тирән тар чокыр рәвешендә генә арчылган, кар көртләре арасындагы сукмак буйлап үзләре торган Гришковский урамына таба китте.

Хәдичә һаман әле биредәге тормышка ияләнеп бетә алмый иде. Янда туган-тумача булмавы, өстәвенә, Хөсәеннең газета эшенә моннан батуы, ә барыннан да бигрәк әтисенең хәзер үзләреннән тәмам йөз чөерүе аны тирән хафага салды. Ләкин Хөсәен никадәр тырышса да, аның кичерешләрен җиңеләйтә алмый иде. Ул барлык көчен-куәтен биреп газетасын чыгарырга тиеш. Һәм әгәр инде шундый тизлектә өчканда сиңа бәләкәй генә таш килеп бәрелсә дә, ул сине челпәрәмә китереп ташлавы мөмкин. Хәдичәнең кичерешләре аркасында өйдә туган тынычсызлык үзенә күрә шундый таш сыман иде. Әлбәттә, ул хәзергә бик кечкенә, очып барганда комачау ясарлык түгел. Ә ул зураеп китсә!..

Җитмәсә Хөсәеннең бу ике елда сәламәтлеге дә шактый какшый төште. Хәзергә Хөсәен үз сәламәтлегенә үзе хуҗа хуҗасын. Ничек әйтә әле Гёте? Бичара кешеләр, хәтта үз сәламәтлекләрен дә саклый алмыйлар, диме? Әйе, Хөсәен алай бирешмәс!

Ул үзалдына ирен читләре белән генә елмаеп куйды.

Аның уйлары тагы газета тирәсенә күчте. Ничек булса да «Урал»-ны хәвефсез-хәтәрсез, ярлардагы һәм су астындагы ташларга бәрдермичә алып бара белергә кирәк. Әле Уфада ук иң җайлы урын Оренбур икәнлеген исбат иткәндә Хөсәеннең тәкъдимен куәтләп Саммер бу шәһәрне баш шәһәр, жиде юл чатындагы башкала дип атаган иде. Биредә Урта Азия белән Россия очраша. Бу шәһәрдәге Меновой двор иң эре базарлардан санала. Биредә төрки халыклардан татар, башкорт кына түгел, казакъ, кыргыз һәм башка Урта Азия халыклары алыш-биреш итә. Бохара сәүдәгәрләре, ерак-ерак ком чүлләрен дөя кәрваннарында кичеп, бирегә үзләренең асыл товарларын китерәләр. Казакъ далаларыннан бирегә көтү-көтү куй-сарык, мөгезле эре терлек, җылкы куалар. Ә бит Оренбурга сату-алу эше белән килүчеләр бары сәүдәгәрләрдән генә тормый, бирегә бер байга хезмәт күрсәтеп ун гидай, ун көтүче, мал әйдәүче авыл фәкыйре килә.

Әйтәсе дә юк, урын җайлы сайланган иде. Инде менә хәзер, булган бөтен мөмкинлекләрдән файдаланып, газетада язылганнарны киң колач белән халыкка җиткерергә кирәк.

Хөсәен өйгә җитәрәк юлын үзгәртергә булды — газета идарәсенә кереп чыгарга кирәк, дигән фикергә килде. Бәлки Галимҗан китмәгәндер әле. Ул, чарасын күреп, Фәрхетдин белән Чынбулатка хәбәр итсен.

## 13

Алтынчы январь, сишәмбе көнне иртәнге сигездә Оренбурдан, ямщик атына утырып, ике кеше Сарыкташ ягына таба юл тотты. Аларның өсләрендә гади киемнәр. Аягына сарык, башына киң мех койрыклы иске бүрек кигәне Чынбулат, кырпусыз бүреклесе исә Фәрхетдин иде.

Вакыт әрәм булмасын өчен, егетләрне атта озатырга карар кылынды. Алар Сарыкташка кадәр ямщикта барачаклар, аннары, төшеп, юлны җәяү дәвам иттерәсе кала. Татар-башкорт авылларын гизгәннән соң, алар казачий станцаларны үтеп, яңадан Сарыкташ аша Оренбурга кайтачак. Көн аяз, ләкин салкынча иде. Дуслар бер-беренә сыеныбрак печән арасына урнаштылар. Фәрхетдиннең болай иркен ачык һавада куптәннән бирле атта барганы юк иде. Күңеле күтәрелеп китте. Ул, Җаек артындагы агачлыкны үтеп, иркен далага килеп чыккач, үзен бөтенләй бәхетле итеп сизде.

— Ярар, булды бу! — диде. Ул Хөсәен абыйсының шундый җаваплы эшне үзенә тапшыруына да бик-бик шат иде. Ярый әле, ул укыйяза белә. Җитмәсә, «Урал» бик аңлаешлы телдә язылган булып чыкты. Тәгаен, Чынбулат укый белсә, үзе генә китәр иде. Берәү үлми икенче көн күрми, дигәндәй, егетнең кара наданлыгы Фәрхетдингә файда итте. Ләкин шулай да ансыз Фәрхетдиннең эшләре барып чыкмас иде. Чөнки Чынбулат бире як кешесе диярлек, аның тирә-юнь авылларда таныш-белешләре, ышанычлы кешеләре бар. Ул күзле, ә Фәрхетдин телле. Шулайрак килеп чыга инде.

Фәрхетдин җай гына ишетелгән чана табаннары чыжлавын тыңлап шулай фәлсәфә корып барды. Моңарчы урынында капчыгын җайлап урнаштыра алмыйча бик озак кыштырдаган Чынбулат та тынып калды.

Аның белән тагы бер тапкыр кайбер әйберләрне аныклап чыгасы бар иде әле. Ләкин Чынбулат сорауны көтмәде, үзе башлады.

— Без башта Сарыкташта минем күптәнге танышларга сугылырбыз,— диде.— Аннан соң инде, агай-эне белән киңәш-табыш иткәннән соң, тәпи-тәпи күрше авылларга чыгып китәрбез.

— Нигә, ат булмас микәнни?

Чынбулат күмердәй кара, кысык күзләрен тагы да йома төшеп, шикәрдәй ак тешләрен балкытты.

— Анысы инде, туган, һинең осталыкка бәйләнгән. Әгәр укыганыңны яратсалар, белмәссең, бәлкем ат менән дә озатып куярлар.

Фәрхетдин аяк очындагы капчык авызына таба үрелде, бер газета алып, ярым пышылдап үзалдына укырга кереште.

— Әй, парень! Газетта нинди яңалыклар бар? — диде ямщик рус.— Кайчан тәртип урнаша инде. Бу бунтовщик яһүдләрне акылга утырту турында кайчан берәр күңелле сүз булыр?

Фәрхетдин ачу белән ямщикка текәлде. Кайчандыр аны нәкъ менә шундый бәндә эченә тибә-тибә кыйнаган иде. Табак битле, исерек тонык күзле — бу да шул нәселдәндер шикелле.

— По-руски ни каләкәм, — диде Фәрхетдин. — Эта наша мусульманский гәҗит.

Ямщикның йөзенә ачу йөгерде, ул, «о, окаянный чорт» дип сукранып, атына кычкырына башлады. Фәрхетдин укуына чумды, Чынбулат исә тирә-яктагы манзараны күзәтеп, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән Фәрхетдин моңарчы ишетмәгән бер башкорт көен суза. Чана табанnaры һаман бер көе чыжлый, бәләкәй җирән ат үз көенә лерт-лерт юырта. Газетада Казан вакыйгалары да язылган иде. Әле генә күтәренке булып торган күңел кинәт төшеп китте. Фәрхетдин Казанны, анда булып узган коточкыч вакыйгаларны хәтерләде, ачлык газабын кичерүче Нәдерне, Хафазасын, әнисен, этисен исенә төшерде. Бала тугандыр инде бәлки, Хафаза аның белән бик азап чикми микән? Күкрәкләрендә сөте бар микән? Бала бик елак түгел микән? Һай, эти, эти! Бәлки син инде бу минутта үләргә ятасыңдыр. Әллә, бәлкем, сине җирләп әни белән Хафаза елый-елый өйгә кайталардыр... Фәрхетдин күзләрен газетага текәгән, күзләрендәге яшь элпәсе аша берни дә күрми иде хәзер. Күрми, ләкин анданиләр язылганын бик яхшы тоя. Юк, юк, ул газетада язылганнарны барлык кешегә укыячак һәм өстәп үзе дә сөйләячәк!

Чынбулат, күрәсең, моңайган арада уйланып яткандыр, кинәт шыншуыннан туктады да үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

— Бүген яһүднең арт сабагын укытырга кирәк дигән кеше, ул иртәгә башкорт белән татарны тукмыйк дип әйтергә дә күп алмый.

— Мин аны үз тәнем белән татыдым, — диде Фәрхетдин сүзгә кушылып, — сиңа сөйләдем ич.

Алар бик озак тынып-уйланып бардылар.

Фәрхетдин узган төнне бик аз йоклаган иде, ихтыярсыздан оеп йокыга талды. Бераздан туңып калтыранып уянды, җылыну өчен төшеп, чана артыннан чаба башлады. Әле Сарыкташка ерак иде. Анда барып җиткәнче берничә тапкыр төшеп, берничә тапкыр җылынып алырга туры килде.

Сарыкташта алар, ямщик белән исәп-хисапны өзеп, төшеп калдылар. Юл буенча сузылган зур авыл урамыннан барганда Фәрхетдиннең күңеле күтәренке иде инде. Ул Чынбулатка авылдан беренче тапкыр Казанга килгәч башыннан кичкәннәрне дә бераз сөйләргә өлгерде. Чынбулат исә ни өчендер артык җитди бер кыяфәттә иде. Көлсә дә сирәк көлә, тик үзе сүзгә кушылмый, сунарчы якынлашуын тойган җәнлек кебек сагаеп атлый иде. Ахырда ул әйтеп куйды:

— Мин бу җирләргә байтак прокламация ташыган кеше.

Күрәсең, үзен танулары ихтималы борчый иде егетне. Фәрхетдин инде, Егорычтан һәм шул ук Чынбулаттан ишетеп, әле узган җәй башында гына Оренбур төрмәсе янында демонстрантларга каршы атлы казакларның рәхимсез һөҗүмнәре булуын, байтак кешенең яралануын, хәтта бер эшченең үтерелүен белә иде. Менә шул көннәрдән соң Оренбурда гына түгел, аның тирә-юнендә дә кулга алулар башланды. Ләкин шулай да бу минутларда ул үзе дә аңламаган эчке шатлык, күңел көрлеге кичерә иде.

— Тукта, сабыр ит! Алга кара! — диде кинәт Чынбулат. Анда ике стражник ниндидер бер ялан башлы кешене бу якка таба алып киләләр иде.

— Әйдәле монау якка, — диде Чынбулат, кинәт уңга борылып, — менә шунда безнең кирәсе җир.

Фәрхетдин дустына сүзсез буйсынды. Алар каршыдагы ишегалдына ашыгып керделәр дә, кече капканы чак кына ачык калдырып, урамны күзәтә башладылар. Бераздан стражниклар белән әлеге ялан башлы кеше капка турысына җитте. Фәрхетдин күзәтеп торды: кулга алынган кешенең чәчләре җирән һәм бөдрә иде. Тунмасын диептер инде, ул ияк астыннан күтәртеп колакларын чүпрәк кисәге белән бәйләгән. Өстендә исә кыска әрмәк, ә аякларында бер кунычы көйгән ак иске киез итек иде.

— Эшләр начар, — диде Чынбулат. — Димәк, безнең мондагы ояны дошман туздырган.

— Нигә? — диде Фәрхетдин куркынып. — Әллә безгә кирәкле, без кирәсе кеше шушы үземе?

— Юк, ул түгел, тик без кирәсе кешенең дә кулга алынган булуы бар.

— Нишлибез соң инде?

— Нишләсәк тә хәзер миңа сакланырга кирәк.

— Алайса, кая барырга икәнлеген әйт, үзем генә барам, — диде Фәрхетдин. Чынбулат дәшми торды.

— Шулай итмәй дә булмас, — диде ул, ниһаять. — Чөнки син бирედә яңа кеше, тик ни дип әйтерсең соң син анда барып кергәч?

— Һич югында, эш сорап керермен. Утын ярырга кеше кирәкмиме? дип.

— Юк, алай булмай. Син ишегалларына керәсең дә: миңа батюшка кирәк иде, шуның кайда торганын әйтсәгезче, дисең. Нәмәгә кирәк ул сиңа? диярләр. Син әйт: мин, диген, чукынып православный булырга телим, диген.

Фәрхетдин өметсез рәвештә кул селтәп көлеп җибәрде.

— Кит әле, тузга язмаганны? Мин Казанда акча биргәндә дә чукынырга бармадым.

— Соң, тинтәк, ул бит пароль. Шуны әйтмәсәң, һине якын да җибәрмәйләр.

Чынбулат Фәрхетдингә барасы урынны аңлата башлады. Бармый ярамый иде. Һәм Фәрхетдин, капчыгын Чынбулатка калдырып, капканы ачты.

Тиздән ул юлдашының дөрес сизенүен анык белде. Әйтелгән өй янына җиткәч, капка төбендә ул ниндидер ярым шәһәрчә киенгән, матур мыеклы, бишмәтенең мех якаларын күтәртеп куйган, үзе әрле-бирле йөренгән бер кешене күрде. Бу хәерле фал түгел иде. Фәрхетдин бу турыда кисәтелгән иде инде. Ләкин ул шулай да түзмәде, тәвәккәлләп шул кеше янына барды.

— Әйт әле, гаспажин, попның кайда торганын белмисеңме?

— Нинди поп тагы? — диде теге кеше акаеп. — Пошел к черту!

Фәрхетдин башын чайкап әлеге кешегә тәнбиһ белән карап торды.

— Минем чукынып православный булырга иде исәп, болай булгач, гайрәт чикте инде, — дип куйды.

— Әйдә, әйдә, тәртенеп торма монда, юлыңда бул, гололобый!

Фәрхетдин Чынбулат янына кире борылып кайтты. Эшләр шәптән түгел иде. Алар, капчыкларын асып, килгән якка урам буйлап кире юнәлделәр.

— Мин аңлап җиткермим, Чынбулат, ул кеше безгә нигә кирәк соң әле?

— Ниндәй кеше?

— Әнә синең белән бәйләнеш тота торган. Безнең бит эш бер дә андый яшерен-батырын түгел. Без бит губернатор үзе рөхсәт биргән газитне сатабыз.

— Ә синең газит сатарга праваң бармы соң? Аннан соң син тиктомалга газитеңне укый башладың, ди, ә тыңлаучыларың дошман кубызына биючеләр, ди. Алар, дустым, сине хәзер үк өреп чыгарачаклар.

Әлбәттә, башкорт егете хаклы иде.

— Монда якында гына, ун чакрымнар булыр, бер татар авылы бар,— диде Чынбулат,— безгә шунда барудан башка чара калмады.

Алар авыл читендә яшәүче бер корткага кереп ризыкларын капкалап, чәй эчтеләр дә яңадан сәфәр чыктылар. Көн суытты, бәхеткә каршы, ярый әле, җилсез. Тирә-юньдә иксез-чиксез ак кар диңгезе. Уң якта гына, бик-бик еракта, күгелҗем күрән булып әллә урман, әллә вак куаклык күренә. Башка караш тукталырлык бер нәрсә дә юк. Тын. Юлчылар башта тыгызланып каткан ат юлының уртадагы сукмагыннан бардылар. Аннан, юлның читтәге сукмакларына төшеп, янәшә атлый башладылар. Бераз кызулап җылынганнан соң сүзгә керештеләр.

Фәрхетдиннең моңарчы да башкортларны күргәне бар иде. Аерата ул аларны Әлмәт базарында очраткалады. Ләкин ничектер бу көнгәчә аңа бер генә башкорт белән дә болай якыннан аралашырга, уртак тәләкләр һәм бер үк язмыш белән яшәргә туры килмәде. Шуңа күрә Фәрхетдин өчен Чынбулатның башыннан кичкәннәрен сөйли башлавы юлны кыскарту җәһәтеннән генә түгел, гомумән дусны тагы да яхшырак аңлау өчен дә кызыклы иде.

— Мин, — диде Чынбулат, — Урал тавының итәгенә сыенып торган Ялаир кантонындагы Карабаш исемле бер бәләкәй авылда туган башкортмын. Урал тавының гүзәллекләрен беләсеңме син? Зәңгәрсуланып күкләргә ашкан таш кыялар. Тау итәкләрендәге куе карагай урманнары, көмештәй саф су тулып аккан тау елгалары. Менә шундый җәннәттәй урында уздырдым мин бала чагымны. Тик ул көннәр, кустым, җәннәттәй урында узса да, тәмугда яшәгәндәй акты. Атаемны хәтерләмим мин, тик шуны беләм: ул картәтәемнең атасы юлыннан киткән. Ә ул бабам минем Пугачев явында сугышкан батыр йөрәкле Карагол дигән бер башкорт булган. Пугачев яулары җиңелгәч, аны каты җәзалаганнар, колакларын, борынын кискәннәр, шулай әдәм карамаслык котсыз бер гарип ясап җибәргәннәр. Тик аның ярәшкән кызы Айбикә, контонда иң гүзәл кыз булса да, минем картәтәемнең атасын ташламаган, элеккечә сөеп шуңа кияүгә чыккан. Менә минем атаем да шул юлдан киткән. Ябагай гына башкорт булса да, бик зур гайрәт белән һәм бераз дуамалрак та кыланган. Башкортның җире элек бик күп булган бит инде. Ил ак патша кулына күчкәч, аны кискәли башлаганнар. Инде соңгы җирләрне тартып алырга керешкәннәр бер заман явызлар. Шунда халык, түзмәгәч, күтәрелеп патша түрәләренә каршы чыккан. Солдат җибәргәннәр. Атаем бер дигән егетләрдән отряд туплаган да шуларга каршы киткән. Тик нәмә эшләй алсын мылтык, пулеметлар белән килгән бер рота солдатка каршы? Аларның бит мылтыгы да һәммәсендә булмаган. Кайберәүләре ук-җәяләр белән генә коралланган булган. Үзең аңлыйсың, минем атаемның отрядын эһ дигәнче

юкка чыгарганнар да куйганнар. Отрядтагы барлык башкорт егетләрен сөргенгә озатканнар, ә атаемны, Карабаш уртасында урамга дар агачы утыртып, асканнар. Өч көн аның гәүдәсе янына кеше җибәрмәгәннәр. Дүртенче тәүлек киткәндә ниндидер кыю кешеләр төнлә аның мәетен алып авыл читендә җирләгәннәр.

Чынбулат бераз вакыт тынып барды, кара күзләрен кыса төшеп, алга, офыкка карады.

Аннан тәмәкесен бер суырды да, черт итеп төкергәч, күңелсез генә елмаеп куйды.

— Ә инде минем белән кызыксынсаң, мин атаем кебек тә, бабамның атасы кебек тә тәвәккәл эшләр кыйрата алмадым. Мин кулга чалгы алырлык булган көннән башлап үзебезнең авыл баенда батраклык иттем. Бай рәхимсез, усал, иләмсез саран иде. Мин барына да түздем. Түзүемнең бер сәбәбе — ачлык, фәкыйрьлек булса, икенче бер сәбәбе — минем шул карунның кече кызына гашыйк булуым иде. Менә нәмә икән ул мәхәббәт! Шул Җомабикәне бер күрү минем өчен иң зур бәхет иде. Арган-талганнар да онытыла, кимсетелүләр дә йөрәкне әрнетми башлый, әйтерсең лә мин — бөтен Урал тауларының бердәнбер хуҗасы. Күрәсең, минем күз карашларымнан, үзе белән җылы сөйләшүемнән үк сизенгәндер кыз. Очрашканда ул миңа текәлеп, сынагандай, бизмәнгә салып минем мәхәббәтемне үлчәгәндәй карый башлады. Бусы инде — мондый игътибар минем башымны күккә тидерде. Мин байдан китмәс өчен барлык көчемне куеп эшлим. Әдәм башкара алмаган хезмәтне майтарам.

Шуннан, көннәрдән бер көнне хәбәр таралды. Имеш, бай Җомабикәне кияүгә бирергә җыена. Мин, шуны ишеткәч, әле дә хәтеремдә, җиргә ятып, тәгәри-тәгәри еладым. Хәзер инде якты көнем караңгы төнгә әйләнде, кулым эшкә бармый башлады, тамактан калдым.

Шулай җәйге төн иде, мин лапаста кабык арбада йокысызлыктан интегеп ятам, кинәт каршымда Җомабикә пәйда булды. Имәнеп киттем. Ни уйларга да белмим. Бу иелде дә мине кочаклап иреннәремнән үбеп алды. Бичараның йөзе яшькә манчылган, үзе үкси.

— Чынбулат, — ди, — син бит мине сөясең. Коткар мине. Атаем мине үзем яратмаган бер кешегә кияүгә бирмәкче була. Алып кит мине. Качыйк бу җирдән, китик, бәгырем, Урал тауларына, ди.

Мин шундук атылып арбадан төштем.

— Әйдә, мин риза, — дидем.

— Бер генә минут сабыр ит, әзерләп куйган төенчегемне алып чыгыйм, ди бу.

Чыннан да, Җомабикә бераздан төенчеккә төрелгән кием-салымнарын, юлга дип хәстәрләп куйган ризыкны алып чыкты. Без, озакка сузмыйча, ындыр аша авылдан чыктык та тауга таба юнәлдек. Шатлыгымнан бөтен Урал тауларын яңгыратып ай-һай саласым килә минем, кычкырып җырлап җибәрәсем килә. Таш кыяга менгәч, мәхәббәтемне бөтен дөньяга фаш итеп, Җомабикәне кочаклап үптем, куеныма алдым. Без шулай, инде ир белән хатын булып, ике көн юл уздык. Барлык көчкә ашыктык, төннәрен дә озакка тукталмаска тырыштык. Ләкин никах укытмаган хәлдә бер-беребезне ирле-хатынлы кешеләр дип исәпләү икебезне дә рәнҗетә иде.

— Аллаһы тәгалә каршында нинди җавап бирербез, Чынбулат бәгырем, — диде Җомабикә, — болай булгач, без бит инде зина кылучылар. Әйдә берәр авылга кереп мулладан никах укытып чыгыйк.

Әйе, аның сүзләре минемчә дә ул чакны бик дөрес тоелды. Тик авылга керү безнең кай якка китүебезне фаш итү дә иде бит әле, өстәвенә, без анда тукталып никадәр вакытны югалтырга тиеш идек. Мин

күз нурыма шуларны аңлаттым. Тик ул минем сүзләремне тыңлады да әйтте:

— Ай, бәгырем, алай димә. Әгәр без ходай каршына гөнаһлы килеш барабыз икән, барыбер безне алланың каһәре куып җитәр. Әдәм аяклары белән генә ходай кодрәтеннән качып котылмалы түгел.

Җомабикәнең үтенеп, ялварып соравын аяк астына салырлык көч бар идеме соң миндә? Мин, бу эшнең ахыры яман булып бетәсен сизенсәм дә, аның күңеле хакына риза булдым. Без, моңарчы килгән кыргый тау сукмакларыннан олы юлга чыгып, бер бәләкәй генә башкорт авылына кердек. Бер мулла сымак әдәмне таптык, сәдакасын биреп, никах укырга күндердек, бер башкортка кереп бишбармак пешертеп, аннан аштан соң бавырсаклап чәй эчеп, бераз чыбыклык эчендә ял итеп иркәләшеп алдык та, тагын юлга чыгып киттек. Мәгәр безнең никах укытуыбыз безне алланың каһәреннән коткара алмады. Авылдан чыгып тау араларыннан илле чакрым да юл узмадык — артыбыздан йөгерек атлар менгән җайдаклар күренде. Тәгаен, безне куып килүчеләр иде. Әле дә менә, Фәрхетдин, күз алдымда. Без шаулап аккан тау елгасының текә ярында бер-беребезгә сыенып басып торабыз. Аста без менгән текә тауны тегеләр чолгап алган. Кычкыралар, йодрык селкиләр, яныйлар. Хәзер үк түбән төшегез, юкса, атып төшерәбез, диләр. Араларында берсе, юаны, аерата каты җикеренә. «Әнә шуңа бирергә булган иде мине атаем»,— диде Җомабикә. «Без сезнең янга төшмибез, үлсәк үләбез, мәгәр төшмибез!» дип кычкырды ул. Кияү булырга тиешле кеше җилкәсеннән мылтыгын алып атып җибәрде. Пуля сызгырып баш очыннан узды. Без тагы да ныграк сыеныштык. Тегеләр үзара нидер сөйләштеләр дә, атларыннан төшеп, тау сукмагы буйлап, ат койрыкларына тотынган хәлдә өскә менә башладылар. Бер генә чара калды: мин аяк астында яткан ташны алдым да аска тәгәрәттем. Тик моны күреп калган кияү мылтыгын төзәп тагы бер атты. Әлбәттә, ул миңа аткан иде, ләкин, күрәсең, мәргәнлеге шул кадәр генә булгандыр, пуля Җомабикәгә тиде. Ул «аһ» дияргә дә өлгермәде, минем кулыма сыгылып төште. Ул арада мин аска тәгәрәткән таш тагы бик күп ташларны ияртеп тоташ таш агымы хасил итте. Мин, бу явызлар тагы да озаграк тоткарлансын дип, тагы бер зур ташны аска тәгәрәттем дә, Җомабикәмне күтәреп, елга ягына аска төшә башладым. Тау артык текә, төшү өчен артык җайсыз иде. Миңа бер кулым белән тотынгалап, икенче кулыма гүзәл бикәчемне тотып төшәргә туры килде. Кул-аякларым, битләрем ертылып, сыдырылып бетте. Ә Җомабикәнең тәненнән кан туктаусыз ага, тирә-юньне кызарта, юлыбызга эзләр булып тама. Мең бәла белән аска төшеп җиттем, Җомабикәмне шарлап аккан елга ярына чирәмгә салдым. Ләкин... минем кадерлем үлгән иде инде. Мин шашып калдым. Мине бары өстән, тау башыннан килгән тавышлар гына уятты. Безне куа килүчеләр менеп җиткәннәр, хәзер безгә таба төшәләр икән. Мин Җомабикәмне тагы кулыма алдым.

— Юк, мин сезгә Җомамны бирмим, сез аның үле гәүдәсен мыскыллый алмассыз! — дип кычкырдым. Аннан суга кердем, хатынымның салкын иреннәреннән үптем. Хуш, дип аны суга салдым. Ә өстән миңа мылтыктан аталар, ташлар ыргыталар иде инде. Җомабикәм шаулап аккан йөгерек елга буйлап агып китте, мин дә чумдым.

Шул агудан мин тау елгасы агымнарында гына акмадым, Фәрхетдин дус, тау елгасыннан да болайрак тормыш агымнарына эләктем. Туган ягыма бер тапкыр да кайтмадым, аны онытырга тырыштым, Белорецкида эшләдем, алтын прискаларында аркамны бөктем, инде йөри торгач менә Орынбур каласына килеп чыктым. Белем юк, табышлы һөнәр иясе түгел үзем. Бары бер юанычым бар: менә Галимҗан агайлар, Хөсәен агайлар караңгы күгемне өмет йолдызы белән бизәделәр.

## 14

Бәхеткә каршы, Фәрхетдиннәр килеп кергән өч мәчетле татар авылында Сарыкташтагы кебек күңелсезлекләр, кулга алулар бу көннәрдә юк иде. Чынбулатның якын танышы — япон сугышында булып кайткан тәбәнәк буйлы, әмма төптән юан Имаметдин — кунакларны якты чырай белән каршы алды. Хатынына шундук самавар куярга кушты, юлчыларның түрдән узуын үтенде.

— Без озакка түгел, — диде Чынбулат.

— Син шулай инде, — диде хуҗа көлеп. Ул ишек янына куелган капчыкларга күз салды. — Бу юлы товарны күп китергәнсез, тик бит рус телен шәп белүче егетебез шахтага ычкынды шул.

Чынбулат Фәрхетдингә карап кәефләнеп көлеп куйды.

— Бу юлы без башка төрлерәк товар китердек, дустым, монысы син дә, мин дә, Мөхәммәтдәмин дә аңларлык. Гарәпшәнең ярдәме кирәкмәй хәзер.

Ул тантаналы рәвештә капчыкларны берәм-берәм чишеп товарын чыгара башлады. Аларның берсендә газетага язылучылар өчен бүләк брошюра, икенчесендә «Урал»ның беренче саны иде.

Чынбулат Имаметдиннең кулына газетасын да, брошюрасын да тоттырды.

— Менә Фәрхетдин иптәшне хас сезгә шушы нәрсәләр турында аңлату өчен алып килдем, — диде ул. — Бүген үк, мөмкин кадәр тизрәк, күрше-күләнне бирегә җыеп аңлатырга куштылар.

— Безнең үз кешеләр генә булырга тиештер инде, шулаймы? Бу гәзитләр тыелгандыр бит?

— Менә бөтен хикмәте дә шунда, боларны Оренбурда губернаторның үз рөхсәте белән чыгара башладылар. Күрше-күләнне, барлык күргән-белгәнне өең сыйдырган хәтле чакырырга кирәк.

Чынбулат бик мәгънәле генә итеп Имаметдингә карап куйды.

— Тик шулай да күргән-белгән дигәч тә, теге мулла-мунтагай, байгура мөртәтләр табанын ялаучы булмавы яхшырак.

Имаметдин газетаны, аннан брошюраның битләрен ачкалап караштыргалады да кәефләнеп башын чайкап куйды.

— Үз телебездә диген, ә, менә хикмәт, бу дөньяда яшәсәң әллә ниләр күрерсең!

Ул, чәй эчкәч тә, ике улын, бер кызын, хәтта хатынын да бу эшкә җигеп, үзе дә җигелеп, Оренбурдан килгән газета сатучылар янына халык дәшәргә чыгып китте. Караңгы төшкән иде инде, өйләрдә ут алынды. Киләсе кеше җыелып беткәнче байтак вакыт узды. Имаметдин, килердәе җыелгандыр инде, аңлат, Фәрхетдин туган, дигәч, Фәрхетдин, кулына «Урал» газетасының беренче санын алып, сәкегә менде дә аяк бөкләгән хәлдә утка якынрак урнашты.

— Орынбурда, җәмәгать, яңа гәзит чыга башлады. «Урал» исемле ул. Менә шушы гәзит. Без менә Чынбулат дус белән шуны сатарга дип чыккан идек. Безнең исәп инде гәзит сатып кесә калынайту түгел, бары теләк бер генә — менә шул гәзитне таратып, халыкның аң җәһәтен күтәреп булмасмы дигәннең эше. Чөнки дә, җәмәгать, гәзит бик тә әйбәт, аны укыган кеше, шул гәзит буенча гамәл кылып яшәгән кеше, беренче кеше инде, дип әйтсәм бер дә хата булмас.

Фәрхетдин, сүзләрем халыкка нинди рәк тәэсир ясый икән дигәндәй, бер мәл карап торды. Сәкедә урын юк иде инде. Байтак кына кеше идәнгә урнашкан, кайберәүләр хәтта бусагага утырган иде. Кайда да крәстиян бер төрле инде, ләкин, Фәрхетдиннең абайлавынча, мондагы халык хәллерәк яши иде. Җир, җир күп шул монда. Кубесенең өстендә, Казан якларындагы чикмән урынына, тире кайры тун, аякта да байтак кеше пимадан иде.

— Мин үзем алай матур итеп сөйли белмим, туганнар, — диде Фәрхетдин,— мин дә сезнең кебек әле кичә генә җир сөргән, печән чапкан крәстиян. Менә минем сүзләремнең дөреслеген күрсәтү өчен мин, булмаса, сезгә гәзитнең үзен укып күрсәтим.

Фәрхетдин кулындагы газетаны йөзенә якынлаштырды да:

— Менә башта «Идарәдән» дигәнен укыйк. Бусы инде гәзит чыгаручыларның әйткән сүзе.

Ул мөмкин кадәр шома итеп, төртелмәскә тырышып укый башлады.

— Россиядәге иске тәртипкә каршы булган көрәш иркенлекне теләгән һәр сыйныфның моңарчы алдагы сафларының гына эше иде. Әмма хәзер бөтен халыкның эшенә әйләнә бара...

Ишек янындарак чүгәләп утырган бер агай сорап куйды:

— Ә ничек аңларга була инде ул сыйныф дигәнен, мәдрәсәдәге түгелдер бит?

— Юк, сыйныф дип аерым төркем халыкны әйтәләр инде. Әйтик анда, крәстиян сыйныфы, эшче сыйныфы, байлар сыйныфы. Әйтик анда,— Фәрхетдин бер мәл икеләнеп торды,— әйтик анда, муллалар сыйныфы.

— Ә менә мәзиннәр сыйныфы бармы?

Фәрхетдин бөтенләй югалып калды. Сорау белән Чынбулатка текәлде.

— Ничегрәк, мәзиннәр сыйныфы бармы?

— Юк, — диде Чынбулат катгый рәвештә. — Алар инде барысы да шул мулла-мунтагай өеренә керә.

Фәрхетдин укуында дәвам итте:

— Хәзер эшчеләр сыйныфының бурычы үзен сыйнфый дошманнарыннан алдатмыенча, бу көрәшне ахырына чаклы җиткезеп, үзенең олуг булган теләге социализм өчен көрәшкә юл ачуыдыр.

Фәрхетдинне тагы бүлдерделәр. Сәкедә утырган җирән сакаллы, зур борынлы бер кеше ни өчендер елмая төшеп сорый куйды:

— Шул сүзеңне дә аңлатып җибәр инде, иптәш. Ничек әле сатсализм дидеңме?

— Социализм инде шундый тормыш... — диде Фәрхетдин. Чынбулат элеп алды:

— Анда инде, агаем, байлар да булмый, фәкыйрьләр дә, патша да булмый, алпут та. Бөтә кеше бер тигез. Менә шул.

— Ә җирне тигез итеп бирәчәкләрме соң крәстиянгә?

— Алпут булмый дип тораммы? Шуларның җирләрен крәстиянгә өләшәләр инде.

— Анысы һәйбәт икән, — дип куйды агай.

Фәрхетдин тагын укып китте. Бу юлы аны бүлдермәделәр. Күрәсең, барысы да аңлашыла иде.

— ...Бу көрәшне ахырына җиткезү бу көрәштә пролетариатның иптәше булырлык крәстиян халкының һәм шәһәр җирләрендәге фәкыйрь халыкның үзләренең файда вә зарарларын аңлаулары артудан һәм үзара берегешеп кушылуларыннан булачактыр. Шуңар күрә без үзебезнең газетабызда пролетариатны бергә кушылырга өндәп, аның сыйныфына билгеле аңын арттыруга булышу кеби, крестьян халкын һәм шәһәр фәкыйрьләрен дә үзара кушылырга өндәячәкбез.

Фәрхетдинне игътибар белән тыңлыйлар иде. Бу хәл аны тагы да канатландыра төште. Ул идарә исеменнән язылган мәкаләне укып чыкты да аны Хөсәен аңлаткан рәвештә тылмачларга кереште.

Крестьяндагы һәр яңага шикләнеп карау үзенчәлеген Фәрхетдин бик яхшы аңлый иде. Үзенә дә бит шул чирдән котылу өчен җитәрлек кыйналырга туры килде. Хәзер исә ул шуны аңлады: җирсезлектән интеккән авыл ярлысы, бата башлаган кешедәй, тотынып калырлык әй-

бер эзли иде. Үзәк Россиядәге революция давылы бу якларга үзенең сулышын әле яңа гына өргән иде.

Фәрхетдин газетадагы икенче Дума турындагы мәкаләне укый башлады. Чынбулат ярдәме белән алар дума турында да белгәннәрен сөйләргә керештеләр. Ташка баскан сүзгә татар кешесе бөтенләй башкача карый, ул инде аның өчен әйтелгән сүз генә түгел. Ул аңа ышана. Шуна күрә сөйләгәннәр газета сүзе белән дә раслангач, тыңлаучыларның иманнары отыры камил булып китте.

Әңгәмә байтак вакыт дәвам итте. Газетаның һәм брошюраның бер өлеше таратылды.

Әмма бу очрашу никадәр уңышлы барып чыкмасын, ахыры аның яман була язды. Таң алдыннан сыер мөгрәгән чак җитү белән Имаметдин каударланып кунакларны уята башлады. Йокы әйләнмәгән дә иде әле. Ләкин егетләр тиз айнydылар: авыл старостасына куштаннар: Имаметдин өендә патшага каршы сөйләшеп утыралар, дип җиткергәннәр икән. Староста исә, озак уйланып тормыйча, караңгы төшүгә карамастан, приставка донос белән атлы җибәргән. Полициянең, бәлки әле атлы казакларның да бик тиз арада килеп төшү ихтималы бар иде.

— Сезгә ычкынырга кирәк, егетләр, — диде Имаметдин. Бик арылган, йокы артык тәмле, бер дә түшәктән аерыласы килми иде.

— Без бит губернатор үзе рөхсәт иткән гәзитне генә укып утырдык, — диде Фәрхетдин.

Чынбулат бу мәсьәләгә аеграк карый иде.

— Алай димә, губернатор дип тормаслар. Гәзит эшенә дә, Хөсәен агайга да зыяны тию бар. Сак булырга кушмадылармыни безгә?

Ашык-пошык җыендылар да, халык уянганчы, ындыр артларыннан гына олы юлга чыктылар. Көн әле яктырмаган иде. Кар явып киткән. Кары коры, таралучан булса да, урыны-урыны белән юлга өелгән көртләрне ерып бару авыр иде. Бераздан артта калган авылның этләре дә өрмәс булды, тирән тынлык эчендә егетләр, ара-тирә генә берберенә дәшкәләп, озын таякларына таянган хәлдә, һаман алга баруларында булдылар.

— Бер биш чакрым киткәнбездер инде,— диде Фәрхетдин.— Әнә тегендә нәрсә ялтырый соң? Авыл түгелме үзе?

Чынбулат тукталып ук калды. Аннан шомланып Фәрхетдингә таба борылды.

— Бүреләр ул!

Чыннан да Фәрхетдин хәзер генә абайлады, бу тычкан утыдай булып күренгән якты нокталар икешәр-икешәр иде. Фәрхетдин санап чыкты: биш пар нокта җемелди.

— Ач бүреләр, — диде Чынбулат, — аларның безгә һөҗүм итүләре бар.

— Туктап торып булмый инде, — диде Фәрхетдин, — аннан барыбер файда юк.

Чынбулат бөтен даланы яңгыратып айхайлап кычкырып җибәрде, Фәрхетдин ачы итеп сызгырды. Ләкин бүреләр кымшанмадылар да.

— Әйдә, — диде Фәрхетдин. Алар кулларындагы таякларын күтәрделәр дә, бер-берсенә сыена төшеп, алга киттеләр. Бүреләр кешеләрдән тәгаен куркалар, я булмаса ниндидер мәкерле эшкә әзерләнәләр иде. Алар чигенә төшеп юлның ике ягына чыктылар, арт аякларына чүгеп сындай катып калдылар.

— Озакламый көн яктыра инде,— диде Чынбулат үзалдына сөйләнгәндәй.— Көн әз генә яктырдымы, бу юлдан ямщиклар да, олаучылар да уза башлый.

Алар тәвәккәлләп һаман алга бардылар. Бүреләр исә кешеләр якынлашкан саен әз генә чигенәләр дә юл буена тезелешеп тагы утыралар иде...

— Әфәндем! Сезне бер генә минутка мөмкинме?

Хөсәен редакциядән тамак ялгап алу өчен өенә кайтып килә иде. Тавыш ишетелгән якка, артына борылды. Дәшүче шактый бай киемле, европача тегелгән тун, мех бүрек кигән, калын гына, озын буйлы бер кеше иде.

— Рәхим итегез, мин гел илтифат, — диде Хөсәен, туктала төшеп.

— Ялгышмасам, сез Хөсәен Ямашев буласыз бит?

— Әйе, Ямашев. Сезне кем дип белик?

— О, анысы әһәмиятсез, мин кечкенә кеше. Исемемне әйтсәм дә, сез аны шул минутта ук онытачаксыз. Мин сезгә, Хөсәен әфәнде, Оренбур халкы исеменнән кайбер сүзләр әйтмәкче идем. Хосусан, сүз сезнең җәмәгатегез Хәдичә ханым мөхәррирәсе булган яңа гына чыга башлаган «Урал» газетасы турында булыр.

— Мин сезне тыңлыйм, әфәндем, — диде Хөсәен чыраена ваемсыз бер нәзакәтлелек чыгарып.— Бик шат игътибарыгыз өчен.

— Сез, Хөсәен әфәнде, җәмәгатегезгә тапшырыгыз. Оренбур халкы «Урал» газетасын ифрат дәрәҗәдә борчылып каршылады. Безнең бөтен өмитләребез, ул газетаның беренче санын уку белән үк, челпәрәмә килде, әфәндем. Без әле моңарчы «Вакыт» газетасын артык мәдәниятсез телдә яза дип уйлый идек. Җәмәгатегезнең газетасы исә бөтенләй урам теле белән, алай гына да түгел, ломовой извозчиклар телендә бәян кыла. Шулай итеп, мең еллык камиллеккә ирешкән, нәфислекнең иң биек ноктасына менгән телебезне итекчеләр теленә алыштырабызмыни?

— Гафу итегез, мин сезнең сүзләрегезне мөхәррирәгә җиткерермен. Әмма мине шунысы гаҗәпләндерә: сез үзегез менә «Дин вә мәгыйшәт» теле белән дә, хәтта «Вакыт» теле белән дә фикерләрегезне бәян кылмыйсыз ич. Мин сезнең телегез «Урал» теленә якынрак дип уйлыйм.

— Икесе ике нәрсә аның. Изге, мөкатдәс булган матбугат битләрендәге әдәбият теле белән урамда сөйләшү теле бер кайчан да бер була алмый.

— Шулай ул, әфәндем, бер була алмый, ләкин аерма артыкка китсә, шулай ук, минемчә, әйбәт булмый. Гади халык агарсын өчен, ул укыганын аңларга да тиеш бит әле.

Юан кеше, моңа каршы бер сүз дә әйтмәстән, башын артка ташлап көлеп кенә куйды. Хөсәен ирексездән аның сап-сары эре тешләренә игътибар итте.

— Гафу итегез, — диде юаш кына. — Әле бу әйтелгәннәр сүзнең баш өлеше генә. Инде мәсьәләнең аслына күчик. Җәмәгатегезгә тапшырыгыз: газетаның мәсләге бөтенләй мөселман гаммасының мәсләгенә каршы. Аңлатыгыз: дошман җыюның ахыры хәерле булмас. Мин сезгә дусларча гына, хөрмәт йөзеннән әйтәм бу сүзләрне, әфәндем.

— Мәсәлән, газетадагы кайсы мәкалә сезне канәгатьләндерми?

— Барысы да, барысы да, — диде юан кеше, кыза төшеп, — хәтта Оренбур хәбәрләренә кадәр үк. Ни хаҗәтемә кирәк иде Заһидулла хәзрәтнең Мәскәүгә Иттифакыл мөслимингә барганда ике тапкыр юлга дип акча алуын язарга, я булмаса, ни өчен Габдулла Буби әфәндедән «Вакыт»та басылган хатындагы кызларга сайлау хокукы гына бирелсен» диюен тәнкыйтьләргә? Үзегезгә мәгълүм, Буби мәдрәсәсе ислам дөньясында иң тәрәккъый мәдрәсәләрнең берсе, аны болай да житәрлек җәберлиләр. Болар гына җитмәгән, газета ниндидер Сәйфи имзасы куелган «Камил ихтыярлы вәкилләр мәҗлесе» дигән зур мәкаләдә, халыкның ирке һәркайчан көрәшеп, ягъни революция хәрәкәте берлән генә алына, ди. Моны ничек аңларга, әфәндем? Димәк, сез һаман атыш-суешлар дәверен дәвам иттерү ягында? Дума, Государственная

дума хәл итәргә тиеш барысын да, сугышсыз, даусыз. Һәм ул шулай булыр да, аллаһы боерса.

— Сез «Дин вә мәгыйшәт» идарәсеннән түгелдер бит, әфәндем? — диде Хөсәен, ачы елмаеп. Әфәнденең йөзе каракучкылланып китте.

— Минем кайдан булуымның әһәмияте юк! Мин сезгә гамма исеменнән әйтәм.

— Әмма гамманың күпчелек өлешен тәшкил иткән гади кешеләргә «Урал» ошый бит. Мин моны дәлилләп исбат итә алам. Газетага язылырга теләүчеләрнең саны, беренче номер чыккач, икеләтә артты. Ваклап сатылырга тиешле өлеше дә сатылып бетте. Инде кызыксынсагыз, идарәгә бик күп санда хатлар килә башлады. Җәмәгатем укып өлгерә алмый.

— Вә ихтыярсыздан сезгә дә газета эшенә тыгылырга туры килә, шулаймы, Хөсәен әфәнде?

Юан кешенең йөзенә мәкерле елмаю билгесе чыкты.

Хөсәен дә хәйләкәр генә елмаеп куйды.

— Һай, сез бик күпне белергә телисез, әфәндем. Читтән тыңлап торучы сезне охранка кешесе дип уйлавы бар.

Юан кеше кискен рәвештә борылды да чаттагы өй артына кереп күздән югалды. Хөсәен ашыкмыйча гына алга баруында булды. «Беренче һөҗүм булды, ә алда бик күп эшләр көтә әле безне» дип уйланды ул. Йөрәгенә кадалган рәнҗү, ачы нәфрәт хисен ул өенә кайтып кергәндә генә бераз баса алды.

Хәдичә бүген аерата күңелсез каршылады аны. Хөсәеннең яктырып елмаюына да артык илтифат итмәде, кастрюль белән ашны кухнядан алып чыгып, сүзсез генә тәлинкәләргә шулпа өләште. Аннан утырып, кулына кашык алгач кына тирән итеп сулап, сүз башлады.

— Миңа тагы аноним хатлар килә башлады.

— Нәрсә, әллә тагы Җәгъфәрдәнме? — диде Хөсәен, кашларын җыерып.

— Юк, бусы «Җәгъфәр Оренбурский»дан.

Хөсәен сорау бирергә өлгермәде, Хәдичә сүзен дәвам итте.

— «Рус хәрефләре илән укыту» дигән мәкаләне син ялгыш аңлауга юл куярлык итеп язгансың, минемчә.

— Ничек инде? — диде Хөсәен, аптырый төшеп. Авызына китергән кашыгын кире тәлинкәгә куйды. — Сине шул мәкалә өчен гаепләмиләрдер бит?

— Гаепләү генә түгел бу. Ниндидер бер фанатик мине рус миссионеры дип, безне чукындырыр өчен килгәнсең син монда, имансыз син, дип хат язган. — Хәдичә хатны Хөсәенгә сузды. Чыннан да, имзасыз хатта кемдер «Урал» мөхәррирәсен татар халкын руслаштыруга омтылуда гаепләгән иде.

— Ә чынлабрак уйласаң, Хөсәен, синдә дә гаеп бар, — диде Хәдичә. — Син ачык, анык итеп язмагансың. Мин бит сиңа үземнең киңәшемне биргән идем. Синең ялгышуың, канатым, минем җилкәгә төшә.

Хөсәен алдындагы ашны ашык-пошык кына капкалады да:

— Кая, нәрсәсе ачык түгел, — дип, газетаны кулына алды. Ул мәкаләдәге юллар буенча күз йөгертеп чыкты.

— Минемчә, бик ачык һәм дөрес әйтелгән, — диде. — «Инородецларга ана телләрен урыс хәрефе белән басылган китаплардан укытырга дип указ чыкты. Татар халкының бер өлеше указга каршы купты, башка бар нәрсәне онытты. Шушы указ кире алынса, дөньяда җәннәт булыр төсле булды. Ләкин аның кире алынуы берлән... тагы шундый указлар чыкмас дип кем ышаныр икән. Шулай булгач, хөкүмәтнең вак-төяк җәберләренә артык әһәмият бирмәенчә, эшнең төбеннән тоту тиешледер. «Транскрипция» мәсьәләсен бетерү белән генә булмый,

бәлки ул транскрипция мәсьәләсе кеби нәрсәләрне тудырып торган тәртипне төбеннән казып ташлау бу көн халыкның бурычыдыр».

Хөсәен җилкәләрен җыереп куйды.

— Мин биредә бернинди дә мәкруһ нәрсә күрмим.

— Синеңчә, ул транскрипция турындагы указ вак-төяк, әйеме?

— Безнең өчен иң мөһиме сыйнфый көрәш, Хәдичәкәй. Без, минемчә, ул турыда бик күп сөйләштек. Сыйнфый көрәш безнең өчен уңай хәл кылынмаса, милли мәсьәлә Россия шартларында беркайчан да хәл ителмәячәк.

Гадәттә, ашаганнан соң, Хөсәен бераз ял итеп ала торган иде. Бүген, үзе дә сәбәбен аңламастан, ул редакциягә барырга ашыкты. Галимҗан аны көтә иде инде. Ул сөрген шартларында яшәсә дә, үзе артыннан сагалауларына да карамастан, һаман төрле хәйләләр корып, халык арасында, аерата Пименев заводы эшчеләре тирәсендә еш булгалый. «Урал» газетасын Төркстан якларыннан килгән кешеләр арасында пропагандалау эшенә дә ул үзе теләп алынды.

Идарәдә башына казакъның томагын, аягына байпагын кигән Галимҗанны күргәч, Хөсәен көлеп җибәрде.

— Әллә шулай киенгәч, танымадылар дип уйлыйсыңмыни? — диде Хөсәен җитдиләнеп.

— Валлаһи, танымадылар, Хөсәен.

— Әйдә, сөйлә. Газетаны укытып карадыңмы?

Галимҗан кызыл мал китергән бохаралылар янында «Шам» кунакханәсендә булуын, аларның кәрванчы егетләре һәм тылмачлары белән очрашуын, битараф бер кеше булып аларга газета укуын сөйләде.

— Ничегрәк кабул иттеләр соң? — дип кызыксынды Хөсәен.

— Минемчә, начар кабул итмәделәр. Аерата дөнья михнәтен күбрәк татыганнары. Ләкин бик куркалар, бичаралар. Безгә хәбәрләрне төрлеләндерә төшәргә кирәк. Газета укучы санда үз өендәге хәбәрләрне дә очратсын.

— Дөрес, Галимҗан! Тик Бохара яклары...

Алар, көндәлек почта актару белән мавыгып, бермәлгә тынып калдылар.

Безнең наширга беренче номердагы Оренбур хәбәрләренең берелеше ошамаган, — дип куйды Галимҗан.

— Ничек алай?

— Шулай. Әле генә искәрдем: 31 декабрьда җәмгыяте хәйрия мәҗлесен шундый ямьсез итеп биргәнсең, минем кайнагага да, миңа да күләгә төшкән, ди.

— Без бит аңа укып күрсәткән идек.

— Әйтәм ич, искәрми калганмын, ди. Сез мине, егетләр, төпсез кәвешкә утырткансыз, ди.

— Фатих Кәрими әфәнде дә үпкәләгәнме?

— Анысын әйтми.

— Юк, Фатих әфәнде әйткән сүзендә тора торган кеше ул. Ул, мәсьәләгә шундый карашыгыз бар икән, сез аны бәян итәргә дә хаклы, дип уйлый. Ул үпкәләмәс. Ә инде Тимерша әфәнде...

Хөсәен уфтанып:

— Эх, күбрәк подписка җыярга кирәк. Наширның кесәсенә көмеш тәңкәләр чынлап агыла башласа, ул шунда ук беренче марксист булып китәчәк, — дип шаяртып куйды. — Газетаның әле беренче саны гына чыкты. Алай да бомба шартлагандай булган!

— Юк, алай гына да түгел. Ул, чыгу белән, иләк хезмәтен үти башлады: кешеләрнең онын-онга, көрпәсен-көрпәгә аера.

— Идея дошманнары, я моңарчы маска киеп йөрүчеләр турында әйткән дә юк. Хәтта өйгә, гаиләгә тәэсир итте ул.

Хөсәен дустына Хәдичәсенең бүген әйткәннәрен сөйләде. Хөсәеннең суырылып калган борчулы йөзенә, ничектер соңгы көннәрдә аерата зур булып киткән кара күзләренә Галимҗан теләктәшлек белән яратып карап торды.

— Минем гаиләгә дә газетның шаукымы керде, туган, — диде ул, рәнҗү аша елмаеп.— Александра Михайловна, нигә син шул татар газетасы белән булашасың? ди, бетмәгәнмени сиңа рус газеталары? ди. Я булмаса, инде мөгаллим булып байбәтчәләргә рус теле укытып тик акча сугып ят, ди.

— Ә син ничек җавап бирдең соң? — дип кызыксынды Хөсәен.

— Мин бит татар, дидем, — Галимҗан урыныннан торып, тәрәзә янына килде. — Татарча белемле һәм аерата марксист кешеләр аз, дидем. Минем иң беренче бурычым — үз халкыма хезмәт итү икәнен яхшы аңлыйсың ич син, дидем. Минем үз халкымның пролетариатына, фәкыйрь хезмәт иясенә, маякчы кебек утлар кабызып, аны тарихи иң дөрес юлга юнәлтәсем килә, дидем. Юк, аңламый. Аңламый, нишлисең! Без Россиядә яшибез, ди. Мәсьәләне бары рус пролетариаты гына хәл итә, ди, башка милләт белән эш итеп вакланырга да кирәкми, ди.

Хөсәен дә өстәле артыннан чыкты да Галимҗанның иңеннән кочты.

— Авыр безгә, тик сынатмыйк.

Галимҗан бераз тынычлангач, Хөсәен тагы сүз башлады:

— Русча укый дигәннән, минем Хәдичәнең дә укуын дәвам иттерәсе килә. Син аны укытырга алынмассыңмы, Галимҗан?

— Рәхим итсен. Мин аңа көнаралаш бирәр сәгать вакыт багышлый алам.

Алар аскы өлеше бозланып каткан зур тәрәзәдән байтак вакыт хәрәкәтсез генә урамны күзәтеп тордылар. Анда — җанлы хәрәкәт. Печән төягән олаулар уза, дөяләргә атланган, я шыксыз дөяләрнең өркәч араларына ике яклап йөк салган казакълар, төркстанлылар уза. Ул ара да булмый, гүзәл аргамак җигелгән артлы җиңел чанада кукраеп утырган ниндидер шәһәр бае күренеп китә. Өйдән-өйгә кереп йөрүче саилчеләр өстерәлә.

Сүз әкренләп көндәлек эшкә, чираттагы номерга күчеп, авылларга чыгып киткән Фәрхетдин белән Чынбулатка барып җитте.

Егетләрдән әле дә бернинди хәбәр юк иде.

## 16

Тукайга «Урал» газетасы басылып чыкканының бишенче көнендә генә килеп җитте. Аны, хас Габдулла Тукаевка дип, Хөсәен Ямашев үзе җибәргән иде.

Габдулла газетаны өстәлгә җәеп салды да, гадәтенчә, башын чак кына кырынайтыбрак, йотлыгып укырга керешә. Бераздан ул утырган җиреннән аягүрә торып басты, күңелдә өермә булып күтәрелгән дәртле хисләр аны бер почмактан икенче почмакка йөрергә мәҗбүр итте. Кинәт аның үзенең дә узган ел урталарында бик мавыгып суллар белән аралашуы, Җаек социал-демократларының җыелышларына йөрүе исенә төште. Алай гына да түгел, ул бик зур дәрт һәм тырышлык белән аларга булышып та карады: Мотыйгый матбагасында, төнге йокыларын калдырып, алар революция җырлары басмадылармыни?! Габдуллага, яшеренә-яшеренә, Җаек шәһәре урамнарындагы коймаларга листовкалар ябыштырып йөрергә дә туры килде, хәтта Җаек суында балык тотучы эшчеләргә дә аның листовкалар өләшкән чагы булды. Ләкин болар барысы да бер мавыгу гына булган иде, ахры. Ничектер үзеннән-үзе Габдулланы шигырь тагы җәлеп итте. Бөтен дөньясын оныттырды, аңа искитмәле рәхәтлекләр биреп, үзенең кай-

нар кочагына алды. Әйе, ул сәнгать кешесе иде, иҗат итү өчен килгән иде бу дөньяга. Һәм Габдулла моны күңеле белән тоя да иде.

Ә хәзер исә ул Хөсәен җибәргән газетаны укый башлау белән үзен куркаклыкта гаепли, суллар эшеннән аерылуын хыянәт дип саный, ә Хөсәенгә карата олы соклану хисе һәм шул ук вакытта аннан ничектер көнләшү тойгысы туганын сизенә иде.

Дөресен генә әйткәндә, Тукай һич тә Хөсәеннән бу дәрәҗәдә үк кыюлык һәм эзлеклелек көтмәгән иде. Ул яңадан өстәл янына утырды да, бу юлы аерылмыйча, баштанаяк газетадагы материалны укып чыкты.

— Гаҗәп хәл бит бу! — диде ул кычкырып. — Кайсы татар газетасы тагы шулай яза ала?!

Габдулланың бу минутта үз тәэсирләрен, кичерешләрен кем белән булса да уртаклашасы килде. Карый да кайтмый, ичмаса, кая киткән тагы ул? Өстәлдә рус телендәге пьесалар ята. Миңлебай да каядыр китеп олаккан.

Габдулла газетаны алып коридорга чыкты. Үзе белән Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсендә укыган, үзе белән бергә үк мәдрәсәне ташлап чыккан, хәзер исә шушы «Казан» кунакханәсендә конторщик булып эшләүче Сиражетдин янына төште. Аянычка каршы, ул да үз өстәле янында күренми. Ниндидер эш белән аны йомышка җибәргәннәр иде, ахры.

Габдулла инде хәзер акны карадан аз-маз аера белердәй теләсә нинди кеше очраса да, аңгәмә корырга, газетаны күрсәтеп, шуның белән шатлыгын уртаклашырга әзер иде. Һәм бу теләк, һич көтмәгәндә, тормышка ашты. Бүлмәгә кереп, инде булмаса эшкә утырыйм дигәндә, Габдуллалар яшәгән җиденче бүлмә каршындагы дүртенче номердан төз гәүдәле, чибәр, яшь бер кеше килеп чыкты. Өс-башына караганда, интеллигент чырайлы бу кеше үз кул көче белән көн күрүчегә охшый иде.

Тукай мөсафирның алдына барып басты.

— Сезнең минем белән бераз сөйләшергә вакытыгыз бармы, әфәндем?

— Вакытым күп булмаса да, бераз бар,— диде теге, уңайсызлана төшеп. — Нинди йомыш?

— Эш менә шунда, мин сезне менә шушы газета белән таныштырырга теләр идем.

— Гафу итегез, сезне кем дип белик инде?

Габдулла, анысы әһәмиятле түгел дигәндәй, кул гына селкеде.

— Мин биредәге кеше, Габдулла Тукаев булам.

Мөсафирның йөзенә аптырау һәм шатлык билгеләре йөгерде.

— Сез теге шагыйрь Габдулла Тукай түгелдер бит?

Габдулла җавап кайтармады, кунакханәдән эш белән чыгып китәргә җыенган бу кешегә, артык тәкәллефләнмичә юлын бүлдереп, үзе артыннан барырга кушты. Алар Тукайлар бүлмәсенә кереп, өстәл тирәсенә кара-каршы утырыштылар.

— Менә укыгыз әле шушы газетаны. Яңа газета. Оренбурда чыга башлаган, — диде Габдулла тантаналы рәвештә.

Мөсафир газетаны кулына алды. Аның ябык, борчулы йөзе кинәт яктырып киткәндәй булды. Тукай исә аның һәрбер йөз чалымы үзгәрешен күңеленә теркәп, каршында аякларын чалган килеш, кәефләнеп көлемсерәп утыра иде.

— «Урал», — дип мыгырданды әлеге кеше, аннан уйлары белән әллә кай еракларга китте, ахры, бермәл тәрәзәгә күз салып уйкуыннан аерылып торды.

— Укыгыз, укыгыз, — диде Габдулла, сабырын югалта төшеп. — Сезнең әле татар телендә мондый газета укыганыгыз юктыр?

Теге ашыга-ашыга газета баганалары буенча күзләрен йөгертә башлады. Ул беренче битне карап чыкты, икенче битне ачты һәм кинәт газетаны өстәлгә куйды да күзләрен учы белән каплады. Тукай ихлас күңелдән курка калды.

— Ни булды сезгә?

Маңгаен ышкып-ышкып елмаерга тырыша иде теге кеше.

— Юк, болай гына, баш бик каты авыртып китте.

Тукай урыныннан җәһәт кенә торды да:

— Бәлки доктор чакырырга кирәктер? — диде.

— Юк, рәхмәт, хәзер үтә ул. Башымның шундый гадәте бар.

Тукай тәрәзә төбендәге катыргы тартмадан нидер алды.

— Менә, алайса, бер пилюля кабыгыз, хәзер су салып бирәм.

Яңа таныш кулларын селкеп каршы төште.

— Юк, юк, зинһар кирәкми, Габдулла әфәнде, үтте инде, үтте.

Ул яңадан газетага үрелде.

— Я, ничек? — дип сорады бераздан Габдулла.

Теге укуыннан аерылып:

— Искиткеч,— диде.— Нәкъ Ямашевка хас стиль, аңа хас тотрыклылык.

— Бәхетле кеше, үз кыйбласын белә, шуңа күрә барлык манигъларны батырларча җимереп бара ала.

— Мин дә аны бәхетле кеше дип уйлыйм.

Габдулла аптырый төште.

— Нәкъ Ямашевка хас дидегез. Димәк, сез Ямашевны беләсез булып чыга? — диде ул, әйтелгән сүзнең мәгънәсен әле генә аңлап.

— Ул бит бик мәгълүм кеше, Габдулла әфәнде. Ленинчы, большевик, «Пролетарий» газетасының сыйфатлавына караганда, «ортодоксального толка, без малейшей примеси национализма».

Габдулланың аптыраудан күзләре зур булып ачылды. Фәкыйрь ябык, төксе чырайлы бу кешедән моны көтмәгән иде ул. Ямашевны белүе үзе бер гаҗәп хәл, ә инде социал-демократларның Женевада чыга торган «Пролетарий» газетасын укыган кеше булуы... бу инде бөтенләй башка сыймый торган бер хәл.

— Гафу итегез, Сез читтән килгән мөсафир булсагыз кирәк. Сезне кем дип белик?

Ләкин яңа таныш авызын ачып сүз әйтергә өлгермәде, кинәт ишек ачылды да бүлмәгә шаулап Миңлебай килеп керде. Ул артык дулкынланган һәм, күрәсең, аның шатлыгы эченә сыймый иде.

— Апуш, такта кәләпүш! — дип кычкырды ул.— Ишеттеңме: Казанда татар телендә публично спектакль куйганнар!

Тукай Хәйруллинны тыңлаган арада, шагыйрьне белдеклелеге белән аптырашка калдырган кеше урыныннан торды, гафу үтенде, һәм, барасы җиремә соңга калам, юкса, керермен әле, дип, бүлмәдән чыгып та китте.

Ул чыгып киткәч кенә, Хәйруллин искәртте аны.

— Кем иде ул?

— Кем икәнен белергә дә өлгерми калдым синең аркада. Бер мөсафир.

— Ярар, әйдә, мөсафирлар күп булыр. Менә шулай, Апуш,— Хәйруллин Тукайның иңбашына кулын салды.— Казанда Галиәсгар Камал әфәнде җәнабләре җитәкчелегендә беренче тапкыр татар телендә спектакль куелган. Халык ифрат күп булган. Яшьләр Печән базары әһелләренә обструкция оештырырга ирек бирмәгәннәр.

Тукайның йөзенә шатлык йөгерде.

— Нур өстенә нур икән, алайса, — диде ул, өстәлдә яткан газетаны дустына сузып. — Менә моны кара әле, менля кем.

Хәйруллин газетаның «Идарәдән» дигән мәкаләсен укып чыкты, аннан икенче битен ачып, андагы подваллык мәкаләне караштыргалады да:

— Әстәгъфирулла тәүбә вә әтү биләйһи! — дип куйды.

— Син хәтерлисеңме, менля кем, ул Ямашевны? Бик тарихи көнне килгән иде ул, син политзаключениедән кайтып егылган көнне...

— Хәтерләмичә, — диде Хәйруллин, — син аның турында миңа бер тапкыр гына сөйләмәдең инде... Молодец, молодец, — диде Хәйруллин, тагы газетаны караштыргалагач.— Тик миннән булмый. Мин частьта бер кич кундым. Анда да әллә ниләр уйлап бетердем. Күрәсең, берәүләргә ходай революционер булырга язгандыр, икенчеләргә шагыйрь...

— Ә өченчеләргә артист, — дип өстәде Тукай.

— Артист, — диде Хәйруллин. — Ул бит әле салынмаган күкәй генә. Тавык саламы аны, утырамы, чеби чыгамы, юкмы — анысы билгесез, Апуш дус.

— Чыга, билләһи чыга, менә мин әйтте диярсең. Тик артист булу өчен театр кирәк, труппа кирәк.

— Ә менә Казанда спектакль куелган инде. Китәм, валлаһи әгъләм, Казанга китәм, җаным. Башта билет сатучы сыйфатында гына булса да театрга урнашам. Аннан... Ким-хур итмәсләр әле!

— Син корьәнхафиз, карый. Мәкамь белән, үзеңнең гүзәл баритон тавышың белән коръән укый беләсең. Кылануда синнән остарак кешене очрата алганым юк. Син бит, җаным, Мотыйгулла хәзрәтне дә, зиратта хәер өстәп утыручы сукыр суфины да уйнап күрсәтә беләсең.

— Габдулла Тукайны да, — дип куйды Хәйруллин.

— Анысы инде, менля кем, киртәсенә азрак керә. Һәрхәлдә, син Тукайны миннән артык килештерә алмыйсың.

Тукай яңадан өстәлдә яткан газетаны алды.

— Юк, син, әфәндем, Хөсәен Ямашев газетасына шулай да тиешенчә бәя бирә алмадың. Син аны укып чык әле башта. Аннан тагы бер кабат сөйләшербез. Без аңа хәер дога белән котлау телеграммасы җибәрергә тиеш. Ә менә синең булган талантыңа ышаныч тудыру өчен миндә бер тәкъдим бар, әй.

— Хуш?

— Әйдә, Уральскида үзебез татарча спектакль куябыз.

— Икәү генәме? Бу юлы мине теләнче итеп киендермәкче буласыңмы?

Алар узган хәлләрне искә төшереп икесе дә көлешеп алдылар. Узган ел булды бу эш. «Казан» кунакханәсендә уздырылган кичәдә Тукай Хәкимҗан исемле бер шәкертне хәерче итеп киендереп, аның каршына баскан хәлдә, үзенең «Теләнче» исемле шигырен укыды. Халык яратты, мәгәр кичәдән соң теге Хәкимҗанның күзен ачырмадылар. Аның кушаматы шул көннән алып «теләнче» булды.

— Юк, юк, — диде Тукай, — без бу юлы настоящий спектакль куярга тиеш.

Алар спектакльгә кемнәрне катнаштыру, нинди пьеса кулай булуы турында бик җитди рәвештә сөйләшә башладылар. Ахырда эшне Камил Мотыйгый белән сөйләшүдән башларга булдылар. Ул, әлбәттә, катнашачак. Чөнки җырлый башласа, артистларыңнан һич тә ким түгел, хәтта кайчагында мәзин урынына манарага азан әйтергә менә дә, азанны җырга әйләндереп, бөтен мәхәлләне шаккаттыра, синең опера арияләрен җырлаучы артистларыңнан бер дә ким түгел!

Дуслар, уйланган эшне озакка сузмыйча, шул ук минутта Камил Төхфәтуллиннарга киттеләр.

## 17

Тукай белән Уральскида «Казан» кунакханәсендә танышкан кеше Казаннан әле бүген генә килеп төшкән Җәгъфәр иде. Әле Тукай белән очрашу, аның Хөсәен Ямашев турында әйткәннәре, аннан да бигрәк Хөсәен чыгарган газетаны күрүе Җәгъфәрне зиһене чуалырлык дәрәҗәдә тетрәтте. Әйтерсең лә Хөсәен аның алдына килеп басты, әйтерсең лә Хөсәен, Җәгъфәрнең күзләренә туп-туры карап, үзәккә үтәрлек ачы хөкем сүзе әйтә. Әйе, бөтен тирә-юньдә Хөсәен рухы үзен сиздергәндәй иде. Җәгъфәр, югыйсә, бу казакъ далаларындагы шәһәргә урнашып, барысыннан да — үзенең узганнарыннан да, тирә-ягындагы үзен белүче һәм сөйләүче кешеләреннән дә, танышларыннан да, элекке дусларыннан да читләшермен, качармын дип ышанган иде. Гөнаһ шомлыгына каршы, килгән көнендә үк шундый очрашу булсынчы! Җәгъфәрнең аңы, юк, беркем дә сине күрмәде, монда сине беркем дә белми, газета нәрсә ул, ул бит җансыз кәгазь генә дия иде. Ләкин тойгылар, хисләр тынычландыруны түгел, киресенчә, күңелне талыйлар. Һәм шуның аркасында аның вөҗданы газаплана иде.

Җәгъфәр, шул газаплардан котылырга теләп, үзе өчен әле ят булган шәһәр урамнарына чыгып китте. Күпчелеге такта түбәле бәләкәй бура өйләр, кар көртләре басып киткән киң урамнар. Күрәсең, салкын булгангадыр, анда халык бик аз. Чыгу белән бит һәм борын очларын, аяк асларын суык чеметтерә башлады. Юп-юка язгы-көзге пальто Себернең бу зәмһәрир салкыныннан саклый алмый иде, әлбәттә. Җәгъфәр якасын күтәрде, кайтармалы иске бүреген батырып киде. Суык исә һаман үзәккә үткәннән-үтә генә барды. Җәгъфәр, үзенең кызганыч, мескен кыяфәтен читтән карап торгандай күз алдына китереп, эчтән көеп, әрнеп барды. Милләт хадиме, кайчандыр зур идеаллар белән дәртләнеп, мин фәлән итәм дә, мин төгән итәм дип йөргән гайрәтле чибәр егет. Ай-һай, тиз бирештең син, әй! Ә синең белән бергә юлга чыккан Хөсәеннәр хәзер шагыйрьләрне сокландырырлык эшләр башкара.

Җәгъфәрнең биредә бер авылдашы яши иде. Ул кайсыдыр байның кибетендә приказчик. Әле кибетләр ябылмаган. Юлында очраган бер бакалея кибетенә кереп, Җәгъфәр шул авылдашы турында сораша башлады. Ләкин ул кешене бу кибеттә белүче юк иде. Җәгъфәр, эше бетсә дә, суыкка чыгарга куркып, берничә минут кызу мич каршында таптанды. Ниһаять, кибет эчендә артык калырга уңайсызланып, урамга чыкты. Җылыдан чыккан шәпкә һава тагы да салкынрак тоелды аңа. Икенче кибеткә җиткәнче, салкын аның сөякләренә кадәр үткәндәй булды. Кибетнең бусында кызыл мал саталар иде. Приказчикларның күпчелеге — татарлар. Җәгъфәр прилавкага якынлашуга, аның янына кара хәтфә кәләпүшен кырын салган приказчик килеп тә җитте.

— Нәрсә күрсәтергә боерасыз? — диде ул, Җәгъфәрне рус дип уйлап, рус телендә. Җәгъфәр үзенең Хәнәфи абзасын сорады.

— Хәнәфи? Ә фамилиясе ничек?

— Анысын атап әйтә алмыйм. Әгәр атасының исемен фамилия итеп алган булса, Шакирҗан абзый улы инде ул.

— Башта аныклап белегез, — диде приказчик. — Аннан соң сорашырсыз.

Ул йөгереп икенче бер кеше янына китте. Шул вакытта гына Җәгъфәр бу кешенең мыек чылгыйлары аның йөзенә шайтани бер кыяфәт кертеп, тырпаеп торганлыгына игътибар итте.

Ул: «Киемеңә карап каршы алалар шул, нәгъләт төшкере» дип уйлады, өс-башының фәкыйрьлеген искә төшереп. Сукранып икенче очта күренгән приказчикка таба юнәлде. Бәхеткә каршы, бусы кечелекле, кеше хәлен аңлый торган бәндә булып чыкты.

— Ишетеп беләм, — диде. — Тик ул безгә тиң кеше түгел инде, ул бит купец второй гильдий Гимушовның уң кулы.
«Кызык икән» дип уйланды Җәгъфәр.
— Ә ничек табарга була соң аны?
Миһербанлы приказчик иренмичә, авырсынмыйча барысын да бәйнә-бәйнә аңлатты.
Яңадан егерме минутлар чамасы вакыт узгач, суыктан барлык буыннары калтырана башлаган Җәгъфәр авылдашын, ниһаять, эзләп тапты. Кибет конторында өсте ябылмалы биек өстәл артында, тимер кысалы күзлек киеп, кенәгәләр актарып утыручы сузан буйлы, чукмар борынлы Хәнәфи абыйсы алдына барып басты.
— Сез мине танымый торгансыздыр инде? — диде, мескенләнә төшеп. — Мин Җәгъфәр булам, сезнең авылдашыгыз. Батырҗан улы.
Хәнәфи тимер кысалы күзлеген салып өстәлгә куйды.
— Батырҗан улы? Җәгъфәр? Батырҗан бай улымы?
— Әйе, исәнмесез, Хәнәфи абый.
Хәнәфи башта ышанмыйча, икеләнеп, кулын бирмичә торды. Аннанниләрдер исенә төшерде, күңеленнән ниләрнедер аныклады.
— Сөбханалла, — дип куйды, соңыннан исе китеп, — Җәгъфәр шул! Танадым, төсмерләдем, төсмерләдем.
Хәнәфинең елмаюы Җәгъфәргә шундук җан тынычлыгы бөркеде, ул үзенә сузылган сыек буынлы эре, озын бармаклы кулны, хуҗасы кире тартып алмагае тагы дигәндәй, бик тиз эләктереп кысты.
Хәнәфи авылдашының өс-башын тиз-тиз генә күздән кичерде, әчтән тагы бер тапкыр гаҗәпсенсә дә сиздермәде.
— Кайчаннан бирле безнең якларда, энем, Җәгъфәр? — дип сорады.
— Дөнья бик әкәмәт нәрсә икән ул, Хәнәфи абый, ничек ди, бер алдын, бер артын күрсәтә диме?
— Әйе, — диде Хәнәфи. — Ишеткән идек, ишеткән идек. Безгә дә килеп җиткәли туган як хәбәрләре. Батырҗан абзый дөнья куйган икән үзе, васыятендә сине мирастан да мәхрүм кылган икән, мәрхүм. Ишеткән идек. Тик мин сине шулай да бу кыяфәттә үк күрермен дип уйламаган идем. Утыр әйдә.
— Шулайдыр инде, — диде Җәгъфәр юаш кына, — рәхмәт. Атаңнан мираска сукыр бер тиен дә калмаса, аякка басулары авыр икән шул, Хәнәфи абый. Авылда ачлык. Казна җибәргән азык тел очына да йогарлык түгел, шәһәр җирендә дә шулай ук, үзең беләсең, бик авыр дөнья көтүләре.
— Алай да, — дип куйды Хәнәфи, — синең бит инде үзебезчә дә, урысча да грамота юк түгелдер. Теге елларда мәдрәсәдә укый, аннан учитель яллап урысча укырга керешкән, дип тә ишеттек.
— Анысы барын бар, Хәнәфи абый, тик менә таныш-белешсез кая барып керәсең!
— Соң Казанда таныш аз түгелдер инде, шул гомер буе Казан каласында яшәп.
— Дөресен генә әйткәндә, мин анда бәхетсезлеккә дучар булдым.
— Нишләдең?
— Өйләндем.
— Бәрәкәт! Өйләнү бәхетсезлек буламы?
— Була икән шул. Мин бер бай хатынга өйләнеп ялгыштым. Ә ахырда тормышым хатын белән яшәү урынына зобани карчыгы белән яшәүгә әйләнде. Мин бөтенләй Казанны ташлап китәргә мәҗбүр булдым.
Хәнәфи, башын кырын салган көе, бик житди кыяфәттә уйланып утырды.

— Булыр, булыр, анысы булыр, — дип куйды. — Монда инде я пан, я пропал дип эш кыласың. Мин дә баемның ирдән тол калган кызына өйләндем. Тик, әйтмәгәнем булсын, аллага шөкер, хатыннан уңдым. Ә синең барып чыкмаган икән. Булыр, булыр. Мин дә, шулай килеп чыкмагае дип, бик курыккан идем башта.

Хәнәфи, кулларын беркетеп, баш бармакларын берсе тирәсендә икенчесен әйләндерә башлады.

— Алай икә-эн, — дип куйды.

— Шулайрак шул, — диде Җәгъфәр, сүзнең бер дә үз файдасына юнәлеш алмавын сизенеп.

— Ни, болай итик, Җәгъфәр, минем бер-ике сәгатьлек эшем бар. Син хәзергә йөреп тор. Шул бер-ике сәгатьтән соң минем янга килерсең. Алла боерса, аннан бездә чәй эчеп китәрсең. Җиңгәңне, минем тормышны күрерсең. Менә шулай сөйләштекме?

Ул жилет кесәсеннән зур көмеш сәгать алып аны учына салды. Нидер әйтмәкче булып Җәгъфәргә карады.

Җәгъфәр исә бу минутта башына кайнарланып кан күтәрелгәнен тойды. Бермәл сулышы кабынып торды. Ниһаять, әйтми булдыра алмады:

— Хәнәфи абый, мин сезне, өйләрегезгә барып, мәшәкатьләп йөрмәм инде. Мин әле Казаннан бүген генә килеп төштем. Синнән яшерен-батырын түгел, миһманханәдә бер кич кенә кунарлык акчам калган иде кесәмдә. Шәфкать ит, миңа булыш. Кем генә итеп булса да менә шушы кибетеңә эшкә урнаштыр. Синең яхшылыгыңны беркайчан да онытмам.

Хәнәфинең болай да төксе йөзенә ниндидер котсыз, явыз кырыслык билгеләре йөгерде, күзләре зур булып ачылды, аскы ирене бөтенләй юкка чыкты диярлек. Шул кыяфәтендә ул бераз вакыт Җәгъфәргә карап торды да, авылдашының агарынып китүен күреп булса кирәк, йомшара төште. Аннан бөтенләй йомшарды, «Вәт мать чистная!» дип, баш түбәсен кашып куйды.

— Эшкә дисең инде син, име?

— Әйе, зинһар өчен, бик үтенәм.

— Товар белән эш иткәнең бармы соң?

— Бераз бар, — диде күңелсезләнеп Җәгъфәр. — Әнә тол хатын дидем бит әле. Печән базарында аның кибете бар иде.

— Алайса, сынап карарга була. Әтиең хакына, Батырҗан абзый хакына. Бик бай, мөлкәтле, бик гайрәтле кеше иде, урыны җәннәттә булсын.

Ул үзенең контора өстәле янында торган, гадәттәгедән биегрәк утыргычыннан сикереп диярлек төште дә:

— Әйдә алайса, — дип, Җәгъфәрне ияртеп кибет эченә алып кереп китте.

Мич янында почмакта гына посып торган йомышчыны ул бармак белән генә ишарә ясап үз янына чакырды. Җан-фәрманга атылып килеп җиткән унике-унөч яшьлек малайга:

— Менә абыеңны күрәсеңме? — диде. — Күрсәң, шул: абыеңны приказчиклар өенә алып бар. Андагы Гариф тинтәктән калган караватны күрсәт. Ул шунда урнашсын.

Җәгъфәргә карап тагы уйланып торды.

— Син «акча бетте» диден бугай әле, име?

Хәнәфи чалбар кесәсеннән шартлап ачыла һәм ябыла торган зур портмонет чыгарды, аннан илле тиенлек көмеш акча алып Җәгъфәргә сузды.

— Менә хәзергә ашарыңа, фатир бушлай бездә. Шуны житкер. Аванстан алып калырмын.

— Әлбәттә, — диде Җәгъфәр, бик ярарга тырышып.

Йомышчы малай аны кибетнең арткы ишегеннән аландай иркен ишегалдына алып чыкты. Анда зур амбарларга, таш кладовойларга сыенып бәләкәй генә бер агач өй тора иде. Малай шул өйгә таба чапты, Җәгъфәр исә аннан калмаска тырышты.

Бу өйдә квартирга чыгарга, я кунакханәдә торырга мөмкинлекләре булмаган, башлыча яшь, әле өйләнмәгән приказчиклар тора икән. Шыгырдавык караватлар, боз каплаган бәләкәй тәрәзәләр. Күрәсең, мичне артык иртә томалаганнардыр, бүлмә һавасы исле иде. Малай пычрак матрас өстенә ертык одеял, сүрүеннән йоннары күренеп торган мендәр ташланган караватны күрсәтте.

— Менә!

Ул шул сүзне әйтте дә өйдән чыгып та китте. Җәгъфәр бөтен өйдә япа-ялгызы калды. Ашыкмыйча гына чишенде. Итекләрен салды, чолгауларын мич кырыендагы бауга элде, анан өске киемнәрдән генә сузылып караватына ятты. Бусы да, һич югында, ярый иде әле. Һәрхәлдә, урам суыгында газап чигү түгел. Рәхмәт төшсен Хәнәфи абыйга.

Җәгъфәр берара мич артында сайраган чикерткәне тыңлый башлады, аннан изрәп йокыга талды. Төшендә Казанны күрде. Имеш, Гөлжиһан белән киенешеп-ясанышып Проломный буйлап туманный картина карарга баралар икән.



## 18

Хөсәен җибәргән егетләр ике көнгә кичегеп кайттылар. Моның ахыры күңелсез булуы мөмкин иде, чөнки алар, туй мәҗлесендә буласы бар дип, бары өч көнгә генә рөхсәт алдылар.

Шундый хәл килеп чыкмасын өчен Хөсәен алдан ук аяк киенергә булды. Ул комитет члены Николай белән сөйләште, теге исә, үз чиратында, тимер юл мастерскойларындагы егетләр белән бәйләнешкә кереп, алардан Фәрхетдингә дә, Чынбулатка да җил-давыл тидертмәүләрен үтенде.

Ниһаять, арып-талып беткән егетләр көннәрдән бер көнне Оренбурга кайтып керделәр. Әлбәттә, аларны каршы алучы булмады. Тик алар никадәр алҗыган, йончыган булмасыннар, шатлыклары йөзләренә үк чыккан иде.

Кайтып төшү белән, алдан сөйләшеп куелганча, «Урал» идарәсенә ашыктылар. Идарәдә Хөсәен чыгачак номерның макетын әзерләү белән берүзе мәшгүль иде. Егетләрне күргәч, шатланып, урыныннан торды. Исәнләшү өчен өстәл артыннан чыкты, егетләргә утырышырга кушты. Үзе алар каршысына басып:

— Ягез, сөйләгез: юл уңдымы?— дип сораша башлады түземсезләнеп.

— Туктагыз әле, Хөсәен агай, — диде Чынбулат, урыныннан кубып, — башта исәп-хисапны өзәек әле.

Ул кесәсеннән янчыкка салынган бакыр, көмеш акчаларны чыгарып өстәлгә бушата башлады. Өстәл өстендә күпчелеге бакыр тәңкәләрдән генә торган бәләкәй өем хасил булды.

— Менә санап алыгыз.

Хөсәен санап тормады.

— Ярар, соңыннан санармын, сөйләгез, егетләр.

— Крәстияннең биш тиенен түгел, Хөсәен агай, бер тиенен алу да авыр эш. Бигрәк тә гәзит-мәзитләргә акча әрәм итәме соң ул! Тик ме-

нә, күрәсең, безнең капчыклар буш, булган әйбер сатылып бетте. Менә шуннан чыгып эшнең мантыганын үзегез аңлагыз инде.

— Мин анысын күрәм, — диде Хөсәен, — миңа күргән-ишеткәннәрегезне бөтен тулылыгы белән сөйләгез.

Егетләр, бер-берсен бүлдереп, булган вакыйгаларны сөйли башладылар.

Хөсәеннең чырае яктырганнан-яктыра, ачылганнан-ачыла бара иде. Ул бераздан кызыклы маҗаралар турында ишетеп шаркылдап көлә үк башлады. Егетләр, Сарыкташ авылындагы уңышсызлыктан соң, китап сатучылар сыйфатында авылдан-авылга йөреп, тугыз җирдә булганнар икән, һәр авылның үзенә аерым бер кызыклы вакыйгасы искә алынды.

— Татар авылларында гына булдыгызмы? — дип сорады Хөсәен.

— Юлыбызда ике башкорт авылы да очрады.

— Ничек соң, башкортлар үзегезне әйбәт каршы алдылармы?

Чынбулат бик кәефләнеп әйтеп куйды:

— Аны сорап тораһы да юк инде, Хөсәен агай, башкорт та, татар кебек үк, җиргә мохтаҗлык кичерә.

— Анысы шулай, тик татар телендә язылганны аңлыйлармы?

— Аның бит башкорт телендә язылганны укыганы да юк, ул инде башкорт өчен китап татар телендә генә языла дип белә. Рәхмәт әйттеләр. Күзебезне ачтыгыз, диләр.

Егетләр бер авылда фәкыйрьрәк бер хәзрәткә очрауларын сөйләп алдылар.

— Я, ничек соң? Мулла абзагыз арт сабагыгызны укытмадымы? — дип сорады Хөсәен.

— Юк, укытмады. Мулла абзый ике гәзит, ике китап сатып алды.

— Ә бер сүз дә әйтмәдеме?

— Әйтмәде. Тагы килегез шулай, диде.

Хөсәен ышанмыйча баш селкеде.

— Ай-һай, ахыры хәерле булсын.— Ул бераз тынып торды.— Хәер, муллаларның да либераллары юк түгел. «Современник», мәсәлән, аларны дүрт сортка бүлә. Менә сез, егетләр, миңа дөресен генә әйтегез әле. Газетада язганнарның барысын да аңлап тыңладылармы? Гади крәстиян төшенәме, юкмы? — дип төпченде Хөсәен.

— Барысын да аңлап бетереп булмый инде ул, Хөсәен абый.

— Ничек инде? Мәсәлән, нәрсәне аңлап булмый диләр?

— Менә, әйтик, анда «социализм» сүзе, «хакканиятьсез», «интиҗабә...» — диде Фәрхетдин.

— Аңлаттыгызмы соң «социализм» сүзен?

— Анысын инде бик матур итеп Чынбулат аңлатты.

— Ә «интиҗабә»не?

— Анысын без белмибез шул, — диде Чынбулат күңелсезләнеп.

— Ул сүз бит безнең газета сүзе түгел, «Вакыт» газетасыннан алынган Габдулла Буби дигән кешенең язганы. — Ләкин шулай да Хөсәен уйга калды. Тел өстендә бик, бик күп эшлисе бар иде әле. Кайчан соң татар теленең галимнәре, маһир белгечләре булыр?!

— Аны әйтегез дә моны әйтегез. Газета идарәсе белән бәйләнешкә керердәй укый-яза белә торган кешеләр табылмадымы?

Теге ике газета сатып алган мулланы санамаганда, шәһәрдән чирләп кайткан бер шәкерт һәм бер җәдит хәлфә очраган икән.

— Язарбыз, хәбәрләр язып торырбыз, дип ышандырдылар, — диде Фәрхетдин.

— Карарбыз, күрербез, — диде Хөсәен, ул кешеләрнең фамилияләрен куен дәфтәренә теркәп.

Егетләр ул арада үзләренең ач бүреләрдән ничек котылганлыкларын сөйләп алдылар. Эшләре харап буласы икән, бары бүреләр һөҗүм итә башлагач, олаучылар килеп чыгуы гына үлемнән коткарган. Хөсәеннең йөзе чытылып китте. Әйе, моннан соң мондый эшләрне ныграк уйлап, һәр ихтималны күздә тотып башкарырга кирәк дип уйланды. Ул урыныннан кузгалды.

— Бик зур рәхмәт сезгә, егетләр, партия оешмасы исеменнән рәхмәт. Тырышкансыз, нәкъ без теләгәнчә эш башкаргансыз.

Егетләр чыгып киткәч, Хөсәен тагы газета макеты белән булашты. Бу өченче сан иде. Бу санда «Россия социал-демократларының партиясе авыл халкы өчен нәрсә булдырырга тырыша» дигән дәвамлы мәкалә басыла башлый. Хөсәен бу мәкаләне редакцияләү өчен аз көч куймады һәм ул аңа зур өметләр баглый иде. Әнә егетләр: «Авыл халкы кызыксына, аның барысын да беләсе килә», — диләр бит. Тагы бу санда бик усал бер мәкалә — милләт өчен тырышу исеме астында буржуазия өчен янып-көеп яшәүче «Мөселман иттифакы» турында мәкалә бар. Тәгаен, бик каты дау куптарачаклар. Бу санда, баштагы ике саннан үзгә буларак, бер шигырь дә кертте Хөсәен. Әлбәттә, ул Тукай шигыре түгел, хәтта Сәгыйт Рәмиев шигырьләренә дә җитми. Ләкин шулай да ул «Урал»да басыла ала торган, шушы газетаның юнәлешенә туры килә торган шигырь.

Ә бүген менә газетаның икенче саны чыгып таралды. Анда Ленин мәкаләсе басылган. Моңарчы әле татар телендәге вакытлы матбугатта беркемнең дә Ленин мәкаләсен бастырып чыгарганы юк иде. Әйе, бәлки мактанчыклыктыр, ләкин Хөсәен бу хезмәте белән горурлана. Шулай ук мәкаләгә дә зур өметләр баглый ул. Һичшиксез, аны Казан эшчеләре дә, Уфа эшчеләре дә укыячак. Ленин бу мәкаләсендә бик гади тел белән Россиядәге партияләр кем файдасына тырышканлыгын аңлата. Бүгенге көнне бу бик, бик кирәк.

Хөсәен шулай күңеленнән сөйләнә-сөйләнә эшен дәвам иттерде. Корректор һәм экспедитор хезмәтен үтәүче Басыйр идарәгә килеп кергәндә, ул газета материалларын тиешенчә урнаштырып бетергән иде инде. Ирексездән Басыйрның, ят кешедәй урталыкта кыюсыз гына таптанып торуын абайлады. Бәлки акча сорарга кыймыйча торадыр, дип уйлады. Ләкин ул Басыйрдан моның сәбәбен белешергә өлгермәде, теге батырлыгын җыеп, әйтер сүзен берьюлы үзе түнкәртеп ташлады.

— Мин сездә артык эшли алмам инде, Хөсәен әфәнде...

Хөсәеннең әле генә Фәрхетдиннәрнең уңышлы сәяхәтен ишетүдән күңеле күтәрелеп киткән иде. Басыйрның һич көтелмәгән бу сүзе башка суккан кебек булды.

— Ни өчен, ни сәбәптән? — диде ул, шомланып һәм кабаланып.

— Шулай, кичерегез, ләкин эшли алмыйм.

— Соң бит син, дус кеше, болай безне бөтенләй аяктан егасың! Әйт, һич булмаса сәбәбен әйт, Басыйр.

Басыйр үз өстәле янындагы утыргычны читкәрәк тартты да, утырып, маңгаен учына салды.

— Минем гаиләм бар, Хөсәен әфәнде, балаларым бар, аңлыйсызмы? — диде ул, кинәт ни өчендер ачыргаланып.

— Хуш, эш хакын арттырыгыз димәкче буласыңмы?

— Әле җунләп эшли башламаган, ничек итеп эш хакын арттырыгыз диярга җөрьәт итим мин?!

— Мин инде, алайса, аңламыйм,— диде Хөсәен. Ишектән Галимҗан күренде. — Мин инде, алайса, Басыйр әфәнде, синең безне ташлап китәргә теләвеңне һич тә аңламыйм,— дип кабатлады Хөсәен.

— Мин моның сәбәбен беләм, — диде Галимҗан тыныч кына. — Аңа ниндидер хулиганнар, әгәр дә газеттан бүген үк китмәсәң, үтерәбез, дип янаганнар.

Хөсәен аптыравыннан көлеп үк җибәрде, ләкин шундук җитди, кырыс бер кыяфәткә керде.

— Шулаймы, дөресме бу? — диде.

— Әйе, дөрес, Хөсәен әфәнде. Кичә, караңгы төшкәч, мин өйгә кайтып барганда, өйгә җитәрәк, каршыма ике кеше чыкты...

— Кемнәр иде ул, танымадыңмы?

— Юк, танымадым. Бүрекләрен батырып кигәннәр, бишмәт якаларын күтәргәннәр иде. Артымнан килделәр дә мине ике яктан култыклап алдылар. Мин аңымны югалта яздым...

— Татарлармы соң?

— Әллә... Юк... Татар, татар...

Басыйр бәләкәй генә буйлы, ябык, зәгыйфь бер кеше иде. Ләкин ул соң дәрәҗәдә тырыш һәм сүз тыңлаучан. Гомерен сасы мәдрәсәдә уздырып, ахырда тырышлыгы аркасында кеше рәтенә баскан бу корректор бик кызганыч тоелды Хөсәенгә.

— Полициягә, хәзер үк полициягә хәбәр итәргә кирәк, — диде ул.

— Әйе, полиция дигәнең «Уралчы»ларга ярдәм итәргә генә тора инде,— диде Галимҗан ачы елмаеп.— Алар сине урамда суя башлаганнарын күрсәләр дә борылып китәчәкләр.

Шулай. Галимҗан мәсьәләгә айнык карый иде. Газетаның беренче саны чыгу белән полиция колакларын торгызды, алар «борыны яхшы сизә исне».

— Минемчә, менә нишләргә кирәк,— диде Галимҗан.— Әгәр без беренче террорга юл куйсак, алар безгә киләчәктә дә көн күрсәтмәячәкләр.

— Нишләргә соң, синеңчә?

— Террорга каршы террор,— диде Галимҗан кызып.

— Синең шул булыр инде, — диде Хөсәен, ачы көлемсерәп.

— Юк, син көлмә әле, зинһар, әйдә башкача атыйк, террор булмасын, ди. Без бүген арттарак калып Басыйрны өенә кадәр озата барырга тиеш. Ни өчен дисеңме? Теге хулиганнарның кем икәнлеген белү кирәк. Аннан күз күрер.

— Монысы белән мин килешә алам.

Хөсәен, «сез»гә күчеп, корректорга мөрәҗәгать итте:

— Эшләгез, курыкмагыз, без сезгә беркемнән дә кул тидертмәбез. Зинһар, бик үтенәм, салыгыз өстегезне, менә дөнья кадәр корректура карыйсы бар.

Басыйр артык кабаланмыйча гына, икеләнә төшеп, өс киемен сала башлады.

Алар редакциядән чыкканда төнге унбер тирәсе иде. Халык күбрәк йөри торган Николаевский урамыннан бергә бардылар, аннан Басыйр үзенең караңгы Водяная урамына җиткәч, Хөсәен белән Галимҗанны шактый артка калдырып, берүзе китте. Хәзер ашыгып лерт-лерт атлаган Басыйр тонык бер нокта булып кына күренә иде.

— Әйдә, без бик артка калмыйк, белмәссең ул бәдбәхетләрне, — диде Хөсәен. Ашыгыбрак атлый башладылар. Бераздан тирә-ягына карангалап барган Басыйрның кечкенә гәүдәсе бөтенләй ачык булып күренде. Галимҗан кинәт Хөсәеннең җиң очыннан тартты.

— Күрәсеңме?

— Күреп барам.

Урамның икенче ягыннан ниндидер кешеләр ашыга-ашыга Басыйрга таба килә башладылар. Басыйр, аларны күргәч, туктап калды. Бераздан ул, үзен тотарга тырышкан кешеләрдән качып, Хөсәеннәр ягына таба китте. Шулай сөйләшенгән дә иде. Хөсәен белән Галимҗан коймага ышыкландылар. Алардан ерак түгел тимер түбәле өй алдын-

дагы рәшәткә турысында Басыйрны куып килүчеләр бераздан ачык күренде. Алдан килгәне, озынрагы, корректорны якасыннан эләктереп алды, ул да булмады, хулиган селтәнеп аны кар көртенә атып бәрде.

— Әйткәнне тыңламыйсыңмы, мордар! Мә, алайса!..

Ләкин ул корбанына яңадан ташланырга өлгермәде, Хөсәен белән Галимҗан барып аның кулларыннан каерып тоттылар. Ул да югалып кала торганнардан түгел иде, ахры, тиз арада аңына килеп, барлык көченә башы белән Галимҗанның иягенә бәрде.

— Ә, кабахәт, син шулаймыни әле?! — диде Хөсәен. Аның ачуы чиктән ашкан иде. Юкка гына аны учительскаяда көчле булуы өчен Аполлон дип йөртмиләр иде шул. Күз ачып йомганчы, теге кешене ул урам буендагы келәт стенасына китереп сылады. Күрәсең, башы белән бәрелде теге — бүреге очып китте, үзе аңын югалтып кар өстенә ауды.

Ул арада Галимҗан да аякка баскан иде инде. Шуны күреп торган икенче хулиган кинәт чигенә башлады. Бераздан, кире борылып, җанфәрманга чабып та китте.

— Катырак булды, ахры,— диде Хөсәен үкенгәндәй, келәт стенасы буенда яткан кешегә ымлап.

— Чурт та булмас, айныр, — диде Галимҗан. Алар икәүләшеп әле һаман кар өстендә чалкан яткан Басыйр янына бардылар.

— Ник тормыйсың син һаман?

— Киттеләрме тегеләр? — диде Басыйр калтыраган тавыш белән. Хөсәен көлеп җибәрде.

— Тор әле, кил, менә бу бәндәне таныйсыңмы? Ул бит сиңа гер белән сукмакчы иде. Әнә гере.

— Аһа, ярыйсы, өч кадаклы гер ич бу, — диде Галимҗан, карда яткан герне кулына алып.— Башыңа бер тамызган булса...

Басыйр көрт эченнән такыр урынга чыгып кагына башлады.

— Менә кара әле, кем бу? — диде Хөсәен, теге кешенең бит турысында шырпы кабызды.

Карда ятучы куркынып күзләрен ачты.

— Бу бит теге талчокчы Эптери.

— Юри ята ул, дуңгыз,— диде Галимҗан.

Эптерине култык асларыннан эләктереп аякка бастырдылар. Хөсәен аның башына карда аунап яткан бүреген чәпәде.

— Я, сорауга җавап бир инде, егет! Нинди үчләрең бар иде Басыйрда?

— Минем бернинди үчем юк, тәти абый. Мин бит ни...

— Хәзер без аны полициягә илтик, анда телгә килер ул, — диде Галимҗан, бик җитди итеп.

— Юк, юк, зинһар, абый җаннарым, частька илтә күрмәгез.

— Сорауга җавап бирмәсәң, илтергә туры килер шул, мәлгунь! — Хөсәен Галимҗанга мөрәҗәгать итте:— Кеше үтерергә ниятләгән өчен ничә ел әле?

— Илле сигезенче статья буенча гомерлек каторга,— диде Галимҗан.

— Әйт, кабахәт, юкса, сине гомерлек каторгага җибәрәбез, — диде Хөсәен.

— Нәрсә әйтим соң? — диде тәмам куркуга калган Эптери.

— Әйт, кем кушуы буенча бу бичара Басыйрны үтермәкче булдың?

— Без үтерергә гүпчи уйламадык та, без куркытырга гына теләдек.

— Аһа! Өч кадаклы гер белән башка сугып куркыту ярыйсы уен ул! Мин дә сине шулай куркытыйм әле, — дип, Галимҗан герне югары күтәрде.

— Абый җаннарым, алла хакы өчен, алла хакы өчен тимәгез!

— Әйт, кем сине Басыйрны куркыт дип котыртты, кем кушты? — диде Хөсәен.

— Нәрсәләр вәгъдә иттеләр моның өчен? — дип өстәде Галимҗан.
— Әйтсәм, җибәрәсезме соң? — диде Әптери еламсырап.
— Нишлибез, җибәрәбезме дөресен әйтсә? — диде Галимҗан.
— Дөресен әйтсә, җибәрәбез. Ә ялганлаган булса, иртәгә үк полициягә хәбәр итәбез. Шаһитлар җитәрлек безнең.
— Безне, егетләр, Хөббихуҗа котыртты.
— Нәрсә вәгъдә итте? — диде Галимҗан.
— Буш итмәм, акча бирермен, әгәр шул мордар Басыйрны куркытып эшеннән чыгарсын, диде.
— Кем соң ул Хөббихуҗа дигәне? — дип сорады Хөсәен Галимҗаннан.
— Мин аны беләм. Вәли хәзрәтнең мәзине, иң кадим, иң мөтәгассыйп бер фанатик. «Дин вә мәгыйшәт» айгырларының берсе инде.
— Барысы да аңлашыла, — диде Хөсәен.
Галимҗан герне учында сикерткәләде дә кесәсенә салып куйды.
— Бу вещественное доказательство дип атала. Кара аны, Әптери, теге качкан әшнәңә дә әйт: моннан соң да, Хөббихуҗалар коткысына бирелеп, безгә каршы берәр явызлык эшләргә җыенуыңны белсәк, баш бетте, себер киттем, дип исәплә.
— Ә хәзер тай моннан, — диде Хөсәен.
— Юк, нигә? — диде Галимҗан. — Ул хәзер бик әйбәтләп Басыйрны өенә кадәр озатып куя.
Әптери алдан, Басыйр аның артыннан күрәлгән юл буйлап киттеләр. Хөсәен белән Галимҗан шактый вакыт, аларның шәүләсе күздән югалганчы, карап торды.
Хөсәен өйгә кайтып кергәндә төн уртасы иде.
— Нәрсә булды? Ник болай озак? — диде Хәдичә йокы аралаш.
— Сугышып йөрдем, Хәдичәкәй.
— Сугышып? Әстәгъфирулла! «Эчеп йөрүең» җитмәгән, инде сугышырга калдыңмыни?
— Ярар, йокла, мин дә ятам хәзер, калганын иртәгә сөйләрмен.

*Ахыры бар.*

## Хәниф Хөснуллин

### Республикам

Хәл белергә килгән дуслар сыман,
Төрле яктан илләр ураган.
Сәлам, дия чуваш Чабаксардан,
Сәлам бирә башкорт Уралдан.
Иртә саен Мәскәү теләк тели:
— Хәерле көн сезгә, хәерле...
Татарстан! Барыр юлың туры,
Һәр адымың илгә кадерле!
Үткәннәрең синең, Татарстан,
Хәтерләтсә ятим язмышын...
Бүген синең туар көнең башка,
Гел кояшлы, аяз таңлы син.
Каеннарың дәшә гашыйкларны,
Чәчәкләрең караш сорыйлар.
Кешеләрең, сөям сине, тормыш,
Сөям сине, диеп җырлыйлар.
Еллар сиңа яшьлек өстәп тора, —
Карый сиңа җирнең йөз иле.
Хыял гына җиткән орбитада
Йөртә сине заман тизлеге

### Казлар сәлам биреп уза

Апрель ае. Зәңгәр һава
Әйтерсең зәңгәр болын,
Шул болында көн дә чаба
Ут яллы алтын колын.
Көн дә чаба, төн дә чаба,
Җирдә — нурлы тоягы.
Кыяр-кыймас күккә бага
Нәни үлән кыягы.
Ә биектә канат белән
Сыйпый-сыйпый дөньяны,
Кошлар килә, әйтерсең лә
Язның канатлы җаны...
Кошлар килә ...Кыйгак-кыйгак...
Чыңлата яз һавасын.

Казлар сәлам биреп уза
Туган як бусагасын.
«Хуш киләсез!» — дия кебек
Кыр казларына тагын
Төннәрен атлар күтәргә
Яраткан бала чагым.
Атлар көттек болыннарда,
Басуда кетә идек.
Кайчак салам эскертенә
Ятып ял итә идек.
...Хәтер — талмас канат, диләр,
Теләсәң күпме кагын.
Ят булып заман читендә
Калмады туган ягым.
Шуңа күрә, кыр казлары,
Сез түбәнгә карагыз:
Атлар эзен асфальт каплый,
Шәһәр буйлап барабыз.
Киек каз юлы диярсең,
Төннәрен балкый утлар.
Эскерт булган урыннарда —
Тугызар катлы йортлар.
Апрель ае. Зәңгәр һава.
Яңгырый: кыйгак-кыйгак.. .
Кошлар үтә канат белән
Яңа шәһәрне сыйпап.

## Ялгыз капка

Нарат капка ялгыз калган,
Йорты юк, коймасы юк.
Бождрасына юлчыларның
Ат бәйләп куясы юк.
Күптәнме соң, кайчан гына
Яңа җиткергән чакта,
Хуҗасына күпме шатлык
Китергән шушы капка.
Хәзер узган, шаулап узган
Гел кирәк булыр чагы.
Агач өйдән унар катлы
Йортларга күчә Чаллы.
Мондый чакта ничек аны
Өлгерсен ачып-ябып,
Автошәһәр төзергә дип,
Ил белән килгән халык.
Сау бул, капка, авыл улы
Булып әйтәм сүземне:
Авыр ул кадерең булып та
Артык тою үзеңне.
Кая гына карасаң да,
Ташпулат тирә-җире.
Йортсыз капка — ялгыз капка,—
Гүя заман әсире.

## Күгәрченнәр уйнап оча

Күгәрченнәр уйнап оча,
Үзләре күк ак һава.
Кошлар юлына менгән дә,
Йөкләр йөртә кыз бала.

Киң офыкка карап куя,
Ул гүя күк иясе.
Килә: — Йөзләп ир көче бар
Бармагыңда! — диясе.

Сызымда яткан йортларны
Нигезенә бастыра,
Киләчәк белән шулай ул
Бүгенне тоташтыра.

Гөнаһ булыр кыз турында
Бернәрсә белми калу:
Эш урыны — ап-ак һава,
Һөнәре — шәһәр салу.

Кранына тияр-тимәс
Очып китә күгәрчен.
Кыз янында ак бәхете
Уйнап йөри, диярсең...

## Бетончылар юл җәяләр

Бетончылар юл җәяләр,
Уйланып ары үтәм.
Юл йөрүе җиңел түгел,
Җәю күп авыр икән.

Үтелгәндер... Күптер инде
Чакрымнар саны артта.
Шатлансам да, кайгырсам да,
Дөньяга күңелем тарта.

Бабам әйткән иде берчак,
Сүзләре гаҗәп хактыр:
«Тормышны алдың кулыңа,
Яхшырак итеп тапшыр.

Сусаганда чамалап эч, —
Дустыңа су каламы?
Тауга менсәң, каранып мен, —
Кеше менә аламы?

Яши алсаң — яшә йөзләр,
Яшә син меңнәр өчен».
Шул уйларга карап тотам
Яшәвем юнәлешен.

Юл җәяләр... Җиңел түгел...
Уйланып ары үтәм:
Гомер юлын туры итеп
Сузу, һай, авыр икән...

## Бер туташ бүлмә акшарлый

Бер туташ бүлмә акшарлый,
Җырлары чыңлап тора.
Кояш әллә эшен карый,
Әллә җыр тыңлап тора.
Күзе белән буяу төшәр
Җирне сыйпап ала кыз.
Шулай күңел яктылыгын
Бизәкләргә сала кыз.
Теләгендә — тик яхшылык,
Кулларында — бәрәкәт.
Кеше рәхмәтен ишетеп
Яшәү кемгә дә рәхәт!
Шуңа микән, сорасалар
Әйтүе читен өзеп:
Кызы — шәһәр кебек үк яшь,
Шәһәре — яшь кыз кебек.
Шәфәкъ монда алсу-алсу,
Алма манчып алырлык.
— Бу да синең эшме? — диеп,
Кыздан сорап калырлык.

## Үтик әле хуҗа шикелле

*Комсомол-яшьләр бригадасы бригадиры*
*Әхәт Гайнуллинга*

Йөрик әле, Әхәт, урамнардан
Үтик әле хуҗа шикелле.
Әкиятләрдән әллә килгәннәрме,
Туташлары шундый сөйкемле,
Ярты юлым инде үтелгән, дип,
Офыкларга карап тарсынма.
Төшик әле, төшик йолдыз сыман
Атылып бер кызлар каршына.
Юкка гына яшәү бирелмәгән,
Кеше күрсен кемнең кемлеген.
Күңелеңдә — шәһәр урамнары,
Җырларыңда — кырлар киңлеге.
Кош баласын давыл сындырган күк,
Һәр буынны яңа үр көткән.
Җитезлегең — җитмеш яшеннеке,
Кыюлыгың — кырык бөркеттән.
Шәһәр булып яшьлек чәчәк ата,
Сүзләр саран, әгәр сөйләсәң.
Бер кулыңда синең — бүгенге көн,
Бер кулыңда — якты киләчәк.
Егетләрем минем әйбәт, дисең,
Алгы сафта атлап киләбез...
Яңа кала үсеп чыккан саен
Ил сүзенә куәт бирәбез.
Йөрик, Әхәт, әйдә, урамнардан
Үтик әле хуҗа шикелле,
Әкиятләрдән әллә килгәннәрме,
Туташлары шундый сөйкемле.

## Кайтып киләм

Кайтып киләм. Әнкәй, мине
Үпкәләми каршыла.
Чит җирдә ялгыз йөргәннәр —
Балаларың барысы да.
Ялгышларым ялгыз түгел,
Хаталарым шактыйдыр.
Тормышым да тай шикелле
Уйный-уйный чапмыйдыр.
Бәрелдем дә, сугылдым да —
Җилгә түмгәк җитәрлек.
Тик курыкма, иманыма
Алар зыян итәр дип.
Һәм шуңа да чиксез шатмын —
Карадан күбрәк агым.
Гомерем әле бизәлер
Ак эшләр белән тагын.
Авылдашлар кайчак: «Улың
Нишләп йөри?» — дисәләр,
Горурланып әйт, әнием,
Төзи, дип, яңа шәһәр.
Ә бервакыт кояш баер
Сарсаз тауларын узып;
Күрше-күлән дөнья хәлен
Сөйләшер кызып-кызып.
Сорашырлар: кемнәр өйгә
Нәрсә яза хатында?
Һәм сүз чыгар ел да кими
Барган атлар хакында.
Шул вакытта хәтерлә син:
Безнең капка каршыннан
Сигнал биреп узып китәр
Без ясаган машина...
Кайтып киләм. Куанычлы
Яңалыклар бар сиңа.
Бу юлы син, әнкәй, мине
Үпкәләми каршыла...

## Безгә үз җырыбыз кирәк...

Чаллыда ничек сөяләр?
Әллә ни үзгә түгел.
Шул ук кояш, шул йолдызлар,
Шул ук ай бизи күген.
Сүзләре дә гади сүзләр, —
Бабайлардан калган сүз.
Эзләре дә таныш эзләр,
Әйтерсең без салган эз.
Шаярта монда егетләр:
— Алтын безнең бәябез.
Күрешергә барасы бар,
Шуңа дип юл җәябез.
Ап-ак өйләр. Яшь-яшь кызлар.

Кызлары сүзгә зирәк:
— Кичләрен бергә йөрергә
Иркен урамнар кирәк.
Анда урам... Монда урам...
Кыр кырыкка бүленә.
Яңа туган урамнарда
Гашыйклар күп күренә.
Ә еракта әйтерсең лә
Нәкъ әкият дөньясы —
Көмеш тасмадай сузыла
Автозавод бинасы.
Яратам, дип, кем дә әйтә,
Исбат итү — кыен эш.
Хисләрнең иң сафын сорый
Җир күрмәгән төзелеш...
Кызлар-егетләр Чаллыда
Җырлыйлар иртән-кичен:
— Безгә үз җырыбыз кирәк
Җырлап туй итәр өчен.

## Төзүчеләр җыры

Ак болытлар әкрен генә
Йөзә баш очларыннан.
Йортларыбыз биек үрли
Табигать кошларыннан.
Әгәр, дуслар, сез килгәндә
Булалмасак өйдә без,
Ак болытлар арасыннан,
Зәңгәр күктән эзләгез.

Күңел тоя: төннәрендә
Була шундый минутлар —
Рәхмәт сүзе булып балкый
Тәрәзәләрдә утлар.
Әгәр, дуслар, сез килгәндә
Булалмасак өйдә без,
Яңа йортта яшәүчеләр
Шатлыгыннан эзләгез.

Сөйли халык, белеп сөйли,
Һәм ул сүзләр хак икән:
Төзүченең якты гомерен
Шәһәрләр дәвам итә.
Әгәр, дуслар, сез килгәндә
Булалмасак өйдә без,
Ак болытларга үрләгән
Җырдан безне эзләгез...

Чаллы, 1975.

## Рөстәм Мингалимов

# САМОЛЕТЛАР ОЧА

хикәя



Алар шәһәрдән аэропортка йөрүче автобус юлына чыгып, төбенә яфрак сибелгән сары каен янына туктадылар. Бәлки аны ак дип әйтү хәерлерәктер?! Шулайдыр! Ләкин бу каен бүген көзге кояштан сары булып күренә, көнбагыш кырларыннан адашып калган кебек.

Җирдә яшәп картаерга өлгергән, балаларына ияреп авылдан шәһәргә килгәч тә инде унбиш ел гомере узган ана кеше нидер уйланып торды... Ә янында аның яраткан малае... Малае Казанда яши, укырга киткән иде дә бөтенләйгә калды. Бөгелмәгә еш кына кайта, яңадан киткән вакытларында ана кеше аны «Хәерле юл, улым!» диеп, әгәр дус-иш белән кайткан чагы булса, «Хәерле юл, балалар!» дип, аэропортка озатып кала.

Моннан җиде ел элек, газетада малаеның хикәясе чыккач, ул, гарәп хәрефләре белән язылган китапларын вакытлыча читкә куеп, хәзерге хәрефләрне өйрәнә башлаган иде, янәсе: малае ни яза икән, акыллы язамы? Ә хәзер ул газетлар да, журналлар да, китаплар да укый беләә, шуның өчен малаена язу кыенлашты — бусын, бәлки, белеп бетермидер... Әнә ул, аның яшендәге күп карчыкларга хас булмаган тизлек белән үрелеп, сары яфрак өзеп алды. Шундук: «Ник өздем соң әле мин моны?» — дип үкенеп куйды. Гафу ит дигәндәй, каенга карап торды. Аннары: «Барыбер өзелер вакыты җиткән лә инде!» — дип, үзен юатырга тырышты. Кулындагы каен яфрагын сул учына куеп, аны уң кул бармаклары белән сөртә башлады. Башта бер ягын сөртте, аннары малаена карап алды. Каен яфрагының икенче ягын сөртте, кабат малаена күз салып алды. Аннары үзенең кул аркасында кабарып беленгән тамырларына карап уйланып торды да тагын малаена карады. Йөзендәге җыерчыкларында, эчкә батып калган кечкенә, ләкин якты күзләрендә ниндидер моң катыш елмаю бар иде. Аңа җавап итеп малае елмайды.

— Улым, әллә син мине яратып бетермисең инде? — диде ана кеше.

— Бу ни дигән сүз, әнкәй? Каян сиңа мондый уй килде? Мин сине бик яратам.

— Алайса, рәхмәт! — Ул зур бер йөгеннән бушанып, иркенәеп калган шикелле булып сүзен дәвам итте. — Ашыкканың өчен әйтәм

инде, балам. Бигрәк бит, кайтасың да — китәсең дә. Минем яннан китәргә ашыгасың кебек... Хәзер менә автобус килер. Синең белән туйганчы сөйләшә дә алмый калам.

— Шулайдыр шул, әнкәй. Киләсе юлга иркенләбрәк кайтырга булыр инде... Бүген болай сөйләшми торганым өчен үпкәләмә, ярыймы? Сөйләшәсем килмәүдән түгел, мин синең турыда, синең сүзләрең турында уйланып тора идем. Дөресрәге, «Сандугач» сүзе хакында... Хәтерлисеңме?

— Ник хәтерләмәскә, хәтерлим. Сары сандугач дип түгел, соры сандугач дип язарга кирәктер, дидем. Җырлаганда соры сүзе сары сүзенә охшап яңгырый, шуңа ул сүзнең язылышын саташтырганнар бугай, һаман сары сандугач дип язалар, дидем.

— Син аны миңа кичә әйттең, ә мин менә бүген дә шуны уйлап йөрим бит әле...

Шул вакыт аэропортка йөрүче автобус килеп чыкты.

— Ярый, сау бул. Хәерле юл, улым! Бөгелмә аша кая гына узсаң да минем янга кереп чыгарга тырыш. Картайдым да инде. Карт кеше белән ни булмас. Мин сине көтәрмен.

Автобус аэропортка ашыкты. Ана кеше малаена кул болгап торды... Шуннан соң зират почмагыннан борылып, вак кына бакчалар, ял өйләре буеннан урманга юнәлде.

Соңгы елларда ул һәр вакыт, малаен озатып калгач, шушы якын урманга китә. Бер сәгать, ике сәгать йөри. Каеннарны, имәннәрне тотып-тотып карый, үләннәр белән сөйләшә. Урманның теге ягыннан, Бөгелмә аэропортыннан күтәрелгән самолетларны озата. Үзе генә иркенләп бер уйлана. Шунысы гына сәеррәк, бу урманда чагында аның уйлары гел бертөрлерәк була...

Урманда йөргән юлы да аның гел бер үк юл. Бүген дә ул инде ял өйләрен, бакчаларны узды. Тактадан эшләнгән баскыч буйлап түбәнгә, чишмәгә төшә башлады. Шәһәр читендәге иске баскычның күп кенә басмалары сынып җиргә иңгән иде. «Шуларны төзәтерлек тә кеше юк микәнни соң бу тирәдә?» — дип сөйләнде ул үз-үзенә. Чишмәдән куш учлап салкын су алды. Кулларын юды. Юеш куллары белән маңгаен, колак өстендәге чал чәчләрен, муеннарын сыпырды, су эчте.

Чишмәдә кул юу, чәчләрен чылату, су эчү тәртибе дә аның һәрчак бертөрле була. Ул моңа күптән, туган як урманнарында, ирләр сугышта чакта алар урынына печән чабып йөргәндә өйрәнгән. Ул әле дә исәнлеге-хәле китеп торган чакта: «Чишмәгә барып кайтыйм әле, чишмә суыннан файда таба торган идем», — дип, һаман чишмәгә килә...

Кинәт шаулап күккә самолет күтәрелде.

— Минем улым бу самолетка утырмагандыр, әле аэропортка барып кына җиткәндер. Әллә шушында микән? — Ана күңеле улының шушы самолетта булуына да ышанырга тели иде. — Хәерле юл, улым! — диде ул, самолетны карашы белән озатып.

Самолет ерагаеп, бик кечерәеп калгач, баскычтан күтәрелде дә, уңга борылып, урманга керде. Куллары, салкын чишмә суы тәэсиреннән, кызышып-янып тора иде. Бәлки чишмә тәэсире дә түгелдер. Аның куллары, гомумән, шулайрак. Ул әле хәзер дә салкын кыш көнендә дә бияләй киюне өнәп җиткерми. Яхшы, йомшак бияләй булып, кызыгып аны киеп чыкса да, тиздән салып кулына тота. Аннары каядыр куеп югалта һәм моның өчен бөтенләй борчыла белми.

Әнә, каршы як тау битендәге юан тал аңа чишмәләр солтаны Каратөпне, туган авылы Камышлыны, үзенең «Гайниҗамалның чибәр кызы» чагын хәтерләтә.

Тал төбеннән чыккан Каратөп чишмәсе өйгә якын гына иде. Суы улак тутырып ага. Шул чишмәдә ул кер чайкый... Сызганып куйган җиңнәрен төшерергә дә онытып, өйгә кайта... Аннан Галиәхмәт белән танышу... Туй. Ул шуларны уйлый башлады:

— Галиәхмәт Камышлыдан мине Йолдыз авылына алып китте. Матур гына яши башладык. Дөрес, ул бүгенге ирләр хатыннарын көйләгән кебек гел мине көйләп кенә яши алмады. Моңа аның вакыты да җитмәгәндер инде. Шулай да ул яхшы иде, эш рәтен белә, гайрәтле, гәүдәле иде. Кирәк җирдә яклый, күтәрә алды. Бер вакыт Йолдызның Галиәхмәттән күп өлкән, дөнья күрүе белән дә, ачы теле белән дә тирә-юньгә танылган Зариф абзый минем белән телгә килә бит. Тел ул миндә дә бар инде барын, шунысы авыр булды: Зариф абзый әллә уйлап җиткермәде, әллә кызмача булып, шактый ямьсез сүз әйтте. Хәтерем калды, мин бу хакта Галиәхмәткә зарландым. Икенче көнне Галиәхмәт эшкә китәргә җыелышып торган ирләр янына барып исәнләшкән дә болай әйткән:

«Зариф абзый, син мине таныйсыңмы?»

«Таныйм», — дигән теге.

«Юк, танымыйсың син мине. Яхшылап кара әле, абзый! Кем мин?»

«Нишләп сине танымаска инде?! Галиәхмәт син!»

«Түгел шул менә, — дигән Галиәхмәт. — Син алай ялгышма, беләсеңме кем мин? — дигән дә ир-атлардан бераз читтәрәк торучы Зариф абзыйның колагына елмаеп кына нидер пышылдаган. Ул чакта Галиәхмәт Зариф абзый колагына өч җөмлә әйткән, диләр. Беренче җөмләсен белүче юк. Икенчесен дә белмиләр. Өченче җөмләсе: «Мин синең газраилең, абзый!» — дигән җөмлә булган икән, ди. Авыл халкы арасында: «Галиәхмәт пышылдаганнан соң Зарифның колак пәрдәсе тишелгән дә инде төзәлми икән» — дигән сүз дә йөрде. Кеше арттырып сөйләгәндер инде, шулай да ул чакта Галиәхмәт мине яклап, Зариф абзыйга нидер әйткән, күрәсең, чөнки сугыш беткәч, авылга кайтасылар кайтып җиткәч, җәйге бер көндә Зариф абзый миңа:

— Иркә, минем газраил кайтмады бит, ә? — диде.

Мондый сүзне кеше тиктомалдан чынлап әйтмәс, шаярып әйтсә дә миңа авыр булды. Шулай да сиздермәдем, мин дә шаярып җавап бирдем:

— Кайгырма, абзый. Үзе кайтмаса, малайлары үсә бит әле, — дидем...

Кайтмады шул...

1941 ел. Ирләр вагонга төялде, сугышка китәләр. Келәүле станцасын калтыратып поезд кычкыртты. Поезд кузгалып китте. Ике кулыма ике улымны күтәреп вагон артыннан йөгерәм. Галиәхмәтнең ярты гәүдәсе, бүтән кешеләр гәүдәсен узып, вагон ишегеннән чыккан. Үзе кул болгый, үзе кычкыра: «Мине көт, кайтам мин! Мин кай-та-ам!..» Шулай китте дә кайтмады... Ул шулай мине гомеремдә бары бер генә алдады...

Урман юлы йомшак.

Аэропорттан, урманның теге ягыннан тагын самолет күтәрелде.

— Минем улым әллә шушы самолетта микән? — диде ана кеше, самолетка карап торды. — Хәерле юл, улым!

Бу сүзләрен әйткәндә ул инде урман аша үтә торган юлның байтак өлешен узган иде. Сулыш алу иркен, атлау җиңел. Урманга килсә аңа гел шулай тоела: еракта — йөрәк түрендә — яшьлектән калган нидер бар кебек. Ни булыр ул? Заман җылысы шулай сизелә бугай?!.

Сугыш уты заманны җылытмый иде шул. 1941 елның кышында, күкрәк баласын калдырып, Соснау урманнарында билдән кар ерып урман кисте ул. Хатын-кыз булып туганың өчен утырып үкенергә дә вакыт юк иде ул чакта. Норманы үтәргә, кешедән калышмаска кирәк... Төнлә ул, кешеләр йокларга яткач, 7—8 чакрымдагы авылларына малаен имезергә ашыга, ә зуррак малаена үз өлешеннән калдырган ипиен алып кайта. Тизрәк, тизрәк! Ашыгырга кирәк. Кайтып балаларны шатландырасы һәм урман кисүчеләр йокыдан уянганчы, алар янына яңадан килеп җитәсе бар бит әле...

...Безнең якның кышкы төннәрендә, таулы юлларында, болай ашыкканда, җәяү калсаң, кеше түгел, болан булу гына бәхеттер.

Урман кисү эшләре көйсезрәк барып, кайтып килү мөмкинлеге чыкмаган чакларда, аның сөт тулып сызлаган күкрәген ашыга-ашыга суырып бушатучы мордва хатынын ул хәзер күрсә икән! — Туганкай, Елена! — дип, аны кочаклап елар иде бер. — Әйдә, миңа кайтыйк әле. Тормышым яхшы, балаларым начар түгел. Миндә кал әле, Бөгелмәдә кал, беразга гына булса да кал әле?! — дияр иде аңа. Ул бит әнә шул Еленалар белән Соснау урманнарында чакта норма өчен, балалар өчен, Галиәхмәт өчен, ил өчен аякта калырга, егылмаска, җиңәргә кирәк дигән теләк белән яшәде.

Салкын кышларның котын очырып, ул карлар, җилләр эчендә иске киемнәре белән җилфердәп йөрде. Кырлар уртасындагы эскерт башларына менде. Ул печән төягән чаналарны еракттан, шыгырдавыннан, эзеннән таныйлар иде.

Ул җигәчәк арба яки чана тәртәләре арасына керергә үгезләр күрыкты. Үзе ул үгезләрдән дә, кешеләрдән дә, эштән дә курыкмады. Юкса, авылда бүтән хатыннардан әллә ни аерылып тормаган, урта буйлы гына хатын иде. Аның хезмәт көне һәр вакыт кешенекеннән күбрәк, һәр вакыт аның ике кулына өч эш булды.

Сугыштан соңгы авыр елларда ул төнлә сыер фермасында каравылда торды, көндез атлар карый иде. Колхоз малларына үлчәп азык җибәрү дә аның өстендә. Бусы да ансат түгел, авыл аша узучы җилгә ияргән бер бөртек саламның да хисапта чагы. Җир ачылыр көнне күзаллап, күңел шатланырга тырышса да, әле мартның башы гына. Елга тиң тоелган шул март аен гына бер күз алдына китергәндә дә аның күз алдында өч төрле үзгәреш пәйда була.

Беренче үзгәрештә дөнья тирес өеменә әйләнә. Әйе, бихисап күп тирес! Атлар астыннан чыгарган авыр, чи тирес! Җир юк, су юк — тирес кенә!.. Ә бер елны әлеге шул март аенда болай булган иде. Килешенгәнчә, атлар астын чистартуны Исмәгыйльгә калдырып, ул ерак кырга саламга китте. Кайтканда юл буе чананың әле уң ягына, әле сул ягына йөгереп чыгып, аны аудармаска тырышты, үр менгәндә атка ярдәм итте, тәмам арыды. Ә кайтып җитсә, ул караган атлар асты чистартылмаган иде... Сизә, тәнендә көчсезлектән гайре берни сизелми. Эшләү түгел, эш турында уйласаң да күз аллары караңгылана... Шулай да ул атлар астын чистартып, тиресне капканың тышкы ягына чыгарып өярлек көч тапты:

— Иртәгә кырга илтермен, бүгенгә ат та арыды, үземнең дә җеп өзәрлек тә хәлем калмады, — дип уйлады. «Атларның астын Исмәгыйль карап куяр», дигәне өчен, ләкин сүзендә тормаганы, алдаганы өчен бригадир Бисбахны урамда күрү белән туздырып ташларга булып, өенә ашыкты. Бусаганы атлап идәнгә басуга, бөтен аруларын онытып:

— Балаларым, канатларым! Ачыктыгызмы? Хәзер ашарбыз, хәзер, — диде. Кайсысы әнкәсенә нидер сөйләп, кайсысы ашыйсы килүен белдереп, балалары шаулашкан арада ул болай уйлап алырга да өлгерде: «Әле генә иртә кебек иде, кич тә җитте. Бетмәсә дә

бетми икән бу эш. Тизрәк кайнар чәй белән тәнгә көч өстәп алырга да атлар янына барырга кирәк. Саламнан кайтышлый артка калучы атлар булды. Алар исән-сау кайтып җитте микән? Ә минем Дәрьял сынатмады, — дип уйлады ул һәр вакыт алдан йөрергә яратуы белән танылган ат турында. «Үзе ябык кына булса да, нык тарта, күндәм»...

Шундый уйлар белән урам як тәрәзәгә күз салуы булды, тыннары кысылып куйды: «Бу нинди тамаша? Авыл башы Исмәгыйл әле яңа гына тугарып куйган Дәрьялны, көне буе эшләп, хәлдән тайган Дәрьялны җигеп алган да кырга тирес илтә. Тау хәтле, дөнья хәтле төягән малкайга!»

— Балалар, мин хәзер керәм!

Ул өстенә кимәде, аягына иске галош элде дә урамга йөгерде:

— Туктале, Исмәгыйл! Сиңа кем Дәрьялны җигәргә кушты? — диде дә ул барып Дәрьялның йөгәненә чат ябышты.

— Бригадир кушты, — диде Исмәгыйл.

— Нинди бригадир, кем турында сөйлисең син? Әллә берәр пәйгамбәр турындамы?! Дәрьял бүген үзенекен эшләде. Сиңа тирес чыгару өчен иртән ат бирелгән иде, ник шуны җикмәдең?

— Апа, — диде соңгы вакытта бик тиз үсеп киткән, үзен беренче сорт батыр егет дип саный башлаган Исмәгыйл. — Мин сиңа әйтәм бит. Бисбах абзый үзе кушты. Ат каршыннан кит! На-а-а, Дәрьял! Кит, апа!

— Эх, син әле шулаймы?! — диде апа дигәнең. Тагын шуңа абыйларыңның тешен коеп төшерерлек сүз өстәп, чананы үрәчәсеннән күтәреп юл кырыендагы ак карга әйләндереп тә салды. Бер хатын түгел өч ир дә болай җиңел аудыра алмас кебек күренгән авыр тирес карда капланып ятканына шаккаткан беренче сорт егет Исмәгыйл яңадан малай булып калды.

— Апа...

Арган атның янәшәсенә үзе җигелергә әзер апаң инде Исмәгыйл кулыннан дилбегәне дә алган иде:

— Энем, Исмәгыйл, — диде ул инде шактый сабырланган тавыш белән. — Бар, Бисбах абзыеңа әйт. Атыңны табыгыз. Ул бәлки артык авыр эштә булмагандыр, шуны ачыклагыз. Бу тиресне моннан алырга иде. Тизрәк килеп җитсәгез, үзем дә төяшермен. Ә Дәрьял үзенә тиешлесен эшләде инде, — диде дә атын үз йортларына таба алып китте. «Тизрәк чәй эчеп алырга кирәк», дип уйлады үзе.

Бу хәлне Исмәгыйлдән ишеткәч, Бисбах: «Кит әле, шул тиресне аудардымы? Үзе генәме?» — дигән. Һәм ияген янгарак борган килеш, шактый вакыт селкенмичә дә уйланып торган. Гаҗәпләнүчеләр аннан башка да күп булган. Тик яшьләр белән бер рәттә эшли дә, сөйләшә дә алучы, кирәк булса авыл мулласы вазифасын да үтәүче Мөхибулла бабай гына бу хәлгә бер дә исе китмичә:

— Яңалык түгел бу, мин ул хатынның җенле икәнен күптән беләм, — дигән.

Март ае исенә төшкәндә аның күз алдына килә торган икенче үзгәрештә дөнья сыер көтүенә әйләнә. Әйе, офыклардан-офыкларга тоташкан сыер көтүе!

...Ул төнге каравылда тора. Төннең инде яртысы үткән. Ә ул, янәшәсендәге яшьтәше Маһиягә нидер сөйли-сөйли, кулына фонарь тотып һаман йөри: озын абзарның әле бер ягыннан, әле икенче ягыннан уза. Әле абзар эченә кереп китә дә сыерлар арасыннан бер күренеп, бер күмелеп бара. Әле туктап тора. Шулчак ике хатын хәлсезләнеп күтәрәмгә калган һәм аягына басарга тырышканда ялгыш янтыгына егылган сыерны кузгатырга, җайлабрак яткырырга кере-

шәләр. Югыйсә, аның сыртына ук әйләнеп калуы, малчылар теле белән әйткәндә, өяләп үлү куркынычы бар.

— Һайт, хайванкай! Кузгал, кузгал...

— Бер, ике, өч...

— Һо-о-оп! Менә шулай! Яз җиткәндә генә теге дөньяга китәргә җыену ярамас безгә...

— Акколак, юләркәй, ятар өчен тигезрәк урын таба алмадыңмы әллә? Нихәл, Тузбаш! — диешеп, сыерлар белән сөйләшеп үтәләр... — Күзләренә, авыз тирәсендәге төкләренә, пуфылдап көрсенеп куюларына караганда, сыерлар каравылчыларны һәм дөнья хәлен дә аңлыйлар кебек. Сөйләшкәнне тыңлап торалар, бары сүзгә генә кушыла белмиләр шикелле.

— Маһия, әллә нигә бигрәк арытып җибәрде, буыннар бушады. Бар әле әзрәк ял ит. Аннан соң мин хәл җыеп алырмын. Шулай чиратлап хәл җыймасак, үзебез дә күтәрәмгә калырбыз дип куркам. Икебезгә бер «егет» бар иде, ул да чирләп киткән, ичмасам, бүген килмәячәк.

— Кара әле, шулай икән шул, Хәертдин абзый чирләп киткән икән. Тизрәк терелә күрсен инде. Ансыз кыен... Килеп чыкмый калганы юк иде. Кайбер төндә икешәр мәртәбә килә иде. Ничек иренми икән ул?

— Тазалыгы бар бит. Күз генә тия күрмәсен үзенә... Ул бит әле монда гына да булмый. Амбарны да, кибетне дә әйләнә. Менә шуннан уйла, амбар кая да, ферма кая да, кибет кая?! Аннан өе?! Шулар арасында йөреп төне дә, гомере дә үтә инде аның.

— Карчыгы да ачуланмый, күрәсең?

— Карчыгы миңа көндез очрады. «Абзыегыз чирләп тора әле, — ди.— Шуңа күрә йөрмә инде, йокла, картаеп беткәнсең, яшьләр синнән башка да яшәрләр дип, өченче көн төнлә бераз үзен ачуланып ташладым», — ди.

— Шул төнне фермага килде, чирләп торуын безгә дә әйтмәгән булды, ә? Карчыгына ни әйткән икән соң?

— Һи-и-и, тавы-ы-ык! Сиңа ни кирә-ә-ә-әк? Йокла йокың килгәч. Кешеләр бит ала-а-ар. Барып хәлләрен бели-и-им. Күңелләре күтәрелеп кит-ә-әр. Шундый чакта йоклап буламы-ы? — дигән дә чыгып киткән.

— Йөрәге түзеп өйдә ята торган кеше түгел инде. Чынлап чирлидер, күрәсең.

— Я, бар әле, Маһия. Ял итеп ал.

Берсе китеп баруга, икенчесенә күңелсез булып калды:

«Төнлә икәү йөрсәң аерылгач кыен була шул. Башта ук берүзең булсаң җиңелрәк, — дип уйлады ул. Кара төннәрне ялгыз уздырган чаклар аз булмады». Аннары ул җырлап карарга булды. Җырның исә бөтен мәгънәсе дә, моңы да, кешегә юлдаш икәнлеге дә төнге тынлыкта ныграк аңлашыла:

Төнлә төшләремдә күрдем,
Сары күлмәк өстендә.
Сары күлмәге өстендә —
Ни булган ул мескенгә?

Өстемдәге аклы күлмәк
Саклап кисәм дә туза.
Аклы күлмәк ничек туза —
Яшь гомер шулай уза.

Болар аның яраткан җырлары. Ул яраткан җырда төс була, әйтик: зәңгәр, яшел, алсу һәм башка төсләр...

Кинәт ни өчендер аның күңеленә Галиәхмәтнең икенче һәм соңгы

хатындагы юллар килде: «Смоленск урманнарында сугышабыз. Якташлар да бар. Монда агач урынына кеше егыла. Син дә, балалар да кайдадыр шушында, тик күрешергә генә мөмкинлек юк сыман...»

Бераздан фонарь уты яңадан сыерлар арасында йөри башлады.

Ә бераздан:

— Маһия, тор! Бәла килде бит әле. Тизрәк тор, харап булдык. Карлыгач үлә.

— Чынлапмы? Кая барыйк? Кемгә барыйк? Карлыгач нәсел сыеры иде. Аның бу хәлгә калырын беркем сизмәде. Ул үлсә, безгә ни әйтерләр?

— Сабирга йөгер, Маһия. Хәзер үк килеп җитсен. Мин Бисбахка керәм.

Бисбах өйдә булмады. Ниндидер эшләр белән күрше авылга, председатель янына китте, диделәр. Моннан өч йорт аша торган Мөхибулла бабайны уятырга туры килде:

— Бабай, тор әле. Фермага төшик. Бер сыер үлем хәлендә. Пычак ала төш, юкса, малны бөтенләй югалтуыбыз бар. Бисбах өйдә юк икән. Маһия Сабирга киткән иде дә әллә ул өйдә, әллә юк. Әлегә күренмиләр. Зинһар, бабай? Авырсына күрмә!

Бабай тиз булды. Сөйләнә-сөйләнә ишегеннән чыкты:

— Йа, алла! Йа алла! Шулай дисең, алайса? Хәле пычакка ук җитте, дисең? Бисбах та юк дисең? Председательгә ерак. Сабир нишләп озаклый икән? Йа мәүлә! Йа мәүлә! Хуҗалар каршында ничек җавап бирербез икән соң?

— Курыкма, бабай. Хуҗалар каршында мин җавап бирәм! — диде чакыра килгән хатын... Хуҗалар каршында җавап бирү ансат эш түгел... Ә Сабир өйдә булмаса? Я килеп өлгермәсә? Мөхибулла бабай «мин бу эшкә катнашмыйм» дисә? Тагы кемне эзләргә? Вакыт үтә... Фәкать шуңа күрә генә үзеп, «мин җавап бирәм» дип, кеше ышанырлык итеп әйтүе иде бу.

Икенче көнне иртүк аны җавап бирергә чакырдылар. Дөресрәге, барысын да чакырдылар, тик үзе уйлавынча иң гаепле кеше беренче булып килеп җитте. Керде дә ишекне япты:

— Исәнмесез.

Көндәлек җитди мәсьәләләр, ашыгыч сөйләшүләр, эш бүлүләр уза торган бригада өендә председатель үзе генә иде:

— Исәнмесез? — диде председатель, бу сүзнең асыл мәгънәсенә аңлашылмый торган төсмер салып. Бу колхозда әле яңа кеше булса да, председатель тәрәз янына нык баскан, яшь кеше булса да, баса белеп баскан, кузгалмый да, әйтерсең бригада йортының таза идәне дә аның аякларының бер өлеше иде:

— Уз, — диде ул хатынга. — Син бүген төнлә нинди җинаять эшләгәнеңне беләсеңме?

Җинаять сүзен ишетүгә кичә көн буе Дәрьялга чана тартышып, төн буе каравылда торган, җитмәсә, Карлыгач белән булган шундый күңелсез хәлне кичергән хатынның йөзе ап-ак булды.

— Яман хәл булды шул, иркә, яман хәл булды. Башка берни эшләргә дә куәтем юк иде... Бөтенләй юкка чыгар, ите булса да калсын дип уйладым, — диде ул, үзен тыныч тотарга тырышып.

— Ите булса да калсын?! — дип кабатлады председатель бер куркыныч фикер әйткән кебек. — Ит кирәк булдымы? Ә колхозга сыер кирәк! — дип тавышын тагын да күтәрә төште. — Ник суйдыгыз? Ник Сабир абыйны көтмәдегез? Ул ветфельдшер, ул завферма, сыерны нишләтергә икәнен син түгел, ул әйтер иде.

— Сабир озак торды... Аның йокыдан уянганын, фермага килеп җиткәнен үлем сыер кырыена ятып көтеп торырга тиеш иде дип уйлыйсыңмы әллә?

Бу сораудан соң кыска гына тынлык булып калды һәм тынлыкны тагын председательнең көчле тавышы бозды:

— Дөресен әйт, йоклаган идегезме? Сыер өяләп үлгәнме? Үлгәч суйдыгызмы? Йоклап мал үтергәнегезне сизмәсләр дидеңме? Син хәйләкәр, беләм мин сине.

— Мине белүең яхшы. Ә менә бер нәрсәне белмисең икән. Өяләп үлгән малның сыртына кан йөгерә. Ул тунагач күренеп тора. Районнан мал врачлары китертерсез — карарлар, әйтерләр.

— Мин сине монда акыл өйрәтергә чакырмадым... Ул нәсел сыеры! Үлгәч суйсагыз да, үлгәнче суйсагыз да башбаштаклыгың өчен башың китә бит хәзер.

— Иркә, син хуҗа кеше. Мин каравылчы, хайван күргән кеше, аның эчендә күпме җаны барын беләм. Карлыгач үлем хәлендә иде. Суйдык. Миңа мондый эшне үз өстемә алу бик авыр булды. Хәзер дә авыр... Нишлим соң? Нишлим? Инде сыер өчен үзем суелыйммы? Пычак бирәсеңме?

— Башта сырыңны фермага төшереп куй, аннан бирермен, — диде председатель.

Ул арада бригада өенә чакырылган кешеләрнең башкалары керде. Сугышның икенче елында аягы яраланып, сугышка яраксыз дип табылып кайткан ферма мөдире ветфельдшер Сабир да килде.

Килгәннәр арасында иң кыска сөйләүче Мөхибулла бабай булды. Ул болай диде:

— Җиде төн уртасында бер хатын-кыз ярдәм сорап миңа килгән икән, бармый кала алмадым. Сабирны көтеп карадык, тагы да көтсәк, каза моннан зуррак була иде.

— Мин сыерны суйганнан соң гына күрдем, — диде Маһия бәлага кысылган итәген ертмыйча алырга теләп. — Каравылда икәү тора башлаган көннән үк, — диде каршында утырган иптәшенә карап, — ул үзен миңа хуҗа кебек итеп тотты. Һәр вакыт ул әйтте — мин тыңладым. Бүген төнлә дә миңа бераз ял итеп алырга кушкан иде, мин ял итәргә киттем. Күп тә үтмәде, килеп мине яңадан уятты. Тизрәк тор, Карлыгач үлә, Сабирны алып кил, диде. Мин Сабирга йөгердем. Башта ишеген шакыдым, ишетмәде. Аннан соң тәрәзәләрен кагып уяттым. Без фермага төшеп җиткәнче, Карлыгачны инде суйганнар иде.

— Мин сыерда алай егылып үләрлек чир дә күрмим, — диде ферма мөдире Сабир. — Аны ашыгыч рәвештә суярлык сәбәп тә күрмим. Дөресен әйтергә кирәк, мине бу эш аптырашта калдырды. Җавапсызлыкмы бу, әллә моны корткычлык дияргәме?

— Сабир, — диде шунда аны бүлеп, инде гаепле булуына да ышана башлаган, әмма мондый ук гаепләүне күтәрә алмасын сизгән хатын. — Астың белән уйлама син, өстең белән уйла! — Ни сөйләгәнеңне колагың ишетәме? Син колхоз каршында сөйлисең? Син бит колхоз өчен бер чиләк су да күтәрмәгән хатының каршында түгел, минем каршыда сөйлисең. Авызыңны ачып миңа пычрак чәчәсең. Уйлый белсәң, сиңа мин бар җирдә тыныч кына утырырга кирәк! Яулык бәйләп утырсаң да ярый.

Башта Сабир, сөйләсен инде бу хатын, җүләрлеген күрсәтсен, дигән кебегрәк утырган иде дә хәзер тыныч кына кала алмады. Урыныннан кузгалып куйды. Нидер әйтергә теләп тамак кырды. Председатель өстәл шакыды. Ләкин ярсып киткән, инде кычкырып ук сөйли башлаган хатын-кызны тыю мөмкин түгел, аны тыңлап бетерү генә хәерле иде:

— Хезмәт көнем ирләрнекеннән күп. Синең өчен дә, синең хатының өчен дә эшли торган хатын мин... Ирем синең өчен сугышты!

— Барыбыз да сугыштык! — диде Сабир.

— Юк, син сугышмадың. Сугышкан кеше солдат хатынына корткыч дигән яла якмас. Син сугышны барып күрдең дә тизрәк борылып кайттың, — диде Сабирның сүзенә рәнҗүдән ни әйткәнен ишетмәс дәрәҗәгә килгән хатын.

— Ә бу кая калган? — диде Сабир да кычкырып һәм сугышта яраланган аягына күрсәтте.

— Туктагыз, болай ярамый, — диде председатель, ләкин гаепле хатын сүзен дәвам итте:

— Сугышта Газизләр, Инсафлар, Нәдершалар, Галиәхмәтләр калды... Дошманга каршы күкрәк киереп барган чакта, аларның күкрәкләре яраланган. Алар кайтмады. Син курыккансың, җиңел яра алып тизрәк кайтыр өчен, гәүдәңне чокырга салып, аягыңны күтәреп, дошманга күрсәтеп яткансың!

Сабир калтыранып куйды. Ул хаксыз сүзнең кабер ташыннан да авыр икәнлеген гомерендә беренче кат шулай сизде сыман. Кулындагы таягын ыргак кысты, ләкин түзә алмады:

— Суга-а-ам! — дип кычкырып урыныннан торды.

Сабирны тынычландыра башладылар.

— Хәзер үк тынычланыгыз, Сабир абый! Апа! — дип кычкырды председатель.

Ә хатын туктамады:

— Сук әле, сугып кара әле Галиәхмәт хатынына! Таягыңны алып немец вата алмаган башыңны ватармын!

— Су-га-ам! — дип кычкырды Сабир һәм кулындагы карама таягын һавага күтәрде...

Март ае уена килгәндә, аның күз алдында өч үзгәреш була дигән идек. Өченче үзгәрештә дөнья үз хәленә кайта. Әйе, бик күп төрле вакыйгалар сыйган дөнья була бу. Юри генә офыклар белән чикләнеп күренә торган чиксез зур дөнья! Анда җир-су бар. Ай шул ук күптәнге матур ай икән, кояш та күптәнге җылы кояш. Сыерлар — сыер, атлар — ат, этләр эт була. Кешеләр яши, бергә эшлиләр, авырлыкларны бергә җиңәләр. Бер-берсен каршы алалар, озаталар. Юллар офык аша үтә... Әйе, әйе, бу мизгелдә дөньяны ул шулай күрә. Ә теге чактагы март аенда болай булган иде:

Сабирның «сугам!» дип кычкырган сүзен дә, Маһияне дә, Мөхибулла бабайны һәм яшь председательне дә — бер генә авылдашын да гаепләргә теләмәгән, биредә әйтелгән сүзләр өчен дә, төнлә килеп чыккан хәл өчен дә үзе гаепле сыман эченнән янган, ләкин шул халәтен йөзенә чыгармыйча утыра белгән Бисбахны да бригада өендә калдырып, ул Хәертдин абзыйга китте.

Бу якларның беренче коммунисты, беренче булып колхозлар төзеп йөргән Хәертдин абзыйның өе авыл халкы өчен бригада өеннән дә, председатель өеннән дә ким түгел иде. Бирегә һәркем килә, бигрәк тә хатын-кызлар, уйлары чуалган хәлдә калып, гел ак күлмәктән йөри торган, зур күзле, киң маңгайлы, мәһабәт гәүдәле, бөтен законнарны яттан белә торган нечкә күңелле Хәертдин абзый катына килә.

Аның өе авылның нәкъ уртасында. Авылда туган һәр кайгы да, һәр шатлык та тиз арада шушы өйнең ишеге аша үтә. Бүген төнлә фермада булган хәл дә инде Хәертдин абзыйга килеп җиткән иде. Ул, чирләп йөрүенә дә карамастан, торган, киенеп урамга чыгарга әзерләнә икән. Каравылчы хатынның килүен тәрәзәдән үк күрде:

— Уз, әйдә-ә-ә. Уты-ы-ыр! — диде ул, керүчене аяк өсте каршылап. Абзыегызга-а чирләргә дә ярамы-ый... Кушмаганны эшләп куяс-ыз. Нәрсә булды-ы-ы, сөйлә-ә-ә? — диде ул. Калын тавышы һәр вакыттагыча җанны тынычландыра торган булып чыга. Ләкин фермадагы хәлне яңадан тыңлагач, бригада өендә булган күңелсезлекне

дә ишеткәч, аның сөйләшкәндә әле бит очы, әле калын иреннәре тартылып-тартылып куя иде:

— Синең кем икәнеңне-е-е... авыл белә-ә-ә, абзыең белә-ә-ә! Ачыкларбы-ы-ыз. Кайгырып йөрмә-ә-ә. Во-о-от! Син безнең турдан узганда-а, урамга басуың минем өйгә сизелә-ә, идәннәргә сизелә-ә-ә. Гел шулай йө-ө-өр! — диде ул һәм күзләрен яшерү өчен читкә борылды. Во-о-от! Әйдә-ә-ә, мин дә чыгыйм әле-е-е. Син кайт, балаларың янына-а-а... Бар да уза-а-ар. Во-о-от!

Узды... Март ахырында, ат тибеп кулын сындыргач, кулы бозыла башлап, врачлар аны кисәргә карар чыгарса да, кистермәгән, «Әшем күп, миңа әле ике кул да азрак», — дип елмаерга тырышкан, шул чакта да һаман эшләп йөргән һәм әле бүген дә исән-сау йөргән каравылчы хатын: «Бар да хәвефсез узды», — дип әйтсә, бу зур хата саналмас.Ләкин менә узган сугышны гына онытып булмый.

Булмый! Алайса, Хәертдин абзый, Мөхибулла бабай, Сабирларның, Бану, Зәйтүнә кебек яшьтәш хатыннарның инде мәрхүм икәннәрен шулай ук онытасы иде. Булмый! Аның хәтер күзләре артык зур һәм тирән. Уйламыйча булдыра алмый икән ул...

Әле моннан берничә ел элек авылга кайткач, Маһияне күрә алмыйча китүен уйлап та борчыла. Безнең якларда озак тормаган теге яшь председатель Куйбышевта, өлкә эшләрендә икән, яхшы булган, үскән, дип уйлый ул аның турында.

Ә «мәңгелек бригадир» Бисбах турында ул болай да фикер йөртә:

— Аңа инде күптән председатель булырга кирәк иде. Тәҗрибәсе зур. Кешеләр белән эшли ала. Үзе һаман бригадир икән. Күтәрелергә теләмәгәнме? Әллә безнең авыл үз кешесен вакытында үстерә белмиме?

Узган гомерләрне шулай сүтеп-чорнап, хисаплап-барлап, ул Бөгелмә урманнарындагы таныш сукмактан атлады... Күзге урман шундый җиңел күренә, иңгә салып китеп булыр кебек.

Урман артыннан, аэропорттан тагын самолет күтәрелде.

— Минем улым вакытында китә алды микән? Әллә шушы самолетта микән? Хәерле юл, улым! — диде дә ул озак кына самолетка карап торды. Әллә инде Карлыгач турындагы уйлар тәэсиреннән, кинәт самолет пычакка охшап оча башлады. Әйтерсең, ул сәер пычак бик ерактан оча. Әйтерсең ул — кайчандыр ил өстенә, Галиәхмәтләр өстенә ябырылган дошман йөрәген тишеп үткән дә, узган кара көннәрнең йөрәкләрен тишеп үткән дә, бүгенге якты көннәрне саклап оча...

Илдә көннәр һәм эшләр якты булганга чын күңеленнән шатлана белүче ана кеше, инде урманны үтеп, асфальт юлга чыкты. Шушы юл аны өенә, кече малае янына, Газинур урамындагы ундүртенче йортка илтә.

...Ул олы малаен озатканда басып торган сары каен янына җитте. «Күзләр элек тә шулай сары иде, Дәүләткол ягы урманыннан Мөбин чокыры буйлап кайтканда авылга мине сары яфрак ташкыны төшерә иде», дип уйлады.

Аэропорттан тагын самолет күтәрелде. Ана кешегә тагын аның улы шушы самолетта кебек тоелды.

— Юктыр. Көн яхшы, самолетлар оча. Минем улым вакытында киткәндер, — диде үзе яңадан.

Аннары үз сүзенә тәмам ышанды, инде ераклаша барган бу самолетта бөтенләй таныш түгел кешеләрне күз алдына китерде. Ул шул кешеләргә тизрәк теләгеен әйтергә ашыкты:

— Хәерле юл, балалар!

## МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА



# МУСАГА—БЕЗНЕҢ ЧӘЧӘКЛӘР

### Сибгат Хәким

•

1974 елның августында, үлеменә 30 ел тулу уңае белән, Плетцензее бургомистры Муса Җәлилгә ак розалар веногы куя.

Ләгънәтләнгән ачы һәм каргалган,
Туфрак, ташлар чат кан урынга,
Фашист үзенең айбалтасы белән
Шагыйрь башын чапкан урынга —
Розалардан венок! Бу хакыйкать,
Түгел буш сүз, түгел уйдырма,
Совет шагыйренә, коммунистка
Венок куйсын өчен бу дөнья,
Каршылыклар белән тулы дөнья
Розаларның ап-ак бәйләмен
Салсын өчен алга, итсен өчен
Тантанасын шагыйрь, бәйрәмен,
Җырга күпме көрәшергә кирәк!
Кайчан да бер олы җан җиңә,
Роза тотып үзе килә дөнья
Татар шагыйренә, Җәлилгә.

## Азамат Суюнчев,

карачай шагыйре

# Кырык үлемне җиңгән ил җырчысы

*Өзек*

Ут канатлы әкият кошы шикелле
Җиңеп барлык киртәләрне, үлемне, —
Эзләреңне ташка уеп калдыру —
Яшәүнең соң мәгънәсе шул түгелме?

Әкияттәге коштан булдың көчлерәк,
Йөрәк белән шуны ничек тоймассың...
Ташны гына түгел, җырың яндырды
Моабитның калын, тимер коймасын.

Канатларын җәеп бөтен иңенә,
Җилпенде һәм омтылды ул иреккә.
Исәннәрнең булып тугры юлдашы,
Дәшеп торды азатлыкка-хөрлеккә.

Тавышыңны ишетте Ватан-ана,
Батырлыгың — үлемсез җырларыңда.
Дөнья сине «Улым!» диеп атады,
Сулмас даның — кешелек зурлавында.

Думбрада көйли җырың казакълар,
Чукоткалы тыңлый йөрәк хисеңне.
Минем Карачай илемдә таулылар
Улларына куша синең исемне.

Кешеләргә сүнмәс ут бүләк иткән
Прометейга тиң димичә буламы:
Ерак Польша тыңлый синең җырыңны,
Прагада син — Фучикның туганы.

Очратырмын бәлки диеп Берлинда,
Өметемне өзми йөрдем һаман да.
...Кырык үлемне җиңгән ил җырчысы,
Очраттым мин сине бүген Казанда.

Чыккансың да көзге таңда мәйданга
Сулыймчы, дип, туган җирем һавасын, —
Күзләреңне текәп Идел өстенә,
Горур баскан хәлдә тынып калгансың.

Яңгыр тамчылары төшә өстеңә,
Көчәеп киткәндәй булды җиле дә.
Алып килгән булсам җылы буркамны,
Бөркәр идем синең юеш иңеңә.

...Өр-яңа көн туып килә каршыңда,
Күнеккәнсең син еракка карарга.
Баш өстеңнән очып уза торналар,
Хәерле юл телисең син аларга.

Исемең синең мәңге төшмәс телләрдән,
Батырлыгың — якты маяк чорларга.
«Азатлык һәм хөрлек» дигән сүзләрең
Мең-мең тапкыр кабатланыр җырларда.

И Җәлил, син минем рухи туганым,
Тоеп яшим синең йөрәк җылыңны,
Һәм башымны иеп мена алдыңда,
Һәйкәлеңә куям шушы җырымны.

РӘШИТ ГӘРӘЙ тәрҗемәсе

## Зәки Нури

### Әйтә күңел

Ярсыса да ташкын агымнары,
Кыю җилләр болыт куса да —
Әйтә күңел: шундый горур көчкә
Ия булган бит, дип, Муса да.

Бакчаларда гөлләр кабынса да,
Елмаешып таңнар туса да —
Әйтә күңел: нур яудыра болар
Кара төнне җиңгән Мусага.

Авыр йөкләр иңгә басканда да,
Яки кайгы-хәсрәт буса да —
Әйтә күңел: син башыңны күтәр
Һәм текәлеп кара Мусага!

Көрәшчеләр авыр юлдан уза,
Һәр адымда — биек бусага.
Әйтә күңел: шулар арасында
Атлый, диеп, батыр Муса да.

Җирдә, җырда һөҗүм дәвам итә,
Алгы сафта һаман Муса да.
Әйтә күңел: син аныңча үстер
Кечкенә бер чәчәк булса да.

Бишьеллыклар маршы гүли җирдә,
Галәмчеләр айга юл сала.
Әйтә күңел: безнең белән бергә
Җырлап яши шунда Муса да!

## Семен Данилов,

якут шагыйре

### Солдат-шагыйрьнең горур карашы

Үлем угы тиеп җиргә аугач,
Кул-аягын каерып, богаулап,
Караңгы һәм тынчу, тар зинданга
Ыргыттылар аны җыйнаулап.

Кан түкергән хәлдә: «Канга — кан» дип
Кычкырды ул бөтен көченә...
Күрде гүя шул чак алсу байрак
Элүләрен рейхстаг өстенә.

Баш идермәк булып кыйнауларның
Чыгарлыкмы икән санына?!
Сүзләрендә тоеп аның көчен,
Теләделәр сатып алырга.

Сатылмады! Көрәш җырыннан тыш
Җирдә яшәү мөмкин түгелгә.
Горур карап барды солдат-шагыйрь
Авыр, ләкин матур үлемгә.

Үлеме белән җиңде үлемне ул,
Үлемсезлек шушы түгелме!
Җирдә мәңге исән калыр өчен
Халкы йөрәгендә терелде...

Тормышта да, инде соңгы тапкыр
Күргәндә дә кояш нурларын,
Без җырларбыз!
Соңгы сулышта да
Без җырларбыз көрәш җырларын!

РӘШИТ ГӘРӘЙ тәрҗемәсе.

## Рәшит Гәрәй

### Йөрәкләрдә Муса җырлары

Бездә Муса үзе булган, диеп
Мин генәме инде мактанган?!
...Минзәләмнең матур, киң урамы
Аның исеме белән аталган.

Шатлык кичерсәм дә, кайгымда да
Шул урамда йөрим таңнарда.
Каеннарым моңсу... Уйга чумып,
Тып-тын кала һаман алар да.

Алар шулай искә ала, ахры,
Шагыйрь монда булган чакларны.
Кырык бернең авыр, салкын кышы
Күңелләрдә озак сакланды.

Тынга капкан зәһәр суыкларда
Иманнәргә тикле күшегә.
Агачларга җылы кирәк булса,
Җан азыгы кирәк кешегә. —

Давылланып туган җырлар кирәк
Пуляларга каршы торырлык;
Ут эченә кергән сугышчыга
Тугрылыклы иптәш булырлык.

Шушы хакта уйлау төннәрен дә
Тынгысызлый, борчый Мусаны.
Каләменә тотына — арып-алҗып
Ял иткәндә якын дуслары.

Иртәгесен яңа шигыре белән
Клубларда каршы алырлар...
Сөйгән улы итеп, үзләренә
Дәшә аны ерак авыллар.

Атлый шагыйрь тездән ера-ера
Кышкы юлның калын көртләрен.
Сизә микән күңеле алда әле
Моабитлар аны көткәнен.

Кем дә әйтә алмый киләчәктә
Бу юлларның кая илтерен...
Авыл халкы бүләк итә аңа
Бияләен, киез итеген.

Бүләк итә сөюен... шагыйрь өчен
Нинди бәхет кирәк тагын соң?!
— Хуш, Минзәлә! — диеп саубуллаша, —
Кайталмасам, җырым сагынсын!

Кайталмады кабат... ә үзе бит
Урап чыкты бөтен җир шарын.
Сагына аны Иншар сеңелләре,
Оныклары сагына Иншарның.

Сөйгән халкы сагына... һәм ул яши
Алга узып дәвер-чорларны...
Таныш урамнарда Муса эзе,
Йөрәкләрдә Муса җырлары.

## Михаил Луконин,

рус шагыйре

# ХАЛЫК УЛЫ

Ялкынлы патриот, герой-шагыйрь Муса Җәлилнең якты образы һәрбер совет кешесенә якын һәм кадерле. Аның хакында язалар һәм сөйлиләр, аның шигырьләрен Грузиядә һәм Чукоткада, Таҗикстанда һәм Украинада укыйлар, яттан беләләр.

Безнең илдә халыкка багышланган бер генә омтылыш та үлми, югалмый, хөрмәтсез калмый. Җәмгыятебезнең бөек закончалыгы һәм кешенең олы бәхете менә шунда инде. Җәлилнең үлем алдыннан иҗат ителгән шигырьләре безгә Моабит төрмәсенең караңгы стеналарын, штыклар һәм чакрымнарны, төрле дәүләт чикләрен үтеп кайтып җитте. Кулаклар кулыннан һәлак булган егерме өч яшьлек комсомолец Сергей Чекмаревның шигырьләре һәм хатлары тупланган кульязма дәфтәр дә утызынчы еллар башыннан безгә нәкъ шулай килеп җиткән иде. Ватанга багышланган һәрбер гомер, һәрбер фикер-идея, һәрбер шигырь юлы, Зоя Космодемьянскаяның үлемсез батырлыгы кебек, «яшь гвардия»челәрнең героик көрәше шикелле, үз-үзләрен аямыйча сугышкан панфиловчыларның каһарманлыгы сыман, Матросов һәм Гастелло исемнәре кебек, халкыбыз тарафыннан күтәреп алына, хәбәрсез югалмый, безнең күп миллионлы һәм күп телле халкыбызда саклана, мактала һәм хөрмәтләнә.

Ялкынлы шагыйрь, Совет Татарстанының күренекле улы Муса Җәлилгә үлгәннән соң Советлар Союзы Герое исеме бирелү үзе генә дә аның героик тормышына бөтен халык ихтирамы, аның батырлыгына хөрмәт билгесе, аның искиткеч шигъриятенә мәхәббәт белдерү ул.

Шагыйрьнең Моабит төрмәсендә бергә утырган бельгияле иптәше тапшырган дәфтәрләрдәге шигырьләр хәзер инде бик күп китапларга күчте. Үлемгә хөкем ителүчеләр камерасында татарча язылган шигырьләр хәзер инде илебездәге бик күп халыклар теленә тәрҗемә ителде. Муса Җәлил турында шагыйрьләр шигырь яза, халык аның хакында җырлар чыгара. Үлемсезлек шулай башлана.

Батырлык апофеозы белән тәмамланган корыч ихтыяр һәм халыкка бирелгәнлек кайда һәм кайчан туа соң? Җәлилнең егерменче елларда, утызынчы еллар башында язылган беренче шигырьләре үк инде үзләренең эчкерсез булулары белән дулкынландыра, яшь шагыйрьнең саф уйлары, карашларының киңлеге, тирәнлеге тәэсирләндерә. Аның ул чордагы шигырьләре үз буынының хисләре белән, шул чор сулышы белән сугарылган. Әйе, шигърият биография белән бергә башланган. Шагыйрьнең кайнар яшьлеге аның соңгы көннәренә кадәр сакланып калган. Тормышка булган караш көрәштә һәм хезмәттә ныгыган, үскән, характерына күчеп чыныккан.

Бик күп еллар узгач, без Муса Җәлилнең мәңге онытылмас тормышы һәм көрәше турында белдек.

Җәлилнең үлем алдыннан язылган оптимистик шигырьләре тормышка, җиңүгә, киләчәккә ышаныч белән сугарылган. Бу шигырьләрдә үлем турында кайгырту юк.

Шагыйрь бөтенләй уйламаган ул хакта. Авыр минутларда аны Ватан исеме, совет халкының бөек көрәше рухландырган.

Халкыбызның революцион тарихы, киләчәк өчен көрәшүчеләрнең якты исемнәре Муса Җәлилнең көч-куәтен, ышанычын арттырган. Ватан образы, Ватан турындагы уйланулар, бәйрәмнәребез, шәһәр-авылларыбыз, туган җир табигате турындагы хатирәләр гомеренең соңгы көннәрендә аны илһамландырган, канатландырган. Моабит шигырьләренең диапазоны киң. Биредә Муса Җәлилнең бөтен уйлары, бөтен киләчәгә бөек ялкын булып кабына.

«Моабит дәфтәре»ндә мәхәббәт турындагы шигырьләр дә, лирика, сатира, юмор да бар. Җәлил үзенең уй-хыялларын, кайгы-шатлыкларын берсен дә үлемгә бирмәгән. Аның шигъри осталыгы кимемәгән, какшамаган, киресенчә, биредә аның шигъри таланты чәчәк аткан.

Җәлилнең Ватанга, тормышка мәхәббәт хисләре белән язылган юлларын совет кешеләренең һәрбер яңа буыны үзенә рухи корал итеп кабул итә. Аның үлемсез шигырь юллары безнең өчен васыять булып яңгырый.

Күренекле совет шагыйре, герой Муса Җәлилнең исеме иң күренекле кешеләребез белән бергәттән балкып торачак. Җәлилнең тормышы, аның шигырьләре һәрчак Совет Ватанына хезмәт итүнең, аны яратуның, яшәүнең якты бер мисалы булачак.

Җәлилнең шигырьләре мәңге яшәячәк, безне мәңге дулкынландырачак, тәрбияләячәк, алга дәшеп торачак.

**«Товарищ поэзия» исемле китаптан.**
**«Советский писатель» нәшрияты, 1963.**

## Сырбай Мәуленов,

казакъ шагыйре

# ТУГАНЫБЫЗ МУСА

Без бер үк фронтта, Волхов фронтында сугыштык. Сугыштык һәм шигырьләр яздык, чөнки без сугышчылар гына түгел, шагыйрьләр дә идек. Ә юлларыбыз, кызганычка каршы, безне очраштырмады, һәм мин аны беркайчан да күрә алмадым.

Ул батырның гомере, патриотизмның югары ноктасына җиткән иҗаты, фашист төрмәләреннән бәреп чыккан данлы үлеме минем сугыштан соңгы иҗатыма, бигрәк тә хәрби темага язылган әсәрләремә, әйтеп бетергесез тәэсир ясады. Шуңа күрә дә мин Муса Җәлилне каләмдәш дусым, тугрылыклы туганым дип саныйм.

Шулай ук мин инде Муса Җәлилнең үземә күпмедер дәрәҗәдә якташ икәнен дә беләм. 1919 нчы авыр елда «Кечкенә Җәлил» Оренбург далаларын иңләп-буйлап йөргән. Татар шагыйре, бүген бөтен дөньяга билгеле патриот Муса Җәлилнең таланты казакъ җирендә ачыла башлавы өчен мин үземне бәхетле саныйм. Һичшиксез, аның башлангыч иҗатына туган Казагыстаным тәэсире булгандыр.

Ул чакларда аклар тарафыннан камалган Оренбург Муса Җәлилгә ленинчыл интернационализм идеяләрен ирештерә башлаган. Нәкъ әнә шул тәэсирдән унөч яшьлек малай кызыл отрядлардагы рус, татар, украин, казакъ милләтләре арасына кергән. Анда исә венгрлар да, австриецлар, немецлар, латыш һәм чех интернационалистлары да була, һәм Муса Җәлил революция дошманнарына каршы көрәшүчеләргә ярдәм итә башлый. Аның бу ярдәме — кызыллар газетасында чыккан беренче шигыре. Шул шигырь аша кечкенә татар малае совет поэзиясенең зур шагыйре булуга юнәлеш ала.

Олы интернационализм, дуслык хисе Муса Җәлилнең ышанычлы юлдашына әй-

ләнә, аның иҗат нигезенә ята. Шигырьләре шуңа күрә дә киң илебезнең барлык милләтләренә, төрле телдәге тугандаш республикаларга, дөнья мәйданына чыга.

Сугышка хәтле, милли сәнгатьләр ярышып үскән, сүз сәнгате һәм әдәбият кешеләре мәртәбәләргә ирешкән елларда ук инде Муса Җәлил исеме популяр була. Мәкалә, шигырь, поэма, сәхнә әсәрләре язу һәм оештыру эшләре белән аның күпкырлы таланты ачыла. Ул әдәбиятны тормышында төп эше итеп сайлый.

Сугыш елларына Муса Җәлил формалашып җиткән кеше булып, партиягә һәм илгә фидаи коммунист булып керә. Ул үзе теләп сугышка китә, иңнәренә хәрби тормыш йөге ала.

Без хәзер яхшы беләбез: төп корал итеп каләмне сайласа да, ул солдат булып атлады, көрәште, ә гомеренең соңгы сәгате сукканда солдат булып җисми үлде, ә рухи халәте белән дөнья шигъриятендә совет солдаты булып калды.

Мин хокуклылар янында хокуклы булып, бәхетлеләр илендә бәхетле булып Казагыстан республикасында яшим. Шунда тудым, үстем, шуннан Ленин шәһәрен якларга фронтка киттем. Каләмдәш дусым, туганым Муса Җәлил көрәшкән якта көрәштем. Һәм туганым Муса Бөек Ватан сугышы солдаты булып, илһамы-моңы халыкка, Ватанга һаман хезмәт итүче патриот шагыйрь булып минем йөрәктә һәр вакыт саклана. Хәтта мин Муса Җәлилне күргәнем бар, аның белән бик якыннан таныш, теләсәм хәзер дә аны очрата алам кебек бер хис кичерәм. Чынлап та, нинди китапханәгә генә керсәң дә, авылда, я шәһәрдә булсаң да — кайда да Муса Җәлил китаплары һәм аның турындагы китаплар белән очрашасың.

Казагыстан — күпмилләтле республика; бездә Җәлилне казакъ, татар, уйгур, немец телләрендә укыйлар. Ә рус телендә Җәлил китаплары иң зур тиражлар белән чыга.

Мин илебезнең күп җирләрендә йөрим. Ленинград янында Волхов фронты узган урыннарда, Муса Җәлил яраланган авыл янында булырга да туры килде. Гитлерчылар белән совет солдатлары йөзгә-йөз бәрелеп көрәшкән, актарылып-ажгырып сугыш тәгәрмәче әйләнгән бу урыннарда мин үземнең эзләрне генә түгел, Муса Җәлил өстенә килгән хәлләрне дә күзалларга, ишетергә тырыштым... Ә кырлар эндәшми, бөдрә урман гына күңелгә ерактагы бер моңны китерә. Җир яралардан арынып бара. Окоплар куе яшеллек астында калган. Кайчандыр мина чокырлары белән чуарланган кырлар өстендә бүген асфальт юллар. Янган авылларны яңалар алыштырган. Бары безнең йөрәктәге иске яралардан гына һаман кан саркый. Бер ярам гел Муса Җәлилне искә төшерә.

Бөек Җиңү кененнән соң инде утыз ел гомер узып киткән булса да, ул сугыш әле һаман сынау сәгатьләре, көрәш еллары, батырлар көрәше булып иҗатыбызга керә. Казакъ шагыйрьләренең күпчелеге Муса Җәлил истәлегенә багышлап шигырьләр иҗат итте. Шундый әсәрләрнең берсен Бөек Ватан сугышында катнашкан, әле дә иҗат сафларында солдатча атлаган якын дусым Җубан Мулдагалиев язды. Ул үзенең әсәрендә татар шагыйренә соклану, аны хөрмәт итү, аның батырлыгы каршында баш ию тойгыларын бирә.

Муса Җәлилнең олы йөрәге фашист илбасарларын көл итәрлек ялкын һәм үз иленә, халкына мәхәббәт белән тулы иде. Хисләрен ул шигырьләренә, фронтның алгы сызыгыннан язылган корреспонденцияләренә салды. Аның батырлык һәм патриотизм белән сугарылган иҗаты әле бүген дә безнең бик күп каләм ияләренә тәэсир итүен мин алда әйтеп уздым.

Без хәзер милли культураларның бер-берсен баеткан, бер-берсенә тәэсир иткән, шул нигездә социалистик реализмның югары үсешкә ирешкән чорында яшибез. Әгәр әдәбият турында сүз әйтәбез икән — бөек илебездәге бөтен кечкенә һәм зур милләтләрнең иң яхшы әсәрләрен күздә тотабыз һәм шунда халыклар дуслыгының, ленинчыл интернационализм идеяләренең тере чагылышын күрәбез. Татар шагыйре Муса Җәлилнең яшәве һәм көрәше нәкъ әнә шул дуслык өчен иде. Шагыйрьнең батырларча үлеменнән соң күп еллар үтте, ләкин аның исеме, якты истәлеге халык күңелендә саклана. Муса Җәлил — һәр совет язучысының тугры дусты һәм туганы. Аның ялкынлы, күтәренке рухлы иҗаты, батырлык үрнәге күрсәткән гомере һәр вакыт безнең яшьләрне илебез өчен хезмәткә әйдәр. Әнә шундый көчле булганга күрә, Җәлил — үлемсез шагыйрь, чын мәгънәсендә Кеше һәм Гражданин.

## Яков Ухсай,

чуваш шагыйре

# ДУСТЫМ ТУРЫНДА

Мин 1930—34 елларда Муса белән көн саен диярлек очрашып, аралашып яшәдем. Әле бүген дә куңел белән шул көннәрдә, төрле вакыйгалар, героик булмаган, гадәти, әмма хатирәле хәлләр эчендә кебекмен... Әлбәттә, хәзер күп нәрсәләр истән чыгып, күп вакыйгалар онытылгандыр да...

Моннан 20 ел элек язган «Муса Җәлил турында хатирәләр» исемле поэмамда дуслыгыбызга бәйле кайбер күренешләрне чагылдырырга омтылган идем (поэманың каралама экземплярын тәнкыйтьче Гази Кашшафка бүләк иттем). Анда язганнарымны кабатлап тормыйм...

Муса — Мәскәү татар язучылары секциясендә, мин — чуваш секциясендә секретарь булып эшләдек. Ихтыярсыз, шагыйрьнең эш стиле, дөресрәге, аның татар совет әдәбиятының сыйфаты өчен януы, көрәше искә төшә. Мәсәлән, ул «Болганчык еллар» романы авторы Мәхмүт Галәү белән озак, нәтиҗәле эш алып барды.

Шулай ук аның шагыйрь Мансур Крымов һәм ул вакытта «Күпер» исемле роман язган Усманов белән сөйләшүләре дә хәтердә нык сакланган. Һөнәре буенча машинист булган Усманов, әлбәттә, әдәбият өчен кирәкле, кызыклы шәхес иде.

Кабатлап әйтәм: Мусаның җитәкчелек эше турында сүз алып барганда, аның татар әдәбиятының югары сыйфатлы булуы өчен көрәшенә аеруча басым ясалырга тиешле. Әлбәттә, бу — тәнкыйтьчеләр, әдәбиятчылар эше.

Аның «Коммунист» газетасы редакторы Агишев һәм язучылардан талантлы, җитди әдип Әхмәт Фәйзи белән иҗади дуслыгы да игътибарга лаек...

Минем үземдә Мусага карата иң изге, саф тойгылар яши. Әмма бирёдә, элек язганнарыма өстәп, шагыйрь турында яңалык әйтә алмам, ахры. Тик шуны искә алырга кирәк дип саныйм: Муса белән без совет язучыларының беренче съездында катнаштык. Бәлки соңрак бу турыда аерым язармын да әле...

Ул минем бер шигыремне татарчага тәрҗемә дә итте — шигырь «Коммунист» газетасының 1934 ел август санында басылды.

## Нажар Нәҗми,

башкорт шагыйре

# ЗАМАН ЛЕГЕНДАСЫ

Муса Җәлил турында нинди дә булса язма сүз әйтүе авыр, аның батырлыгы, бер уйласаң, адәм заты кылган нәрсәләргә охшамаган шикелле һәм аның хакында хәтта теленнән язып, эчтән генә, хәйран калып уйланырга гына мөмкин кебек. «Кичер мине» дип, аңа мөрәҗәгать итеп 1957 елда язылган минем шигырем дә бары тик, ни әйтергә белми, ишетелер-ишетелмәс «уф!» дип бер көрсенеп кую кебек кенә.

**Демблин... Радом... Берлин... Шул юллардан**
**Алып барды сугыш мине дә.**

**Шул ук юлдан дошман, чигенә-чигенә,**
**Алып киткән икән сине дә.**
**Бер үк юлда ике төрле язмыш...**
**Ә мин исә исән калганмын.**
**Әйтерсең лә дошманнарны куып,**
**Мин тик сине эзләп барганмын.**
**Хәтерлимен төрмә коймаларын,**
**Бәреп кергән тимер капканы.**
**Үз күзләрем белән күргәнмен мин,**
**Үз кулларым белән тотканмын мин,**
**Сине харап иткән балтаны.**
**Бу хәтерләү нигә кирәк хәзер,**
**Синең исемең шуңа калганмы.**
**Палачларга сине бирмәс идем,**
**Кичер мине — соңлап барганмын.**

Бу уртача язылган шигырь, үзенең автобиографик булуы белән, ничектер, Муса Җәлил гомеренә бик-бик читтән булса да кагылышлы булганы өчен миңа кадерле.

Сугыш вакытында Икенче танк армиясе составына кергән, мин хезмәт иткән утыз дүртенче мото-стрелковый гвардия бригадасы Демблин шәһәрен азат итте һәм азак Вапнярско-Демблинская дип аталды. 1945 елгы кышкы сугышларда без Радомнан берничә километр төньяктанрак үттек. Аннан соң Берлин сугышлары... Алар бөтенесе Муса Җәлил булган урыннар.

Сугыш елларында сирәк-мирәк кенә көндәлек алып барган идем. 1945 елның 3 май көнендә язылган язуларда шундый урыннар бар: «...Кичә Берлин тәмам капитуляцияләнде. Берлин сугышлары турында язып барырга вакыт булмады. Берлинга 23. IV. килеп кердек. Шуларның дүрт көнен Плетцензее төрмәсендә эшләп үткәрдем»...

Сугышта мин хезмәт иткән батальон Берлинның Плетцензее төрмәсе капкаларын бәреп ачып керде һәм төрмәнең берничә хезмәткәрен кулга алды.

Төрмә... Плетцензее төрмәсе... 1945 елның апрель аенда, Берлин сугышлары барганда, тирә-якта һәм төрмә ишеге алдында да миналар сирәк-мирәк ярылып торганда, тоткыннарның камералардан чыгулары, ишекләре ачылган камералардан шыр сәккә калган мәетләрнең күзгә күренүләре, подвалдагы иске-москы аяк киемнәре өеме, төрмә ишегалдында торган бер катлы корылма, аның эчендәге кара чаршаулар, ә чаршаулар артындагы бүлмә уртасында кеше башын кисә торган балта-гильотина, аннан бер читтәрәк юан матчага бәйләнгән, кешеләрне аса торган, чиләнеп, каешланып беткән баулар... Барысы да бүгенгедәй күз алдымда.

Миңа төрмәнең ике надзирателеннән сорау алырга туры килде. Алар икесе дә җәзалауда катнашкан булып чыктылар һәм алардан бөтен җәзалау ритуалын сөйләтеп яза бардым. Искитмәлесе шул: җәзаланучы гильотинага яткырылып, махсус корылмага муены беркетелгәч, палач, киселәчәк башны, киселгәч җиргә төшермәс өчен, куллары белән тотып торган. Шушы «хезмәте» — һәрбер киселгән баш өчен ул өстәмә паекка лаек булган: ике йөз грамм икмәк, ярма һәм башка һәм башка граммнар... адәм башы өчен өстәмә тукланулар... Муса Җәлил башы өчен дә — шагыйрь башы өчен дә аларга өлеш тигәндер... Боларны искә төшерү дә, язу да җиңел түгел...

Мин надзирательләрдән сорау алганда җәзаланучыларның үзләрен ничек тотулары турында да кызыксындым. «Төрлечә тоттылар, — дип җавап бирделәр алар, — кайсыбере өстәлне-гильотинаны күрү белән акырып җибәрәләр дә барлык көчләре белән каршылык күрсәтәләр, ә бәгъзеләре тыныч кына барып яталар». Әнә шул «тыныч кына барып ятучылар» арасында елмаеп көлүчеләр дә булганнар. «Татарлар елмаеп үлделәр» дигән канатлы һәм гыйбрәтле сүзләр бөтен җир шарын әйләнеп чыкканы барыбызга да билгеле.

Көлеп үлделәр... Үлемгә көлеп караудан да көчлерәк ихтыяр көче бармы соң?! Муса Җәлил гомере һәм «...палач балтасына башны тоткан килеш» язылган соңгы шигырьләре — үлемгә көлеп карау көченең тиңсез мәгънәсе. Андый көчле ихтыярга ия кешеләр, шагыйрьләр җирдә сирәк була. Шундыйлар хакында легендалар туган да. Муса Җәлил — үзе хакында үзе тудырган легенда, заман легендасы.

## Олег Шестинский,

рус шагыйре

# ҮЛЕМСЕЗЛЕК

Муса Җәлил турында уйласам, татар поэзиясенең батырлык, үлемсезлек рухы белән тулы сәхифәләре күз алдыма килә. Якташларының рухи матурлыгын гына түгел, аларның батырлыгын да шигърият итә алганга, үз халкының бөек шагыйре булып танылды ул...

Әмма Муса Җәлил бары тик татар халкының гына улы түгел, гомере белән ул раслаган патриотизм, шигырьләрендәге героик пафос — болар хәзер совет яшьләрендә гражданлык тойгысы тәрбияләү бурычлары белән аерылгысыз бәйләнгән.

Фашизм — рәхимсез, мәрхәмәтсез. Халык культурасының талантлы вәкилләрен үтерү, кырып бетерү — фашизмның «культура» политикасы асылы әнә шул иде. Фашистлар Болгариядә революцион поэзиянең күренекле вәкиле — шагыйрь Никола Вапцаровны атып үтерделәр. Ул да, Муса Җәлил кебек үк, фашистик террор да җиңә алмаган героик сәнгать байрагына әверелде.

Әсирлектә, тоткынлык көннәрендә күпләп шигырь һәм поэмалар иҗат итү өчен Мусага бик зур рухи көч кирәк булгандыр! Һәм нинди көчле әсәрләр язган ул! Җиңүгә, үз халкыңа ышаныч белән, зур батырлык хисе белән сугарылган әсәрләр!..

Чыннан да, үзенең рухи көче белән үлемне җиңә алган, үлемсез булып калган чын Кеше ул Муса Җәлил!



*Татар-башкорт комсомол работникларының беренче губерна киңәшмәсе. 2 нче рәт уңнан өченче Муса Җәлил.*

## МОИ ПЕСНИ

*Песни, в душе я взрастил ваши всходы,*
*Ныне в отчизне цветите в тепле.*
*Сколько дано вам огня и свободы,*
*Столько дано вам прожить на земле!*

*Вам я поверил свое вдохновенье,*
*Жаркие чувства и слез чистоту.*
*Если умрете — умру я в забвенье.*
*Будете жить — с вами жизнь обрету.*

*В песне зажег я огонь, исполняя*
*Сердца приказ и народа приказ.*
*Друга лелеяла песня простая.*
*Песня — врага побеждала не раз.*

*Низкие радости, мелкое счастье*
*Я отвергаю, над ними смеюсь.*
*Песня исполнена правды и страсти —*
*Тем, для чего я живу и борюсь.*

*Сердце с последним дыханием жизни*
*Выполнит твердую клятву свою.*
*Песни всегда посвящал я отчизне,*
*Ныне отчизне я жизнь отдаю.*

*Пел я, весеннюю свежесть почуя,*
*Пел я, вступая за родину в бой.*
*Вот и последнюю песню пишу я,*
*Видя топор палача над собой.*

*Песня меня научила свободе,*
*Песня борцом умереть мне велит.*
*Жизнь моя песней звенела в народе,*
*Смерть моя песней борьбы прозвучит.*

*26 ноября 1943 г.*

*Рус теленә*
*С. Липкин тәрҗемәсе*

# УНИКАЛЬ БҮЛӘК

*Татарстан китап нәшрияты, герой-шагыйрьнең зур юбилеен каршылап, СССР һәм дөнья халыклары телләрендә кызыклы сувенир китап бастырып чыгарды. Эчтәлеге һәм эшләнеше белән уникаль булган бу китап Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре» циклына кергән атаклы «Җырларым» шигыренең тәрҗемәләрен үз эченә ала. Б. Кербабаев, С. Липкин, Д. Кугультинов, О. Новицкий, О. Сарывелли, Х. Бәйрәмукова, А. Гаджиев, А. Адалло, П. Хузангай, Ф. Ансори, К. Шангытбаев, Т. Байзаков кебек танылган шагыйрьләр тәрҗемә иткән бу шигырь җыентыкта илледән артык телгә яңгырый. Китап, һичшиксез, шагыйрьнең үлемсезлеген раслаучы, укучыларыбыз өчен кадерле бер бүләк булачак.*

*Журналыбызның бу сәхифәсендә без «Җырларым» шигыренең рус, литва, үзбәк, грузин, әрмән, осетин, якут, бурят, тува һәм абхаз телләренә тәрҗемә үрнәкләрен бирәбез. Шигырьне С. Липкин, А. Йонинас, М. Бабаев, В. Горганели, Г. Севан, Д. Дарчиты, А. Абагинский, Г. Чимитов, А. Даржаа, Н. Куцниа тәрҗемә иткәннәр.*

Ә. СИНЕГУЛОВ,
*җыентыкны төзүче.*

## Әмир Мәхмүдов

# МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ СУГЫШКА КАДӘРГЕ ИҖАТЫНДА ЭСТЕТИК ИДЕАЛНЫҢ ФОРМАЛАШУЫ

Эстетик идеалның аерым язучы иҗатындагы роле әдәбият белемендә җитәрлек өйрәнелмәгән. Һәм әлеге мәсьәләне ныклап өйрәнми торып, теге яки бу әдип иҗатына дөрес бәя бирү, аның иҗатының төп пафосын ачыклау бик кыен булачак. Сөекле шагыйребез Муса Җәлил иҗаты уңае белән дә шул ук сүзләрне кабатларга туры килә.

Күренекле әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты турында дистәләрчә хезмәтләр язылган. Ә менә М. Җәлил иҗатының эстетик идеалы бүгенге көнгә кадәр ныклап тикшерелмәгән дияргә була.

Мәгълүм булганча, һәр язучының эстетик идеалы тормыштагы социаль вакыйгалар, ул яшәгән тәбәктәге иҗтимагый мохит һәм табигать күренешләре тәэсирендә формалаша башлый. Һәм бик иртә формалаша башлый.

Сеңелесе Зәйнәп Җәлилова шагыйрьнең эстетик идеалын хаклы рәвештә Муса туып-үскән җирнең гүзәл табигате белән бәйли: «Безнең авылның исеме Мостафа. Ул вакытларда урта күләмдәге ике мәчетле авыл иде. Тау башында тора. Тирә-якта урманлык юк, ләкин күз күрер җиргә кадәр тигез, матур тугайлык. Өч яктан урап Нит елгасы ага. Авылның бер башында су тегермәне, икенче башында агач күпер. 4—5 километр җирдә Саелмыш елгасы ага. Саелмыштан 2—3 километрда тигез җирдә мәһабәт булып Бурлы тау калкып тора. Бурлы тауга капма-каршы якта, авылдан 4—5 километрда, тезмә таулардан торган Колама тау бар. Нитның авылга якын килгән төшен гадәттә күл дип йөртәләр. Күпердән борылып, авылның икенче ягыннан үткән җире күе камыш белән уратылган аерым күлләрдән тора. Һәр күлнең үз исеме бар: Комлык, Аргы кара яту, Әйләмә һәм башкалар.

Бу нәрсәләрне тәфсилләп язуымның хикмәте шунда: Муса авылның табигатен бик ярата иде» [1].

Муса Җәлил күңелендә беренче эстетик тойгылар уянуда фольклор әсәрләренең: халык җырлары һәм әкиятләрнең, легендалар һәм бәетләрнең дә роле аз булмый, билгеле. Ул бала чагыннан әкиятләр һәм җырлар тыңлап үсә, халык авыз иҗаты җәүһәрләрен күңеленә сеңдерә бара. Ул, шулай ук, Көнчыгышның бөек классикларын, Габдулла Тукай һәм Мәҗит Гафури әсәрләрен өйрәнә, аның беренче шигырьләре шул остазлары тәэсирендә языла.

1913 елда шагыйрьнең әти-әниләре ул вакытта татар мәдәниятенең бер үзәге саналган Оренбург шәһәренә күчеп киләләр. Биредә Җәлилнең шигъри канатлары ныгый, дөньяга карашы киңәя. Оренбургка күчеп килгәч, шагыйрь «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый башлый, мәдрәсә күршесендәге «Белек» китапханәсенә языла һәм

[1] Муса турында истәлекләр. Казан. 1964 ел. 12—13 битләр.

მუსა ჯალილი

# ჩემი სიმღერა

ჩემო სიმღერავ, ნაზარდო სულში,
სამშობლოს ტრფობით ჰყვავი და ხარობ.
ხარ ისე მძლავრი, რომ ჩვენს მამულში
სულ იმჩქეფარებ ისე, ვით წყარო.

შენ განდე ჩემი აღფრთოვანება,
გრძნობა, ცრემლები, იმედი, ფიცი.
მოვკვდე, თავი არ დამენანება,
მე შენთან ერთად ვიცოცხლებ, ვიცი.

შენში ანთია ოცნება წრფელი,
რაც მიკარნახა ხალხმა, ეპოქამ.
მტერს თავს ესხმოდა სიმღერა ჩემი,
გულს უხარებდა ძმას და მეგობარს.

ბედნიერება არ მწამს ლაჩრული,
სულმოკლეობას ვუყურებ ზიზღით.
მწამს ვაჟკაცურად სიმღერა თქმული
აი რისათვის ვცოცხლობ და ვიბრძვი.

ხალხის გარეშე ცხოვრება არ მსურს,
არც მინატრია, არ მიფიქრია.
ჩემი სიმღერა ეკუთვნის მამულს,
ვისთვისაც თავი შემიწირია.

მეც ვუმღეროდი გაზაფხულს მარადს,
როცა მტერს ვდევდი კუბოს კარამდი,
ახლაც ამას ვწერ, ვუმღერი ამას,
როდესაც ცულით მადგას ჯალათი.

თავისუფლების სიმღერით ვკვდები,
ვკვდები სიმღერით, ო, განა უხმოდ.
ხალხს უმღეროდა სიცოცხლე ჩემი,
სიკვდილი ჩემი ბრძოლისთვის უხმობს.

26 ივნისი, 1943 წ.

თარგმ. ვახტანგ გორგანელმა.

*Грузин теленә*
*Вахтанг Горганели*
*тәрҗемәсе*

тиз арада китапханәнең иң актив укучысына әйләнә. Шагыйрьнең кардәше Мәрьям Сәйфетдинова, Мусаның кечкенәдән белемгә омтылуына сокланып, түбәндәгечә яза: «9—10 яшьләргә җиткәндә инде Мусаның ул вакыттагы татар әдәбиятыннан укымаган китабы калды микән? Калмагандыр. Чөнки «Белек» китапханәсендә аңа бирергә китап таба алмый аптырый торганнар иде. Барысын да ул белә, укыган булып чыга иде. «Ак юл» журналын (балалар журналы) иң беренче табып укыган кеше ул була иде» [1].

Муса Җәлилнең дөньяга һәм әдәбиятка карашы, шулай ук эстетик идеаллары формалашуда Оренбургта яшәгән татар шагыйре Төхфәт Ченәкәйнең йогынтысы да шактый зур була. Үзенең истәлекләрендә Төхфәт Ченәкәй Җәлилнең һәр нәрсә белән кызыксынучан, гыйлемгә омтылучан кеше булуы турында яза: «Минем китапханәмдә шактый гына борынгы китаплар бар: Әбелманих Каргалиның «Өммикамал» исемле шигырьләр китабы, «Мөхәммәдия», «Бакырган», «Йосыф» китаплары, «Таһир-Зөһрә», «Бүз егет» һ. б. Мин бу китапларны Мусага аңлатып бирәм, аларның шигырь төзелешләрен күрсәтә идем. Шул 1918 елның ахырында Гали Рәхимнең «Шәрык шагыйрьләре» исемле китабы басылып чыкты. Аны без Муса белән бергә укыдык. Анда Хәйям, Хафиз, Ширази, Руми, Рабиндранат Тагор һ. б. авторлардан үрнәкләр бар иде. Муса бу китапны үзенә алып китеп тә укыды, теткәләнеп беткәннән соң гына кире кайтарды. Димәк, ул аларны бик нык өйрәнгән. Мусаның шагыйрь булып формалашуына, һәрхәлдә, аның беренче адымнарын ясауга, бу өйрәнүләрнең тәэсир булмый калмагандыр» [2].

Сүз дә юк, ул укыган күп санлы китапларның да, Шәрык әдәбияты үрнәкләренең дә аның эстетик идеалын формалаштырудагы уңай ролен инкарь итеп булмый. Шул ук вакытта М. Җәлил шигырьләренең төп чыганаклары катлаулы вакыйгаларга бай тормышның үзеннән килүен дә истән чыгармаска кирәк. Яшь шагыйрьнең беренче әсәрләре зур тарихи вакыйгалар, революция дулкыннары, ил тормышында булган кискен үзгәрешләр тәэсирендә языла.

Заманның хәлиткеч вакыйгалары яшь шагыйрьне тормышка яңача карарга мәҗбүр итә, аның шигырьләренең идея-эстетик эчтәлеген баета. Менә шуның өчен дә ундүрт яшьлек чагында ук ул иҗтимагый яңгырашлы, көчле шигырьләр яза алган.

1919 елда М. Җәлилнең революциягә, Кызыл Армия сугышчыларына багышланган «Бәхет» исемле шигыре басыла. Яшь шагыйрь бу әсәрендә бөек чорның давыллы вакыйгаларына соклануы, революция казанышларын якларга әзер торуы хакында сөйли:

[1] Шунда ук. 30 бит.
[2] Шунда ук. 43 бит.

Кулыма мин «кызыл кылыч»ны алсам,
Шулай шуннан «кызыл фронт»ка барсам,
Олуг бер дәрт белән сафка атылсам,
Кулымны уртага, дошманга салсам,
Бөтен куәт белән шунда сугышсам,
Җиңелми мин һаман да алга барсам,
Менә шунда берәр пуля очса-килсә,
Килеп ул күкрәгемне бишкә киссә,
Үлем кулы килеп басса — егылсам,
Җаным күккә-гарешкә очса-китсә,—
Менә шунда бәхетле мин, бәхет — шул.
Минем өчен зур-олуг шан — зур бәхет ул,
Шулай, эшчем, коралган, бар сугышка,
Юлыңнан кайтма син, кирәк — егыл-үл!

Егерменче елларда татар шигърияте яңа баскычка күтәрелә. Безнең әдәбиятта бик күп яңа әсәрләр иҗат ителә, яңа геройлар барлыкка килә. Инде Муса Җәлилгә килгәндә, аның иҗатында төп урынны халык азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен уткасуга кирәргә әзер торган яшь көрәшчеләр ала. Шагыйрьнең геройлары, мещанлык бәхетенә каршы чыгып, җирдә гүзәл тормыш төзү өчен көрәшәләр. Һәм без аның башлангыч чор иҗатында ук инде тормыш турында җитди уйлануларын, әдәби-эстетик алымнарының төрлеләнүен, эстетик идеалының тирәнәюен күрәбез. Әсәрдән-әсәргә шагыйрьнең дөньяга карашы һәм тормыш турындагы фикерләре тирәнәя, камилләшә бара.

М. Җәлил, шагыйрь буларак, тормыштагы төп бурычын халыкка хезмәт итүдә күрә. 1920 елда язылган «Ирек шагыйре сүзләре» исемле шигырь — шуның ачык бер мисалы. Идея-эстетик юнәлеше белән ул «Бәхет» шигыренә якын тора.

Күтәрдем кул, барам алга табан мин,
Минем үз көч, бүтән көчкә таянмыйм.
Ни килсә дә авырлыклар һаман да,
Өмет өзмим, еламыйм, бер дә янмыйм.

Ирек, хаклык терәк аркамда яхшы,
Ничек йоклап ятыйм мин алга басмый!
Өмет-идеал нуры алда, халыкка
Ничек яшим шуны күрсәтми-ачмый!

Халык углы — минем кардәшләрем ул,
Халык — эшче, минем күңелем-җаным ул,
Халыкка нур чәчеп, ак юлга атлау,
Минем бит иң олуг идеалларым ул!

Яшим халкым өчен, көчләр табам мин,
Халык өчен һаман алга барам мин,
Минем гомерем тәгәлләнер шуның өчен,
Күмелсәм дә бу юлда, бер дә янмыйм!..

«Минем гомерем тәгәлләнер шуның өчен» дигән юллар яшь шагыйрьнең халык язмышы, ил язмышы, үзенең тормышта тоткан урыны хакында шул елларда ук тирән уйлануы турында сөйли. Шагыйрьнең бу чордагы идея-эстетик принциплары Бөек Ватан сугышы елларындагы әсәрләрендә дә чагылыш таба.

Канат җәеп үлем куркынычы
Торган саен окоп алдымда,
Мин көчлерәк тоям ирек тәмен,
Яшәү дәртен кайнар канымда.
Күзләрдә яшь,
беләм, алар горур

Яшәү хисе белән яшьләнгән,
Нәрсә артык җирдә,
илне саклап,
Тар окопта батыр яшәүдән!!

(«Окоптан хат».)

«Бәхет» шигырендә М. Җәлил халыкны үз артыннан ияртүче шагыйрь образын калку итеп сурәтләсә, бусында фашист илбасарларына каршы кулына корал тотып көрәшкән фронтовик-шагыйрь образы беренче планга куела.

Димәк, әдипләрнең эстетик идеаллары еллар үтү белән үсә, камилләшә бара. Ләкин кайбер очракларда язучы иҗатының башлангыч чорындагы идеалы белән соңгы чордагы идеалның бер үк булуы да мөмкин икән.

Муса Җәлилнең эстетик идеалы гражданнар сугышы елларында формалаша, дидек. Бу бик аңлашыла. Шагыйрьнең гражданнар сугышы вакыйгаларында актив катнашуы, яңа җәмгыять төзү эшендә алдынгылар сафында баруы аңа бай тормыш материалы бирә. Социализм төзү эшенә җаны-тәне белән бирелгән шагыйрьне илнең киләчәге нык дулкынландыра, революцион көрәш елларында туган батырлар әдипне яңадан-яңа әсәрләр иҗат итәргә рухландыра. Бөек тарихи вакыйгалар тәэсирендә М. Җәлил комсомолның данлы юлына багышланган «Авыру комсомолец» поэмасын, немец коммунистларының революцион көрәшен чагылдырган «Кисәкләр» исемле әсәрен яза.

«Авыру комсомолец» поэмасының беренче варианты 1924 елның июнендә языла һәм ул 1925 елда шагыйрьнең «Барабыз» исемле шигырьләр җыентыгында басылып та чыга. Әсәрнең төп герое — тормышның ачысын-төчесен татыган, халык бәхете өчен көрәштә тазалыгын югалткан авыру комсомолец. Геройның күз алдыннан бер-бер артлы Ленада булып үткән канлы вакыйгалар, Бөек Октябрь көннәре, Юденич һәм Махно бандаларына каршы көрәш эпизодлары үтә. Һәм бу вакыйгаларның барысы да комсомолец хәтерендә кешелек җәмгыятенең якты киләчәге өчен барган көрәшнең аерым этаплары булып җанлана.

Егерменче елларда шагыйрьнең дөньяга карашы тагын да киңәя төшә, аның иҗаты яңа биеклеккә күтәрелә. Үзенең бу еллардагы эстетик позицияләре һәм идеаллары формалашуга тукталып, М. Җәлил түбәндәгечә яза: «Комсомол эше минем тормыш тәҗрибәмне баетты, мине чыныктырды, дөньяга карашымны яңабаштан тәрбияләде» [1].

Революция һәм гражданнар сугышы романтикасы белән илһамланган шагыйрь яңа чынбарлыкка, киләчәк коммунистик җәмгыятькә багышланган шигырьләр иҗат итә. «Безнең сөю» исемле шигырь — шундый әсәрләрнең берсе.

**Егерменче елның әче җиле**
**Якаларга кереп өрә иде.**
**Син бик озак миңа коммунизм**
**Тормышының серен сөйләдең.**
**— Әле авыр,**
**Әле канлы еллар,**
**Канлы юллар, дидең, үтәбез.**
**Менә, дидең,**
**шушы авырлыкны**
**Җиңеп бер көн аңар җитәрбез.**
**— Коммунизм...**
**Бөтен кешелекнең**
**Иң бәхетле чоры, дидең син,**
**Сыйныф булмас,**
**Анда бөтен кеше**
**Тулы үсешенә ирешер.**

[1] М. Җәлил. Сайланма әсәрләр. I том, Казан, 1955 ел, 5 бит.

Тик ул көнгә, дидең,
                    кискен көрәш
Аша гына бару кирәк тә.
Маркс бабай менә шулай дигән,
Ленин менә шушы өйрәтә.

Шигырьдән күренгәнчә, кискен сыйнфый көрәш елларында туган комсомол мәхәббәте егет белән кызның интим хисләренә генә кайтып калмый, ә бәлки туган илгә булган мәхәббәт хисе дәрәҗәсенә күтәрелә.

Һәр чын язучының тарихи вакыйгаларга, үзе яшәгән чорга карата төпле эстетик карашлары, ныклы эстетик идеалы була. Муса Җәлил язучының төп бурычын чынбарлыкны дөрес чагылдыруда күрә. Шагыйрь сәнгатьнең халыкчанлыгы, партиялелеге, сыйнфый аныклыгы өчен көрәшә: «Чынлыкны дөрес чагылдыруда ике моментны онытырга ярамый, — ди ул. — Бер яктан, безнең әсәрләрдә партиячелек, сыйнфый юнәлешлелек бик кискен торырга тиеш. Партиясез әсәр безгә кирәкми. Менә шул партиячелек үзе чынлыкны дөрес чагылдыруны тәэмин итә. Бары партия юлына ышанмаган, партия һәм эшчеләр сыйныфы идеаллары белән нык сугарылмаган язучы гына чынлыкны бозып, буяп күрсәтәчәк. Икенче яктан, безнең әсәрләр художество ягыннан югары сыйфатлы булырга тиешләр»[1].

Һәр шагыйрь катлаулы тормышка үзенчә карый һәм аңа үзенчә бәя бирә. Әгәр бериш язучылар дөньяның бөеклеге һәм гүзәллеге белән соклансалар, икенчеләре үз әсәрләрендә шул бөеклекнең һәм гүзәллекнең серләрен, дөньяның асылын ачып бирәләр. Тормыш турында тирән мәгънәле әсәрләр язган шагыйрьләр турында сүз барганда, безнең күз алдына, һичшиксез, Муса Җәлил килеп баса, аның зур тәэсир көченә ия булган шигырьләре искә төшә.

Күкрәгемне ачам кояшка,
«Чахотка» ди доктор,
                    дөрес түгел.
Ул күкрәктә еллар ташкыны.
Мин дулкынлы алгы көрәшкә
Күлә-күлә күләч күкрәгемдә
Язлар тудырыр кояш асырыйм.

«Яз» дип исемләнгән бу шигырьдә тормыш сулышы, заман ритмы ярылып ята. Геройның якты өметләре, якты теләкләре бу шигъри юлларда гомумиләштерелеп бирелә. Пессимистлар уйлап чыгарган «картлык» сүзе М. Җәлил геройлары өчен ят нәрсә. Батырлар йөрәгенә яңа тәзелешләр, гигант ачышлар шавы гына дәва була ала. Шагыйрь әсәрләрендә сурәтләнгән геройларның «көрәш җимеше булып илгә яңа язлар килә».

Шагыйрьнең хыялы һәм шигъри омтылышлары — «күлә-күлә күләч күкрәгемдә язлар тудырыр кояш асырыйм» дип горурланган егетләрдә һәм кызларда, аларның фидакарь хезмәтендә, һәм менә шундый көчле ихтыярлы, тормыш авырлыкларына бирешми торган кешеләрдә М. Җәлилнең эстетик идеалы гәүдәләнә.

Безнең илдә тиңсез хезмәт белән
Социализм йорты төзелә.
Минем гомерем, кирәк бер таш булып,
Кереп ятты шул йорт нигезенә.
                    («Еллар, еллар...»)

М. Җәлил фикеренчә, шагыйрь тормышны гади рәвештә кәгазьгә күчерүче генә түгел, ә бәлки тормыш вакыйгаларын тирән аңлап, үз йөрәге аша уздырып, ялкынлы шигырь юлларына әйләндерүче кеше: «Җанлы кешене күрсәтү, аның башка кешеләр белән конкрет бәйләнеше һәм мөнәсәбәте аркылы җанлы характерын бирү — кешеләр белән җәмгатьчел бәйләнеш аркылы аңы индивидуально-

[1] М. Җәлил. Сайланма әсәрләр. III том, 123 бит.

сте ачылуын күрсәтү дигән сүз... Конкретлылык белән гомумилек бердәмлеге, индивидуаль як белән җәмәгатьчел якның бердәмлеге, минә, минемчә, әдәби әсәрдә шуңа омтылырга кирәк» [1].

Муса Җәлил үзенең идея-эстетик принципларына һәм идеалларына һәр вакыт турылыклы булды. Шагыйрьнең фәлсәфи эчтәлекле тирән шигырьләре моны тулысынча раслый. Мисал өчен бер генә шигырен алыйк:

**Үләрбез, булмабыз кол!**
**Маркс сүзе**

**Ирекле, дәртле көч без юл табарбыз,**
**Барырбыз туктамый, алга китәрбез.**
**Бөтен илләр өчен бер юл ачарбыз,**
**Шулай һәр чак теләккә без җитәрбез.**

**Түзә алмабыз, кара кан да коярбыз —**
**Басарбыз, киртәләргә бирмәбез юл;**
**Теләсәләр асарлар, без үләрбез,**
**Ләкин һичбер вакытта булмабыз кол.**
(«Төрле парчалар».)

Бу юллар революция казанышларын якларга әзер торган яңа кешенең сыйнфый дошманга кискен җавабы булып яңгырый. Без бу әсәрдә көрәш рухы белән сугарылган эстетик идеалның тулы чагылышын күрәбез. Хәзер инде, эстетик идеалның эволюциясен, аның үсешен тулырак күзаллау өчен, М. Җәлилнең 1943 елда язылган «Катыйльгә» исемле шигыренә мөрәҗәгать итик:

**Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,**
**Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә,**
**Кирәк икән, үләм аягүрә,**
**Балта белән башым киссәң дә.**

Эстетик идеалның тагын бер үзенчәлеге шунда, ул җәмгыятьнең алдынгы фикерләрен гомумиләштерә, художникның индивидуальлеге белән үрелеп, әдәби әсәр аша укучы күңеленә юл таба. Сәнгатьтә ул бәяләү категориясе булып тора. Һәм сәнгатьнең үз спецификасы булган кебек, эстетик идеалның да үз спецификасы бар.

Язучы тормышның кайсы гына өлкәсе турында язмасын, аның әсәрләрендә шул чорның, шул җәмгыятьнең характерлы яклары да чагыла. Димәк, эстетик идеал җәмгыять тормышын да чагылдыра. Муса Җәлилнең егерменче елларда формалаша башлаган эстетик идеалы турында шул ук сүзләрне кабатларга була.

М. Җәлилнең егерменче еллар иҗатындагы эстетик идеал, әдәби-эстетик принциплар шул чорда язылган бик күп шигырьләрендә һәм бигрәк тә «Орлес заводында» исемле поэмасында тулы чагыла. Бу әсәрдә шагыйрь ару-алуны белмәс хезмәт кешесен сурәтли. Автор төзү пафосы, югары энтузиазм белән рухланган кешенең характерын ачып бирә.

Без монда социализм төзү чоры әдәбиятына хас бер кызыклы күренеш белән очрашабыз. Күтәргән мәсьәләләре, формасы һәм эчтәлеге ягыннан «Орлес заводында» исемле поэма В. Маяковскийның күп кенә шигырьләрен хәтерләтә.

Моңа артык гаҗәпләнергә кирәкми. Яңа социалистик җәмгыять төзү чорында төрле милләт шагыйрьләре эчтәлеге ягыннан бер-берсенә авазадаш булган шигырьләр язалар, охшаш шигъри авазлар тудыралар.

М. Җәлилнең шагыйрь булып җитлегүен, аның эстетик идеалларының камилләшүен илебездә һәм чит илләрдә барган вакыйгалардан аерып карарга ярамый, әлбәттә. Бөек Ватан сугышына кадәр үк ул фашизмның никадәр куркыныч булуын сизә, аларның ерткычлыгын фаш иткән шигырьләр, зур күләмле әсәрләр яза. «Джим» исемле поэмасында шагыйрь фашизмның социаль нигезләрен, аның кешелеккә дошман бу-

[1] Шунда ук, 362 бит.

луын ачып бирә. Зур күләмле бу әсәрендә ул немец кызы кечкенә Эмманың бәхетсез бала чагы турында сөйли.

Муса Җәлил кешелек дөньясының чәчәк атуы, дөнья халкының бәхетле яшәве турында хыяллана. Миллионнарча балаларның ачлыкта үткән гомере шагыйрьнең йөрәген телгәли. «Джим» — иң бөек кешелек хисләре һәм иң югары идеаллар белән сугарылган поэма.

Кагыйдә буларак, әдипнең эстетик идеалы ул иҗат иткән уңай образлар аша бирелә. Лирик геройның уй-фикерләре аша язучы үзенең дөньяга, чынбарлыкка карашын билгеләрә, тормышның җитешсез якларын тәнкыйтьли.

Күпчелек очракта әдипнең эстетик идеалында, ул яшәгән чорның үзенчәлекләре белән бергә, киләчәк тормышның үрентеләре дә чагылыш таба. Художникның эстетик идеалы шулай ук нинди сыйныф, нинди партия мәнфәгатьләрен яклавы белән бәйле. Мәгълүм булганча, совет әдәбиятының идеалы нигезендә коммунистик партиялелек принцибы ята. В. Маяковский шигырьләре, А. Фадеевның «Тар-мар»ы, М. Шолоховның «Тын Дон»ы, Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ы һәм башка язучыларның әсәрләре шул турыда сөйли. М. Җәлил дә коммунистик идеаллар белән сугарылган «Таң алдыннан», «Сәрвәр», «Зәйнәп», «Иделдән хат», «Директор һәм кояш», «Җиһан», «Яшьлек», «Хат ташучы», «Алтынчәч» һәм «Илдар» кебек масштаблы әсәрләр иҗат итә.

МУСА ҴЬАЛИЛЬ

## САРА САШӘАҚУА

Сашәақуа, сгу ами, сыҧсы ами шәызлысхыз,
Шьҭа шәыҟуҩла сҭәыла, шәгуҭгаган шәгала!
Шәаҟа хақуитрен мца-ҧхарен шәызнысхыз,
Убрнаҟара ҧсҭазаарагь шәоушт, шәаҧырла!

Шәара ишәысҭеит сцәанырра анхышхыцәоз,
Сгурҕьара, сыҧабжьыш шәысҭеит шәара.
Шәыҧсыр — издыруеит наӡаӡа ҳәа сшыцәо,
Шәыҟазар — ишәарҭам са сзыҳәан аҧсра.

Енбасырҟит сара уи ашәа уцраларҭә,
Инагӡо сгу адҵа, жәлар рыдҵа.
Сҩыза игу ахура сырҕьон уи абжьала,
Саҕа снҿагылон еснагь сыҕуҕуаӡа.

Ихаҭәаам агурҕьара, анасыҧ — башоуп,
Урҭ сырхыччонт, срышьҭам зынӡас.
Анашоуп сашәа иузнанаго, нашоуп
Сыззыҟуҧо, сыҧсгьы зҭоу хаҵаҵас.

Аҧсҭазаара хаара сыҧсы алыхухуа ишалоу,
Инасыгӡонт, аа, шәҿаҧхьа сҭоуба:
Сыҧсадгьыл назыск'уан сажәақуа еиҧраалан,
Иахьа сыҧсҭазаара азыск'уеит, ижәба.

Ашәа схәон сара, ааҧын сгу арҿыхаш,
Ашәа схәон сара, ашьаура анаҭахха.
Абар, ацыхутәантәи ашәагь аҧысцонт,
Иеиха кны дшысхагылоу аҕа.

Ахақуитраз аҿуҧашьа снарҵеит сара ашәа,
Сшыкуҧо сҭахарц уи исаҭоит адҵа.
Ашәаны ирылан сыҧсҭазаара ажәлар,
Сыҧсра аӡбахугьы ган нашәаны, иҿацаӡа.

Еит. Н. Куҵниа.

*Абхаз телендә*

*Н. Куцнина тәрҗемәсе*

Совет власте елларында Татарстанда яңа социалистик мөнәсәбәтләр барлыкка килде. Табигый ки, ул мөнәсәбәтләрне язучылар да читләтеп уза алмыйлар иде. Бу чорда безнең әдәбиятта мәхәббәт темасына багышланган бик күп әсәрләр языла. Күренекле татар шагыйре Һади Такташ «Мәхәббәт тәүбәсе» исемле мәгълүм поэмасында яңа моральгә, мәхәббәттә яңа мөнәсәбәтләрнең барлыкка килүенә дан җырлый. Аның геройлары саф мәхәббәткә ышаналар, саф мәхәббәт хакына утка да, суга да керергә әзерләр.

Әгәр Такташ поэмасында Зөбәйдә белән Мәхмүт үз күңелләрендәге каршылыкларны җиңү өчен көрәшсәләр, Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестенда исә без характерлары, тормышка карашлары капма-каршы булган геройлар белән очрашабыз. Башка язучылардан аермалы буларак, М. Җәлил мәхәббәт мәсьәләләрен хезмәт темасы белән тыгыз бәйләнештә сурәтли. Ул, татар совет әдәбиятында беренчеләрдән булып, кешеләрнең хезмәткә, социалистик милеккә карата яңа мөнәсәбәте турында яза.

Шагыйрьнең сугышка кадәр язылган әсәрләрендә яңалык белән искелекнең көрәше аеруча зур урын ала. Үз поэмаларында ул кешенең тормышка карата яңа мөнәсәбәте турында сөйли. Мәсәлән, «Хулиган» исемле поэмасында М. Җәлил кешенең җәмгыять алдындагы мораль җаваплылыгы турында яза, яшьләргә әхлакый тәрбия

бирү мәсьәләсен күтәреп чыга. Үзенең идея-эстетик принциплары ягыннан «Сәрвәр» поэмасы хәзер генә телгә алган «Хулиган» исемле әсәргә якын тора.

Поэмада иске һәм яңа авыл капма-каршы куела, матур киләчәк турында сүз алып барыла. Әсәрнең эчтәлегеннән күренгәнчә, яңа авылда Сәрвәр кебек алдынгы карашлы яшь егетләр һәм кызлар яшәячәк.

**Комсомоллар —**
**тиңсез күмәк булып,**
**Бирелгәннәр сыйныф эшенә.**
**Иске тормыш килеп билен бөксен**
**Чор тудырган яңа кешегә.**

Художникның эстетик идеалын чагылдыруда тел чаралары һәм әсәрнең композицион алымы зур роль уйный. Эстетик идеалның нигезендә шагыйрьнең тормышка, чынбарлыкка булган мөнәсәбәте ята.

«Сәрвәр» поэмасында М. Җәлил кешенең җәмгыятьтә тоткан урыны турындагы мәсьәләне күтәреп чыга. Шагыйрьнең бу әсәрендә без аның утызынчы еллар авыл тормышындагы кискен үзгәрешләргә карата мөнәсәбәтен тоябыз. М. Җәлил үз геройларының шәхси тормышын коллектив тормышы белән тыгыз бәйләнештә карый. Аның геройлары халык, җәмгыять интересларын шәхси интересларыннан өстен куялар.

Шагыйрьнең уңай герое күп планлы. Ул үзе геройларының характерын ачканда таптанган алымнардан, шаблоннардан качарга тырыша. М. Җәлилнең уңай герое — кыю һәм тәвәккәл кеше, ул бервакытта да югалып калмый. Аның күңелендә хезмәткә, хезмәт кешеләренә карата иксез-чиксез мәхәббәт ята. Хыялны тормышка ашырырга! Аның геройларының девизы әнә шундый.

Гади генә хезмәттә дә батырлык күрсәтергә мөмкин дип уйлый шагыйрь. Кырыс табигать шартларына карамый югары уңыш үстерү үзе генә дә героизм түгелмени? Гомереңне кешеләр бәхете өчен көрәшкә багышлаудан да мактаулырак нинди эш булырга мөмкин?!. «Иделдән хат» исемле поэманың лирик герое әнә шундый уйлар һәм теләкләр белән яши.

Әсәрнең баш герое Сибгат абый — яңалык өчен көрәшнең алдынгы сафында баручыларның берсе. Шагыйрь Сибгат абый образында яңа чор кешесенә хас сыйфатлар күрә.

**Идел мине**
**Ерак**
**Алып китсә дә,**
**Йөрәк —**
**Сезнең кырларда.**
**Сез булырсыз минем**
**Җырланмаган килер**
**Яңа җырларда.**
**Бу колхозлы кырлар**
**Миңа яңа җырлар,**
**Көйләр өйрәтте.**
**Барсыннан да тирән**
**Сеңеп калды миңа**
**Синең сурәтең...**

Югарыда тикшерелгән әсәрләреннән чыгып, без шагыйрьнең киң масштаблы художник булуын күрәбез. Аны тормышның бөтен өлкәләре дә кызыксындыра. Әдип, конкрет тормыш материалына таянып, яңа социалистик җәмгыять кешесенең формалашуын, аякка басуын күрсәтә. «Директор һәм кояш» исемле поэмасында М. Җәлил изге теләкләр белән яшәгән, авыл хуҗалыгын күтәрү өчен бөтен белемен һәм көчен куйган совхоз директоры образын иҗат итә. Һәр яңа уңыш белән директор әйтерсең үзе дә яңадан туа, хезмәттәге уңышлар аны канатландыра, яңадан-яңа җиңүләр яуларга рухландыра.

Муса Җәлилнең сугышка кадәр язылган әсәрләрендә без социалистик җәмгыять төзүче совет кешеләренең сыйнфый дошманга каршы кискен көрәшүен, аларның дөньяга карашлары һәм аңнары үсә баруын күрәбез. Тормышны гөлбакчага әйләндерүче, зур-зур ачышлар ясаучы, бөтен яктан да камил образлар тудыру шагыйрьнең иң югары теләге була. Һәм менә шул аның эстетик идеалының конкрет эчтәлеген тәшкил итә дә инде.

Үзенең поэмаларында шагыйрь илдә барган үзгәрешләрнең бөеклеге, аларның гүзәл киләчәкнең хәбәрчесе булуы турында яза. Бу әсәрләр хезмәт күтәренкелеге, яңа социалистик тормыш романтикасы белән сугарылган.

Киң колачлы поэмаларында автор замандашларының аңына, рухына мөрәҗәгать итә. Аның уңай герое якты тормыш өчен көрәшнең алгы сызыгында бара. Шагыйрь әсәрләренең уңай геройлары заман, чор белән тыгыз бәйләнгән.

М. Җәлил эстетик идеал төшенчәсен яңа тормыш өчен барган көрәш процессы белән генә чикләми, ә бәлки аңа героик көрәшнең һәм хезмәтнең нәтиҗәсен дә кертә. Ул — хезмәттә яулап алынган бәхет, хезмәт бәйрәме.

Колхоз авылын үзгәртеп коруга багышланган «Җиһан» поэмасы җир хуҗасына, хезмәт кешесенең фидакарь хезмәтенә дан җырлый. Биредә шагыйрь хезмәттә яулап алынган җиңүдән дә зуррак бәхет юк дигән фикерне үткәрә.

Утызынчы елларда күп кенә татар язучылары үз әсәрләрендә хезмәт батырларының тормышчан образларын күтәреп чыгалар. Мондый әсәрләр М. Җәлил иҗатында байтак очрый. Халык авыз иҗатының бай традицияләренә таянып, ул чынбарлыкның катлаулы мәсьәләләрен тирән итеп ачып бирү югарылыгына күтәрелә.

Әгәр шагыйрь элекке шигырьләрендә яңалыкның искелекне җиңүе, гуманистик, интернациональ традицияләрнең иске гореф-гадәтләрдән өстен булуы турында язса, кешенең тормышта тоткан урыны турында сөйләсә, «Хат ташучы» поэмасында ул социалистик җәмгыятьне нигыту, кешенең аңы үсүе, гади кешенең рухи пакьлеге турында сөйли. Шунысы да игътибарга лаек, М. Җәлил, татар совет әдәбиятында беренчеләрдән булып, җәберләүләрдән һәм изелүдән Бөек Октябрь азат иткән хатын-кыз образын тудыра. Хатын-кызны көрәшче, яңа тормыш төзүче итеп күрсәтү аның эстетик идеалында бик мөһим рольне уйный.

М. Җәлилнең эстетик идеалы халыкның героик рухыннан башлангыч ала. 1948 елда СССР Дәүләт премиясенә лаек булган «Алтынчәч» драматик поэмасы (Н. Җиһанов язган опера) моның бер матур үрнәге булып тора. «Алтынчәч» драматик поэмасы халыкның ерак үткәненә багышланган. Ул татар халкының героик эпосы нигезендә язылган. Әсәрнең баш герое булган халык образында без хан гаскәрләренә каршы торырлык горур көчне күрәбез. Реалистик һәм романтик алымнарны кулланып, М. Җәлил поэмада халык массаларының омтылышын һәм теләген, идеалларын ачып бирә алган.

Әсәрнең нигезендә азатлык сөюче халыкны буйсындыру мөмкин түгел дигән идея ята. Халыкның идеаллары — азатлык, бәйсезлек өчен көрәштә җиңеп чыгу. М. Җәлил бу турыда язып та чыккан иде: «Тугзак әби җәйләвенең Казан ханы тарафыннан туздырылуы, Җикнең халыкны ханга каршы көрәшкә туплавы бу эпоска халыкның изелүгә каршы көрәшен чагылдырган героик эпос төсен бирә. Либреттода, аңлы рәвештә, менә шул идея нигезгә алынып, вакыйгалар шул планга корылдылар» [1].

Поэма оптимистик рухта язылган патриотик җыр белән тәмамлана.

**Без җырлыйбез илнең данлы**
**Тимер куллы баһадиры**
**Мәргән турында.**
**Тиздән матур гөлләр үсәр,**
**Шаян кызлар җырлап үтәр,**
**Идел буенда.**
**Без җырлыйбыз илнең чибәр,**
**Алтынчәч күк ирек сөяр**
**кызы турында.**

Сөземтә рәвешендә шуны әйтәсе килә: Муса Җәлилнең эстетик идеалы аның балалык елларында ук формалаша башлый һәм халык тормышында булып үткән кискен үзгәрешләр, бөек тарихи вакыйгалар белән тыгыз бәйләнештә үсә бара. Әдипнең эстетик идеалы Бөек Ватан сугышына кадәрге иҗатында ук тәмам камилләшеп җитә. Ә Бөек Ватан сугышы елларында М. Җәлил иҗатының иң югары ноктасы булган «Моабит дәфтәре» языла, шагыйрьнең шигъри һәм сугышчан батырлыгы бөтен дөньяны таң калдыра.

---

[1] М. Җәлил. Сайланма әсәрләр. II том. 346 бит.

# МУСА ҖӘЛИЛ САРАТОВ ӨЛКӘСЕНДӘ

Утызынчы елларның башы. Авыл җирендә сыйнфый көрәш аеруча нык кызган еллар. Колхозлар яңа гына оешып килә, колхозларга техника кирәк, авыл җирендә техника белән эш итә белүче хәзерлекле кадрлар җитми. Кыскасы, авыл һәрьяклап зур ярдәмгә мохтаҗ чак. Менә шундый чакта, 1933 елның язында, Саратов өлкәсенең Дергач районы Верхазовка (Илмин) машина-трактор станциясенә Мәскәүдән, «Коммунист» газетасының күчмә редакциясе белән, Муса Җәлил килеп төшә.

Муса Җәлил, җаваплы редактор буларак, кыска гына вакыт эчендә редакциянең эшен җайга сала. Верхазовка (Илмин) машина-трактор станциясе хезмәт күрсәтә торган колхозларда яшьләрдән һәм өлкән яшьтәге актив колхозчылардан, шулай ук авыл интеллигенциясе вәкилләреннән хәбәрчеләр туплый, шулар ярдәмендә колхозларда хезмәт дисциплинасын күтәрү, авыл хуҗалыгын ныгыту өчен көрәш башлап җибәрә.

Талантлы оештыручы һәм журналист булу белән бергә, ул авылларда культура-масса эшләрен җанландыру буенча да күп эш башкара. Аның якыннан катнашы белән әдәби кичәләр уздырыла, концертлар куела. Муса Җәлилнең җәмәгать эшчәнлеген бу авылларда[1] әле дә онытмыйлар, сагынып һәм хөрмәт белән искә алалар.

Дергачтагы колхоз хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе, 1925 елдан КПСС члены, персональ пенсионер Галләм Һидият улы Батраев, ул көннәрне искә төшереп, болай ди:

«Мин сөекле шагыйребез Муса Җәлилне беренче тапкыр 1933 елның язында Дергач районының Илмин авылында очраттым. Ул «Коммунист» газетасының күчмә редакциясе белән Мәскәүдән килгән. Мин ул чакта сугарыла торган участокта (хәзерге көндә «Алтата» совхозы) орлыкларның сортын сынау станциясе директоры булып эшли идем. Муса Җәлил үзен тәҗрибәле оештыручы, яхшы журналист, сәләтле партия работнигы итеп таныты. Газета чыгару эше белән беррәттән, ул авылларда үзешчән сәнгать көчләрен оештырды һәм аларның эшчәнлеген җәелдереп җибәрде. Үзе дә мандолинада бик матур уйный иде. Газетада еш кына аның үз шигырьләре басыла, һәм аларда ул колхоз алдынгыларын мактый, ялкаулардан көлә, эштәге кимчелекләрне тәнкыйтьли иде. Ул колхозчылар алдында еш кына лекция һәм докладлар белән чыкты. Муса Җәлил колхозчылар алдында зур ихтирам казанды».

1929—1935 елларда Илмин авылында бригадир, ә соңыннан механизатор булып эшләгән, хәзерге көндә пенсионер Сафа Хөсәен улы Гайнетдинов Муса Җәлилне болай дип искә ала:

«1933 елның язында, язгы чәчү алдыннан, районнан колхоз идарәсенә олаулар җибәрергә куштылар. Ул елны яз иртә килде, юл өзелгән чак иде. Шулай да олаулар җибәрелде. Күчмә редакция безгә менә шундый пычрак вакытта кичкырын килеп төште. Төнлә мине колхоз идарәсенә чакырып алдылар. Редакциягә типография машинасын өйләндерү өчен бер таза егет һәм тагын наборщик кирәк булып чыкты. Безнең бригададан Мөстәкыйм Фәтхуллин дигән егет наборщик итеп билгеләнде. Өч тәүлек тә үтмәде, күчмә редакциянең беренче газетасы басылып та чыкты. Моннан соң инде ул тәртипле рәвештә көнаралаш чыга башлады. Газетаның һәр санында диярлек

---

[1] Мәкалә авторы Камил Абдразаков — чыгышы белән Илмин авылы кешесе, Хәзер Казанда яши, запастагы подполковник, Редакция,

«Алдынгыларга тигезләнегез» дигән бүлек була. Бу бүлектә басылган материалларда тырыш колхозчылар мактала, ялкаулардан көләнә, җитешсезлекләр тәнкыйть уты астына алына. Без Мусаның кыска гына вакыт эчендә колхоз хәлләре белән шулай яхшы танышып өлгерүенә хәйран кала торган идек. Күчмә редакция килеп бер атна вакыт үттеме-юкмы, Муса безгә колхозда комсомол-яшьләр звенолары оештырырга киңәш итә башлады. Оештырдык. Алар яхшы эшләделәр. Бу яшьләр арасыннан Әһлиулла абзый кызы Зөһрә Саттарова, Рәхмәтулла абзый кызы Әсма Байбикова, Гыйлаҗи абзый кызы Җәмилә Фәтхуллина, Әминә Байбикова, Сираҗи абзый кызы Нәфисә Әмирова, Нәбиулла абзый кызы Әминә Фәйзуллина һәм Сафиулла абзый кызы Тәзкирә Батраеваларның аеруча актив эшләүләрен күрсәтеп үтәсе килә. Газета, гадәттә, иртүк чыгып өлгерә иде. Муса, газетаның яңа номерларын алып, минем белән бергә бригаданың кыр станына бара һәм шунда колхозчыларга кычкырып газета укый торган булып китте. Әйе, хезмәт сөючән бу шагыйрь эштә язгы ташкын шикелле көчле һәм ыргылулы иде».

## МИН ЫРЫАЛАРЫМ

Сүрэҕим иитиэхтээбит ырыалара,
Аҕа дойдубар тэлээрэн тиийиҥ,
Эһиэхэ ингмит көнгүл-дьол уоттара
Күөдьүппүт күүһүнэн сирэлийиҥ!

Эһиэхэ инээртим истиг эрэлбин,
Итии иэйиибин, көмүскэм уутун,
Умнуллубат ырыаларбар этиллэммин
Тыыннаах буолуом мин эмиэ куруутун.

Сүрэҕим этэрин, норуот этэрин
Толорон, ырыа-тойук айарым —
Ырыанан доҕор сүрэҕин күүрдэрим,
Өстөөҕү ырыабынан кыайарым.

Чалым үөрүүнү, көрүнньүк дьолу мин
Элэктиибин, билинэ барбаппын,
Ырыабар дьингнээх кырдьыгы этэбин,
Этэбин туох иһин охсуһарбын.

Сүрэх, тиһэх тэбиитигэр диэритин,
Толоруо Аҕа дойдубар иэһи:
Кииниэхэ ырыабын аныыр этим мин,
Бүгүн кииниэхэ тыыммын биэрэбин.

Ыллыыр этим саас иһэр сибиккитиҥ,
Ырыалаах бу кыргыһа сылдьабын.
Көрөбүн палач хаан сиһик сүгэтин,
Бу кэриэс ырыабын суруйабын.

Миигин ырыа үөрэппитэ көнүлгэ,
Бу ийүнниүү өлөргө этэ ырыа...
Олоҕум ырыа буолта Ийэ сиргэ,
Өлүүм да ырыа буолан сатарыа.

Бэс ыйын 26 к. 1943 сыл.

*АРХИП АБАГИНСКАЙ тылбааһа.*

*Якут теленә*
*А. Абагинский тәрҗемәсе*

Заманында «Кызыл маяк» колхозының комсомол-яшьләр звеносында эшләгән Җәмилә иптәш Фәтхуллина да ул елларны яхшы хәтерли икән.

«Районнан сезгә күчмә редакция килә дигән хәбәр алынгач, колхоз идарәсе ирем Йосыф Азизовтан күчмә редакцияне каршы алуны үтенде,— ди Җ. Фәтхуллина.— Ирем өч пар үгез, ике дөя белән Дергачка китте. Муса Җәлил һәм аның юлдашы Габделбари (фамилиясе онытылган) бездә тукталды. Редакцияне һәм типографияне мәктәп бинасына урнаштырдылар. Барыннан да бигрәк безне Мусаның ару-талуны белмичә киеренке эшләве сокландыра һәм гаҗәпләндерә иде. Ул иртәдән кичкә кадәр авылларда колхозчылар арасында була. Атка һәм дөягә атланып та, җәяү дә йөри. Ә кичләрен ярты төнгә кадәр материаллар эшкәртә иде».

Нәшмә иптәш Алимова ул вакытларда Илмин авылында укытучы булып эшләгән.

«Мин авылда культура-агарту эшләрен оештыру буенча Муса Җәлилдән күп нәрсәгә өйрәндем,— ди ул.— Язгы чәчүләр беткәч, яңгырлы көннәрнең берендә Муса уку залына килеп керде. Бирегә шактый күп яшьләр җыелган иде. Без аннан берәр шигырен укуын үтендек. Ул шунда безгә үзенең яңа гына язган «Ләйсән» дигән шигырен укыды.

Төтен төсле тетелеп,
Болыт агыла
Алтын бодай йоткан кырларга.
Колхозчының ярсу йөрәге
Сөенеп тибә менә шуңарга.

. . . . . . . . . . .

Шагыйрьнең күтәренке рух белән укуы, шигырьдәге сүзләрнең тирән мәгънәле булуы һәм шул чактагы реаль вакыйгаларга туры килеп торуы яшьләрдә тирән тәэсир калдырды. Муса үзенең шигырьләрен колхозчыларга еш укый иде. Әле дә хәтеремдә, бервакыт ул «Карак» дигән шигырен укыды. Әсәр түбәндәге сүзләр белән тәмамлана:

**Колхоз милке**
**Яңа көннәреңнең**
**Корыч нигезе булган өчен дә,**
**Сыйнфый дошман хәзер колхозларның**
**Мал-милкенә күбрәк үчегә.**
**Син аңыңа сеңдер —**
**Колхоз милке**
**Сезнең уртак милек булганын,**
**Колхоз милке өчен**
**Көрәш утын**
**Көчәйт, әйдә,**
**Күтәр югары!..**

Шагыйрьнең «Язгы юлда» дигән шигыре колхозчыларда аеруча зур кызыксыну тудырды. Чөнки ул Дергач районы колхозларындагы конкрет хәлләрдән чыгып язылган иде...

Муса Җәлилнең күп кенә шигырьләре хәзер бу авылларда халык җырлары булып киткән, һәм яшьләр аларны яратып җырлыйлар. Тик шунысы кызганыч, күчмә редакция чыгарган газеталар бер җирдә дә, хәтта Мәскәүнең В. И. Ленин исемендәге китапханәсендә дә сакланмаган. Шуңа күрә Муса Җәлилнең күчмә газета битләрендә басылган шигырьләрен без белмибез.

Илмин авылы колхозчылары герой-шагыйрь истәлеген зур ихтирам белән саклыйлар һәм, аның истәлеген мәңгеләштерү ниятеннән чыгып, авылда шагыйрьгә мемориаль такта куярга һәм яңа салынган мәктәпкә Муса Җәлил исемен бирергә телиләр. Саратов өлкәсе партия һәм совет оешмалары җитәкчеләре һәм Совет язучылары союзының Саратов өлкәсе бүлеге бу изге теләкне тормышка ашыруда колхозчыларга ярдәмгә килерләр дип ышанырга кирәк.

Сүз уңаенда шуны да әйтеп китәсе килә, тәнкыйтьче Гази иптәш Кашшаф Муса Җәлилнең «Сайланма әсәрләре»нә язган сүз башында: «Партиянең Дергач райкомы июль аенда аны Сталинградка командировкага җибәрә» (I том, 48 бит), дип яза. Биредә ул кечкенә бер төгәлсезлек җибәргән. Ул чагында партиянең край комитеты Сталинград шәһәрендә түгел, ә Саратов шәһәрендә урнашкан була.

Герой-шагыйрь Муса Җәлил турында әйтергә теләгән сүзләрем менә шулар иде.

**КАМИЛ АБДРАЗАКОВ**

**Капан Камбаров,**
филология фәннәре кандидаты

# КАҺАРМАН ШАГЫЙРЬГӘ ҺӘЙКӘЛ

Казакъ шагыйре Җубан Молдагалиев 1956 елда «Җыр турында җыр» исемле поэма яза. Билгеле булганча, аның бу әсәре тугандаш татар халкының атаклы шагыйре Муса Җәлилнең якты истәлегенә багышланган.

Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең тиңдәшсез батырлыгын һәм үлемсез шигырьләрен дөньяның барлык илләрендә яхшы беләләр. 1942 елның җәендә, Волхов фронтындагы каты сугышлар вакытында, шагыйрь авыр яралана. Аңын җуйган Җәлилне фашист палачлары әсир итәләр һәм концлагерьга ябалар. Ләкин шагыйрь анда да югалып калмый. Үлем лагерендагы тоткыннар арасында яшерен эш җәелдерә, ялкынлы сүзе, дошманга нәфрәт тулы шигырьләре белән аларны гитлерчыларга каршы көрәшкә өнди, фашизмга каршы көрәшүче яшерен оешма төзи, партизаннар белән элемтә урнаштыра, концлагерьдан күмәк качулар оештыра. Кызганычка каршы, аның бу эшләре фашистларга беленә. Нәтиҗәдә Җәлилне һәм аның иптәшләрен, үлем җәзасына хөкем итеп, Берлиндагы Моабит төрмәсенә китереп ябалар. Авыр төрмә шартларында ул үзенең атаклы «Моабит дәфтәре»н яза.

Әйе, хәзер без Муса Җәлил турында, аның тоткынлыктагы тормышы һәм көрәше турында күп беләбез. Әмма илленче елларда, Җубан Молдагалиев герой шагыйрь хакында зур күләмле шигъри әсәр язарга җыенып йөргән көннәрдә, хәл бераз башкачарак иде. Дөрес, геройлыгы бәхәссез. Аның ике ел дошман төрмәсендә утыруы, үлем җәзасына хөкем ителүе дә мәгълүм. Шуның белән бергә, шагыйрь биографиясендә ахыргача ачыкланып җитмәгән моментлар да шактый. Мондый очракта ни эшләргә, нәрсәгә таянырга соң?

Бердәнбер юл кала, ул да булса шагыйрьнең үз иҗатына таяну. Җубан Молдагалиев шулай эшли дә. Ул бик җентекләп һәм зур игътибар белән Мусаның әсирлектә язган шигырьләрен өйрәнә башлый. Һәм тиздән бер нәрсәне аңлап ала: шагыйрьнең бөтен тормышы шигырьләрендә чагыла икән ләбаса. Шатлык-кайгылары һәм газап-сагышлары да, туган иленә һәм туган халкына чиксез мәхәббәте дә, дошманнарына булган нәфрәте дә... Акрынлап поэманың төп идеясе ачыклана. Шагыйрьне әсир итәргә дә мөмкин, әмма шигырьне әсир итеп булмый. Шагыйрьне үтерергә дә мөмкин, әмма аның иҗаты — үлемсез.

«Җыр турында җыр» шагыйрь иҗатының үлемсезлеген раслаган символик юллар белән башлана. Муса Җәлилнең әсирлектә язган шигырьләре, таш капчыктан чыгып, туган илгә кайтып җитә һәм, трибунага менеп, шагыйрьнең фаҗигале язмышы турында сөйли башлый:

**Әй шагыйрь! Шагыйрь килмәде,**
**Буш торды түрдә урыны.**
**Шигыре залны иңләде**
**Күңел кылына орынып:**

## ЫРЛАРЫМ

Сагыжымга доруктуңар, ырларым,
Ада-чуртка чечектелип саглаңнаңар.
Чалбыыш биле хосталганы шипшип бердим,
Айдың черге чурттаарыңар мөңге болзун.

Изиг көс дег бодалдарым, тура-соруум,
Ийи караам арыг чажы ырларымда.
Ынчангаштың кады өлүр, деңге чурттаар—
Ырым-биле даады тудуш салымныг мен.

Ынак чүрээм, чонум чарлыын катай бодап,
Ырларымны чалбыыш-биле тынгарган мен.
Эргелиг ыр өңнүктерни тааладыр,
Эрбенниг ыр дайзыннарны шугулдадыр.

Кара чаңгыс дужун хараар кежик, дыштан
Хая көрнүп, бужарзынып шоодар мен.
Ыры болза шынныг болгаш чүткүл сиңген,
Ынчангаштың демисежип, дириг чор мен.

Амыдырал, сөөлгү тыныш үзүлбээнде,
Алыс чүрээм таңгыракка шынчы бөлур:
Ада-чуртка ырларымны өргүп чордум,
Амы-тыным Ада-чуртка бөгүн туттум.

Часкы салгын арыын тынып, ырлап чордум.
Төрээн чурт дээш тулчуп тургаш, ырлап чордум.
Шаажылакчы мези туткаш, арнып турда,
Дөскел билбес сөөлгү ырым бижип кагдым.

Ыры мени хосталгага чаңчыктырган,
Ыры мени тулчуп тургаш, өлзүн диген.
Өйлүг назым чонга ырлап, бараалгаан мен,
Өлүмүм-даа демиселдиң ыры апаар.

*1943 ч. ноябрь 26.*

*Тува теленә*
*А. Даржаа тәрҗемәсе*

**— Эзләсә мине кем дә кем,**
**Байрагы итсен шигъремне.**
**Шигъремнең сүтсә йомгагын,**
**Серләрен ачар гомремнең.**

Җ. Молдагалиев әсирлектә, төрмә камерасында газап чиккән шагыйрьнең үз ватанына, газиз халкына, туган-үскән җиренә булган мәхәббәт хисен ифрат оста һәм тәэсирле итеп сурәтли. Дөньяда илне ярату хисеннән дә көчлерәк тагын ни бар икән?! Шул хис шагыйрьгә иң кыен чакларда яшәү көче биргән, шул хис таш диварлы караңгы читлектә нурлы шигырьләр яздырган.

**Туган җир, ерак калдың син,**
**Якын тик үзең хәзер дә,**
**Ерак син — чөнки кул җитми,**
**Якын син — чөнки хәтердә!**

Кысан таш бүлмәдә яткан шагыйрьне хыялы туган җиренә алып кайта. Ә анда сабан туе гөрли. Гармунчы егет гармунын сузып җибәрә, кызлар биергә чыга. Бер читтә «Галиябану»ны җырлыйлар.

**«Иркәм» дип куйды пышылдап,**
**Сизмичә тоткын үзе дә.**
**Сагынган җирләр тагын да**
**Күренде төсле күзенә.**

Шагыйрьнең еракдагы иленә, ватандашларына булган мәхәббәте, кайнар тойгылары һәм сагыну хисләре «Моабит дәфтәре»ндәге тетрәткеч шигырьләре белән кушылып китә:

**Туган илем, үксез улың булып,**
**Үләм инде читтә тилмереп,**
**Яшем барсын сиңа елга булып,**
**Каным шытсын кызыл гөл булып.**

Башкача әйткәндә, «Җыр турында җыр» авторы әсәр героеның күңелен, аның нечкә кичерешләрен Мусаның үз шигырьләренә таянып ача. Поэма юкка гына «Җыр турында җыр» дип аталмый.

Сайрар кош кысынкылыкка түзә алмый, былбыл тынчу читлектә һәлак була. Шуның кебек, М. Җәлилнең төрмәдә язган шигырьләрендә, бу хурлыктан үлем артык, дигән юллар да очрый:

**Мин алдымда күрдем шыр сөяктән**
**Котылгысыз үлем шәүләсен,**
**Кил син миңа, үлем, бары гомрем**
**Коллык белән тәгәлләнмәсен!**

Тик әсирлектәге шагыйрь үз җаны өчен түгел, ә язган һәм язачак шигырьләре, аларның киләчәк язмышы өчен борчыла. Җубан Молдагалиев бу хисне шагыйрьнең монологы аша сурәтли:

**Калса да тәнем ят җирдә,**
**Кайтачак илгә йөрәгем.**
**Ике үлем юк. Җыр гына**
**Үлмәсен,— тик шул теләгем!**

Муса Җәлилнең Моабит төрмәсендә утырганда язып калдырган васыятендә шундый юллар бар: «...Бәлки аны үлем җәзасына хөкем итәрләр. Ул үләр. Ә аның әсирлектә һәм тоткынлыкта язган 115 шигыре бар. Ул шулар өчен кайгыра... Әгәр бу китап кулыңа төшсә, сугыштан соң Казанга хәбәр итеп, үлгән татар халык шагыйренең шигырьләре итеп дөньяга чыгар. Минем васыятем шул! Муса Җәлил, 1943, декабрь».

«Җыр турында җыр»да васыятьнең йөрәкне сулкылдатырлык монологка әйләнүен күрәбез. Шагыйрь җанын, аның үзеннән соң калган әсәрләре өчен хафалануын шагыйрьдән дә артык кем төшенсен?! Җ. Молдагалиев үз әсәрендә гаять отышлы алым тапкан. Ул тоткын шагыйрьнең омтылышын һәм тойгыларын романтик төсмерләргә төреп биргән. Поэманың тагын бер үзенчәлеге әнә шунда булса кирәк.

Ватаны, халкы өчен утка керергә әзер торган Муса дошманына карата рәхимсез һәм аяусыз. Хөкем ителеп, сәгатьләп-минутлап үлем җәзасын көтеп ятканда, 1943 елның ноябрендә, шагыйрь «Катыйльгә» дигән шигырен яза:

**Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,**
**Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә,**
**Кирәк икән, үләм аягүрә,**
**Балта белән башым киссәң дә.**

Поэма авторы Муса Җәлил шигырендәге бу юлларны тагы да үстергән, әсәрдәге каһарманлык мотивларын яңарта, тулыландыра төшкән. Менә беренче бәрелеш. Гестапо залиме тоткын шагыйрьне тозакка төшермәкче. Ул аны илен, халкын сатарга димли. Безнең белән хезмәттәшлек ит, үзең дә исән-сау калырсың, хатының, балаң белән дә күрешерсең, ди. Мусаның йөзендә мыскыллы караш, ә күзләрендә әйтепсөйләп бетергесез нәфрәт:

**Нәфрәтле үткен күзендә**
**Күз нуры түгел, ут яна;**
**Ут түгел, аннан каһәрләп**
**Дошманга мең-мең ук ява.**

Мыскылы көлү — шагыйрь күңелендәге эчке хисләрнең тышка бәреп чыгуы, аның фашист палачларына чиксез нәфрәте ул. Мыскыллы көлү, нәфрәтле караш, ук шикелле, дошман күкрәгенә барып кадалып, аны тетрәнергә мәҗбүр итә:

**Коралым бирсәң, бел дә тор,**
**Атармын төзәп башыңа.**
**Каләмем бирсәң, бер шигырь**
**Язармын кабер ташыңа!**

Бу строфа үзенең тапкырлыгы, үткенлеге һәм тирәнлеге белән аерылып тора. Ул дошманга юнәлгән нәфрәт утын тагын да дөрләтә төшә. Мыскыллы көлү, ике кырлы алмаз кылычка әйләнеп, орынган җирен яраламый калмый. Шул ук вакытта бу юллар поэма героеның куркусыз һәм тимер ихтыярга ия кеше булуын да раслый. Шагыйрь образы алдагы бүлекләрдә яңа сыйфатлар белән тулылана, тагын да ачыклана бара.

Тоткын шагыйрьнең тормышы һәм фашизмга каршы көрәше Җ. Молдагалиев поэмасында шактый тулы сурәтләнә:

**Уйланып Муса төнката**
**Шигърият утын яндыра, —**
**Җырыннан үреп такыялар,**
**Баракта «Яфрак» яудыра.**

Соңгы юлдагы «яфрак» сүзе листовка мәгънәсендә алынган. Фашистлар, шагыйрьне әсир итсәләр дә, аның көрәш рухы тулы шигырьләренә богау сала алмаганнар. Төрмәдә дә шагыйрь фашизм белән якалаша, шигыре белән, корычтай ихтыяр көче белән көрәшә.

## ԻՄ ԵՐԳԵՐԸ

Ձեր ծիլերն եմ աճեցրել կրծքիս տակ,
Հիմա ծաղկեք հայրենիքիս ջերմ գրկում,
Ձեզ տրված է ազատություն ու կրակ,
Եվ ապրելու երջանիկ բախտ՝ աշխարհքում։

Խոր ներշնչանք, բորբ զգացմունք, աղնիվ լաց.
Ինչ որ ունեմ՝ վստահել եմ ձեզ հավետ.
Թե դուք մեռնեք՝ ես կմեռնեմ մոռացված,
Ու թե ապրեք՝ կապրեմ հավերժ ես ձեզ հետ։

Ես եմ երգում սրբազան հուր եմ վառել՝
Ժողովրդի հրամանով գերագույն,
Իմ երգը պարզ ընկերոջս է գուրգուրել,
Քանի անգամ հաղթել է նա թշնամուն։

Ես չեմ ուզում ոչ կարճատև խնդություն,
Ոչ աննշան երջանկություն աշխարհում,
Երգ եմ ուզում՝ ճշմարտախոս և արթուն,
Դրա համար եմ ես, պայքարում։

Ես չեմ դրժի իմ երդումը հաստատուն՝
Թե իմ արյան վերջին կաթիլն ուզենա,
Ձոնում էի քեզ բյուր երգեր իմ սուրբ տուն,
Հիմա քեզ եմ կյանքս տալիս անխնա։

Երգում էի՝ զգալով շունչը գարնան,
Երգում էի՝ նետվում կռվի քեզ համար,
Անա վերջին երգս եմ գրում հաղթական՝
Գլխիս վրա դահճի կացինն արնավառ։

Ազատություն սովորեցրեց երգս ինձ,
Երգս է կոչում՝ մեռնել մահով կտրիճի.
Սուրբ երգ դարձած՝ կյանքս այրվեց անթախիծ,
Եվ թող մահս որպես կռվի երգ հնչի։

26 նոյեմբերի, 1943 թ.

Թարգմ.՝ ՀԵՆՐԻԿ ՍԵՎԱՆ

*Әрмән телена*
*Г. Севан тәрҗемәсе*

Акрынлап көннәр үтә, көн үткән саен, таш камерага ябылган Мусаның гомере кыскара, айбалта күтәргән җәллад якынлаша. Әсир шагыйрьнең үз ватанына, халкына, сөйгән ярына багышланган соңгы шигырьләре безнең күңелләрне тетрәтә.

**Юллый ир соңгы сәламен:**
**«Саф булды җаным, вөҗданым,**
**Күрсәм дә әсир хурлыгын,**
**Җан саклап антым бозмадым».**

Бу юллар Муса Җәлилнең «Ышанма» дигән үз шигырендәге фикерләр белән авазадаш яңгырый. Шагыйрьнең ватаны, халкы белән саубуллашу монологы исә—«Җыр турында җыр»ның иң тәэсирле, иң уңышлы өлеше.

Шагыйрь аңлы рәвештә Мусаның үлемен тасвирламый, моның белән ул мәңгелек иҗат калдырган патриот шагыйрь үлми, дигән хакыйкатьне раслый. Муса Җәлил совет кешеләренең хәтерендә мәңге исән, үз сүзләре белән әйткәндә, ул — халкы яшәгәндә үлемсез.

Фашизмга каршы көрәшкә бөтен прогрессив кешелек дөньясы күтәрелә, аның белән алыш тик сугыш кырында гына түгел, җир йөзенең һәр тарафында, Муса җәфа чиккән лагерьларда һәм төрмә камераларында да бара. Әсирлектә, аның белән бергә, Европа, Азия һәм башка материкларның иң яхшы уллары һәм кызлары иза чигә. Алар да бу төрмәләргә фашизмга каршы көрәшкән өчен ябылганнар. Халыкара көрәш масштабы поэманың пульсын катырак тибәргә мәҗбүр итә. Үлем җәзасына хөкем ителгән шагыйрь барлык халыкларның азатлыгы өчен көрәшергә кулына корал алган.

Җыйнак кына лирик поэманың киң масштаблылыгы аның эпик характерын да көчәйтә төшкән. Әсәрнең эпик сулышы шагыйрьнең төрмәдәге һәрбер хәрәкәтеннән, көрәшеннән, ялкынлы шигырь юлларыннан, диалоглары һәм монологларыннан да анык күренә. Эпик нигездә әйтелә торган уй, бирелә торган хисләр лирик гәүдәләнешен таба.

Поэмага драматизм хас. «Җыр турында җыр»да эпик, лирик, драматик элементлар, үзара кушылып, бер бөтен хасил итә. Боларның бердәмлеге совет патриотының, ялкынлы шагыйрьнең характерын, рухи көчен һәм ихтыяр ныклыгын калку төстә сурәтләүгә хезмәт итә.

«Җыр турында җыр» Җубан Молдагалиев иҗатында яңа бер биеклек булды. Шуның белән бергә, бу дастан Бөек Ватан сугышы темасына илленче елларда язылган казакъ поэмаларының да иң әйбәтләреннән санала.

**Казакъчадан Т. ӘЙДИ тәрҗемә итте.**

Исхак Зәбиров,
филология фәннәре кандидаты

# ҮЗБӘК ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ МУСА ҖӘЛИЛ

Үзбәк һәм татар әдәбиятлары арасындагы дуслыкны, аларның үзара бәйләнешен үстерүдә татар халкының күренекле шагыйре Муса Җәлил зур роль уйнады. Аның күп кырлы һәм сокландыргыч иҗаты үзбәк укучысына яхшы таныш. М. Җәлил әсәрләрен ул Хәмзә Хәкимзадә һәм Гафур Гөләм әсәрләрен белгән кебек үк яхшы белә. Үзбәкстанның халык шагыйре, Ленин премиясе лауреаты Гафур Гөләм исә татар әдәбиятының олы дусты, аны армый-талмый пропагандалаучы иде. Үзбәк укучысы Габдулла Тукай, Һади Такташ, Муса Җәлил һәм башка татар шагыйрьләренең әсәрләре белән беренче тапкыр Гафур Гөләм тәрҗемәләре аша танышты.

1966 елда, Муса Җәлилнең тууына 60 ел тулу уңае белән, Г. Гөләм «Шәрык йолдызы» журналының икенче санында «Шагыйрьнең мәңгелеге» дигән мәкалә бастырды. Нибары ике бит ярымлык бу мәкаләсендә ул Муса Җәлилнең зур иҗат юлына нигезле һәм тирән анализ ясый, укучының игътибарын Муса Җәлил әсәрләре тагын да көчлерәк һәм актуальрәк яңгыраячак киләчәк көннәргә юнәлтә.

Муса Җәлилне татар поэзиясенең зур әдибе һәм совет иленең тугрылыклы патриоты санап, Гафур Гөләм аның үлемсез шигырьләренә, шәхси фидакарьлегенә соклана: «Муса фашистлар кулында тоткын, ләкин фашистлар аннан куркалар. Җәлладларда корал бар, ә Мусаның кулында — каләм. Аның күңелендә көчле сөю һәм нәфрәт утлары».

Заманында Гафур Гөләмнең Муса Җәлил белән очрашканы да булган. Бу очрашу турында ул болай дип искә ала: «Без Зыя Сәид белән икәүләшеп Казанга киттек. (Бу 1928 елның җәендә була.— И. З.) Безне өлкән язучылар рәтендә каршы алып, бик зур кадер-хөрмәт күрсәттеләр. Газеталарда рәсемнәребез басылды. Мин «Татарстан» газетасы белән «Чаян» журналы өчен нәрсәдер язып та бирдем. Казанда мин үземнең яшьлек дустым Такташны очраттым... Такташ безне шактый күп язучылар белән таныштырды: Гадел Кутуй, Демьян Фәтхи, Шамил Усманов, Афзал Шамов, Кави Нәҗми һәм башкалар. Шул танышкан язучылар арасында озынча йөзле, 22 — 23 яшьләрендәге Муса Җәлил дә бар иде. Һади Такташның аның белән таныштырганда:

— Менә бу — киләчәге уттай балкый торган яшь шагыйребез, безнең аңа өметебез зур! — дигәне хәтердә.

Әй, гомер дигәнең шулай сизелмичә үтә дә китә икән! Шул көннәрдән соң 48 ел вакыт узган!

Әгәр Муса Җәлил фашистлар балтасы астында һәлак булмаган булса, хәзер аңа да 60 яшь тулып, дуслары уртасында ай кебек балкып утырыр иде».

Гафур Гөләмнең Казанга бу һәм аннан соңгы килүләре үзбәк һәм татар әдәбиятларын бер-берләренә тагын да якынайталар, ике шагыйрьне бер-берсе белән тагын да ныграк туганлаштыралар.

МУСО ЖАЛИЛ

**ҚЎШИҚЛАРИМ**

Қўшиқларим, униб қалбимда,
Она юртда гуллай балқингиз!
Канча бўлса сизда куч, ёлқин,
Шунча бўлар ерда ҳаққингиз.

Сизда ҳамма ҳис-туйғуларим,
Сизда тоза ёшим, ўйларим.
Сиз ўлсангиз — унутиларман,
Яшасангиз — тирик бўларман.

Мен қўшиқда ёлқинлантирдим
Не деса қалб, халқим ўшани,
Қўшиқ билан дўстни мақтадим,
Қўшиқ билан енгдим душманни.

Пасткашликнинг завқи алдолмас,
Ва турмушнинг ҳаю-ҳаваси.
Шеъримдаги хақ, олов, севги —
Хаётимнинг бутун маъноси.

Ўлганда хам қалб содиқ қолар
Шеъримдаги эзгу онтимга.
Бор қўшиғим элга атадим,
Умримни хам берай халқимга.

Куйлаб ўтдим шонли курашни,
Умрим хали кўркам ёз эди.
Сўнгги шеърим жаллод болтасига
Бошни тутган чоқда ёзилди.

Хур яшашга шу куй ўргатди,
Хам ўлишга мардона туриб.
Умрим менинг мунгли куй эди,
Ўлимим хам янграр куй бўлиб.

Татарчадан МАМАРАСУЛ БОБОЕВ
таржимаси.

*Үзбәк теленә*
*М. Бабаев тәрҗемәсе*

Күренекле җәмәгать эшлеклеләренең һәм язучыларның Муса Җәлил турындагы фикерләренә кушылып, Гафур Гөләм мәкалә ахырында болай ди. «Мин Муса Җәлил... алдында бөек ихтирам белән башымны иям!»

Муса Җәлилнең иҗаты бик күп үзбәк шагыйрьләренең игътибарын үзенә тартты. Аның шигырьләрен үзбәкчәгә Гафур Гөләм, Мамарәсүл Бабаев, Юсуф Шамансур, Мирмухсин, Хәмид Гөләм, Әсгат Мохтар, Рәүф Галимов, Азиз Абдуразаков кебек шагыйрьләр тәрҗемә итте.

Муса Җәлил әсәрләрен тәрҗемә итүдә Мамарәсүл Бабаев аеруча зур тырышлык күрсәтте һәм бу өлкәдә иң уңышлы эшләүче шагыйрь булды. Ул үзе дә Совет Армиясе сафларында хезмәт иткән, немец-фашист илбасарларына каршы көрәштә катнашкан шагыйрь. Шуңа күрә сугыш темасы аңа аеруча якын. Ул Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре»н тулысынча үзбәкчәгә тәрҗемә итте. Бу тәрҗемәләр аерым җыентык булып ике тапкыр басылып чыкты. Җәлилнең ул тәрҗемә иткән шигырьләре үзбәк телендә дә үзләрнең матур яңгырашларын югалтмыйлар. Моны раслау өчен, «Җырларым» шигыренең беренче строфасына күз төшереп үтү дә җитә:

**Кушикларым, униб калбимда,**
**Она юртда гулдай балкингиз!**
**Канча булса, сизда куч, ёлкин,**
**Шунча булыр ерда хаккингиз.**

Үзбәк укучысы Муса Җәлил шигырьләрен батырлыкка чакыру авазы итеп кабул итә. һәм бу чынбарлыкта да нәкъ шулай булган. Антифашистик яшерен оешманың курkусыз җитәкчесе Муса Җәлил үзбәк хәрби әсирләре Мәхмүд Мөксинов һәм Хәбибулла Фәйзуллаев белән берничә тапкыр очрашкан, аларга үзенең шигырьләрен укыган. Ул шигырьләр шагыйрьнең үзбәк көрәштәшләре хәтерендә онытылмаслык булып уелып калган. Хәбибулла Фәйзуллаев үзе дә шигырьләр язу белән шөгыльләнгән. Аның кульязмаларын беренче булып Муса Җәлил укыган, аңа киңәшләр биргән.

М. Бабаев тарафыннан оста итеп башкарылган тәрҗемәләр аша үзбәк укучысы үз телендә Муса Җәлил шигырьләренең мәгънәсенә тирәнтен үтеп керү мөмкинлеген алды. Ә ул тәрҗемә иткән шигырьләр аны илебезнең күренекле тәрҗемәче-шагыйрьләреннән берсе итеп танытты. Тәрҗемәче буларак күрсәткән хезмәтләрен искә алып, Татарстан хөкүмәте аны Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләде.

М. Бабаев һәм М. Җәлил шигырьләренең идея-художество үзенчәлекләренә ныклабрак күз салсак, бу ике шагыйрьнең фикерләвендә, әдәби алымнарында күп уртак яклар барлыгын күрәбез.

**Утка очкан күбәләкләр кебек**
**Яктыралар минем уйларым.**

Тынгы белмәс сүзләр басымыннан
Күңелем ташыганын тоямын.

М. Бабаев үзенең «Шагыйрь йөрәге» исемле шигырендә әнә шулай дип язды. Муса Җәлилнең «Шагыйрь» дип аталган шигырендә исә без түбәндәге юлларны укыйбыз:

Төн утырып шагыйрь шигырь язды,
Ак кәгазьгә тамды яшьләре.
Тышта давыл иде; бертуктаусыз
Күк күкрәде, яшен яшьнәде.

М. Бабаевның «Бәхет», «Төш», «Беренче мәхәббәт», «Сатлык җан» һәм М. Җәлилнең «Шагыйрь», «Төрмәдә төш», «Сөю», «Икейөзле кешегә» шигырьләрендә дә уртаклык күп.

Мамарәсүл Муса Җәлилнең шигырьләрен генә түгел, «Моабит дәфтәре»нең ахырындагы «искәрмәләр»не һәм әдәбият белгече, тәнкыйтьче Гази Кашшафның һәр шигырьнең кайда, ничек язылуы турындагы аңлатмаларын да тәрҗемә итте. Үз тәрҗемәләрендә М. Бабаев, Муса Җәлил шигырьләренең эчтәлеген, образларын саклау белән бергә, аларның ритмын, музыкасын да төгәл бирә. Мондый ритмик төгәллеккә мисал итеп, «Имән», «Дүрт гөл», «Алман илендә», «Батырлык турында» һәм башка бик күп шигырьләрнең тәрҗемәләрен күрсәтергә мөмкин.

Муса Җәлилнең М. Бабаев тәрҗемәсендә үзбәкчә басылып чыккан шигырьләр җыентыгына язган сүз башында Хибзитдин Мөхәммәтханов патриот шагыйрьнең иҗатын болай характерлый:

«Бу шигырьләр Муса Җәлилнең Казандагы йомшак кәнәфиле эш бүлмәсендә түгел, Моабит төрмәсенең юеш, караңгы камерасында язылган... Фашизм белән көрәштә совет халкы һичнәрсә белән дә тиңләштереп булмый торган коралга — куәтле рухи көчкә ия иде. Мондый көч Җәлилгә дә хас иде».

Муса Җәлил шигырьләрен русчага тәрҗемә итү өлкәсендә Ташкент шагыйре Рәүф Галимов та зур тырышлык куеп эшләде. Үзбәкстан укучылары Мусаның «Моабит дәфтәре»нә кергән «Дуска», «Кошчык», «Бүләгем», «Була кайчак», «Катыйльгә» һ. б. кайбер шигырьләре белән беренче тапкыр рус телендә аның тәрҗемәсендә таныштылар. Бу шигырьләр 1954 елда «Звезда Востока» журналында басылып чыкты.

Рәүф Галимов укучыларга Җәлил шигырьләренең мәгънәсен бозмыйча җиткерә алган:

Ведь недаром радует нас вести
С Родины. Ее успех, судьба;
Это сила — коль с народом вместе
На чужбине чувствуешь себя.

«Дуска» шигыренең әлеге юлларыннан күренгәнчә, русча текст оригиналга бик якын.

Шагыйрьнең «Кошчык» шигыре дә Рәүф Галимов тарафыннан уңышлы тәрҗемә ителгән:

Лети же, пташка, песней полнокровной,
В которой сила мужества звучит.
Пусть плоть моя останется тут — что в ней!
Но сердце пусть на Родину летит!..

Муса Җәлилнең Моабит циклына кергән шигырьләренә күренекле үзбәк язучысы Әсгат Мохтар да ифрат югары бәя бирде. «Сез аңарда үлемгә хөкем ителгән кочсез кеше фәлсәфәсен тапмассыз,— дип язды ул.— Дәрес, ул илен һәм дусларын чиксез сагына, аларны юксына. Йөрәге аңа әнә шул хис-кичерешләр турында язарга куша. Шул рәвешчә, аның юксынуы һәм кичергән газаплары шигырьгә әверелә. Бу шигырьләр намуслылык, Ватанга бирелгәнлек турында сөйли».

Әсгат Мохтар Муса Җәлилнең батырлыгын Юлиус Фучик, Гастелло, Николай Островский, Александр Матросов, Зоя Космодемьянская батырлыгына тиңли.

*Муса Джалил*

МÆ ЗАРДЖЫТÆ

Сымах æз ædасæй мæ риуы фæжæстон,
Ныр та мын æфтаут зæрин хурмæ тау
Уæ тыхы сæраппонд мæ уды фæхъардтон,
Тæлæсоны бæсты мын мæ ут фæатау.

Сымах æз æхсыстон æндонау мæ тугæй,
Уæ хуылфы—мæ цæхæр, уæ хуылфы — мæ хъыг,
Куы мын уат цæрæццаг — æз хайдзын уæ дугæй,
Куынæ уат — мæ мардыл уæд чи кæндзæн хъыг.

Фæлæ мæ куыд фæндыдис — ахæм мæ зарæг,
Æмбалы уын кодта рæвдаугæ, ныфсхаст.
Цыфыддæр знагæн уыд разынд йæ марæг —
Нынныхст-иу цыргъ фатау йæ зæрдæйы раст.

Мæхи цард нымадыс нæ уыди мæ цæсты,
Уыд жамонды стъалы мæ бæстæ, йæ кад.
Æмæ та-иу зарæг дæр бацыди хæсты,
Æнæнцой тымыгъты нæ зыдтон фæллад.

Æнувыд хъæбул дæн мæ бæстæн кæронмæ,
Йæ номæй зын рæстæджы бакодтон ард.
Фæдзырдта-иу зарæг йæ сæрыл хæстонмæ,
Æз дæр мæ нывондæн æрхастон мæ цард.

Мæ зарæг-иу цины бон систон уæлдæрмæ,
Нынæрыд-иу зарæг куы-иу нсстыиг хæст.
Фыесын ныр фæстаг хатт... Фыдызнаг мæ сæрмæ
Цыргъ фæрæт куыд систа, уый хатын æрмæст.

Мæн зарæг йæ базыртыл систа бæрзондмæ,
Æмæ мæ уый домы дæгдзинад æргом,
Мæхи цард дæр разынди зарæг кæронмæ,
Уыдзæнис мæ фæстæ дæр зарæг мæ ном.

*Рацета йæ Дарчиты Дауыт*

*Осетин теленә*

*Д. Дарчиев тәрҗемәсе*

«Муса образында,— дип дәвам итә ул,— совет кешесенең характеры тулы ачыла. Бу образ — шагыйрьнең йөрәк җылысын, тойгылар гүзәллеген, халыкны һәм Ватанны сөюен берләштергән коммунистик идеалга тугрылыклы булып чыныгуы нәтиҗәсе.

**Гомерем минем моңлы бер җыр иде,**
**Үлемем дә яңгырар җыр булып...**

Таң калырлык шушындый юлларны язган кешенең дөньяның иң бәхетле шагыйре дип аталырга тулы хокукы бар. Андый шагыйрь — герой ул, ә аның поэзиясе героик поэзия».

Күренекле үзбәк язучысы Хәмид Голәм «Үзбәкстан мәдәнияте» газетасының 1966 елгы 12 февраль санында басылган «Геройның иҗаты» исемле мәкаләсендә, Җәлилне Пушкин белән чагыштырып, болай ди: «Муса Җәлил Пушкин яшендә һәлак булды. Аны гитлерчылар Моабит төрмәсендә үтерделәр. Муса Җәлил, Пушкин шикелле үк, дуэльда үтерелде: фашизм белән коммунизм дуэлендә!..»

М. Җәлил шигырьләре — халыкның нацистларга чыгарган гадел хөкеме ул. Чөнки аны фашистлар хөкем итсә дә, алар түгел, шагыйрь җиңүче булып чыга.

Муса Җәлилнең әсәрләре дөньякүләм әһәмияткә ия, аның батырлыгы бөтен дөньяны таң калдырырлык, дигән нәтиҗә ясап, Хәмид Голәм бик дөрес фикер әйтә. Әйе, Җәлилнең илгә тугрылыклылыгы, искиткеч чыдамлыгы безгә Эрнст Тельман, Юлиус Фучик, испан, француз һәм Италия коммунистлары каһарманлыгын хәтерләтә.

Үзбәкстанның халык шагыйре Уйгун Муса Җәлилгә үзенең бик матур шигырен багышлады. Нибары уналты юллык шигырендә Уйгун: «Мин үлемнән курыкмыйм, бу коры сүз генә түгел. Без үлемгә чирканып карыйбыз, дип әйтәбез икән — бу, чыннан да, шулай. Ләкин үлгәннән соң да яшәү бар. Үлгәннән соң да халык күңелендә, халык аңында яши торган хәят бар»,— дип язган политрук Җәлилнең үзе белән әңгәмә алып бара.

Сугыш кешеләрнең хисләрен кискенләштерде, бурыч, намус, Ватанга мәхәббәт кебек төшенчәләрне реальләштерде, һәркемнән үз-үзеңне аямауны һәм тәвәккәл булуны таләп итте. Муса Җәлилнең иҗат батырлыгын Уйгун түбәндәгечә бәяли:

**Буыннардан күчеп буыннарга,**
**Үлмәс җырың мәңге сакланыр:**
**Һәрбер юлы аның, һәрбер сүзе**
**Дастан-ядкарь итеп ятланыр.**

Үзбәк шагыйре Юсуф Шамансур да «Бөдрә тал» шигырендә тоткынлыкта газап чиккән хәр күңелле Җәлил хисләренә тирән мәхәббәтен белдерә:

**Аңласаң иде, бөдрә тал,**
**Әрнүле хис-моңымны...**
**Әй, язгы җил, сөеклемә**
**Илтче минем җырымны.**

**Ис син, җилем, ак каенлы**
**Илдә кунак булырсың.**
**Алып кил син миңа аннан**
**Туган җирем сулышын.**
**Син өзеп биргән бер яфрак**
**Җиңеләйтерме хәлләрем...**
**Китерсәң иде син миңа**
**Сөеклемнең хәбәрен.**

Совет укучысы герой шагыйрьнең иҗатына зур ихтирам белән карый. Ул җитәкләгән яшерен оешма членнары Гарәф Фәхретдинов һәм Рушад Хисаметдиновның хәтерендә, мәсәлән, Җәлил тарафыннан язылган егермедән артык шигырь сакланган. Ул шигырьләр шагыйрьнең киләчәктә чыгачак җыентыкларына кертүне көтә. Ташкент телевидениесендә татар, рус һәм үзбәк телләрендә барган тапшыру буенча ул шигырьләрнең күбесе белән укучы таныш та инде.

Җәлилнең яңа табылган кайбер шигырьләре белән үзбәк укучыларын беренче тапкыр 1968 елда «Гулистан» журналы таныштырды. Аларны үзбәк теленә шагыйрь Азиз Абдуразаков тәрҗемә итте. Аның тарафыннан «Сөйгән Ватаныма», «Идел кызы», «Аерылу», «Ант», «Чит җирдә», «Хыял», «Кечкенә җыр» шигырьләренең тәрҗемәләре зур осталык белән башкарылган. Җәлил белән бергә җәзалап үтерелгән Гайнан Курмашевның «Сине сагынам», «Дания», «Хатым сезгә минем» дигән шигырьләре дә Азиз Абдуразаков тарафыннан уңышлы тәрҗемә ителде. Тәрҗемәче бу шигырьләрдәге хис һәм фикерләрне укучыга төгәл җиткерә.

Без үзбәк укучысын татар шагыйренең героик поэзиясе белән киң таныштыруга ярдәм иткән ике арадагы бәйләнешнең аерым элементларына тукталдык. Муса Җәлил шигырьләрен һәм аның башка жанрларда тудырган әсәрләрен киләчәктә тагын да күбрәк тәрҗемә итү әдәбиятларыбызның үзара дуслыгын туктаусыз үстерүгә тагын да зуррак өлеш кертәчәк.

**ТАШКЕНТ**

**Солтанморат Акбиев,**
филология фәннәре кандидаты

# МУСА ҖӘЛИЛ ҺӘМ ДАГСТАН

Казан. Күпме көрәшчеләр тәрбияләп үстергән, күпме даһиларга иҗат канаты биргән данлы кала. Биредә Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Хөсәен Фәезханов, Казем-бек кебек акыл ияләре, А. М. Бутлеров, Н. И. Лобачевский кебек галимнәр яшәгән һәм иҗат иткән. Казан университетында студент Ульяновның дөньяга карашы формалашкан. Н. Е. Федосеев, М. Вахитов, Х. Ямашевларның көрәш юлы шушы шәһәрдә башланган. А. М. Горький Казанда тормыш мәктәбенең күп баскычларын узган, татар халкының даһи шагыйре Г. Тукай үзенең иҗат канатын шушында чыныктырган.

Көрәшче һәм шагыйрь, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил исеме дә шул якты йолдызлар арасында балкый. Борынгы Казан Кремленең таш стеналары буенда аңа мәңгелек һәйкәл куелган. Шуннан торып ул киң Идел өстенә, илебез өсетнә, киләчәккә карый. Һәйкәлнең мәрмәр нигезенә патриот-шагыйрьнең үлемсез сүзләре уелган:

**Гомерем минем моңлы бер җыр иде,**
**Үлемем дә яңрар җыр булып.**

Әйе, аның гомере Татарстанда гына түгел, бөтен илдә, бөтен дөньяда җыр булып яңгырады. Муса Җәлил исеме азатлык сөйгән барлык халыклар өчен каһарманлык үрнәге, көрәш һәм җиңү символы булып калды.

Муса Җәлил исеме тугандаш Дагстан халкына да якын һәм кадерле. Аның көрәшкә өйдәгән ялкынлы шигырьләрен шәһәр китапханәләрендә укыйлар, тау-таш арасындагы ерак авылларда телдән-телгә сөйлиләр. Ул әсәрләр пионер сборларында, мәктәп бәйрәмнәрендә, клубларда, колхоз кырларында яңгырый. Гаять күп телдә сөйләшүче Дагстан халкы — аварлар, даргиннар, кумыклар, лаклар, лезгиннар ул шигырьләрне үз туган телләрендә укып өйрәнәләр. Дагстан әдипләре, татар халкының батыр улына багышлап, шигырьләр, поэмалар иҗат итәләр, күп кенә пионер дружиналары, мәктәпләр герой-шагыйрь Муса Җәлил исеме белән аталган.

Шагыйрьнең тормыш юлы һәркемгә яхшы таныш. Балалык, яшьлек чоры 20 нче елларга туры килгән күп совет кешеләре шул ук тормыш юлын узган. Шатлык-куанычлардан мәхрүм ителгән бала чак, ачлык, ялангачлык, революция еллары, гражданнар сугышы, көрәш, омтылыш, комсомол ялкыны, революцион романтика, фидакарь хезмәт... Кыскасы, бу язмыш — Корчагиннар язмышы. Һәм Муса Җәлил тормышында боларга тагын Бөек Ватан сугышы, фашист әсирлеге, тиңдәшсез авыр көрәш һәм палач балтасы өстәлә.

Муса яшүсмер чагыннан ук үзен зур көрәшләргә хәзерләгән.

**Түзә алмабыз, кара кан да коярбыз,**
**Басарбыз, киртәләргә бирмәбез юл;**
**Теләсәләр асарлар, без үләрбез,**
**Ләкин һичбер вакытта булмабыз кол,**

(«Төрле парчалар».)

— дип язган ул унбиш яшендә. Һәм аның шуннан соңгы иҗатында әлеге хисләр та-

гын да көчәя, тирәнәя төшә. Әле «Моабит дәфтәре»нә кадәр үк шагыйрь йөзләрчә лирик шигырьләр, лирико-эпик һәм тарихи-героик поэмалар, либреттолар иҗат иткән, берничә шигъри җыентык бастырып чыгарган. Әмма аның исемен ил күгендә янар йолдыз дәрәҗәсенә күтәргәне — «Моабит дәфтәре».

1953 елның апрель аенда «Литературная газета» битләрендә Муса Җәлилнең «Җырларым», «Ышанма», «Кичер, илем» һ. б. шигырьләре басылып чыкты һәм шул ук көнне шагыйрьнең фашист тоткынлыгындагы тиңдәшсез батырлыгы турындагы хәбәр күп милләтле Дагстан халкына да барып ирешә. Ә тагын өч ел узуга радио дулкыннары таулар иленә тагын бер якты хәбәр алып килделәр: көрәшче шагыйрь Муса Җәлилгә СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Шул уңай белән Дагстан республикасының барлык газеталарында Мусаның рәсеме һәм кыскача тормыш юлы басылып чыкты. Газета-журналлардан дагстанлылар шагыйрьнең утлы-ялкынлы шигырьләрен үз ана телләрендә укыдылар. Әйтик, «Дослук» исемле әдәби журналда «Кыз үлеме», «Хат», «Шагыйрь», «Бүләк», «Җырларым» шигырьләре кумык телендә басылды. Аларны күренекле кумык шагыйрьләре Шәрип Әлбәриев һәм Баһаветдин Әстәмиров тәрҗемә иттеләр. Соңгы елларда Ш. Әлбәриев Мусаның тагын күп кенә әсәрләрен тәрҗемә итте. «Катыйльгә», «Ышанма», «Үлемгә» шигырьләре аның җыентыгына да кертелделәр. Муса Җәлил иҗатын күп көч куеп өйрәнүче бу әдипләр патриот шагыйрьнең әсәрләрен генә түгел, аның тормыш сәхифәләрен һәм фашист тоткынлыгында эшләгән героик эшләрен дә кумык халкына үз телләрендә сөйләделәр. «Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә һәм үләргә кыю ир булып» дигән ялкынлы сүзләр кумык телендә дә нәкъ Җәлилчә көчле яңгырады.

Муса Җәлилнең үлемсез иҗаты һәм киләчәк буыннарга үрнәк булырлык легендар тормышы турында авар, лак, даргин, лезгин әдипләре дә күп яздылар. Шулай итеп, тау иле халыклары хәзер татар халкының бөек улы Муса Җәлилне яхшы беләләр, аның каһарманлыгы алдында баш ияләр.

Мусаның патриотик шигырьләре Дагстан халыклары әдәбиятын тагын да баетты. Безнең шагыйрьләребез Муса Җәлил китапларын кулдан төшермиләр, аның әдәби мирасын торган саен тирәнрәк өйрәнәләр. Әйтик, авар шагыйре Нурмөхәммәт Абихәсәнов «Моабит дәфтәре»нә кергән шигырьләрен аерым китап итеп чыгарды.

*Муса Джалиль*

## Аялга дуунуудни

Аялга дуунуудни, сээжэдэм мүндэлэн түрөөлта —
Аба орондом замхангүй хододоо ханхиныт.
Эрхэ сүлөөтэйгөөр элии ниидэхээр гараалта —
Энэ юртэмсэдэ утa наһа наһалыт!

Дура сэдьхэлээ, зоригжолоо, арюун хүсэлөө би,
Дууһынь тандаа, аялга дуунуудни, найдаалби.
Замхаа һаатнай — арадтаа мартуулан хосороолби,
Зэдэлһээр һаатнай — амиды мэндэ зандаалби!

Сээжэ зүрхэнэйнгөө, арад зонойнгоо уряагаар
Сэгээн гэрэл дуун соогоо аһаагааб.
Аялга дуумни нүхэдэйм зориг бадараагаа,
Аюулта дайсанине дуумни һүнөөн һалгаагаа.

Бултанда шоодбори жэжэхэн жаргалые
Буруушаажа, наадалан эльгэ хатанаб.
Үнэн сэхэ, арюун хэрэг, шуналые
Үрэ зүрхэнэйнгөө аялга дуугаар магтанаб.

Хаха буухынгаа урда тээхэнэ уялгам гэн,
Хатуу тангаригаа дүүргэхэнь лэ зүрхэмни:
Эхэ орондоо дуугаа ходо зорюулдаг һэм,
Эхэ орондоо ами наһаяа үгэхэмни.

Хабар тухай дуулагша һэм нүхэдөөрөө,
Хатуу тэмсэлдэ ороходоо, дуугаа дуулааалби.
Эрлиг алууршанай дарлайгаад байһан һүхэ дор
Эгээн һүүлшынгээ дууя бэшэжэ һуунаалби.

Эрхэ сүлөөдэ дуумни намайя дурлуулаа,
Эрэлхэгээр тэмсээд, уна гээд дуумни захирнал.
Үнэнтэ байдални зэдэлмэ дуун бэлэй лэ,
Үхэлни тэмсэлэй дуун болон ханхинахал.

Гунга ЧИМИТОВ
буряадшадаба.

*Бурят теленә*

*Г. Чимитов тәрҗемәсе*

1966 нчы елда илебез Җәлилнең 60 еллыгын бәйрәм итте. Бу бәйрәмне Дагстан җәмәгатьчелеге дә лаеклы каршылады. Завод-фабрикаларда, авыл клубларында тантаналы җыелышлар, кичәләр булды, меңләгән пионерлар үз мәктәпләрендә юбилей сборлары уздырдылар. Әдипләребез, күчмә бригадалар оештырып, тау-кыялар арасына, ерак авылларга юнәлделәр, авыл халкына үзләренең тәрҗемәләрен, Җәлилгә багышланган шигырьләрен алып бардылар, әдәбият белгечләре герой-шагыйрьнең тормышы, язмышы турында сөйләделәр. Аларның юбилейга багышланган кайбер әсәрләре республика матбугатында урын алды. Рус телендә чыга торган «Советский Дагстан» журналы, Җәлил иҗатын бәяләп: «...аның шигырьләре безгә шагыйрьнең көрәш ялкынын, йөрәк кайнарлыгын алып килделәр. Бу шигырьләрдә Муса Җәлилнең кайнар каны тибә һәм ул кан укучының йөрәк тамырына да үтеп керә, ул кешеләрне көрәштә нык булырга, җирне, тормышны яратырга өйрәтә»,— дип язды. Шул ук журналда без рус телендә герой-шагыйрьнең:

**Песни, в душе я взрастил ваши всходы,**
**Ныне отчизне цветёте в тепле.**
**Сколько дано вам огня и свободы,**
**Столько дано вам прожить на земле!**

— дигән ялкынлы юлларын укып сокландык.

Шул ук елны Дагстанның халык шагыйре Әнвәр Аджиев «Дослук» журналында үзенең Муса Җәлил шигырьләрен ничек тәрҗемә итүе хакында сөйләде, «Моабит дәфтәре»ннән «Җырларым», «Тик булса иде ирек», «Катыйльгә», «Тозлы балык», «Яулык», «Бөрлегән» һ. б. шигырьләрен тәрҗемә итеп бастырды. Тәрҗемәченең татар телен яхшы белүе М. Җәлил шигырьләренең эчтәлеген генә түгел, калыбын, рифма-ритмын һәм барлык сурәтләү чараларын да төгәл саклап калырга мөмкинлек бирде:

**Гелер-гелер, алар бизин Москва!**
**Шу зынданда къалмасбыз биз кюстюне.**
**«Яшав», «ярыкъ», «эркинлик» деп язылгъан**
**Москваны байрагъыны тюбюнде.**

Фашист зинданында иҗат ителгән «Моабит дәфтәре»ндә патриот-шагыйрьнең Ватанга, бөтен кешелеккә тирән мәхәббәте, дошманга нәфрәте вулкандай бәреп тора. Бу шигырьләр хакында даргин шагыйре Сөләйман Рабаданов болай дип язды: «Моабит дәфтәре» безне тематик яктан күпкырлылыгы, шактый зур чорны эченә алуы белән генә түгел, жанр төрлелеге белән дә сокландыра. Анда сатирик көлү алымнары белән янәшә сагыш, нәфрәт, көрәш кырына омтылу, азатлыкка сусау хисләре дә, тормышка, балаларга тирән мәхәббәт тойгылары да ярылып ята».

Бу сүзләргә куәт итеп, С. Рабаданов шунда ук шагыйрьнең «Яулык», «Дуска», «Сөю», «Хөкем алдыннан», «Батырлык турында» шигырьләрен даргин теленә тәрҗемә итеп чыгарды.

Муса Җәлилнең шигъри таланты турында авар, лак әдипләре дә язып чыктылар. Әмма, минемчә, аның иҗатына иң төгәл бәяне лезгин халкының танылган шагыйре Ибраһим Гусейнов бирде: «Һәр шагыйрьнең тәрҗемәи хәле аның шигырьләрендә, диләр. Муса Җәлилнең тәрҗемәи хәле, чыннан да, аның үз шигырьләрендә,— дип язды Гусейнов.— Ул шигырьләрдән без зур көчкә һәм акылга ия булган ир-егетне, илне, тормышны яратучы кайнар патриотны, туган җиргә бөтен йөрәге белән гашыйк булган олы җанлы, матур, гүзәл кешене күрәбез. Татар шагыйренең бу шигырьләре үзләренең хисси тәэсире һәм мәгънәви тирәнлеге белән лезгин лирикасына якын тора. Аларда артык чуар буяулар юк. Һәм алар вакыт уздыру өчен генә язылган төче мадригаллар түгел. Алар — көрәштә чыныккан, өлгергән каһарман ирнең кырыс хакыйкать турындагы чын хикәяте, алар — төз атылган пулялар...

Муса Җәлил, син батырларча һәлак булдың! Шигырьләреңне укыгач, без синең үлемеңне башкача күз алдына да китерә алмыйбыз. Тормышың да, үлемең дә чын батырлык булды синең! Үзең әйткәнчә, үлемең синең җыр булып яңгырады, шигырьләрең яшәү, азатлык, батырлык гимны булып мәңге яңгырар!»

Ибраһим Гусейнов Муса Җәлилнең күп кенә шигырьләрен лезгинчәгә тәрҗемә

итеп, «Дуслук» журналының ике санында бастырды. Ә «Моабит дәфтәре» аның тәрҗемәсендә тиздән аерым китап булып чыгачак.

Мәгълүм булганча, Муса Җәлил шигырьләре әсирләр арасында телдән-телгә күчеп йөргән. Совет кешеләре күңелендә җиңүгә ышаныч, көрәшкә дәрт уяткан бу шигырьләрне төрле кәгазь кисәкләренә язып, җай чыккан саен ирекккә озата торганнар. Җәлил иҗатының шундый тәэсир көченнән дулкынланып, лезгин шагыйре Алирза Сәидов «Муса Җәлил» исемле шигырь язды:

**Түгәрәк күл, кечке шәүләләр...**
**Җил иркендә көзге яфраклар.**
**Тешен кайрый комсыз аждаһа,**
**Яфракларда сары хәсрәт бар.**
**Туплар ява, яна җир өсте,**
**Башын ими ава имәннәр.**
**Чыңлый... чыңлый сары яфраклар,**
**Әйтерсең лә хәрби медальләр.**
**Туптан көчле Муса авазы,**
**Убып төште төрмә идәне.**
**Торып басты имән-каһарман —**
**Үлемсезгә үлем тимәде.**

Хәзерге көндә тагын бер лезгин әдибе — прозаик һәм шагыйрь Абдул Раджабаев Муса Җәлил батырлыгына багышланган зур поэма яза.

Муса Җәлил иҗаты кулына беренче кат каләм алган яшь шагыйрьләрне дә, чәчәнә чал кергән өлкән әдипләрне дә бер үк дәрәҗәдә дулкынландыра. Дагстанның халык шагыйре Аткай Аджаматовның Җәлилгә атап әйткән сүзләре шул турыда сөйли. Кумык әдәбиятының аксакалы Аткай да, Муса кебек үк, кечкенәдән борынгы татар культурасын үзләштереп, татар халык иҗатын һәм әдәбиятын укып-өйрәнеп үскән кеше. Шуңадыр, ахры, ул Муса шигырьләрен аеруча яратып укый. Кайбер әсәрләре буенча Аткай Җәлилне кумык классигы Ирчи Казак белән чагыштыра. Ирчи Казак кайчандыр бөк алдына горур басып: «Дөреслекне яклаган шигърият — үлемсез шигърият»,— дигән.

**MUSA DŽALILIS**

## MANO DAINOS

**Jūsų daigus širdimi išpenėjau,**
**Skleiskitės mano šalies erdvėse,**
**Kiek sielos karščio ir laisvės įliejau,**
**Tiek jums ir lemta gyvent žmonėse.**

**Dainos, paskyriau jums meilę ir triūsą,**
**Ašaras karštas ir aistras tyras.**
**Jeigu numirsit — aš užmirštas būsiu,**
**Jeigu gyvensit — gyvensiu ir aš.**

**Ugnį įžiebęs dainoj, išteséjau**
**Įsaką liaudies ir savo širdies.**
**Draugą kukliąja daina aš mylėjau,**
**Priešui jos posmais kirtau iš peties.**

**Laimė smulkutė, džiaugsmeliai išblėsę**
**Juoką man kelia, aš niekinu juos.**
**Mano daina neša meilę ir tiesą**
**Tiems, dėl kurių gyvenu ir grumiuos.**

**Jokia mirtis nenutildys krūtinėj**
**Priesaikos žodžių šventų ir taurių:**
**Savo dainas aš aukoju tėvynei,**
**Šiandien jai savo gyvybę skiriu.**

**Kūriau aš dainą, pavasariams žydint,**
**Dainą nešiausi į ugnį kovos.**
**Štai paskutinę dainuoju, išvydęs**
**Budelio kirvį virš savo galvos.**

**Dainos man liepė laisvam eit per žemę,**
**Liepia kovoloju stot prie duobės.**
**Visas gyvenimas buvo daina man,**
**Lai ir mirtis kaip daina nuskambės.**

**1943 m. lapkričio 26 d.**

**Išvertė A. JONYNAS**

*Литва телендә*
*А. Йонинас тәрҗемәсе*

«И син, татар халкының батыр улы! Син дөньяда дөреслек җырлары яшәсен өчен һәлак булдың,— дип язды Аткай.— Фашистлар башлыгы Гитлер синең буйсынмас җырларыңны юк итә алмады. Синең үлмәңә фашист газеталары китереп тордылар, әмма ул газета читләренә язылган синең шигырьләрең Гитлер пропагандасыннан күп

көчле булып чыкты. Фашист сафсаталары инде күптән онытылды, газеталары чүплектә череде. Ә синең җырларың Идел буенда да, аннан еракларда да һаман яңгырый. Синең җырларың имән ялкыныдай яна, чирәм җир күтәрүче сабан төрәнедәй ялтырый».

Гъар гюн сени камуранга фашистлер
Охусун деп газетлерин бергенлер,
Дуньяны инг зулумчу ханы — Гитлер
Йырларынгны енгсин деп иш гёргенлер.

Сен оланы газетини уьстюне
Фашист сёзләр сёнердәй йыр язгъансан,
Гъар бир йырынг азув басып кюстюне,
Туснакъда да сен олардан озгъансан.

Фашист ойлар — чий темирде тот йимик,
Фашист газет тю-юнлене дымлыкъда.
Сени йырынг яна эмен от йимик,
Йыртыллайгъан сабан йимик тынлыкъда.

Әйткәнебезчә, Муса Җәлил исеме Дагстан балалары алдында аеруча зур хөрмәткә ия. Буйнак районының Эрпели, Түбән Казанчы мәктәпләрендә пионер дружиналары аның исемендә. Бу мәктәпләрдә һәр язда Муса Җәлилнең туган көнен бәйрәм итәләр. Анда пионерлар үзләренең укуда һәм хезмәттә булган уңышларына йомгак ясыйлар, рус телендә һәм үз туган телләрендә Җәлил шигырьләрен сөйлиләр, аның җырларын җырлыйлар, Җәлил идеалларына тугры булырга, аныңча яшәргә һәм аныңча хезмәт итәргә тантаналы вәгъдә бирәләр.

Түбән Казанчы урта мәктәбендә М. Җәлил исемендәге дружина пионерлары сугышчан дан бүлмәсе оештырганнар һәм Муса иҗатына багышланган альбомнар төзегәннәр. Альбомнарның берсе шагыйрьнең авыр бала чагы, комсомолда узган яшьлек еллары, күпкырлы иҗтимагый-политик эшчәнлеге турында сөйли. Шунда ук Мусаның балалар өчен язылган әсәрләре — «Чулпанга», «Көз» һ. б. шигырьләре тупланган. Икенче альбомны пионерлар, мәңгелеккә саклау өчен, район комсомол комитетына тапшырганнар.

«Муса Җәлил батырлыгы балаларга патриотик тәрбия бирү эшендә бетмәс-төкәнмәс чишмә ул, — ди Эрпели мәктәбе укытучысы Билал Сәлахов. — Безнең балалар аның шигырьләрен чын күңелдән яраталар. Без, укытучылар, әдәбият дәресләрендә үз теләге белән фронтка, ут эченә киткән патриот-шагыйрь турында еш сөйләшәбез. Ул бит фашист әсирлегендә дә үзенә күп якын дуслар тапкан. Кем белгән, бәлки аларның кайберләре шушы балаларның бабасы яки абыйсы булгандыр... Мондый сөйләшүләр бала күңелендә сугыш каһарманнарына карата тирән ихтирам хисе уята, Ватанга, халкыбызга тугры хезмәт итү теләге тудыра».

Бу мәктәпләрдә хәзер Мусаның 70 еллык бәйрәменә хәзерләнәләр.

Йомгак ясап әйткәндә, Дагстан халкы Муса Җәлилне белә, ярата, хөрмәт итә. Аның данлы иҗаты, үлемсез образлары безнең өчен илһам чыганагы. Шуңа күрә патриот-шагыйрьнең 70 еллык юбилее дагстанлылар өчен дә зур бәйрәм. Илебезнең башка халыклары белән беравыздан без дә әйтәбез: «Мәңгелек дан сиңа, чорыбызның бөек кешесе! Сине тәрбияләп үстергән халыкка зур рәхмәт!»

**Махачкала.**

# МУСА РӘСЕМЕН ЯСАГАНДА

1939 ел. Июль кичләренең берсендә, чакыру буенча, мин атаклы гармунчы-музыкант Фәйзулла Туишев квартирына килдем. Анда Фатих Хәснинең Туишев турындагы яңа тәмамланып килә торган «Гармунчы» исемле повесте укылачак икән. Мин Туишевларга килеп кергәндә, анда биш-алты әдип җыелган иде инде. Арадан өлкән язучы Шәриф Камал һәм шагыйрь Нур Баян электән дә миңа таныш, калганнарын исә беренче мәртәбә күрүем иде. Кичәдә мин Муса Җәлил белән дә таныштым. Исемемне әйткәч, Муса:

«Җәүдәтнең сөйләве буенча, сезне электән үк беләм,— диде.— Мәскәүдә укыган чакта безнең стена газетасының башын сез ясап биргән идегез бит?»

Менә композиторлар да килеп җитте: Александр Ключарев, Заһид Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзи... Урындыкларга урнашып, «Гармунчы» повестеның яңа бүлекләрен тыңлый башладык. Тиздән чәй китерделәр. Әсәр буенча фикер алышу иркенле төстә барды. Уку барышында әсәрнең авторы Фатих Хәснине бүлдереп, кем дә булса реплика ташлаган очракта да, сүз әйтүче булмый иде. Беркетмә кебек нәрсәләр дә алып барылмады. Уку тәмамланып, китәргә җыена башлагач, Фәйзулла ага Туишев, «мөһим бер эш» барлыгын белдереп, берничә минут сабыр итүебезне үтенде. Сүз татар композиторлары һәм музыкантларының күмәк портретын ясау — сынлы картина тудыру хакында бара икән. Җәүдәт Фәйзи дә, шулчак сүзгә кушылып, бер фикер өстәде: әгәр бу идея хуп күрелсә, диде ул, картинада татар язучылары һәм художниклары да булырга тиеш, ул чагында рәсемнең әһәмияте тагын да артачак. Бу эшне мин яшь рәссам, Сәнгать академиясе студенты Хаҗиморат Казаковка йөкләргә тәкъдим итәм. Ул үзе дә бүген безнең янда, мин аның бу эшне булдыра алачагына ышанам, дип төгәлләде ул сүзен. Кичәдә катнашучылар Фәйзулла аганың һәм Җәүдәт Фәйзинең бу тәкъдимен хупладылар, картина персонажлары исемлегенә Салих Сәйдәшев һәм Нәҗип Җиһановны да кертергә кирәк дигән фикер әйттеләр. Миңа исә, озакка сузмыйча гына, картинаның эскизын хәзерләү йөкләнде.

Без Бауман урамы буйлап бергә кайттык. Матбугат йортына җиткәч, Шәриф Камал белән Җәүдәт Фәйзи, саубуллашып, уңга борылдылар. Муса Җәлил миңа Матбугат йортында урнашкан Язучылар союзы идарәсен ничек табарга өйрәтте, этюд ясау өчен үзем сайлаган теләсә нинди көнне аның янына килә алуымны әйтте.

Мин Мусаны озата киттем. Юл буенча без сынлы сәнгать, аның үзенчәлекләре хакында сөйләшеп бардык. Муса Җәлилнең кызыклы чагыштырулар китереп, рәсем сәнгатенең үзенә генә хас сурәтләү чаралары, язучы һәм рәссамның иҗат алымнарындагы үзгәлекләр турында җанлы итеп сөйләгәне хәтердә. Әңгәмә барышында ул, ничектер, бик табигый рәвештә «сез»дән «син»гә күчте. Безнең арада үзеннән-үзе гади мөнәсәбәт урнашты. Хәзерге Куйбышев мәйданына килеп җитүебезне мин сизми дә калганмын. Вакыт шактый соң иде инде, Муса капыл тукталды да: «Моннан сиңа да, миңа да юлның нәкъ яртысы, шушында аерылышыйк, хәерле төн!» — дип, кулымны каты итеп кысып, китеп барды...

Картинаны язган чорда миңа анда урын алачак әдәбият-сәнгать эшлеклеләренең рәсемнәрен аерым-аерым этюдлар рәвешендә берничә мәртәбә кәгазьгә төшерергә туры килде. Тик Салих Сәйдәшевнең генә рәсеме фото буенча ясалды.

Муса Җәлилне рәсемгә алу өчен мин Язучылар союзы идарәсенә килеп йөрдем — союзның идарә председателе иде ул. Кайчан карама, эш белән мәшгуль, кабул итү бүлмәсендә чират көтүчеләр өзелми иде. Шунда, эш бүлмәсендә үк, кульязмалар укыла, тикшерелә икән.



*Картинадан репродукция. Уңнан сулга: Җәүдәт Фәйзи, Заһид Хәбибуллин, Александр Ключарев, Салих Сәйдәшев, Фәйзулла Туишев, Муса Җәлил, Нур Баян, Шәриф Камал, Фатих Хөсни, Мөхәммәт Садри, Хаҗимфат Казаков.*

Менә мин карандаш белән җиңелчә генә сызыклар төшерә башлыйм. Ләкин минут саен эш туктала, Мусаны бертуктаусыз бүлдерәләр, бимазалыйлар. Шулай да Муса, секретарена беркемне дә кертми торырга кушып, миңа ярты сәгать вакытын бүлә алды.

Муса хәрәкәтчән һәм җитез фикерле кеше иде. Монда да ул, шул санаулы минутлар эчендә, художникларның тормышы һәм хезмәте хакында төрле сораулар биреп, фикер алышырга, шаяртып та алырга өлгерде. Мин сызгалыйм, ә ул болай дип сорый: «Сез, рәссамнар, күпчелек художниклар исемнәренең «Р»га башлануына игътибар иткәнегез бармы?» «Мәсәлән, кемнәр?» «Менә, рәхим итегез: Рембрандт, Рафаэль, Рубенс, Репин, Ренуар, Рублев, Рылов...» «Ә-ә, алай сайласаң тагын дәвам итеп була,— дим мин.— Рибейро, Рюйсдаль, Рейнольдс, Роден, шуларга өстәп — Рокотов, Казан рәссамнары Радимов, Родионов...» «Менә күрәсеңме! — ди ул тагын да җанланып.— Ә алфавитның башка хәрефләренә ул чаклы исемнәрне җыеп булмый. Мәсәлән, әйтик, «А» хәрефенә: Айвазовский, Антопольский, Архипов, безнең Ахун, шуның белән бетә дә шикелле». Художникларның исемнәрен Мусаның әнә шулай үзе теләгәнчә җиңел тезә алуы миңа чынлап та бик кызык һәм гаҗәп булып тоелды.

Мин эшемне дәвам иттерәм. Муса тагын сүз башлый. Мәскәүгә бару белән Третьяковская галереяда, күргәзмәләрдә булырга кирәк әле, ди ул, үзе белән мине дә чакыра. Муса Мәскәүдә минем кемнәрдә тукталуым белән дә кызыксына, үзенең Мәскәүдәге бүлмәсенә килергә куша. Сөйләшкәндә Муса әледән-әле шаяртырга ярата, утырдашын да көлдерә, үзе дә рәхәтләнеп көлә.

Бу минутларда аның ниндидер бер шаян хәйләкәрлек белән кысылган күзләре әңгәмәдәшләрен туктаусыз күзәтәләр. Соңыннан мин Мусаның күп фоторәсемнәрен күздән үткәрсәм дә, аның үзенә генә хас елмаюын, күңел җорлыгын чагылдырган бер генә рәсемне дә очрата алмадым диярлек.

Картина тәгәлләнеп килгән чакта Муса Казанда юк иде. Сентябрь башларында әсәр белән башкалар да танышты, портретлар, шул исәптән Муса Җәлил рәсеме дә, уңышлы гына чыккан диделәр. Тиздән каникул бетте, мин дә Казаннан китеп бардым.

1940 елда бу картина Татарстан совет республикасының егерме еллыгына багышланган юбилей күргәзмәсенә куелган иде. Хәзер ул Фәйзулла Туишевның тормыш иптәше Ләйлә ханымда саклана.

**ХАҖИМОРАТ КАЗАКОВ.**

Иннокентий Кудинов

# «ШАГЫЙРЬ МУСА ҖӘЛИЛОВ БУ...»

ОЧЕРК

Миңа Волхов фронтында татар шагыйре, армиядә чыга торган «Отвага» газетасы корреспонденты Муса Җәлил белән очрашу бәхетенә ирешергә туры килде. Бу очрашулар һич тә гадәти булмаган сугыш шартларында булды.

Ул көннәрдән соң инде утыз елдан артык вакыт узды, күп нәрсәләр онытылып та бара, шулай да бу очрашуларның күңелдә тирән эз калдырганнары турында, Муса Җәлилнең фронттагы көрәшенең соңгы көннәре турында сөйләп бирергә, шулай итеп, батыр шагыйрь һәм коммунистның гүзәл биографиясендәге кайбер сәхифәләрне азмы-күпме дәрәҗәдә тулыландырырга телә идем.

Беренче очрашу мең тугыз йөз кырык икенче елда, май аеның беренче көннәрендә булды. Ул вакытка дошманның тирән тылында хәрәкәт итүче Волхов группировкасында гаять киеренке хәл килеп туган иде.

Март аенда ук инде Мясной Бор янында фашистлар, фронт сызыгын өзеп, безне барлык тәэмин итү базаларыннан аердылар. Азык-төлек, сугыш кирәк-яраклары килүдә өзеклекләр башланды, ә тиздән тәэмин итү бөтенләй үк тукталды. Һәм бары тик бик сирәк очракларда гына яралылар һәм авырулар өчен азык-төлек самолетлар белән китерелгәли иде. Ачыккан сугышчылар үлән, ылыс, яшь агач кайрылары ашадылар. Снаряд кыйпылчыклары һәм пулялар ялаган каеннардан каен суы җыеп эчтеләр...

Бернигә яраксыз сазлык җирләрдә тирән окоп, яхшы блиндаж турында уйлавы да кыен иде. Дошман пуляларыннан һәм снаряд ярчыкларыннан саклану өчен берәр чокыр казысаң, аны шунда ук су, пычрак күмеп китә. Хәтта ботаклардан ясалган шалашларда утырганда да аяк астында үзәккә үткеч ләм чыпырдый.

Ә сугышлар көнен дә, төнен дә туктамады. Дошман һөҗүмнәрен бертуктаусыз кире кайтарып торырга туры килә иде. Пычрактан һәм дары төтененнән каралып беткән солдатлар искиткеч батырлык, ныклык һәм осталык белән сугыштылар. Фрицларны кечкенә «капчыкларга» алдап кертәләр дә, шунда аларны рәхимсез юк итәләр иде.

Майда ачлыкка икенче явыз дошман — юл өзеге килеп кушылды. Үтеп тә, узып та йөрмәслек баткаклыклар башланды. Ә коеп яуган яңгырлардан соң хәл тагын да начарая иде. Бүрәнәләр җәеп юллар, сулы сазлыкларда чокырлар ясый башладык.



*«Җәлил блокадада».*
*Худ. В. Скобеев.*

Шундый авыр вакытта безнең дивизия Любаньга таба үзенә юл ачуга керешге. Бу гомуми сугышчан бурыч иде. Любань өчен Волхов группировкасының бүтән берләшмәләре дә сугышлар алып барды.

Безнең участокта, Родофинниково станциясеннән төньяктарак, Тосно елгасы аша тимер юл күпере янында каты сугышлар башланып китте. Дошман миналары белән теткәләнеп беткән яр буендагы кечкенә генә җир кисәген өлкән лейтенант Баранов командалыгындагы дан казанган Себер батальоны солдатлары искиткеч батырлык белән тотып тордылар.

Фашистларның бу күпергә күптән күзләре кыза иде. Аны кулга төшерү дошманга Новгородтан Ленинградка юл ачкан булыр иде. Бу тимер юлны сугыш башланыр алдыннан төзегәннәр һәм топографлар аны картага төшерергә өлгермәгәннәр иде әле. Немецлар күперне ничек кенә булса да алырга тырыштылар.

...Алгы сызыктан шалашка кайтып, без, политотдел работниклары, аланлыкта табын әзерләдек һәм төшке ашка утырдык.

Ямьле май көне. Зәңгәр күк гөмбәзендә күзне чагылдырырлык төшке кояш нур сибә. Берсен-берсе уздырып урман кошлары сайрый, һәм шушы сихри авазлар аша, күк күкрәгән шикелле, снаряд гөрселдәүләре ишетелә. Урман эченнән борчылган поши аваз сала.

Гөрселдәү тавышларына колак сала-сала, политотдел инструкторы Тищенко термостан һәркайсыбызның котелогына аш бүлде. Байтак көннәр буе кайнар шулпа, ипи кисәге күрмәгәнебезне искә алсак, бу төшке ашыбыз искиткеч сый иде.

Һәм менә без сыйлана гына башлаган идек, шалаш артында аяк тавышлары ишетелде. Янгыбызга политбүлек начальнигы — нык гәүдәле, егетләрчә кыяфәттәге батальон комиссары Емельянов һәм урта яшьләрдәге, пилотка кигән һәм пистолетлы кабура таккан таныш булмаган бер офицер килеп чыкты. Мин кунакка карап алдым. Уртача буйлы, киң җилкәле, акыллы кара күзле һәм кыска гына итеп алынган чем кара чәчле өлкән политрук иде бу.

Емельянов кунакны безнең белән бергә төшке ашка чакырды.

— О-о! — дип куйды ул шунда ук. — Мондый ләззәттән баш тартып булмас. Аш белән күптән шаярган юк. — Өлкән политрук ашыкпошык ясалган өстәл янына утырды, алдындагы котелокта итле зур сөяк күргәч, гаҗәпләнеп куйды.

— Кайдан килде бу сезгә? Башка берләшмәләрдә итнең тәмен дә күптән онытканнар инде. Хәтта иске тиреләрне дә ашап бетерделәр. Ә сез бай яшисез, иптәшләр.

— Ашау ягыннан бездә дә яхшыдан түгел, иптәш корреспондент, — дип җавап бирде Емельянов.
— Очраклы рәвештә генә туры килде.
— Һич тә уйламаганда... — һәм батальон комиссары яраланган бер пошиның безгә килеп юлыгуын сөйләп бирде. — Шулай туенабыз менә.
— Әкияттәге кебек... Ә ите тәмле, — дип мактады кунак. — Казанга әләгү өчен пошилар еш килеп чыккалыйлармы сезгә?
— Өченчесен ашап киләбез.
— Сугышчыларны да ит белән туйдырасызмы?
— Дивизиягә өч поши — алай ук күп түгел инде ул.
— Ә шулай да! Тәҗрибәгезне сөйләп бирегез әле!
— Нинди тәҗрибә булсын инде! — Емельянов кулын селтәп куйды. — Ачлык шулай җаен табарга куша.
— Ничек итеп җаен тапкалыйсыз соң?
— Ничек? — Емельянов кайнар ашын капты да снаряд ярган агач төбенә еленгән поши тиресенә карап алды. — Җиңелчә яралылардан без аучы бригадалары төзедек. Менә шулар инде сирәк-сирәк кенә булса да поши ите, кош ите алып кайткалыйлар. Яралылар һәм авырулар өчен шунысы да әйбәт булып куя.
— Бик оста уйлагансыз бит, ә! — диде дә тәмле генә итеп сөяк кимереп утыручы кунак ачынып өстәп куйды: — Болар бөтенесе дә яхшы яхшысын. Ләкин фронтның барлык берләшмәләре дә сездән үрнәк алып шушы матур боланнарны юк итә башласа, ни булыр, ә?
Емельянов гәүдәсен турайтты да дәшми генә поши тиресенә карап торды.
— Беләбез! — диде начполит, тавышын аз гына күтәрә төшеп.— Беләбез, иптәш өлкән политрук. Табигатьне сакларга кирәк. Ләкин ничек? Мәрхәмәтсез сугыш беркемне дә кызганмый. Кешеләрне дә, җәнлекләрне дә, очар кошларны да. Цивилизация законнарын да белми ул! Элек бу сазлыклы урманнарда һәм чытырманлыкларда заповедник булгандыр бәлки. Ә хәзер монда нинди эшләр бара, үзегез күрәсез.
— Әйе, сугыш кешеләргә генә түгел, җир йөзендәге барлык тереклек иясенә рәхим-шәфкатьсез. Мин алгы ут сызыгында еш булам. Сугышчылар тәмам ябыкканнар, ә ярсыган арысланнардай сугышалар.
— Әгәр аларга азык белән дә булышсаң! Дошманны тагын да ныграк кыйнарлар иде.
— Сезнең аучылык итү тәҗрибәсенең әйбәт роле шундадыр да, шәт.
— Мин дә шулай уйлыйм.
Аштан соң корреспондентны каен суы белән сыйладык.
— Искиткеч эчемлек, — дип мактады кунак. — Һәм бу юлы да сез тапкырлык күрсәткәнсез, иптәш батальон комиссары.
— Саз суында бөҗәкләр мыжлап тора, бака тулып ята. Сугыш сөреме сеңгән. Эчеп булмый, күңел болгана. Борынгы бабалар тәҗрибәсенә мөрәҗәгать иттек менә.
— Сүз дә юк, безнең шартларда әйбәт тәҗрибә. Файдалы. Каен суында шикәр күп бит!
Сөйләшә-сөйләшә вакыт тиз узды. Ашаганнан соң барыбыз да урыннарыбыздан тордык. Үз бурычларыбызны үтәргә таралыша башладык. Берәүләр рота партия ячейкасы секретарена булышырга, сугышлар тынып торган арада коммунистларның җыелышын үткәрергә, икенчеләре — партиягә кергәннәргә партия билетлары тапшырырга ашыга иде. Мин чираттагы политинформация өчен мәгълүматлар җыярга хәзерләндем.
Шул вакыт Емельянов, миңа якынрак килеп, кунакка күрсәтте:

— Бу шагыйрь Муса Җәлилов!

Муса! Бу исем миңа таныш иде. Сугыш алды елларында яшьләр газетасында эшләгәндә без аның шигырьләрен бастыра идек. Алар башка газеталарда да басыла иде. Шигырьләрнең кайберләрен мин күңелдән ятладым. Һәм менә безне сугыш очраштырды, каен суыннан әзерләнгән чәй янында...

— Мин аны беләм, иптәш батальон комиссары, — дидем һәм якынрак килеп Мусага кул бирдем.

Шагыйрьнең күзләре киңрәк ачылды. Ул мине исенә төшерергә тырышты булса кирәк. Моны мин сизеп алдым һәм аның белән матур шигырьләре аша таныш булуымны әйттем.

Шагыйрь елмайды да миңа карап куйды.

— Журналистмы?

— Фронтка газетадан киттем.

— Себердәнме?

— Әйе. Армиядә — «Отвага»да.

— Блокнот белән фронт буйлап, сазлыклар аша еш йөрисезме?

— Алгы сызыкта булгаларга туры килә. Сугышның иң кызган урыннарында гына очерклар, зарисовкалар һәм шигырьләр өчен материал табарга мөмкин бит.

Фронт матбугатында эш турында, дошман «капчыгында» калган Волхов группировкасының кыенлыклары турында без тагын бераз сөйләшеп тордык.

Беренче сүздән үк Муса фикер йөртүдә төгәл логикага, оптимизмга ия булуы һәм мәкерле дошманны һичшиксез җиңүебезгә тирәнтен ышанганлыгы белән мине гаҗәпкә калдырды.

Безнең янга начполит килде һәм миңа боерык бирде:

— Шагыйрь синең юлдашың була. Аны алгы сызыкка озат һәм Войтинский белән таныштыр. Аның ротасы штык сугышында үзләреннән көчле дошманны елга артына чигендерде.

Мин боерыкны үтәргә әзер булуымны әйттем һәм без Муса белән алгы сызыкка юнәлдек.

Сукмак вак урман буйлап сузыла. Сазлыктан юеш һәм черек исе килә.

Сугыш гүләгән тавышларны тыңлый-тыңлый, Муса минем семьям, аның хәзер кайда булуы турында сораштыра барды.

— Омскида, — дидем мин. — Хатыным һәм ике кызым. Берсенә уникенче китте, кечесенә — икенче.

— Ә исемнәре ничек?

— Эмилия белән Элеонора.

— О-о, матур исемнәр!

— Маркс һәм Энгельс кызлары хөрмәтенә.

— Мин шулай дип уйлаган да идем.

— Олысына үзебез шундый исем куштык, ә менә кечесенә — бөтен редакция коллективы белән уйлап таптык.

Муса елмаеп куйды һәм:

— Сезгә ничә яшь, өлкән политрук? Ничәнче елда туган? — дип сорады.

— Мең тугыз йөз алтынчы елгы.

— Мин дә. Яшьтәшләр икәнбез.

— Сезнең семьягыз бармы соң?

— О-о, ничек булмасын! Хатыным Әминә һәм кызым Чулпан Казанда яши.

— Сагынасызмы?

— Сагынмый буламы соң. Мин семьямны, туганнарымны, якыннарымны яратам. Тик сугышта кешегә башка төр эмоцияләр хуҗа: дошманга карата бетмәс нәфрәт! — диде Муса һәм барган юлдан ко-

ры үлән сабагын йолкып алып кискен генә аяк астына бәрде. — Беләсезме, мин кайчакта фронттагы тормышның мәгънәсе турында уйланам. Секунд саен безнең сугышчыларыбызның каны коелганда, шушы сазлык измәсе газабында Ватанны саклау өчен күбрәк ничек файда итәргә? — Шагыйрь бераз уйлап торды да, тагын сөйләп китте: — Каһәр суккан фашистларны йөз тапкыр күбрәк үтерергә! Ничек булса да, пуля яки граната беләнме, такмаклар яки шигырь беләнме, барыбер, тик үтерергә! Шуны эшләмәдеңме, көнеңне бушка уздырдың дигән сүз...

Шагыйрь гадәттән тыш дулкынлану, әрнү белән сөйләде. Аның ялкынлы йөрәге безнең җиребезне таптаучы, ерткычлыклары белән коточкыч явызлыклар эшләүче килмешәкләргә карата каты үч алу хисе белән ярсый иде.

Муса бераз тынычлана төшкәч, мин аңардан шигырьләр язып буламы дип сорадым.

— Язам, — диде ул, җанлана төшеп. — Әмма газетага бүгенге көн кирәк, ә бер еллык хәлләрне тасвирлау түгел. Күбесенчә көчле рухлы сугышчылар турында очерк, зарисовкалар язам. Менә сезгә дә шундый материал эзләп килдем. — Ул бераз дәшмичә торды һәм кабат җанланып китте. — Шулай да сирәк кенә шигырьләр дә язарга туры килә. Фронтта алар да кирәк бит! Менә тыңлагыз. — Һәм ул кинәт үзенең армия газетасында басылган бер шигырен укый башлады. Темасы ул чак өчен бик әһәмиятле иде һәм Муса шигырен рухланып, сарказм белән укыды. Ул «Гитлерның язгы резервлары» дип атала иде.

Позицияләргә якынайган саен сугыш гөрелтесе арта барды. Сукмак безне урманлы тауга алып килде. Беренче язгы чәчәкләр күренде. Муса атлый-атлый чәчәкләр өзә һәм аларны бәйләмгә сала бара. Үзе акрын гына шигырь әйтә. Шигырьләр сугыш турында, яраланган җирдәге чәчәкләр турында. Кайчакта ул тын гына туктап тора һәм сугыш гүләвен тыңлый. Куен дәфтәрен алып, анда ашыга-ашыга нәрсәдер язгалап куя.

Тагын ике йөз метрлар чамасы барасы калды. Яшеренә-яшеренә генә хәрәкәт иттек. Куаклыклар артында үләннәр һәм куак ботаклары белән маскировкаланган сары калкулыклар күренде. Иелеп, йөгереп күчә-күчә шул калкулыкларга ашыктык.

Мин Мусага карап алдым. Тиз-тиз һәм тавышсыз-тынсыз гына яшел куаклыклар арасыннан ашыга ул. Ә янәшәдә генә сугыш кайный.

Нәкъ алгы сызыкка җиткәндә миномет уты астына эләктек. Ләкин миналар бездән аз гына уңгарак төшә. Мин Мусага баш кактым.

— Ә-әнә, теге уйсулыкка яшеренәбез. Ул безне алгы сызыкка илтеп чыгарыр.

— Аңлашыла, — шагыйрь башын кагып килешүен белдерде.

Без судагы йомшак һәм сусыл үләннәр өстеннән шуышып киттек. Миналар якында гына шартлый. Шартлау дулкыны кайнар һава китереп бәрә. Ут астыннан чыгарга кирәк. Муса аякларына басты һәм иелеп кискен генә алга ыргылды. Аннары тагын ун метрлап йөгерде һәм бөтен көченә окопка ташланды. Аның артыннан ук мин дә шунда мәтәлеп төштем. Артыбыздан куып килгәндәй мина чиелдады. Аннары икенчесе, өченчесе... Ләкин без инде ышанычлырак урында идек.

Гимнастеркалары чыланган, тузаннан һәм корымнан соры төскә кергән, миналар шартлавыннан һәм тоташ пулемет-автомат шытырдавыннан колаклары тонган сугышчылар безнең көтмәгәндә килеп керүебезгә игътибар да итмәделәр. Алар кызу сугышка бирелеп, елга

аръягындагы тимер юл калкулыгыннан үтеп чыккан фашистларга ут сиптерәләр иде.

— Рота командиры кайда? — дип сорады Муса олы яшьләрдәге бер сугышчыдан.

Тегесе кулы белән күрсәтте.

— Әнә анда барыгыз, — диде һәм, битеннән тирен сөртеп, яңадан автоматын иңбашына кысты.

Тар гына казылма буйлап без утыз метрлап бардык һәм политрук Войтинскийны таптык. Ул команда пунктында, брустверга сыенган хәлдә, телефоннан комбат Баранов белән сөйләшә иде.

— Әйе, әйе. Уң флангта өч танк күренде. Икесе безнең пулеметларга таба килә. Һәм тагын берсе — туп-туры безгә. КПга... Пушкалардanмы? Кирәкми. Рикошет белән үзебезнекеләргә тидерерсез. Без аларны үзебез. Гранаталар белән. Яндыра торган шешәләр белән! Ә менә дошман кичүенә пушкалардан бәрегез! Бөтенесе ачык. Бетте, бетте. Танклар килә...

Трубкасын аппаратка куйгач, политрук безне күреп алды, монданиләр барганын үзегез дә күреп торасыз дигәндәй, иңбашларын сикертеп куйды. Кулын селтәде һәм яңа команда көтеп торган сугышчыларга кычкырды:

— Контрһөҗүмгә әзерләнергә! — һәм безнең якка борылып өстәп куйды: — Өченче мәртәбә үрмәлиләр, кабахәтләр.

Мин политрукның профиленә карадым. Аның яшь-яшь йөзендә тир тамчылары ялтырый. Ул сөрем катнаш тозлы тирдән соры булып күренде, үзе ярсу һәм юлбарыстай ашкынучан. Политрук гөрелдәп һәм шыкырдап танклар якынлашып килгән куаклыклардан күзен алмый. Аның эчкә баткан яңагында кырыйларына кан каткан җәрәхәт әзенә күзем төште. Моны Муса да күреп алды.

— Яңагыгыз яраланган, — диде ул.

— Дошман тамгасы, — дип кулын селтәде Войтинский һәм игътибар белән алга таба карап торуын дәвам итте.

Дошман һөҗүме көчәя барды. Сугышчылар, коралларын кысып тоткан хәлдә, контрһөҗүмгә сигнал көтәләр иде. Танклар якынайганнан-якыная. Алар артындагы соры тузан томанында каскалы немецлар бутала.

Менә танклар, башняларын кискен борып, тупларын команда пунктына төбәделәр. Бронясына тәре төшерелгән коточкыч машина окоп алдына ук килеп җитте. Войтинский гранаталарыннан бөҗраларын өзеп алды, бөгелә төште һәм «Мәгез, кабахәтләр!» дип кычкырып, гранаталар бәйләмен бруствер артына тондырды. Коточкыч шартлаудан җир тетрәп куйды, окоп стеналарыннан туфрак коелды.

Сугыш кызулыгына бирелгән Муса бер мизгелгә бруствер өстеннән башын чыгарды һәм шатланып кычкырып җибәрде:

— Яна-а-а!

Танкны ялкын чолгап алды. Җил белән күкк исе килеп бәрелде.

Кирәк булса дип кулына граната тоткан Войтинский да бруствердан муенын сузды. Һәм броняны ялаучы ут еланнарын күреп, ул да түзмәде:

— Яна-а-а, каһәр суккыры! Яна-а-а!

— Хәзер фрицлар танктан чыгачак, — диде Муса, кулына пистолетын тоткан хәлдә. Шунда ук башня ачылганы күренде. Төтен һәм сөрем пәрдәсе аша немец башы күренде.

— У-у, кара елан! — диде теш арасыннан гына Муса һәм атып җибәрде. Юан офицер бөгелде дә изелгән куаклыкка акрын гына шуып төште.

Шунда ук башнядан икенче баш күренде: пилоткасы яна, күзләре шарланган.

— Коточкыч күренеш! — диде шагыйрь, чирканып, һәм читкә борылды. Войтинский да атмады, безгә борылып болай диде:

— Снарядлар шартлый башлаганчы китәргә кирәк, иптәшләр.

Без барыбыз да янган танктан читкә йөгердек. Шул арада рота сугышчылары икенче танкны да яндырдылар, ә өченче танк, кире борылып, урман эченә кереп югалды.

Сугыш тагын ун минут чамасы дәвам итте. Тәртипсез чигенеп, атыша-атыша, күп кенә үле гәүдәләр һәм яралыларны калдырып, немецлар Тосно елгасының аръяк ярына күчтеләр.

Тынлык урнашты. Әйтерсең лә сугыш бөтенләй булмады. Бары тик яралылар гына ярдәм сорап сукраналар иде. Вакытлыча тынычлыктан файдаланып, мин шагыйрьне Войтинский белән таныштырдым. Ул телефон янына чүгәләгән җиреннән Мусага таба борылды.

— Исәнмесез, иптәш корреспондент! — политрук торып басып кул бирде.

— Муса Җәлил! — диде шагыйрь танышып. — Менә, сугыш геройлары белән кызыксынам...

— Рәхәтләнеп таныштырырмын, — диде рота командиры һәм бераз уйланып, иңбашларын җыерып куйды. — Тик монда нинди ыгы-зыгы кайнаганын үзегез күрәсез. Бүген өченче һөҗүмне кире кайтардык. — Войтинский кулы белән маңгаендагы тирне сыпырып төшерде. Ул тагын нәрсәдер әйтергә теләгән иде, тик шул чакта элемтәче йөгереп килеп җитте дә политрукка ашыгыч рәвештә комбат чакыруын хәбәр итте. Войтинский гафу үтенде һәм связной белән бергә окоп ярыгы борылышында күздән дә югалды.

Муса окоп стенасы буена чүгәләп куен дәфтәрен алды, тиз-тиз яза башлады.

Озак та үтми, Войтинский әйләнеп кайтты һәм взводларны яшерен рәвештә урман авызына алып чыкты. Шунда ук, тимер юл полотносыннан ерак түгел, комбат Барановның башка подразделениеләре дә позицияләргә урнаштылар.

Муса күпер оборонасының төп герое Войтинский белән яхшылап сөйләшә алмаган иде әле. Ул рота командирын аптыратырга теләмәде. Бөтенесен үзе күрде. Тик җаен туры китереп кенә батальонны яңа позицияләргә шулай ашыгыч күчерүнең сәбәпләре турында сораштырды.

Политрук бу чакта алда торган сугышның аерым детальләре турында уйлый иде булса кирәк, аңа ашыгыч кына җавап бирде:

— Шулай кирәк, хөрмәтле шагыйрь. Кызганычка каршы, обстановка шундый, шайтан алгыры... Бәлки соңрак сөйләшербез, ә? Сугыштан соң, яме?

— Аңлашыла, — диде Муса ягымлы гына һәм куен дәфтәренә нәрсәдер язгалап, аны тир сеңеп беткән гимнастеркасының кесәсенә тыгып куйды.

Рота командиры Войтинский взвод командирларын чакырды. Алар көттермәделәр. Талчыкканнар, чалбарлары пычранып беткән, кулларында — автоматлар, каешларына гранаталар кыстырганнар.

— Сезнең боерык буенча җыелдык, иптәш политрук! — барысы өчен дә озын буйлы, ябык йөзле, кечкенә кара мыеклы лейтенант хәбәр итте.

— Күрәм. Башлыйбыз, иптәшләр! — һәм ул аларны яңа сугышчан бурыч белән таныштырды.

Сугышларда хәлсезләнгән взвод командирлары алда торган хәл иткеч бәрелешкә хәзерлекнең бөтен катлаулылыгын аңлыйлар иде.

— Аңлашыла. Безнең бер сугышчыга — уннарча тук фриц.

— Кызганычка каршы, хәл шундый. Шуның өстенә пулялар,

снарядлар бетеп бара. Бушка атмаска! Юл бер. Фашистларны якынгарак җибәрәбез дә штык һөҗүменә барабыз.

— Дөрес. Штык сугышына! — диештеләр взвод командирлары, политрукны хуплап. — Күп булмасак та, безнең сугышчылар кул сугышына осталар алар!

Взвод командирлары таралышкач, Войтинский Муса янына килде.

— Ә сез кайда булырсыз?

— Сезнең белән барам, — диде Җәлил.

— Нигә утка керергә соң, Муса!

— Шулай кирәк, политрук. — Һәм елмаеп өстәп куйды: — Синең белән куркыныч булмас.

Войтинский да елмайды:

— Яхшы! Алайса, винтовкалар әзерләгез!

Войтинскийны эчкерсез караш белән озатып калды да Муса чын күңел җылылыгы белән болай диде:

— Менә нинди ул, герой!

— Ә комбат Баранов үзе ни тора! — дидем мин аны хуплап. — Солдатлар һәм командирлар бөтенесе дә күперне саклаучылар!

— Килешәм. Аларның исеме бер — Себер баһадирлары!

— Шул, шул. Курку белмәс кешеләр!

Безгә кирәгенчә кораллану кыен булмады. Муса миңа тутәсе чәрдәкләнгән, күпне күргән винтовка тоттырды. Үзенә исә авыр «семоновка»ны алды һәм штыгын кидереп мактап куйды:

— Якыннан сугышу өчен әйбәт корал.

Бераз ял итәргә дип, ауган агачка утырдык. Бер флягадан каен суы эчтек.

Кояш җылы нурларын сибә. Биектә-биектә тургайлар сайрый, урман эченнән миләш чыпчыгы җыры ишетелә.

Ирексездән уйлап куйдым: тирә-якта шундый рәхәт. Менә-менә шушы күпер янында кабат үлем сугышы башланачагына, ихтимал, күп кенә сугышчыларның инде беркайчан да шушы кошлар тавышын ишетә алмаячагына һич тә ышанасы килми иде. Һәм йөрәккә шундый авыр булып китте...

Ямансу уйлардан айнып китеп Мусага карап алдым. Ул гадәттәгечә үзенең куен дәфтәренә яңа туган фикерләрен язып утыра иде. Аның йөзендә көчле ихтыяр, җитдилек сизелеп тора. Менә ул урман читендә яңа позициягә урнашкан сугышчыларга, аннары миңа карап алды.

— Беләсеңме, кайчакта фронт батырлары турында шул кадәр шигырьләр, очерклар, новеллалар язасы килә. Йөрәгемдә хисләр ташып чыга,— дип сөйли башлады кинәт шагыйрь күңел күтәренкелеге белән. — Алар алдында гаять зур бурычлы бит мин. — Муса кабат алгы сызыкка карады һәм уйчан гына дәвам итте. — Биредә, шушы күпер янындагы сугышта башыма гүзәл бер фикер килде: «Сазлык батырлары» исемле зур булмаган шигъри роман язарга. Волхов эпопеясы батырлары турында.

Аның шундый фикере мине гаҗәпкә калдырды. Дошман һөҗүмен көтәбез, көчләр тигез түгел, ә ул Волховтагы бөек сугыш турында шигъри роман язарга уйлый. Һәм мин моны бары тик көчле рухлы кешеләрнең генә булдыра алуларын аңладым. Ә шагыйрь Муса Җәлил шундыйлардан иде.

Баранов батальоны урман кырые буйлап сузылган ныгытмаларга яшеренде. Алар артында кызгылт-сары төстәге тимер юл полосасы сузыла. Күпергә якындарак Войтинский ротасы позицияләргә урнашты. Флангларга ике пулемет куйдылар.

Һәм тиздән сугыш башланып китте. Көтелгәнчә, фашистлар бөтен көчләрен иске позицияләргә ташладылар. Алар башта позиция-

ләрне бомбага тоттылар, миномет уты яудырдылар. Аннан соң, кыргыйларча акыра-акыра, һөҗүмгә ташландылар. Үзләре винтовка һәм автоматлардан бертуктаусыз аталар. «Руссиш золдат»ларны куркытырга маташып, бугазларын ерта-ерта үкерәләр. Тик кайда соң алар «руссиш Иваннар?» Нигә дәшмиләр?..

Немецлар безнең яңа позицияләрне тиз генә белеп ала алмадылар. Алар акрын гына, курка-курка урман авызына якынлаштылар. Кыюлык өчен булса кирәк, автоматлардан тагын да катырак ата башладылар. Ә безнең пулеметчы егетләр, сигнал көтеп, дошманның алгы һәм арткы рәтләрен мушкага алганнар иде. Ниһаять, сигнал бирелде һәм Войтинский пулеметлары ут яудыра башладылар. Фашист солдатлары, автоматларыннан ата-ата, төрле якка сибелде.

Шуны гына көтеп торган Войтинский сикереп торды. Винтовкасын күтәреп, кычкырып команда бирде:

— Минем артта-а-ан, алга! Ватан өчен! — Үзе беренче булып атакага ташланды.

— Ура-а-а! — Командир артыннан сугышчылар, бердәм булып, штык сугышына күтәрелде.

Штыкка-штык килеп, якыннан сугыш башланды.

Муса тимер юл күперенә ыргылучы немецлар юлына аркылы төшеп йөгерүче рота командирыннан калмады. Спортчы, көчле һәм җитез, шуның өстенә курку да белмәс командир башта пуля, аннары штык белән тиз арада берничә фрицның башына җитте. Солдатлар да, командирлар да батырларча сугыштылар. Сугышның иң кызган чагы иде. Куаклыклар артыннан ике фриц сикереп чыкты һәм кинәт Войтинскийга ябырылды. Кыска ботлы юанын ул штык белән кадап егарга өлгерде, ә кыр кәҗәсе кебек җитезе һәм озын буйлысы аңа штыклы винтовкасын төбәде.

Муса моны күреп алды да ярдәмгә ташланды. Ул Войтинскийга нәрсәдер кычкырды, винтовкасын күтәрде. Тик янәшәдә генә ату тавышы ишетелде: безнең бер сугышчы аннан алдарак атарга өлгерде. Немец акрын гына бөгелеп җирдәге агачка ауды.

Фашистлар төп ударны күпергә якын ук килеп тоташкан вак урманга тупладылар. Войтинскийның хәлсезләнгән ротасы фашист гаскәрләре батальонының һөҗүмен шуннан кире кайтара иде. Ул зур югалтуларга дучар булды, әмма көчләре белән өстен булган дошманга батырларча каршы торды.

Войтинский командалыгында күперне тотып торуын дәвам иткән взводта сугышчыларның яртысы да калмаган иде инде. Аларга ярдәмгә, резерв ротасын алып, комбат Баранов килеп җитте. Тимер юл күпере өчен яңадан каты көрәш башланды.

Немецлар рус штыгына түзә алмадылар һәм тәртипсез рәвештә елгага таба чигенделәр. Безнең батареялар утыннан зур югалтулар калдырып аргы ярга чыктылар.

Баранов батальоны ут сызыгына урнашты. Войтинский ротасы да тимер юл полотносы буйлап окоплар казыды.

Сугыш белән уятылган урман шаулый. Яралыларның ыңгырашкан тавышлары ишетелә. Аларның кайберләре сугыш кырыннан үзләре чыга алган, күбесен — санитарлар һәм сугышчылар алып чыккан, өлкән яшьтәге, кыска сакаллы һәм арыган хәрби фельдшер үзе дә канга буялып беткән, ашыга-ашыга яралыларны бәйли һәм аларны урман сукмагы буйлап санбатка озата.

Күпер өчен сугышларда дан казанган политрук кайда соң? Үзләренең рота командиры Войтинскийны сугышчылар яралылар арасыннан озак эзләделәр. Аны зур тал куагы төбендә таптылар. Сугышчыларның яраткан политругы кулларын җәеп чалкан ята иде.

Янәшәдә генә — немец офицеры, күкрәгенә штык кадалган, ә кулында пистолет.

Рота командирының гәүдәсен сугыш кырыннан күтәреп чыктылар һәм саз чәчәкләре түшәлгән җиргә куйдылар.

Войтинский белән очрашырга дип Муса Җәлил дә килеп җитте. Очрашты, тик инде сөйләшә алмады...

Бу чиксез батыр коммунист, Совет Армиясе командиры һәм сугышчысының каһарманлыгы һәм үлеме шагыйрьне тетрәтте. Һәлак булган герой алдында ул башын иеп озак басып торды.

Үзләренең командирларын хөрмәтләп күмү өчен сугышчылар сафка тезелде. Аксый-аксый комбат Баранов та килеп җитте.

Шунда, яңа казылган кабер янында, Войтинскийның палаткага төрелгән гәүдәсе өстендә Муса, геройга багышлап, ул исән чакта язган шигырен укыды. Ул «Войтинский истәлегенә» дип атала иде. Сүзләре тулысынча хәтердә сакланмаган.

Комбат Баранов та бу сугышта каты яраланган иде. Таякка таянып, кабер янында ул озак кына дәшми торды. Сугышчан иптәшенең үлеме аның өчен аеруча авыр иде.

Шагыйрь кулы белән акрын гына комбатның иңбашына кагылды. Комбат башын күтәрде:

— Китәсезме?

— Әйе, комбат.

— Геройлар белән шатлыклырак очрашулар телим!

— Әйбәт теләкләрегез өчен рәхмәт.

Урман буйлап без кайтыр юлга чыктык. Тирә-якта гадәттә булмаган тынлык. Күк йөзендәге бердәнбер болыт кисәге кояшны каплап алды. Күләгәсе безгә төште. Урманда тагын кошлар сайрый башлады. Муса сүзсез генә атлый. Нәрсә турында уйлаган ул бу минутларда? Бәлки өе, сөекле хатыны, кызы турындадыр. Ә бәлки Войтинскийның үлемсезлеге турындадыр?..

Саз баткакларын читләтә-читләтә бормалы сукмак буйлап атлаганда, ул бер генә тапкыр сүз кузгатты. Озак кына барганнан соң, көтмәгәндә, тимер юл өчен булган сугышның аңа онытылмаслык тәэсир ясавын, тәкәббер дошманның данлы Кызыл Армияне беркайчан да җиңә алмаячагын әйтте.

— Беркайчан да! — диде ул кабатлап. Һәм, үзенең сүзләрен раслагандай, бераз сүзсез барганнан соң өстәп куйды: — Рус җирендә политрук Войтинский һәм комбат Баранов кебек баһадирлар бар вакытта.

... Безнең гаскәрләр урнашкан җирдә Муса озак тормады.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**ФЕВРАЛЬ, 1975 ЕЛ**

КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, профессиональ союзларның Бөтенсоюз Үзәк Советы һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты союздаш һәм автономияле республикаларның, милли округларның, край һәм өлкәләрнең, шәһәр районнары һәм шәһәрләрнең, районнарның промышленность, төзелеш һәм транспорт работникларының 1974 елгы халык хуҗалыгы планын срогыннан элек үтәү өчен Бөтенсоюз социалистик ярыш йомгакларын карадылар.

Татарстан АССР КПСС Үзәк Комитетының, СССР Министрлар Советының, ВЦСПСның һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл байрагына лаек булды.

Чаллы шәһәренең «Камснаб» идарәсе коллективы ярышта җиңүче дип табылды һәм КПСС Үзәк Комитетының, СССР Министрлар Советының, ВЦСПСның һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының күчмә Кызыл байрагы белән бүләкләнде.

ТАСС, Мәскәү.

КамАЗ монтажлау стадиясенә керде. Агымдагы елда 11 меңгә якын җиһазны урнаштыру, ә 3,5 мең җиһазны файдалануга тапшыру планлаштырыла. КамАЗлылар үз көчләре белән 4 мең станокны монтажлаячаклар, бөтен практик көйләү — ходка җибәрү эшләрен башкаруны үз өсләренә алачаклар. Эшләрнең күпчелек өлеше елның икенче яртысына туры килә. Ул чорда һәр ай саен 1200—1300 әр станок һәм агрегат көйләнәчәк. Бу — ВАЗда «пик» айларында монтажланган җиһазлар күләменнән өчтән бер тапкырга артыграк дигән сүз.

«Социалистическая индустрия»
на строительстве Камского автозавода».

«Гидрострой» идарәсе коллективы Бөек Җиңүнең 30 еллыгы хөрмәтенә «Герой шәһәрләргә — безнең хезмәт салютыбыз» дигән девиз белән удар хезмәт вахтасына басты: коллективлар һәр ункөнлектә ун герой шәһәрнең берсе хөрмәтенә эшләячәкләр.

«Труд», Мәскәү.

«Энергетик» культура сараеның үзешчән театр-студиясе имтихан тота. Тамашачылар хөкеменә аның «Заман тудырган батырлар» дигән беренче иҗади эше тапшырылган.

Театрда яңа иҗат коллективы оеша. КамАЗны төзү белән бергә, үз-үзеңне үзгәртеп кору да таләп ителә. Барлык нигезләрнең нигезе нәкъ әнә шуннан гыйбарәттер дә, мөгаен. Үзләре сәхнәгә куячак пьесаларны яшьләр нәкъ әнә шул таләптән чыгып сайлыйлар да. Бүгенге көндә алар М. Шаровның «Пржевальский аты» пьесасын әзерлиләр. Чиратта — Егор Исаев әсәре буенча эшләнгән «Хәтер хөкеме» инсценировкасы. Бу инсценировкада революциядән алып КамАЗга кадәр чор эчендә ил тормышында булып узган үзгәрешләр турында сөйләнәчәк.

«Социалистическая индустрия»
на строительстве Камского автозавода».

Бишьеллыкның чиксез зур төзелеше — Кама автомобиль заводлары комплексының көндәлек тормышындагы яңалыклар Ленинград кинематографлары тарафыннан төшерелгән «КамАЗ-74» дигән тулы метражлы документаль фильмда чагылдырыла.

**«Труд», Мәскәү.**

Монда, икенче төрле аталып, «Кама проекты» дип йөртелсә дә, күпчелек америкалылар КамАЗ турында беләләр. Һәм шундый зур комплексның әле беркайда да төзелгәне булмаганга, аның белән якыннан кызыксыналар. Бу кызыксынуның тагын бер сәбәбе бар: КамАЗга Американың сиксәнләп фирмасы җиһазлар җитештерә, ә аларның берсе — «Суинделлдресслер» фирмасы автогигант өчен металл кою заводын проектлаштыра. Рус белгечләре белән эшләү ифрат кызыклы, диләр Америка инженерлары. Бу — Советлар Союзы һәм Америка арасындагы экономик хезмәттәшлекнең беренче конкрет гәүдәләнеше; практик карашлардан чыгып фикер йөрткәндә, бу проектны аларның профессиональ осталыкларына чакыру ташлау дип тә әйтергә мөмкин.

— Әлбәттә, эшләве дә бик үк җиңел түгел, — дип өстиләр аннан америкалылар. — Бер-беребез белән якыннан танышу, төрле эш ысуллары хакында үзара аңлашу, телләр аерымлыгы барьерын үтү өчен шактый вакыт кирәк булды. Ләкин уртак максат бездә иптәшлек хисе тудырды. Әмма бары эшкә генә бәйләнешле бәхәсләр дә булып ала, тик ул бәхәсләрнең берсе дә шәхси тойгыларга кагылмый.

— Проект төзергә керешкәндә, — дип искә ала бу эшкә катнашучы «ветеран»нарның берсе, — бәлки без аның зурлыгын төгәл генә күз алдына да китерә алмаганбыздыр. Эшкә ныграк тотынган саен безнең гаҗәпләнүебез артканнан артты. Чаллыда булу вакытында мин тап-такыр яланда үзенең зурлыгы ягыннан Нью-Йорктагы Кеннеди исемендәге аэропорт мәйданы белән чагыштырырлык гигант үсүен күрдем. Һәм мин әйтер идем: завод искиткеч яхшы төзелә.

...Питтсбургта эшләр төгәлләнү алдында тора. Артта — дүрт меңгә якын сызым. Совет белгечләре инде бер-бер артлы үз илләренә кайтып китә башладылар. Ләкин КамАЗның америка флангы әле шунда кала: нәкъ үзәктә, «Дженерал моторс» компаниясе небоскребында сатып алу комиссиясе эшли, җиһазлар җибәрү турындагы контрактларга кул куела. Бирегә ул җиһазларны кабул итеп алучылар килә башлады.

«Чейз Манхэттен» банкы каршында төзелгән «Чейз уордл информейшн корпорейшн» компаниясе моннан бер ел элек «КамАЗ — миллиард долларлык башлангыч» дигән китап бастырып чыгарды. Эшлекле дөнья бу төзелешкә әнә шул рәвешчә авыр, ләкин кызыклы һәм күп нәрсә вәгъдә итүче башлангыч дип карый...

Күптән түгел «Нью-Йорк таймс» газетасы «Сәүдә — Көнчыгыш һәм Көнбатыш арасындагы киеренкелекне йомшартучы йөрәк» дигән мәкалә бастырды. Ул мәкалә шушы өлкәдә эшләүче танылган эксперт, «Үзара янәшә яшәү һәм сәүдә» исемле җитди фәнни хезмәтнең авторы Самуэл Пизар тарафыннан язылган.

«Ә алга таба нишләргә?» — дип сорый Пизар һәм үзе үк җавап бирә: «Рус-Америка сәүдәсе, соңгы елларда сәүдә килешүләреннән башка да барган шикелле үк, үсүен дәвам итә ала. Ләкин сәүдә үзенең оптималь, потенциаль күләменә ирешсен өчен поездны рельскә кертү сорала. Русларга Америка базарында сатарга (шулай ук сатып алырга) озак сроклы мөмкинлекләр тәкъдим итәргә кирәк. Экономик чынбарлыкка күз ташласак, һәр ике якта да мондый ихтыяҗ яшәп килгәнлеген күрербез.

Совет-америка янәшә яшәвенең тагын икенче бер ягы да бар. КамАЗ аркасында эшле булган кешеләр хәзер Питтсбургта өч йөз проектлаштыручы гына түгел. Домна җиһазлары хәзерләүче «Аджекс магнетермик корпорейшн» компаниясе заводларында КамАЗ заказлары 540 кешене эшле итте. Хадсондагы (Огайо штаты) «Дженерал моторс» заводы Чаллы заказлары аркасында гына бөтен куәтенә эшли. «Кама проекты»нда катнашучы башка компанияләр турында да шуны әйтергә мөмкин. Һаман арта барган эшсезлек фонында һәрбер өстәмә эш урыны зур әһәмияткә ия...

Шулай итеп, «миллиард долларлы башлангыч» булып саналган КамАЗ һәр ике як өчен дә отышлы һәм файдалы.

**«Советская Россия», Мәскәү.**

## Жан Миндубаев

# АЛГА КАРАП, ЕРАКНЫ КҮРЕП

Төзүчеләр янында булган чакта да, Чаллының кичке тын урамнарында ялгыз гына уйланып йөргәндә дә, бәйрәмчә киенгән камазлылар белән бергә өр-яңа культура сараенда концерт карап утырганда да күңелемне гел бер хис — горурлык хисе биләп торды. «Менә бит без хәзер нинди зур эшләр эшли алабыз! Менә бит хәзер безнең көчебез никадәр күп!» — дип соклanудан туган хис иде ул.

Ләкин Чаллы сокландырып кына калмый. Ул уйланырга да мәҗбүр итеп, күңелдә күп кенә сораулар һәм аның иртәгәге көнен күрергә теләк тә уята.

Хәзер Чаллыда ике йөз мең кеше — атаклы КамАЗны төзүчеләр яши. Дөньяда тиңе булмаган бу гигант төзелешкә алар киң илебезнең төрле якларыннан җыйналган. Автогигант белән бергә, күзгә күренеп, хәзерге заман шәһәре — Чаллы да үсә. Менә шул шәһәр белән якыннанрак танышасы: аның ничек яшәвен, нинди шатлык-куанычлары, нинди хәсрәт-хаҗәтләре булуын, нинди чикләргә барып җитүне үзенә максат итеп куйганлыгын һәм шул максатына ни дәрәҗәдә ирешүен беләсе килә иде.

Бер көнне шәһәр башкарма комитеты председателе Гыйләҗев Ренат белән утырганда, сүз арасында ул миңа бүтән шәһәр советы председательләренең аңа кызыгып та, шул ук вакытта кызганып караганнарын әйтте. Моның сәбәбен аңлау кыен түгел. Бер яктан, чыннан да, аннан көнләшер нәрсәләр байтак. Мәсәлән, Чаллыда шәһәр төзү эшенә республикабызның башка шәһәрләренә караганда чагыштыргысыз күп акча тотыла. Үзләрендә үк төзелеш индустриясенең куәтле базасы да бар. Төзелеш өлкәсендә ирешелгән яңа проектлар, ул проектларны гамәлгә ашыру мөмкинлекләре — шулай ук Чаллыда. Төзелеш алып бару өчен җайлы булган иркенлекне дә истән чыгарырга ярамый, шәһәр япан кырда, моңарчы бернинди дә иске корылмалар булмаган уңайлы җирдә төзелә. Ниһаять, Чаллыны төзү, шәһәр советы башкарма комитеты көче белән генә алып барылмыйча, аны Үзәк министрлыклар һәм ведомстволар да игътибар үзәгендә тоталар. Менә шуларны искә алганда, Гыйләҗевтән көнләшерлек нәрсәләр җитеп ашкан.

Ә икенче яктан килеп караганда исә, председательнең хәленә керерлек сәбәпләр дә байтак икән. Әйтүе генә ансат: биш ел эчендә шәһәргә ике йөз мең кеше килгән. Ай саен өч мең, көненә бер йөз кеше туктаусыз килеп торган диган сүз бу! Баласыз да, балалар белән дә, әйберләр төяп тә һәм әйберсез дә, семьялары белән һәм ялгыз-ялгыз да килгән алар. Һәм, әлбәттә, берсе дә үзләре белән өйләрен яки квартираларын күтәреп алып килмәгән. Кибет, аптека, карават, бала имезлеге һәм башка шуныңише мең төрле кирәк-яраклары берсе дә булмаган аларның. Чөнки алар шәһәргә киләбез дип, димәк, анда барысы да булырга тиеш дип уйлап килгән. Һәм шулай уйлап дөрес иткәннәр. Дөресе дөрес, ләкин...

Иске Чаллы ул чакта берничә йөз агач йорттан гына гыйбарәт иде бит. Бер шаяны

әйтмешли, хәзерге КамАЗ заводларыннан берсенең түбәсе бөтен иске Чаллыны каплап куярга җитәр иде. Менә шундый хәлдә көн саен килеп торган йөз кешегә торак урыны табу мәсьәләсе үзе генә дә никадәр катлаулы булганлыгын күз алдына китерү кыен түгел. Ә бит ул меңләгән кешеләрне азык-төлек белән тәэмин итәргә дә, аларны төзелеш мәйданына илтү һәм эштән алып кайту чарасын күрергә дә кирәк, шуның өстенә, алар әле кино, спектакльләр карарга телиләр, анысы турында да кайгыртмыйча ярамый. Шәһәр советы хезмәткәрләре шуларның барысын да оештырырга, барысына өлгерергә тиеш булалар.

1970 елның кышында шәһәр советының төп бурычы төзелешкә килгән кешеләрне торак урыны белән тәэмин итүдән гыйбарәт була иде. Ул чорда башкарма комитет кешеләренә кешеләрне урнаштыру өчен иске Чаллы һәм аның якын-тирәсендәге авылларга барып, өй борынча йөреп фатир эзләргә туры килде. Һәр семьяга кимендә бер-ике төзүче урнаштыралар. Ә моның өчен гаять зур түземлек, тырышлык һәм дипломатлык кирәклеге һәркемгә билгеле.

Шуннан соң үткән дүрт-биш ел эчендә Чаллыда искиткеч зур үзгәрешләр булды. Уникешәр катлы йортлар. Заманча киң проспектлар. Культура сарае. Ательелар. Почтамт. Администрация биналары. Кинотеатрлар... Кыскасы, шул: иске Чаллы урынында чын мәгънәсендә бүгенге яңа шәһәр калкып чыкты. Иске Чаллының елга буйларында, чокыр-чакырларда посып калган соңгы корылмаларны да тиздән сүтеп бетереп, алар урынына мәһабәт йортлар салачаклар. Анда иске шәһәрдән тик бер генә нәрсә — ул да булса зират кына калачак. Бу — Чаллының көньяк көнбатышы, беренче төзелеш башланып киткән урын. Моннан тыш тагын Чаллыда пенопластан кисеп ясалган шикелле тигез, ак ташлардан бишәр, тугызар, уникешәр катлы йортлардан торган өр-яңа шәһәр дә бар инде. Ул йортлар Мәскәүнең яңа районнарында төзелгән йортлардан һич ким түгел. Әйтерсең ниндидер бер могҗиза булган да, Мәскәүнең бер кисәген шушы Чаллыга китереп утыртканнар! Бу яңа шәһәрдә хәзерге көндә туксан мең кеше яши. Шәһәрнең тарихын өйрәнү өчен архивларда казынып торуның кирәге юк. Монда барысы да күз алдында, соңгы дүрт-биш ел эчендә генә дөньяга килгән.

— 1970—1974 елларда төзүчеләр бер миллион өч йөз мең квадрат метр торак мәйданы төзеп тапшырдылар,— ди шәһәр советы председателенең төзелеш буенча урынбасары Биктимер Мурясов. Бу санга культура-көнкүреш объектлары керми. Бездә елына дүрт йөз мең квадрат метр торак мәйдан төзелә. Уннарча кибетләр ачтык. Ресторannar, кафелар... Алар барысы да беренче класслы итеп эшләнгән. Чаллы «Универсам»ы — Татарстанда иң зур универсам... Яңа шәһәрнең үзендә генә дә кырык мең төп агач утырттык...

Биктимер Мурясов Чаллыга җитмешенче елда килгән.

— Эшнең иң болгавыр чагына туры килдем,— ди ул, шул көннәрне искә алып.— Башкарма комитет сөт заводы салу мәсьәләсен хәл итәргә тотынды... Ашханәләр мәсьәләсе бик кыен иде әле, аны юлга салу өчен көрәш башладык. Шәһәрне ямьләндерү һәм яшелләндерү өчен өмәләр оештырдык...

Болар — уннарча мең кешенең тормыш-көнкүрешен яхшыртуга, яңа төзелә торган шәһәргә карата алар күңелендә моны мин дә төзештем бит дип горурлану, аны ярату хисе уятуга китерә торган бик мөһим эшләр. Шәһәрнең матурлыгы, андагы тормыш шартларының яхшыруы, ахыр чиктә, ул шәһәрдә яшәүчеләрнең аны ямьләндерүдә күпме һәм ни дәрәҗәдә күңел биреп катнашуына кайтып кала лабаса!

Әнә шулай эшне дөрес оештыру, барлык депутатларның да активлыгы белән алып барырга тырышу нәтиҗәсендә яңа шәһәр үсү белән бер үк вакытта башкарма комитет үзе дә көннән-көн ныгый, эше камилләшә һәм аның халык алдында дәрәҗәсе арта бара.

Вакыт дигән нәрсәнең иң кысан, иң кадерле урыны — КамАЗда. Мондагы эшләрнең барышы тизләтелгән кинокадрларны хәтерләтә. Андый кинотрюкларда агачлар күз алдында яфрак яра, тамашачылар күз алдында карбыз өлгереп җитә. КамАЗда да хәлләр шуңа охшаш: бер көн эчендә бер миллион сумлык эш эшләнә. Бер ай эчендә тугызар катлы, йөз кырыгар квартиралы гаҗәеп матур йортлар төзелеп куела! Бу — безнең җитештерү көчләребез никадәр зур үскәнен ачык раслаучы дәлил.

Әйе, җитештерү һәм төзү мөмкинлекләребез көннән-көн тизрәк үсә бара. Ә менә кешеләрнең тормыш-көнкүреше, шәһәрдәге тормыш шартлары да шундый

ук тизлек белән үзгәрә һәм үсәме икән соң? Үссә, үзгәрсә — ничек үсә, ни дәрәҗәдә үзгәрә? Һәм ул үсеш-үзгәрешләрдә җирле власть органнарының өлеше һәм роле никадәр?

Теләсә кайсы шәһәр башкарма комитетларының, алар каршындагы даими комиссияләрнең дә бурычлары бер: халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү, сәүдә, мәктәп һәм балалар бакчалары, сәламәтлек саклау эшләре белән шөгыльләнүдән гыйбарәт.

Чаллы шартларында бу проблемалар аеруча кискен куелган. Аның сәбәпләре шактый күп: шәһәр халкының беркайда да булмаган тизлек белән артып торуы, ул кешеләрнең нигездә яшьләр һәм илебезнең төрле почмакларыннан җыйналган алтмыш төрле милләт вәкилләре булуы... Чаллыда төзелгән яңа йортларның яртысы — вакытлыча яшьләр өчен гомуми торак итеп файдаланыла. Монда һәр вакыт төрле «бум»нар булып тора: производство бумы, «бэби бум» — яшьләр бумы. Баштарак КамАЗ төзүчеләргә пешкән икмәкне һәм сөтне якын-тирәдәге поселоклардан ташыйлар иде. Төп төзелеш мәйданы — КамАЗ комплексы — беренче торак микрорайоннарыннан егерме километр ераклыкта иде... Күрәсез, болар барысы да гадәти булмаган уңайсыз шартлар. Ә бит тормыш агыла тора: яшьләр өйләнешә, балалар туа. Бүтән гадәти шартларда да балаларга ясле булмау, әлбәттә, проблема. Ләкин ул хәл итеп булмастай проблема түгел. Чөнки «иске» шәһәрдә яки авылда яшь ана белән яшь атаның туган-тумачалары, әти-әниләре була. Һич югында, анда баланы вакытлыча карап торырга берәр карчык белән килешергә мөмкин. Ә Чаллыда? Монда әби-бабайлар, карчык-корчыклар турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Монда бары тик үзең эшкә киткәндә балаңны карап тору өчен күршеңне генә күндереп тора аласың. Ә бит ул да эшләргә дип килгән, ул да КамАЗда яши. Менә шулай итеп, гадәти шартлардагы гади генә көнкүреш проблемалары монда кайчакта катлаулы драмага әйләнеп кала... Шушындый хәлләрдә шәһәр советы нишли, нинди чаралар күрә соң?

Түшәгеңә карап аягыңны сузасың, диләр. Беренче чиратта, транспорт, мәгариф, җәмәгать туклануы мәсьәләләрен җайга салу максат итеп куела.

Әйтик, транспорт мәсьәләсе. Яңа төзелеш мәйданында җылылык трассасы да, су да, электр энергиясе дә булмау сәбәпле, җитмешенче елда беренче торак йортларны иске Чаллыда, гидротөзүчеләр поселогында төзергә туры килә. Ә КамАЗның завод корпусларын шуннан егерме километр читтә төзергә керешәләр. Кыскасы, төзүчеләргә һәр көн егерме километрга барып-кайтып эшләргә кирәк була. Ә йөрү өчен транспорт җитешми. Бу хәл, бер яктан, төзүчеләрнең көнкүрешендә кыенлык тудыра, икенчедән, аның төзелеш темпын киметүгә китерүе мөмкин.

Мәсьәлә башкарма комитет утырышларында, шәһәр советы сессияләрендә тикшерелә, проектчылар, төзүчеләр һәм транспортчылар белән бергәләп карала. Шәһәр советы депутатлары трамвай һәм троллейбус юлларын кайдан уздыру халык өчен уңайрак булачагын бик җентекләп өйрәнеп, проектчыларга үз тәкъдимнәрен әйтәләр һәм нәтиҗәдә проектларга шактый гына файдалы үзгәрешләр керттерүгә ирешәләр. Транспорт һәм юл төзелеше буенча даими комиссия транспорт йөртүчеләрнең эш шартларын яхшырту чараларын күрә, хәрәкәт графигын тикшерү өчен депутат постлары оештыра. Трамвай юлын тизрәк төзү өчен өмәләр оештыру, төзелеш өчен кирәкле материалларны вакытында кайтарту мәсьәләсен алдан кайгырту, автобусларга гаражлар төзү — саный китсәң, очына чыгарлык түгел... Әмма тырышлык үзенең яхшы нәтиҗәсен бирә: КамАЗ төзелә башланганга өч ел дигәндә транспорт мәсьәләсе тулысынча хәл ителде. Хәзер шәһәрдән завод төзелешенә телисең икән автобуска утырып, телисең икән трамвай белән бар. Яңа мәктәпләр, кибетләр, ашханәләр, кинотеатр, сөт заводы, ит комбинаты — боларны тизрәк сафка кертү өчен дә шундый ук тырышлык күрсәтелә.

Шәһәр советының хезмәткәрләре һәм депутатлары барысы да яшьләр. Яшьлекнең үзенең күп кенә өстенлекләре булса да, кайбер кимчелекләре дә бар. Бу очракта сүз эш тәҗрибәсе турында бара. Мәсәлән, председательнең беренче урынбасары Биктимер Мурясов элек завод директоры урынбасары вазифасын башкарган кеше. Ә башкарма комитет секретаре Роза Корнева редакциядә бүлек мөдире булган, Гомәр Гыйләҗев төзелеш идарәсендә эшләгән. Кыскасы, бүтәннәрне өйрәтүдән элек, алар үзләре өйрәнергә, үзләре эшнең тәртибенә төшенергә тиеш булалар.

Әмма алар баштан ук дөрес юлны сайлыйлар: депутатлар белән тыгыз элемтәдә торып, җәмәгатьчелеккә таянып эш итәләр. Сайлаучылар наказларын, депутат комиссияләре фикерләрен һәм тәкъдимнәрен күз алдында тотып эшләүне программ бурыч итеп саныйлар.

Менә, мәсәлән, халык мәгарифе өлкәсен алып карыйк. Гомуми урта белем бирү безнең илдә мәҗбүри итеп куелган. Бу — бәхәссез. Ләкин Чаллыда моңа ничек ирешергә соң? Күп кенә төзүчеләр вакытлы поселокларда төзелештән бөтенләй ерак та яши. Әле хәзер дә утыз меңләп кеше вагон-поселокларда көн күрә. Ата-аналар КамАЗ төзи, ә балаларны укытырга, берәвенең дә мәктәптән читтә калмавына ирешергә кирәк. Җиңел мәсьәлә булмаса да, шәһәр советы аны уңышлы хәл иткән.

Конкрет мисал китерик: шәһәрдән читтәге поселоклардагы балаларны исәпкә алалар, аларның әти-әниләрен җыеп сөйләшәләр, аннары мәктәп хәтле мәктәп булган мөһим объектларны төзүдә ярдәм сорап, тиешле оешмаларга һәм предприятиеләргә мөрәҗәгать итәләр. Шулай итеп, ике поселокта тиз арада һәм «планнан тыш» ике мәктәп салына. Депутатлар соравы буенча, төзүчеләр халык мәгарифе бүлегенә тагын бер бина тапшыралар һәм анда да яңа мәктәп ачыла... Бүтән поселоклардагы балаларны шәһәргә алып килеп укыту өчен транспортны тоткарлыксыз бирү мәсьәләсе хәл ителә.

— Без балаларыбызның тормыш юлына тиешле белем алып чыгуларын телибез, — ди шәһәр советы председателе урынбасары Гөлсабира Хәкимова. — Беренче этапны үттек инде: мәктәпләр булдырылды. Хәзер көн тәртибендә — укытуның сыйфатын, белем бирү дәрәҗәсен тагын да күтәрергә ирешү...

Яки менә сәүдә, җәмәгать туклануы мәсьәләләрен алып карыйк.

Башкарма комитет секретаре Роза Корнева өстәлгә күп кенә кәгазьләр китереп куя:

— Монда безнең унөч даими комиссия эшләгән эшләр билгеләп барылган, — ди ул. — Тарихка калсын өчен дип түгел, тәртип булсын өчен, оешканлыкка ирешү өчен шушылай тырыштык.

«Сәүдә. Җәмәгать туклануы» дигән бүлекләрдә комиссия эшләгән эшләр кыска гына итеп теркәлеп барылган: «Җәмәгать туклануы предприятиеләре эше турындагы мәсьәлә башкарма комитетта бер елда ике тапкыр тикшерелде».

«КамАЗның инде эшен башлаган ремонт-инструменталь заводында диетик ашханә ачтыруга ирештек».

«Шәһәрдәге азык-төлек кибетләрендә хезмәт күрсәтүнең яңа формаларын гамәлгә кертүгә ярдәм иттек».

«Аш-су эшенә өйрәтү өчен, бүтән шәһәрләрдән осталар чакырдык»...

Мондый фактларны бик күп китерергә булыр иде. Шуны гына искәртеп үтү дә җитәр кебек: бишьеллыкның дүрт елы эчендә Чаллы шәһәрендәге сәүдә мәйданы унике тапкырга диярлек арттырылган!

Монысы мәсьәләнең сан ягы. Ә сыйфат ягыннан караганда эшләр ничегрәк тора соң?

Җитмешенче елны Чаллыда, «Камгэс» поселогындагы бердәнбер урамда ике стандарт кибет бар иде. Биш катлы йортларның беренче катларында урнашкан ул кибетләрнең берсендә азык-төлек, икенчесендә промышленность товарлары сатыла. Болар Чаллыдагы иң зур кибетләр булып, кичке биштән соң аларга баш тыккысыз була: әйбер алырга теләсәң, берәр сәгать чират торырга туры килә. Дөрес, автолавкалар, бәләкәй павильоннар, вагон-ашханәләр дә гамәлгә кертелгән. Ләкин алар белән генә сәүдә мәсьәләсен хәл итү мөмкин түгел һәм аңа исәп тотарга да ярамавы көн кебек ачык иде.

Инде менә хәзер, ул көннәрдән соң дүрт ел вакыт узгач, шуны әйтергә кирәк: куандырырлык нәрсәләр күп эшләнгән — йөз егерме сатучы урыны булган, сату залы мең ярым квадрат метр мәйдан тәшкил иткән бик шәп «универсам» салынды. Үлчәп-төреп куелган товарлар, тиз исәпли торган касса аппаратлары... Полиэтилен пакетларга әйберләрне механик төрү җайланмалары, вакуумлы төрү линиясе, электрон үлчәүләр... Производство телевидениесе, селектор элемтәсе, кибет хезмәткәрләре

өчен өйрәнү бүлмәләре, душ бүлмәләре. Кыскасы, бу кибет — сәүдәне оештыру өлкәсендә алга таба бер яңа зур адым.

Чаллыда сәүдә челтәрен киңәйтү анда яңа алымнар кертү белән генә чикләнми, анда иртәгәге көн таләпләрен күздә тотып эш итәләр. Шуңа күрә дә кибетләрне, ашханәләрне, кафе һәм рестораннарны әйбәт итеп, заманча итеп җиһазландыруга аеруча зур игътибар бирелә. Анда Казаннан чакырып китерелгән художник-оформительләр даими эшләп тора, анда сатып алучыларга яхшы хезмәт күрсәтү буенча әледән-әле конкурслар үткәрелә, анда сәүдә хезмәткәрләренең осталыгын арттыру буенча даими курслар булдырылган. Халыкка хезмәт күрсәтү дәрәҗәсен күтәрү җәһәтеннән бүтән төрле чаралар да күрелә: мәсәлән, Киев, Мәскәү, Рига ресторанныарының иң әйбәт аш-су осталарын чакыртып китереп, автошәһәр сәүдә хезмәткәрләрен укытуны оештыру. Яки Чаллы сәүдә хезмәткәрләрен бүтән шәһәрләргә җибәреп укытып-өйрәтеп кайтару... Боларның барысы да сәүдә эшен яхшыртуга ярдәм итә. Бүген инде йорт кирәк-яраклары сатып алу өчен, элекке еллардагы шикелле, Әлмәткә яки Казанга барып йөрүнең, төсле телевизор кайдан юнәтим дип баш ватуның да хаҗәте юк — Чаллы кибетләрендә барысы да бар.

Моннан дүрт ел элек пароходта миңа Алабугага чәч алдырырга баручы КамАЗ егетләре белән барырга һәм аларның Чаллыда парикмахерлар аз булуына зарлануларын ишетергә туры килгән иде. Ә хәзер Чаллыда чәчеңне теләсә нинди модалы итеп теләсә кайчан алдыр!

Шулай итеп, Чаллыда барысы да эшләнгән, бөтенесе дә тиешенчә оештырылганмыни инде? диярсез. Бу сорауга «әйе» дип бер генә сүз белән җавап бирү өчен чамадан тыш оптимист булырга кирәк. Әле күптән түгел генә уртача бер гап-гади поселок булган Чаллының бар яктан килгән иртәгәге көн шәһәре булып үсеп җитүе өчен алга карап, еракны күреп, күп көч куярга кирәк әле. Менә кайбер фактлар һәм шулар турында беркадәр уйлану.

— Казан художниклары бик шәп итеп бизәгән «Кама» ресторанында кайбер ашлар начар сыйфатлы әзерләнә.

— Шәһәрдә мунча салганнар. Ләкин ике ел да үтмәгән — түбәсеннән су үтә, стеналары җимерелә, электр үткәргечләре сафтан чыга башлаган.

— Ателье ачканнар, шәхси заказ буенча кием тегәләр. Монысы бик яхшы. Ләкин менә әйбер тектерергә килгән кешеләрнең ризасызлык белдереп язган хатларына дүртәр ай буенча җавап бирмичә торуларын һич тә мактап булмый...

Мондый кимчелекләрнең сәбәбе күп төрле. Кайчакта тиешенчә карап-тикшереп тору җитенкерәми. Көнкүреш хезмәте күрсәтү өлкәсендә эшләүчеләр арасында эшкә бик үк намуслы карамаучылар да бар. Шуның өстенә Чаллының үзенә генә хас бер кимчелек тә бар әле: халыкка хезмәт күрсәтү сферасында эшләүче һәр дүрт кешенең өчесе — унтугыз-егерме яшьлек егетләр һәм кызлар. Аларда көч тә, энтузиазм да җитәрлек. Ул яктан тел тидереп булмый. Ә менә эш тәҗрибәләре җитәрлек түгел. Укытасы, өйрәтәсе иде аларны. Ләкин өлгереп булмый, чөнки автошәһәр көнләп түгел, сәгатьләп үсә. Ашыгырга туры килә. Шуннан файдаланып, кайбер кешеләр, ярамаган тагы, сыйфат турында баш ватып торыр чакмыни, дип эшкә салкын караган очраклар да булгалый. Ә бит инәдән-җептән генә чыгып килә торган яңа шәһәрдә әнә шундый ваемсызлыклар, дорфалыкларны, эшкә салкын карауларны һич кенә дә күрәсе килми.

Яңа автозавод-гигантны төзеп бетереп сафка кертү өчен шактый күп көч куясы бар әле. Ләкин Горький, Тольятти, Мәскәү һәм бүтән шәһәрләрдәге зур-зур автозаводларда инде якын арада КамАЗда эшли башлаячак кешеләр укыйлар, өйрәнәләр, тәҗрибә туплыйлар. Бу — алдан кайгыртучанлык күрсәтеп, Автомобиль промышленносте министрлыгы инициативасы белән эшләнә. Яңа шәһәрдә сәүдә, көнкүреш, тукландыру мәсьәләләрен җайга салырга тиешле ведомстволар да, шушы үрнәктә, илебезнең иң яхшы училищеларына поварлыкка, сәүдә эшенә, парикмахерлыкка, кисү-тегү эшенә укырга кешеләр җибәрсәләр, һич тә начар булмас иде. Шәһәр бит бөтенләй буш урында, көнкүреш хезмәте күрсәтүдә бернинди традицияләре дә, тәҗрибәсе дә булмаган җирдә төзелә. Ә бу сфера — шактый катлаулы, аның үзенең бик күп нечкәлекләре бар.

— Кул житмәгән эшләр житәрлек әле,— ди Биктимер Мурясов.— Гражданнарның үпкәсе-зары да житәрлек. Көнкүреш хезмәте сферасын идеаль дәрәжәгә житкерә алганыбыз юк әле. Без никадәр генә калышмаска тырышсак та, тормыш безне узып китә бара..

Ул ашыга иде. Нәкъ шул көнне шәһәр башкарма комитеты үзе инде өйрәнелгән «иске» урыныннан яңа урынга — Яңа шәһәр төзелә торган районга күченеп йөри иде. Шунда бергә киттек.

Әле яңа төзелеп кенә беткән, тәрәзәләре япан кырга карап торган йортның ике катын биргәннәр.

— Биш елга инде өченче тапкыр күченәбез, — ди җыештыручы булып эшли торган бер апа. — Һич тә бер урында гына утыра алмыйлар шул. Һаман халыкка якынрак барырга кирәк диләр.

Бу шәһәрдә киләчәктә көнкүреш мәсьәләләре генә түгел, бәлки бүгенге һәм алдагы көнге тагын да зуррак проблемалар да шунда хәл ителәчәк.

Баштагы өч елда Чаллы төзүчеләре күбесенчә жир эшләре башкардылар. Бу — төзелеш мәйданын әзерләү, юллар төзү, жир асты коммуникацияләре — су, канализация, газ трубалары үткәрү һәм электр линиясе сузу дигән сүз иде. Ә хәзер алар заман таләпләренә тулысынча жавап бирергә тиешле яңа шәһәрне төзү белән дә мәшгуль.

Әйе, яңа Чаллы макетта гына түгел, чынбарлыкта да бик шәп: бөтен ягын искә алып планлаштырылган кварталлар, бүгенге заман архитектурасы ирешкән уңышлар нигезендә житкерелгән мәһабәт йортлар, киңлек-иркенлек — болар барысы да күңелгә хуш килә, куандыра... Монда барысы да алдан уйлап эшләнгән: урамнар аша үтү өчен жир асты юллары, киң магистральләр, балалар һәм спорт мәйданчыклары бар.

Һәм менә шул һәр яктан бары тик мактауга гына лаек фонда — яңа шәһәрдә әле уңайлыкларсыз яшәргә туры килүе хакында көтелмәгән күңелсез жалобалар. Аларны, әле шушы араларда гына жәннәткә керергә билет тоткан шикелле куанып, кулларына яңа квартирага ордер тотып йөргән кешеләр язган.

— Ә эш шунда, — ди башкарма комитет председателе, — яңа йортларга күчкән кешеләр беренче көннәреннән үк шәһәрчә бөтен уңайлыклар белән яшәргә телиләр. Ә без аларга әле барысын да өлгертеп бирә алмыйбыз.

Бу менә болай дигәнне аңлата: инде эксплуатациягә бирелгән йортларның кайберләренә әле һаман газ кертелмәгән, балалар бакчалары житешми, кибетләр һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре торак йортларга караганда, гомумән, акрынрак төзелә...

Менә сиксән мең квадрат метр торак мәйданлы унынчы микрорайон. Карап туймаслык мәһабәт биек-биек йортлар. Бик әйбәт итеп эшләнгән подъездлар. Яктыкояшлы квартиралар. Төзүчеләргә дә тел тидерерлек урын юк: идән-түшәмнәр, стеналар барысы да күңел биреп, жиренә житкереп эшләнгән. Ул йортлар янында гына кибетләр, балалар бакчалары булырга тиеш. Әмма алар әле төзелмәгән.

Сәбәп? Микрорайонда торак йортларның һәм кибетләрнең нигезләре бер үк вакытта салына. Шулай кабул ителгән тәртип бар. Ләкин торак йортлар әзер блокларны монтажлау юлы белән бик тиз төзелә. Ә кибетләрнең яки балалар бакчаларының норматив буенча төзелү вакыты шактый озак, шуңа алар торак йортлардан бик нык соңга калып өлгерә. Димәк, аларны, «койрык» булып артта калмасыннар өчен, йортларга караганда шактый алданрак төзи башларга кирәк. Мәсәлән, Ленинградта инде нәкъ шулай эшлиләр дә.

Мондый кыенлыклар һәм очы-очка ялганмаган очраклар еш кына проектчылар, фәнни-тикшеренү оешмалары гаебе аркасында да килеп чыга. Әйтик, газ кертелмәве гаҗәп хәл. Өр-яңа менә дигән торак, ә үзендә әле газ юк. Чөнки йортлар житмеш беренче-житмеш икенче елларда төзелгән, ә магистраль газ үткәргеч Чаллыга соңрак, житмеш өченче елда гына китерелә. Ә нигә соң яңа йортлар квартираларына электр плиталары түгел, бәлки газ плиталары кую гына планлаштырылган? Кухняда электр плитасы хыял түгел, бәлки бүгенге көндәге чынбарлык бит ул. Һәм әлеге

йортларның проектын, төзелеш мәйданындагы хәлләрдән чыгып, үз вакытында үзгәртеп булмады микәнни?

Шәһәр советында яңа шәһәр өчен кирәк булачак балалар бакчаларын һәм яслеләрне планлаштырганда проектчылар хәлне тиешенчә исәпкә алып бетермәгән дип саныйлар. Чаллыда ел саен өч меңгә якын бала дөньяга килә. Ләкин шәһәрнең генераль планын төзегәндә мондый «демографик сикереш» шулай ук исәпкә алынмаган булса кирәк, чөнки урын җитмәү ихтималы бар.

Күрәсез, җитешеп бетмәгән яклар бар әле. Ләкин шунысын әйтеп үтик: торак йортлар салу белән культура-көнкүреш объектлары төзүдәге өзеклекне бетерү өчен шәһәрдә махсус төзелеш идарәсе оештырылган, аның эзлекле үтәлә торган конкрет эш планы бар.

Әлеге «койрык»ларның төп хикмәте, артка калуның тагын бер сәбәбе яңа төзелешләрне финанслауның гамәлдәге системасына кайтып кала дисәк, һич тә Америка ачу булмас.

Баштагы елларда шәһәр советына капиталь төзелеш мәсьәләләре белән ныклап торып шөгыльләнергә туры килмәгәнлеген алда искәртеп киткән идек. Моның сәбәбе шунда: Чаллыда торак һәм бүтән объектларның төп заказчысы шәһәр советы башкарма комитеты түгел, бәлки КамАЗ дирекциясе. Аннан кала «Камгэсэнергострой» берләшмәсе һәм тагын ваграк унлап предприятие. Алар кулында — акча, алар кулында — лимит. Төзүчеләр шулай ук аларга «беркетелгән». Шуннан? Шуннан шул: заказчы, барыннан да элек, ике нәрсәне — предприятиене (бу очракта КамАЗны) һәм торак йортларны тизрәк төзеп бетерү өчен тырыша. Әлбәттә, ул бүтән нәрсәләрне: юл төзү, балалар бакчалары, больницалар, кибетләр салдыру турында да кайгыртырга тиеш. Ләкин барыбер производство предприятиесен тизрәк сафка кертү аның төп бурычы булып кала. Бу — аның иң беренче максаты. Менә шуңа ирешү өчен тырышканда ул әлеге бүтән бурычларын онытыбрак җибәрә, аны икенче планга калдыра. Ул «икенче» бурычларны гамәлгә ашыру өчен акча да, лимит та аның кулында бит. Ләкин... Кыскасы, һәр яңа төзелештә «төп герой» — ведомство, заказчик.

Бу җәһәттән Чаллыда да эшләр нәкъ шулай тора. Биредә инде төзелгән ике миллион квадрат метр торак мәйданның нибары егерме биш меңе генә шәһәр советы карамагында, ә бүтәннәренә КамАЗ һәм башка ведомстволар хуҗа. Менә шуңа күрә әле хәзерге көнгә кадәр шәһәр советының капиталь төзелеш бүлеге дә, җитлеккән архитектура надзоры да юк. Хуҗалык өлкәсендә эшли торган бер иптәш әйткәнчә, монда власть башкарма комитет кулында булса да, күп очракта ул идарә итми. Ә бит, закон буенча, аның карамагындагы территориядә ведомстволар һәм предприятиеләр төзелешне ничек алып барганны нәкъ менә ул башкарма комитет күзәтеп, тикшереп торырга тиеш. Дәүләт торак фондлары һәм коммуналь хуҗалык объектлары белән идарә итүне үз кулына алырга аңа тулы хокук бирелгән. Шәһәр хуҗасы булган шәһәр советына үзенең яхшылап җайга салынган торак-коммуналь хуҗалыгы булу бик кирәк. Әгәр дә заказ бирү тик аның карамагында гына булса, шәһәр тормышын җайга салу белән бәйле күп кенә проблемалар тизрәк хәл ителер иде. Кичәге көн шартларында бүгенге шәһәр нормаль үсә алмый. Ул шартларны үзгәртү, яңача эш итә башлау кирәк икәнлеге көннән-көн ачыграк сизелә бара.

Бу — гади генә мәсьәлә түгел. Ләкин аны хәл итү — төп бурыч. Моның өчен шәһәр советының үз инициативасы да, РСФСР Торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының ярдәме дә, КамАЗда төзелеш алып бара торган ведомстволарның шул хаҗәтне аңлаулары да кирәк. Озакка сузмыйча, хәзер үк гамәлгә ашырасы конкрет проблемаларның берсе бу. Югыйсә, төрле ведомстволар җирендә җиткермичә киткән эшләрнең соңыннан шәһәр башкарма комитеты җилкәсенә авып калуы мөмкин.

Торак йортларның проектлары хәзердән үк торак фондны эксплуатацияләүнең һәм аңа хезмәт күрсәтүнең заманча иң яңа методларын: диспетчер хезмәте булдыруны, лифт хуҗалыгын автоматлаштыруны күздә тотып эшләнә башлады инде. Бу ни дигән сүз? Барыннан да элек, бу — халыкка уңайлык тудыру өчен эшләнә. Әйтик, хәзерге гадәти йортларда яшәүчеләрнең квартираларында кран ага башласа, аны төзәттерергә слесарь эзләп квартира хуҗаларының җелеге кибә. Лифт бозылса да, шул ук хәл. Ә менә Мәскәүдә Тушино районында шундый вак-төяк көнкүреш кыенлык-

ларын ничек ансат кына хәл итеп булганын күрсәгез икән! Торак йортларның берсендә махсус диспетчер пункты оештырылган. Ул пункт микрорайондагы барлык йортлар белән телефон һәм селектор аша бәйләнештә тора. Диспетчер пунктындагы пульт каршында утыра торган кызга барысы да — квартиралардагы суның температурасы күпме икәне дә, салкын суның басымы күпме булуы да, йортлардагы лифтларның ничек хәрәкәт итүе дә бик яхшы күренеп тора. Әгәр берәр җирдә берәр нәрсә сафтан чыга икән, квартира хуҗалары ишек төбенә чыгалар да, кнопкага басып, селектор аша диспетчерга мәсьәләне аңлатып бирәләр. Диспетчер шундук күрше бүлмәдә генә дежур торучы слесарьны әлеге квартирага кирәкле нәрсәне төзәтергә җибәрә... Нәкъ әкияттәгечә! Ләкин бу инде гамәлгә кергән чынбарлык. Һәм бу уңайлыкларны булдыру Чаллы йортлары проектларында да каралган.

Кызганычка каршы, ул проектлар әлегә кәгазьдә генә калып килә. Торакка мохтаҗлык зур булу сәбәпле, заказчы ул җитешсезлекләргә күзен йома да йортны файдалануга кабул итеп ала. Чаллы торак фондының шәһәр советы карамагына киләчәктә әнә шундый хәлдә тапшырылу ихтималы бар. Ә бу — алга атлау түгел, бәлки бер урында таптану дигән сүз. Уфа, Ленинград, Свердловск (Мәскәү турында әйттек инде) шәһәрләрендә күп кенә яңа кварталлар әнә шулай торак төзелешендәге иң соңгы, иң яңа алымнар ярдәмендә җиһазландырыла башлаган хәзерге вакытта ул алымнарны Чаллыда, әлбәттә, гамәлгә кертәсе иде. Һәм коммуналь хезмәт күрсәтү генә түгел, барлык бөтен төр хезмәтләр дә монда үрнәк дәрәҗәдә куелсын иде.

Гүзәл Кама буена утырган яңа Чаллы шәһәрен искиткеч зур эшләр башкаручы йөз меңләгән кешенең яшәү урыны итеп кенә түгел, бәлки егерменче гасырның икенче яртысында шәһәр төзү эшендә ирешелгән иң яңа, иң кыю, иң мөһим проектларның экспериментал лабораториясе итеп тә күрәсе килә. Димәк, алга карап, еракны күреп кыюрак эш итәсе бар.

**Шәмси Хамматов,**

Татарстан журналистлары союзы идарәсе председателе, «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы

# БИШЬЕЛЛЫК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

**Бишьеллыкның бөек гигантлары**
**Һаман үсә,**
**Һаман күккә таба үрелә,**
**Башларыннан инде сез яшәгән**
**Коммунизм кыры күренә...**

Һ. Такташ.

Бишьеллыклар тарихы — совет халкының бөек җиңүләре тарихы ул. Бу тарихи елъязмага тугызынчы бишьеллык гүзәл сәхифәләрен язды. Билгеләнгән һәм хәл ителгән бурычлары белән бу бишьеллык ифрат үзенчәлекле булды. Аларны тормышка ашыруга актив катнашу, барлык совет кешеләре кебек үк, язучыларның һәм журналистларның да гражданлык бурычы булып әверелде.

Мәгълүм хакыйкать: совет язучысының, совет журналистының художестволы фикерләренә публицистик рух хас. Чөнки социалистик реализм методы, журналистиканың ленинчыл принциплары әдәбиятның һәм публицистиканың тормыш белән актив элемтәдә булуын, каләм осталарының дөньяны үзгәртеп коруга турыдан-туры катнашуын күз алдында тота.

Бишьеллык әдәбият, матбугат эшлеклеләре алдына югары таләпләр куйды. Публицистлар бу бишьеллыкта иҗат активлыкларын тагын да күтәрделәр, совет җәмгыяте, замандашыбыз, чорыбыз турында дулкынландыргыч әсәрләрне кыюрак иҗат итә башладылар.

Тугызынчы бишьеллыкның — героик чорыбызның елъязмасын булдыруга «Социалистик Татарстан», «Советская Татария», «Татарстан яшьләре», «Комсомолец Татарии» газеталары һәм аларның авторлары да мәгълүм өлеш керттеләр. «Татарстан коммунисты», «Казан утлары», «Азат хатын» журналларының күп кенә сәхифәләре данлыклы бишьеллыкның, аның батырларының онытылмас биографиясе булып кабул ителде. Татарстан китап нәшрияты публицистик рух белән өртелгән дистәләгән яңа китап өстәде. Күренекле язучыларыбыз, публицистларыбыз партиябез җитәкчелегендә совет халкы башкарган героик эшләрнең елъязмачылары, аларда турыдан-туры катнашучылар булдылар.

Бу героик эшләрнең төп өлеше галиҗәнаб эшчеләр сыйныфына туры килә. Табигый хәл. Чөнки, партиянең XXIV съездында КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш Л. И. Брежнев әйткәнчә, илебездә эшләүче халыкның 55 процентыннан артыграгын эшчеләр тәшкил итә. Ләкин социалистик җәмгыятьтә эшчеләр сый-

ныфының урыны анық саны белән генә билгеләнми, бу сан экономиканың үсешенә, фән-техника революциясе темпларына карап үзгәрергә мөмкин. Эшчеләр сыйныфы җәмгыятьнең төп житештерүче көче булды һәм шулай булып кала. Аның революционлыгы, дисциплиналылыгы, оешканлыгы һәм коллективизмы социалистик иҗтимагый мөнәсәбәтләр системасында анык җитәкче хәлен билгели.

Әйтелгәннәр тулысы белән безнең республикабызга да кагыла. Анда эшчеләр сыйныфының яңа коллективлары формалашты. Әлеге вакыйгалар чорның елъязмасын тудырырга тиешле публицистлар һәм журналистларның игътибарыннан читтә кала алмый. Дөресен әйткәндә, аларның узган биш ел эчендәге иҗади активлыгы иң беренче чиратта КамАЗ төзелешен ни дәрәҗәдә яктыртулары белән үлчәнә дисәк тә, дөрес булыр.

Алдан ук шуны искәртик, моңарчы без публицистика артта кала, очерклар язучы аз, кайбер әдипләребез, журналистларыбыз бу өлкәгә атлыгып тормый дип әйтә килдек. Һәм бу сүзләрдә хаклык та юк түгел иде. Ә менә хәзер икеләнмичә раслый алабыз: тугызынчы бишьеллыкның гигант төзелешләре, коммунистик җәмгыять төзүче кешеләребезнең героик хезмәте публицистикага да шифалы йогынты ясады, аны күпмедер дәрәҗәдә алга этәрде. Хикмәт матбугатта урын алган публицистик язмаларның, очеркларның саны артуда гына түгел, ә иң мөһиме — сыйфаты яхшыра баруда.

Һади Такташ моннан кырык биш ел элек шахтерлар тормышын күреп кайткач, «Донбасска баргач» дигән мәкалә язган. Бу язмада әйтелгән үткен фикерләр, Донбасста барган «бөек төзелешнең язучы алдына куйган бөек бурычлары» хәзер илебездә, безнең республикада, Чаллыда төзелә торган КамАЗ турында каләм тибрәтүче публицистлар, әдипләр өчен дә үрнәк булды.

«Пролетариат язучысы,— дип язды ул чакта Һ. Такташ,— әле төзелеп өлгермәгән, ләкин җиңелмәслек бер омтылыш белән төзелеп килгән бөек тормыш күренешләрен күрсәтү нигезендә безнең бүгенге идеалларыбызның җиңүләренең иртәсе белән меңнәрне кызыктыра алырга, аларны шул җиңүләр өчен булган көрәшләргә чакыра белергә тиешле.

Моның өчен ул бүгенге социалистик экономиканың иртәсе алып килгән җиңүләрне айнык рәвештә алдан күрергә, меңнәрнең кул хәрәкәтләрен, уй-омтылышларын өйрәнергә, тормыштагы бөтен күтәрелешләрне, бөтен тайпылышларны аңлап, бөек төзелешнең һәрбер винтын карап, күреп үтәргә, һәрбер тәгәрмәченең хәрәкәте китергән энергиянең күләмен үлчәп үтәргә тиешле» [1].

Яңаны төзүне, иҗади хезмәтне, үз заманы героен, бишьеллыкның бөек гигантларын җырлаучы трибун Һ. Такташның бу сүзләре язучылар, журналистлар өчен әйтерсең әле генә әйтелгән бүгенге теләкләр, наказлар булып яңгырады.

Һади Такташның әдипләргә, шагыйрьләргә «тормыш якларына да күз салырга кирәк, Волховстройлар, Днепростройлар төзелә, шахталар машиналаштырыла. Нигә сез шуларны җырламыйсыз? Эшчеләр арасында ике-өч көн генә кунак булу җитми, язучыларыбызга уңышларыбызны айлар, еллар буенча өйрәнү... кирәк» [2], дип борчылып тәкъдим ясавы — безнең заман художникларына да ялкынлы мөрәҗәгать булды.

*

* *

КамАЗ турындагы беренче очерклар хаклы рәвештә газета журналистлары тарафыннан иҗат ителде. Дөрес, алар әле беренче сынау, беренче эзләнү, беренче табышлар иде. Әмма беренче булса да, адымнары ышанычлы иде. Республикабыз газеталары башлап җибәргән бу агымга «Казан утлары», «Азат хатын», «Татарстан коммунисты» журналлары һәм аларның авторлары кушылды. Без бу мәкаләбездә тугызынчы бишьеллыкта республикабызның кайбер матбугат органнарында чыккан публицистик әсәрләр, редакцияләр алып барган эшләр, тәҗрибәләр турында сөйлибез.

Иң беренчеләрдән язылган һәм берничә еллар ераклыгыннан караганда да башка очерклардан шактый өстен торган ике әсәрне билгеләп үтү урынлы булыр. Болар —

[1] Һади Такташ. Әсәрләр. Татгосиздат, Казан, 1942 ел, 314 бит.
[2] Һади Такташ. Әсәрләр. Татгосиздат, Казан, 1942 ел, 311—313 битләр.

Диас Вәлиевнең «Хәрәкәттә — бәрәкәт»е һәм Равил Вәлиевнең «Каурыйлар чыныкканда»сы. Д. Вәлиевнең очеркы КПССның Чаллы шәһәр комитетының беренче секретаре Рәис Беляев, КамАЗ төзелеше начальнигының беренче урынбасары Евгений Батенчук, «Гидропроект» институтының техник бүлеге баш белгече И. Завалишин белән әңгәмә формасында язылган. Автор төзелешнең колачы, кешеләр язмышы, анда торган проблемалар турында әңгәмәчеләре белән бергә тирән уйлана, ул проблемаларны үз йөрәге, үз күңеле аша үткәрә.

Журналист Равил Вәлиев очеркы турында сүз башлаганчы, шундый сорауга җавап бирәсе килә. Океан эчендә йөзгән кораб, аның кешеләре турында яр буенда утырып язылган очерк отышлырак булыр идеме, әллә шушы кораб эчендә язылганымы? Әлбәттә, икенчесе. Р. Вәлиев тә океандагы кораб турында ярда утырып язмый. Ул, Казан университетының журналистика бүлеген тәмамлаганнан соң, В. Мәүликов бригадасында гади ташчы булып эшли, коллектив кешеләре, аларның уй-омтылышлары, теләкләре, шәхси һәм коллектив тормышлары турында көндәлек алып бара. Авторның вакыйгаларга карата самими мөнәсәбәте укучы күңеленә тиз барып җитә. Аның очеркы, күп очеркларга хас булганча, геройлар биографиясеннән генә тормый. Ул кызыклы итеп, кирәк урында юморны да оста кулланып, чын әдәби югарылыкта язылган. Әсәр хаклы рәвештә «Казан утлары» журналындагы елның иң яхшы әсәре дип кабул ителде һәм махсус бүләккә лаек булды.

Язучылар арасында КамАЗ төзелеше турында иң актив һәм нәтиҗәле эшләгәне — Геннадий Паушкин. Төзелеш мәйданы иң беренче көннәреннән аның иҗат мәйданына әверелде. Ул газеталарда һәм журналларда КамАЗ кешеләре турында чын күңелдән дулкынланып язылган очеркларын бастырды. Ян Винецкийның «Советская Татария» газетасы битләрендә чыккан очерклар сериясе, М. Зарипов, Т. Сәгыйтов, Б. Камаловның «Казан утлары» журналында дөнья күргән очерклары да төзелешнең төрле якларын, төрле язмышларны яктырта.

Журналист Р. Бикташировның «Кубиклар» турында баллада»сы Куйбышев ГЭСы төзелеше турында сөйләүдән башлана. Автор, әле ул вакытта кечкенә малай, кеше кулы һәм акылы белән эшләнгән эшләргә гаҗәпләнеп һәм сокланып карый. Менә 20 елдан соң ул Чаллыда газета хәбәрчесе булып эшли башлый. Ул күрә: Куйбышев ГЭСын төзүчеләрнең хезмәт батырлыгы монда дәвам итә. КамАЗ — беренче һәм сугыштан соңгы бишьеллыкларның гигант төзелешләре дәвамы, аны шушы төзелешләрдә чыныккан, тәҗрибә туплаган кадрлар һәм бүгенге яшь энтузиастлар төзи. Автор үз очеркында әнә шул фикерне үткәрә.

Шунысы куанычлы, хәзер очерк авторларыбыз үз республикабыз чикләрендә генә дә бикләнеп ятмыйлар. Газеталар битләрендә, «Азат хатын», «Казан утлары» журналларында Себер нефтьчеләре, БАМ төзүчеләре турында да җылы гына язылган очерклар басылды. Алар арасында М. Маликова, К. Тимбикова, Н. Габдуллин тарафыннан язылганнары укучылар күңеленә хуш килгәндер дип уйлыйм.

Хезмәт коллективларын туплауда, аларны халык эшенә тугрылык, коллективизм һәм интернационализм рухында тәрбияләүдә беренче бишьеллыклар геройларының хезмәт традицияләре гаять зур роль уйный. Алар кешеләргә эмоциональ йогынты ясау көченә ия. Шуңа күрә публицистларның өлкән буын хезмәт традицияләрен пропагандалаулары экономик һәм политик тәрбиянең мөһим бер өлеше булып матбугат тарихына керде. Бу эш беренче бишьеллык батырлары А. Стаханов, П. Кривонос, М. Виноградова, А. Бусыгин, И. Гудовның КамАЗ төзүчеләргә хаты уңае белән аеруча көчәйде. М. Рафиков белән Р. Зәкиев «Батырлык каласы» исемле очеркта Магнитка батырлары, бу батырлыкның бүгенге яшьләребезгә эстафета булып күчүе турында язсалар, М. Әмирхановның «Шахта иленә сәяхәт»ендә «Донбасс белән КамАЗ кул кысышты, дуслык дәвам итә» дигән фикер кызыл җеп булып ята.

Бүгенге Чаллы — ташчылар һәм монтажчылар, механизаторлар һәм штукатурлар шәһәре генә дә түгел. Монда төрле профессия кешеләре яши. Күп кенә очерклар аларга багышланган. Язучы Әдип Маликов үзенең «Язмышлар» очеркында балалар бүлмәсе тәрбиячесе өлкән лейтенант Рафика Фәхретдинова, ә журналист Д. Зөбәерова врач Зәйтүнә Кашапова («Әманәт») турында хисләнеп һәм күңел җылылыгы белән яздылар.

Публицистика өлкәсендә журналистлар һәм язучылар гына түгел, производство

кешеләре үзләре дә актив катнаштылар. «Казан утлары» журналында 1974 елда бригадир Ә. Гайнуллин, балта остасы Ф. Хәбибуллин язмалары тәкъдим ителде. Ә. Гайнуллин үзенең язмасын көндәлек формасында кызыклы сюжет белән алып бара. Монда бригадирның үз бригадасы членнарына булган мәхәббәте, алар турында кайгыртучанлыгы сизелеп тора.

Әйе, баксаң, КамАЗ һәм аның кешеләре турында күңелгә барып җитәрдәй байтак очерклар һәм публицистик язмалар иҗат ителгән икән.

Әмма, алары белән бергә, КамАЗ төзелеше пульсын тоеп булмый торган очерклар да күренгәләде. Аларда кешеләрне уйландыра, борчый торган проблемалар да, гыйбрәтле язмышлар да юк. Алар үз алларына бер генә максат куялар: КамАЗ — ул бөтен союз күләмендәге гигант төзелеш, аны күккә чөяргә кирәк. Ни өчен яхшы, нәрсәне мактарга — бу сорауларга җентекле җавап бирәсе урынга, саннар белән гомуми нәтиҗәләр чыгарыла да геройларның биографиясе сөйләнә. Безне бүген очерк-иллюстрация, очерк-биография генә канәгатьләндерә алмый. Укучы публицистикада тирән гомумиләштерүгә ия булган зур фикер, тикшеренү, анализ күрергә тели.

Эшчеләр сыйныфына багышланган очерклар арасында нефтьчеләр, химиклар, башка профессия кешеләре турында язылганнары да байтак. Нефть чыгаруның яңа алымнарын куллану, химия предприятиеләрендә куәтләрне сафка бастыру, хезмәт кешеләренең тәвәккәллеге, фидакарьлеге, алда торган проблемалар чагыла аларда. Бу уңайдан Д. Вәлиевнең «Җамалиевлар династиясе»н аерым телгә аласы килә. Кайчандыр крестьян булган, бөек төзелешләр башлангач, Казан заводларына эшкә кергән, соңрак бөтен гаиләләре, хәтта династияләре белән эшчеләр булып киткән Җамалиевлар турында киң колачлы очерк бу. Автор монда күпләгән образлар галереясы тудыра, һәр персонажның уй-теләген, омтылышын, дөньяга карашын ача. Бүгенге тормышыбызга хас булган күренеш — крестьянның эшчеләр сыйныфы сафына басуы ышандырырлык һәм кызыктырырлык итеп бирелә. Акча өчен генә йөрүче түгел, ил байлыгын арттыру өчен бөтен көчләрен бирүче кешеләр болар. Хуҗи улы Вәлиәхмәткә болай ди: «Мин үләрмен, синең оныкларың, Нуриәхмәтнең оныклары үләр. Без бу җиргә беребез дә мәңгелеккә килмәгән. Әмма безнең намусыбыз мәңгелек! Менә шуңа күрә тормышта кешеләрчә яшәргә, аны үз кулларың белән төзешергә, әйбәт якка үзгәртергә кирәк...» Бүгенге совет кешесенең уй-фикерен, дөньяга карашын автор әнә шундый гади сүзләр белән калку итеп ачып сала.

Рәхмәй Хисмәтуллинга үз очеркларында («Тирәннән чыккан шытымнар», «Бәйрәм белән, дуслар!», «Ялгыз торна күле») хезмәт кешесенең эчке зур дөньясын әдәби осталык белән ача белү хас.

Без шундый чорда яшибез ки, шәхеснең үзе эшли торган коллективка йогынтысы арта бара. Публицистика бүгенге эшлекле кеше, аның тормышка актив мөнәсәбәте, производстводагы роле, җитәкче белән коллектив арасындагы мөнәсәбәт проблемаларына игътибарны арттырды. Болар, бер яктан, тормыш мәсьәләләре булса, икенче яктан, әдәбият һәм журналистика мәсьәләләре дә.

Язучы һәм журналист Марсель Зарипов үз очеркларында әнә шул мәсьәләләргә аеруча нык игътибар итә. Ул нефтьчеләр турында да («Саран катламнар» хәзинәсе»), авыл хуҗалыгындагы техника прогрессы («Тавык кошмы, түгелме?»), фән кешесе турында да яза. Ул аларда проблемалар куеп кына калмый, кешенең, коллективның ул проблемаларны нинди юллар белән хәл итүен бәян итә. Шуңа күрә геройлар биография юлларына кысылган җансыз персонажлар булып түгел, уйлана, эзләнә, көрәшә, җиңә торган тормышчан образлар булып алга килеп басалар. Аларда рухлану, илһамлану бар, фәлсәфи фикерләр, фәлсәфи нәтиҗәләр бар.

Бу авторның узган елны август аенда «Казан утлары» журналында басылган «Киңлекләр» очеркына мөрәҗәгать итик. Бер караганда, кабатланган форма кебек. Автор Иделнең башланган урыныннан сәяхәтен башлый да, агым уңаена аска төшә-төшә, төрле милләт халыклары, төрле шәһәрләрнең үткәнен бүгенге белән чагыштыра. Ләкин чын публицист каләме белән язылган юллар сине үзенә җәлеп итә, уйландыра, илһамландыра. Автор Ватаныбыз уртасыннан аккан Иделне бөек дуслык символына әверелдерә.

«Иделнең иң киң урыныннан узганда башка менә нинди уйлар килә: аерым-аерым гына агып ятсак, кечкенә инешләр кебек, без дә зур елгага әверелә алмабыз. Ә кө-

чебезне бергә кушсак, юлында бернинди киртәләр белән хисаплашмаган Иделгә әвереләбез. Монда, Идел белән Кама кушылган урында, Тукайның тирән фәлсәфи фикерле шигъри юлларын тагын бер тапкыр күңелеңнән үткәрәсең:

**Һич бетәрме тарихи бу бергәлек! —**
**Без туган бер җепкә бергә теркәлеп»** [1].

Халыкларыбызның дуслыгын, бу дуслыкның алга баруыбызның төп этәргеч көч булуын публицист М. Зарипов әнә шулай данлый.

Авторларыбыз авыл эшчәннәрен дә онытмыйлар. Сибгат Хәким, Габдрахман Минский, Риза Ишморат, Барлас Камалов, Малик Хәмитов һ. б.лар бишьеллык батырлары, аларның күркәм эшләре турында язылган матур-матур очерклары белән сөендерделәр. Журналистлардан Р. Максудов, Ф. Насыйров, Ш. Садыйков очеркларын да матбугатта еш күрергә мөмкин. Ләкин авыл хезмәтчәннәренә багышланган очерклар әле бертөрлерәк. Аларда күбрәк колхоз-совхоз җитәкчеләре турында языла һәм авыл ирешкән уңышларны санауга күп урын бирелә. Маңгай тире белән иген иккән, корыч машиналарны иярләгән, терлекчелек фермаларында эшләгән кешеләр турында йөрәк җылысы белән язылган очерклар күрәсе килә. Бу җәһәттән хөрмәтле язучыларыбыз тырышлыкларын арттыра төшсеннәр иде.

*

* *

Язучы Ф. Хөснинең хикәягә карата әйткән бер чагыштыруы бар: ул аны тыныч кына аккан елганың кискен бөтерелүгә күчкән урынына — чоңгылга тиңли. Публицистика тормыш елгасының, әнә шул әйләнмәле чоңгыл кебек, хезмәт белән ярыш шавында кайнаган үзәгенә разведка ясау ул. Суны шулай шауларга, бөтерелергә мәҗбүр иткән эчке агым нинди икән? Ул шуны ачыклый, хәрби телгә күчерсәк, батальон разведкасы ролен үти.

Ә менә батальон разведкасы мәгълүматларының полкта, дивизиядә бергә тупланышын хәтерләткән тагын бер күренеш бар: ул — көндәлек матбугатта урын алган публицистик әсәрләрне бергә туплап, я булмаса, нәшриятлар заказын үтәү рәвешендә китаплар чыгару. Бу инде бүген әһәмиятле, бүген хәл итәсе мәсьәлә-проблемаларның, газета-журналлар аша укучы күңеленә, зиһененә бер кат үтеп, бүген үк яңадан хәрәкәткә килүе, танылуы. Бу, бердән, аларның тормыш сынавын уңышлы үтүе, тормышта урын алуга хак яулавы, икенчедән, алгы рубежны алган сугышчының, һөҗүмне туктатмыйча, гел алга баруы, бурычны ахырынача үтәргә омтылышы.

Мондый сугышчан, гел хәрәкәттәге китапларга — публицистика булсынмы, әдәби әсәрләрме — Татарстан матбугаты арсеналы, әйтергә кирәк, шактый бай. Шуңа Мәскәү нәшриятлары тәкъдиме белән башкала язучылары да керткән өлешне исәпкә алсаң, Татарстан турында тугызынчы бишьеллыкта язучылар, журналистлар чыгарган публицистик китаплар, брошюралар байтакка җыела. Мин, мәсәлән, шундыйларны өч дистәгә якын санадым. Ул китап-брошюраларның күзне тартырдай, күңелне җәлеп итәрдәй зәвык белән басыла башлавы да — матур күренеш.

Иң элек, билгеле, әдипләрнең әдәбият һәм культурага кагылышлы җыентыкларын искә алу кирәктер. Бу уңайдан Г. Бәширов, Ә. Фәйзи, Ф. Хөсни, Н. Дәүли, Г. Ахунов һәм башкаларның публицистик мәкаләләрен туплаган җыентыкларны искәртеп үтәсе килә. Көндәлек әдәби процессны гомумиләштерү, татар совет әдәбиятының аерым-аерым мәсьәләләре хакында кызыклы, файдалы, тирән эстетик мәгънәгә ия фикерләр, аның үсеш үзенчәлекләренә караш, әдипләрнең иҗат тәҗрибәләрен күрсәтү ягыннан өлкән буын язучыларының бу мәгълүм җыентыклары җәмәгатьчелек игътибарыннан читтә калмады. Кыйммәте нәрсәдә соң аларның? Объективлык, критерийларның төгәллеге, хәзерге заман татар әдәбиятының, татар халкы культурасының, әдәби мирасның үзләрен кызыксындырган, борчыган, шатландырган якларына карашларының җитди, нигезле булуы — менә нидә. Авторларның күзәтүләре нигезендә һәрчак проблемалылык, көн таләбе ята.

Язучы — безнең тормыштагы мөһим процессларга иҗади, ялкынлы катнашуның синонимы ул. Бу карашның кыйммәтен үлчәр критерий — язучының кеше, халык, ил язмышы өчен шәхси җаваплылык хис итүе, ягъни гражданлыгы.

[1] «Казан утлары», 8 сан, 1975 ел, 125 бит.

Халыкның хезмәт батырлыгы иҗат батырлыгына да чакыра. Язучылар көрәшкә чакырып кына калмаска, үзләре дә шул көрәшнең алгы сафында барырга тиешләр. Йөрәкләре, хисләре кушуы белән иҗатка омтылган язучылар бездә аз түгел. Бишьеллыкның мөһим төзелешләренә багышлап чыгарылган төрле җыентыклар, китаплар шул хакта сөйли. Г. Ахунов белән М. Зариповның «Без Казаннан, Иделдән» дигән киң масштаблы, тирән анализлы, Г. Паушкинның «Чаллы җирендә» дип исемләнгән, М. Хәмитовның «Егетлек» дигән очерклары җыентыгын, Д. Вәлиевнең «Көн артыннан көн», Б. Камаловның «Кулга-кул тотынып», И. Низамовның «Кул җылысы» дигән публицистик китапларын күздә тотам мин.

Алар фикер һәм сүз һөҗүмен тугызынчы бишьеллыкны үтәү көрәшенең төрле өлкәләренә юнәлдерә. Алар нәрсәдән гыйбарәт соң? Промышленность, аның да Татарстанда кискен үсеш алган, илебез экономикасының мөһим бер состав өлеше булган нефть һәм химия тармаклары! Инде индустрия юлына күчә барган авыл хуҗалыгы. Әйткәнебезчә, идеология фронтының әдәбият, культура, яңа кеше тәрбияләү мәсьәләләре. Коммунизм төзелешенең экономик, социаль һәм рухи җирлеген шулай һәрьяклап тикшерү, язучыларыбызның бу бурычларны һәрчак күз уңында тотуы — аларның активлыгы хакында сөйли торган күренеш.

Шунысы кыйммәтле: көннең, вакытның, чорның нинди генә актуаль, мөһим проблемаларын чагылдырырга алынмасыннар, язучы иптәшләр заман бурычларын чагылдыруга хезмәт иясе кешесе характерын гәүдәләндерү аша якын киләләр. Дөрес, публицистика байлыгыбызны күздән кичергәндә әле производство мәсьәләләренең технология анатомиясе белән артыграк мавыгу күренешләренә дә тап булгалыйсың. Бу бигрәк тә безнең чорның киеренке темпын калку чагылдырган КамАЗ төзелешенә багышланган очеркларда ешрак очрый. Алар китапларга да үтеп керә. Ләкин, куанычка каршы, күпчелек китапларда үзәккә социалистик чынбарлыгыбызның образы, аның көзгесе булган кеше — аның кичереше, уй-фикере, холык-фигыле, ихтыяҗы куела.

Шушының тасвирнамәсе рәвешендә Г. Паушкинның «Чаллы җирендә»[1] дигән китабын тагын телгә аласы килә. Биредә язучының КамАЗ турындагы очерклары тупланган. Төзелешнең яңа башланган чагы. Күп журналистлар, язучылар республикабызның гына түгел, бәлки илебезнең дә күпме завод һәм фабрикаларын үз ихтыяҗына, үз ритмына буйсындырган бу комплекс турында масштаб белән гаҗәпсенү, саннарга, планнарга, машиналарга шаккату рухындарак язган бер заманны Г. Паушкинның очеркларында тасвирлау, өйрәнү объекты булып 70 нче еллар энтузиасты булган кеше алынды. Язучы үзе мөрәҗәгать иткән героен хезмәттә һәм көнкүрештә гәүдәләндерергә, күңел хисләренә чиертергә, психологиясенә үтеп керергә тырыша.

Журналист И. Низамов җыентыгында[2] да шул рухтагы очерклар тупланган. Производство үзгәрешләре, яңалыклар, зур-зур хезмәт күрсәткечләре аның очеркларында үзмаксат итеп, укучыны таңга калдыруны исәптә тотып искә алынмый. Саннар аның кулында кеше фидакарьлегенең көзгесе сыйфатында телгә алына.

Үткән биш ел эчендә публицистика өлкәсендә билгеле бер үз ролен үтәгән китаплардан тагын М. Насыйбуллинның «Без капчыкта ятмый», «Төнге ату», В. Ихсанованың балалар өчен язылган «Учаклар», И. Низамов төзегән «Түбән Кама — яшьлек шәһәре», Б. Камалов белән Җ. Кәлимуллинның «Дуслык таулар күчерә» дип аталган очерклар һәм язмалар җыентыклары да дөнья күрде.

Публицистик китап һәм җыентыкларны күз алдыннан кичергәндә КамАЗга багышланган очерк, язмалар хакында ешрак сүз йөртергә туры килә. Язучыларның, журналистларның тормыштагы, тимерче миче сымаграк, кайнап-шаулап торган җиргә омтылышы аңлаешлы нәрсә. Алай да күңелдә беркадәр канәгатьсезлек юшкыны калганлыгын танымый һич мөмкин түгел. Китап һәм брошюраларның тема ярлылыгы үзен сиздерә. Татарстан китап нәшрияты чыгара килгән «Минем һөнәр» циклы брошюралары да бу тарлыкны киңәйтә алмый әле. Бу җәһәттән Д. Вәлиевнең «Көн артыннан көн», Б. Камаловның Буа районындагы «Коминтерн» колхозы хакында сөйләгән «Кулга-кул тотынып» дип аталган документаль повестьлары аерылып тора. Безгә менә

[1] Г. Паушкин. На земле Челнинской. Казань, 1971.
[2] И. Низамов. Кул җылысы. Казан, 1975.

шундый, авторларның хезмәт геройлары хезмәт коллективлары арасында яшәве нәтиҗәсе буларак иҗат ителгән документаль жанрдагы күләмле публицистик әсәрләр җитенкерәми.

Хезмәт коллективларының социалистик ярыш ялкынында, бишьеллык бурычларын үтәүдә катнашуның күп тармакларына үтеп керү, шуны иҗади анализлауга корылган китаплар сорый күңел. Шушы уңайдан китап нәшриятыбызның матур бер инициативасын хупларга кирәк. Ул төзүчеләре Д. Вәлиев, М. Глухов, Р. Максудов, Е. Лисин булган альманах сериясе чыгара. (Билгеле, моңа охшашлы җыентыкларның промышленность, авыл хуҗалыгы, фән һәм культурага кагылышлыларын да кулга аласы килә.) Бу китаплар сериясе бишьеллык пәһлеваны — Кама автомобиль заводлары комплексы төзелеше уңаеннан дөнья күрә башлады. «Камадагы батыр», «Батыр адымы», «Батыр үр яулый» дип исемләнгән альманахларда төзүчеләр үзләре дә сүз ала. Китаплар эчтәлеге белән дә, фоторәсемнәр күп бирелүе белән дә — документаль. Чын мәгънәсендә кирәкле, зур эчтәлекле хезмәтләр болар.

Үткән бишьеллыкта дөнья күргән публицистик китапларга бу кыскача күзәтү ахырында бер проблемага игътибар юнәлдерәсе килә. Ул да булса, шушы китапларны эшлекле анализлау мәсьәләсе. Әйтик, әдәби китапларның шактый өлеше рецензияләнеп, тикшерелеп килenә. Публицистикага караганнары исә игътибардан читтә кала. Хәер, кайбер әсәрләр көндәлек матбугатта чыккан очеркларны күзәткән чакта телгә алына алынуын. Ләкин сүз китаплар турында. 30 га якын публицистик җыентык — аз түгел бит. Тәнкыйтьчеләргә зур җирлек бу. Язучы һәм журналистларның иҗат итү гамәлләрен гомумиләштерү, матбугатыбыз публицистикасының йөзен, үзенчәлеген, халәтен, бурычларын ачыклауга зур өлеш булыр иде уя, югыйсә. Тормыш проблемаларының язучылар иҗатында ни дәрәҗәдә чагылуын билгеләү турыдан-туры иҗат мәсьәләсенә, иҗат проблемаларына килеп тоташа бит.

*
* *

Александр Фадеев үзенең бер мәкаләсендә «Әдәби биографиям эшче газетасында башлану белән горурланам» дип яза. Өлкән буын татар язучылары да шулай әйтә алырлар иде. Аларның күпчелеге республика газета-журналларында турыдан-туры эшләгәннәр. Вакытлы матбугат белән бу иҗади дуслык бүген дә дәвам итә, үсә бара. Мисал өчен аларның «Социалистик Татарстан» газетасында хезмәттәшлеген алам. Өлкән һәм урта, яшь буын язучыларыбызның публицистик чыгышлары, очерклары газетабыз битләрен бизәп киләләр. 1971 елда тугызынчы бишьеллыкның беренче елында ук язучы Л. Ихсанова газета укучыларга «Могҗиза» исемле публицистик мәкаләсе белән мөрәҗәгать итте. Ул анда коммунистик җәмгыятьнең материаль-техник базасын төзүдә могҗизалар күрсәтеп эшләүче хезмәтчәннәр турында рухланып язды. Драматург А. Гыйләҗев үзенең мәкаләсен «Тугызынчы» дип атады. Язучылар З. Нури, А. Шамов, Б. Камалов, Г. Кашшаф, Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни һ. б. публицистик мәкаләләр белән газета битләрендә чыгыш ясадылар.

Бу көннәрдә «Язучы һәм тормыш» дигән рубрика урынына «Язучы һәм бишьеллык» рубрикасы активлашты. Шул ук елны «Әдәбият-сәнгать» сәхифәсенең 10 февраль саны «Илһамыбыз — бишьеллыкка» дигән рубрика астында чыкты.

Язучы, журналист — җәмгыятебезнең иң актив профессия кешесе. Шулай булгач, үзеннән-үзе аңлашылганча, ул тормышыбызның, яшәешебезнең төрле яклары белән кызыксына, уйлана, фикер йөртә, борчыла. Партия, ил, халык өчен файдалы булган мәсьәләләр күтәрә. Бу уңайдан Г. Бәшировның «Социалистик Татарстан»да басылган «Исраф» исемле төпле, нигезле, ышандырырлык итеп язылган һәм укучыларны тирәнтен дулкынландырган публицистик мәкаләсен искә төшерәсе килә. Автор анда икмәк һәм экономия мәсьәләсен күтәргән иде. Мәкалә киң катлау укучыларда кызыксыну уятты. Газетага бик күп хатлар килде. Шулар нигезендә автор икенче мәкаләсен язып чыкты. А. Шамовның Татарстан табигате, аның кабатланмас урыннары, аларны яңадан торгызу һәм саклау турында борчылып язылган «Аккошлар, кире кайтыгыз» мәкаләсен укучыларыбыз бүген дә хәтерлиләрдер. Әлбәттә, мондый публицистик чыгышлар республика җәмәгатьчелегендә фикер кузгата һәм аның шифасы да булмый калмый.

Газетабызда актив катнашучылардан — шагыйрь С. Хәким һәм прозаик Ф. Хәсни. Аларның чыгышлары укучыларыбыз тарафыннан көтеп алына. С. Хәкимнең «Кое янында сөйләшү» исемле язмасы бүгенге авыл, аның проблемалары хакында. Ул Арча районында гына түгел, республикабызның башка районнарында да бүгенге авыл турында мәсьәләне уртага салып сөйләшүләргә сәбәпче булды. Бу исә язучы һәм газета редакциясе максатка иреште дигән сүз.

Шунысы куанычлы: газетада басылган язучы мәкаләләрендә әхлак проблемаларына тыгыз бәйле экономик һәм социаль бурычларның күп төрлелеге белән бишьеллыкның кешеләр психологиясен үзгәртүе, аларны яңача уйларга һәм хис итәргә, вакыйгаларны партияле позициядән торып бәяләргә омтылу күзаллана.

Публицистика жанрларында актив эшләп килгән өлкән әдипләр сафына соңгы елларда сәләтле яшь язучылар, публицистлар И. Низамов, Р. Вәлиев, Х. Хәйруллин, Җ. Рәхимов һәм башкалар өстәлде. Алар һаман үзгәреп торган тормыш вакыйгаларыннан иң әһәмиятлеләрен сайлап алырга, аларны фәлсәфи һәм художестволы итеп фикерләргә сәләтлеләр. Алар совет чынбарлыгын расларга, укучыда яңа фикер уятырга тырышалар, хезмәт кешесен данлыйлар.

Тик шунысы бар: кайбер урта һәм яшь буын язучылар сугышчан публицистика жанрларында әллә ни активлык күрсәтә алмыйлар. Мондый пассивлык аларның иҗат мәйданнарын чикли, бигрәк тә тормыш белән элемтәләрен йомшарта, ә кайчакта аларның бүгенге көннең иң әһәмиятле проблемаларын сиземли алу сәләтен киметә.

Икенчедән, газетага тәкъдим ителә торган язмаларның сыйфатын нык яхшыртасы бар. Ник дисәң, байтак язмаларда дыңгычлап тутырылган сан һәм мисаллар арасыннан бүгенге геройның үзен күрә алмый калабыз. Газета укучылар очеркларда, әдәби әсәрләрдә бу кешеләрнең рухи яктан ничек үсүләрен, әхлак җәһәтеннән нинди дәрәҗәгә күтәрелүләрен, хезмәт процессында иҗтимагый аңнары үсешен, коммунистик җәмгыять төзүчеләргә хас сыйфатларның ничек туууын, формалашуын күрергә телиләр. Иҗат работнигы үзе һәр вакыт актив булганда, иҗади эзләнүләр белән яшәгәндә, тормыш белән даими элемтәдә торганда, республикабыз алдындагы бурычларны дөрес аңлаганда гына ышандырырлык һәм тәэсирле итеп яза ала.

Әлбәттә, язучының активлыгы өстенә газета-журнал редакцияләренең оештыру эше дә өстәлергә тиеш. Шул чагында иҗат тагын да нәтиҗәлерәк, максатка юнәлгәнрәк була. «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе партиябезнең XXV съездын каршылау көннәрендә «Язучы һәм заман герое» исемле рубрика ачып җибәрде. Бу рубрика астында бишьеллык батырлары турында язучыларыбызның очерклары һәм башка публицистик мәкаләләр биреп барыла. Язучылардан М. Садри, Б. Камалов, Ф. Шәфигуллин, беренчеләрдән булып, редакциянең үтенече буенча, командировкада булып кайттылар, һәм язмалары газетада басылып та чыкты. Иҗат работниклары белән мондый элемтә киләчәктә тагын да үстерелер дип ышанырга кирәк. Бусы — бер. Икенчедән, язучыларны газетага тарту буенча әдәби битләрнең роле мәсьәләсе. Мондый сәхифәләр инде 1956 елдан бирле чыгып килә. Хәзер аның гомуми саны 700 гә якынлашып бара. «Әдәбият-сәнгать» сәхифәләре укучыларыбыз арасында популярлык казанды.

Укучыларыбыз күреп баралар: соңгы елларда «Әдәбият-сәнгать» сәхифәләренең һәркайсында язучының, тәнкыйтьченең яки сәнгать эшлеклесенең культура тормышыбыздагы иң әһәмиятле мәсьәләләренә багышланган мәкаләсе төп урынны алып тора. Һәр сәхифә өчен бу — беренче таләп. Мондый мәкаләләрне сәхифәнең үзәге дияргә мөмкин. Ул — аны җитди, саллы, кызыклы итүче материал. Димәк, һәр сәхифәдә — язучы публицистикасы дигән сүз. Редакцияне бигрәк тә коммунист образын, хезмәт кешесен уртага куеп язылган, патриотик темага, кыскасы, гражданлык хисләре калку чагылган әсәрләр кызыксындыра. Сәхифәләр өчен проза һәм поэзия, сәнгать әсәрләрен сайлаганда без әнә шул таләпләрдән чыгып эш итәбез. «Илһамыбыз — КамАЗ төзелешенә», «Сүзебез сезгә, игенчеләр», «Язучы һәм тормыш», «Тормыш һәм иҗат работнигы» кебек рубрикалар чор таләбе җирлегендә туган рубрикалар.

Өченчедән, «Түгәрәк өстәл янында сөйләшү»ләр матур бер гадәткә әйләнде. Актуаль әдәби мәсьәләләр турында иҗат интеллигенциясен, киң җәмәгатьчелекнең фикерен тыңлау максаты белән иҗади дискуссияләр оештыруны, «түгәрәк өстәл янын-

да сөйләшүләр» үткәрүне без үтемле чара дип исәплибез. «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе татар драматургиясе һәм театры, әдәбиятта проза жанры, татар поэзиясендә Тукай һәм Җәлил традицияләре буенча иҗади дискуссияләр һәм киңәшмәләр үткәрде. Редакциядә Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» романы буенча язучылар, тәнкыйтьчеләр, тел галимнәре, археологлар, фольклорчылар катнашында зур сөйләшү булды.

«Түгәрәк өстәл янында сөйләшүләр» КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы мөһим карарыннан соң тагын да җанлана төште. Шундый сөйләшүләрнең беренчесе, мәгълүм карар яктылыгында, республикабыз әдәбияты һәм сәнгате, аның эшлекләләре алдында торган бурычларны тикшерүгә багышланды. Карар чыгуның икенче елында булган очрашуда алдагы елгы сөйләшүдә кузгатылган проблемаларның ничек тормышка ашырылуы мәсьәләсе каралды. Һәр икесендә дә язучылар, әдәбият һәм сәнгать белгечләре, тәнкыйтьчеләр, галимнәр катнашты. Өченче сөйләшү КПСС Үзәк Комитетының бу мөһим карары чыгуга өч ел тулганда үткәрелде. Шул вакыт эчендә республикабыз газета-журналлары редакцияләре карарда күрсәтелгән чараларны үтәүдә нәрсәләр эшләргә өлгерделәр, нәрсәләргә игътибар җитеп бетмәде — редакция хезмәткәрләре һәм язучыларыбыз катнашында узган әңгәмә шушы сорауларга җавап бирде. Барлык сөйләшүләрнең нәтиҗәләре газетада махсус сәхифә булып дөнья күрде.

Дүртенчедән, редакциядә диалог үткәрү матур бер традициягә кереп бара. «Бөек Ватан сугышы һәм татар әдәбияты», «Фән-техника революциясе һәм татар әдәбияты» дигән темаларга уздырылган диалоглар газета укучыларда һәм әдәби җәмәгатьчелектә мәгълүм кызыксыну уятты.

Мондый сөйләшүләрнең, әңгәмәләрнең кыйммәте шунда: алар тикшерелә торган мәсьәләләрне күмәкләп, дөрес, объектив хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Публицистика өлкәсендә туктаусыз эзләнү, яңа адымнар куллану игътибарга лаек. Публицистика проблемасы бүген аеруча зур әһәмияткә ия. Сүз бу өлкәнең дәрәҗәсен күтәрү, аның теоретик багажы, үткенлеге, инандыру көче, публицистның әдәби осталыгы турында бара. Укучыбыз язучылардан, журналистлардан истә калырлык, телдән төшмәслек очерклар, мәкаләләр, публицистик чыгышлар көтә. Шул максатны тормышка ашыруда газета-журналларда чыккан очерклар, публицистик мәкаләләр, китаплар турында сөйләшү өчен Язучылар һәм Журналистлар союзларының берләштерелгән җыелышларын, утырышларын үткәрү файдалы булыр иде.

*
* *

Без унынчы бишьеллыкка аяк бастык. Ул сыйфат бишьеллыгы буларак тарихта калыр. Хәзер бар нәрсәгә сыйфат күзлеге аша карала. Катлаулы, җаваплы, бөтен көчне туплауны таләп итә торган бурыч.

«Кызыл Татарстан» газетасында 1930 елның декабрендә басылган «Тун трагедиясе» дигән шигырендә (ул Казандагы мех фабрикаларына багышлап язылган) Һади Такташ сыйфат өчен борчылып болай дип язган иде:

**Их, егетләр!**
**Илдә сыйфат өчен**
**Көрәш бара**
**[Оят язарга],**
**Ә сез, эшегезне рәтләп эшләмичә,**
**Брак чыгаргансыз базарга!..**

Безгә, язучы, журналист, публицистларга, партиябезнең сыйфат өчен көрәш программасын үтәүдә алгы сафта барырга, совет матбугатында, әдәбиятта бу өлкәдә булган бай традицияләрне яңа шартларда, унынчы бишьеллык елларында киң колач белән дәвам иттерергә кирәк. Сыйфат бишьеллыгы бездән, язучылардан, журналистлардан, инициатива, тырышлык, иҗади эзләнү сорый. Инде хәзер беребезнең дә матбугатта тема яңалыгын, вакыт кысанлыгын, оперативлык кирәклеген сылтау итеп, бүген бар, иртәгә онытыла торган әсәрләр белән чыгарга хакыбыз юк. Бу — публицистның үз-үзенә куйган таләбе генә түгел. Бу — художникка тормыш үзе, шул тормышны бизәүче хезмәт геройлары таләбе дә.

Очерк язган кеше героеның үсеше, характеры формалашу, эчке халәте диалектикасын күрсәтергә омтылуны аның биографиясенә экскурс ясау белән алыштырмасын иде. Кайбер чакта редакциягә аптырап та калгалыйсың: әсәрне укыйсың, укыйсың, геройның энергиясенә сокланасың. Бактың исә, автор әллә кайчан булган вакыйгаларны сөйли икән. Ә аның бүгенге көндә яшәеше, көрәшүе урынына еш кына колхоз-совхоз, предприятие коллективларының уңышларын саннар чагыштырмасы белән күрсәтү күп кулланыла.

В. И. Ленин матбугатның, публицистиканың төп бурычы «**массаларны** тормышның барлык өлкәләреннән алынган җанлы, конкрет мисаллар һәм үрнәкләр нигезендә **тәрбияләү**»[1] дип билгеләгән иде.

Максат көн проблемасын, характер конфликтын тасвирлауга юнәлмәсә, авторның публицистик чыгышы көчсез, кечкенә, кешеләрне алга пышылдап чакырган сыманрак булыр. Эндәшкәч шундый итеп эндәшергә кирәк — кайтаваз булып халык колагына, халык күңеленә барып ирешсен. Публицистикада иң мөһиме нәрсә диган сорау куелса, җавапны ялкынлы сүзнең тормышта яңгыраган кайтавазы көчлелеге хакында сөйләүдән башларга кирәк; кешеләрнең бәхете һәм иминлеге, аларның рухи дөньясы проблемасын хәл итүдә ул ничек катнаша? Сүз, шулай итеп, публицистиканың иҗтимагый резонанс, фикерләр уята алу көче хакында бара. Газета һәм журнал өчен бишьеллыкның алгы постында торып язган язучылар, журналистлар укучының иҗтимагый аңын тәрбияләү, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне камилләштерү, заман идеясен, замандашларның матурлыгын һәм бөеклеген калку чагылдыру хакында уйланырга тиешләр. Чөнки публицистның җәмәгать эшлеклесе буларак характерлаган иң беренче нәүбәттәге сыйфатлары аның армас-талмас җәмәгать эше, гражданлык темпераменты белән билгеләнә бит.

Язучы Г. Марков СССР Язучылары союзының IV пленумында публицистиканы сәгатьнең секунд теле белән тиңләгән иде. Ул болай диде: «Публицистика — вакыт үлчәве. Әгәр әдәбиятны сәгать механизмы белән чагыштырсак, роман, пьеса, поэма кебек жанрларны аның акрын әйләнеп торган сәгать стрелкасына, ә шигырь, хикәя жанрларын минутларны күрсәтүче стрелкага, публицистиканы исә секунд стрелкасына тиңлисе килә. Секундлардан минутлар, сәгатьләр җыелган кебек, публицистика да әдәбиятның зур жанрлары тууга җирлек әзерли»[2].

Безнең язучы һәм публицистларга әнә шул секунд теленең мөһимлеген, үзенчәлеген, кабатланмаслыгын тою, күрү, күрсәтә белү җитенкерәми. Дөрестән дә, язучылар, публицистлар, тормыштагы мөһим мизгелләрне читләтеп, вакыйганың озынын тасвирлый башлыйлар һәм сүлпәнлектән, күп сүзлелектән, вакыйгалар озынлыгыннан котыла алмыйлар. Ләкин бит гомер итү — көн үткәрү түгел, гомер итү — хәтердә калырдай мизгелләр кичерү белән кадерле әле ул. Безгә дә тормышның, кеше характерының әнә шундый мизгелләрен сайлап алып күрсәтергә кирәк.

Публицистика сыйфаты турында сүз алып барганда күз алдында кояшта ялтыраган алмазны тотарга кирәк. Ул да бит, тиешенчә тотмасаң, нурын җуя. Язучыларыбызның, журналистларыбызның иҗат уңышларын искә алганда моны күздән төшереп калдырырга һич ярамый. Публицистика шушындый таләпләр югарылыгыннан әдәби ел йомгакларында гына күзәтелеп калмасын иде, аның хакында көндәлек матбугатта да агымдагы тәнкыйть биреп бару бик әһәмиятле. Әлегә публицистика проблемалары хакында оператив мәкаләләр газеталарда һәм журналларда әллә нидә бер генә күренгәли. Публицистик китаплар гомумән аз рецензияләнә.

Безнең публицистика арсеналы теге яки бу факт һәм вакыйгаларны механик чагылдыруга кайтып калган материаллардан арынып, факт һәм вакыйгаларның тормышчан диалектик каршылыгына үтеп кергән, ул каршылыкны үсештә тикшергән, тормышта булырга тиеш һәр нәрсәне ачык күргән очерк-язмалар, мәкаләләр исәбенә баесын иде. Андыйларны булдыру — язучылар, журналистлар алдында торган мактаулы бурыч. Аларның сыйфат бишьеллыгы таләпләреннән чыгып язылган чын мәгънәсендә яхшы сыйфатлы үрнәкләрен укыйсы, шулар белән сокланасы, дулкынланасы иде.

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. 28 том. Дүртенче басмадан тәрҗемә. 86 бит.
[2] На переднем крае жизни. Москва, 1973 ел, 12—13 битләр.

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ 90 ЕЛЛЫГЫНА

Танылган әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Ибраһим Нуруллин Мәскәүнең «Молодая гвардия» нәшрияты чыгара торган «Атаклы кешеләр тормышы» сериясе өчен бөек шагыйребез Г. Тукайның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган фәнни-популяр әсәр тәмамлады. Бу саннан шул яңа әсәрдән өзекләр баса башлыйбыз.

## Ибраһим Нуруллин

# ТУКАЙ



Атаклы 1905 ел башкаланың Сарай мәйданында яңгыраган мылтык залплары белән башланды. Бу залплар, йөзләгән эшчеләрне үтерү белән бергә, бик күпләр күңелендә патшага ышанычны да үтерделәр: хокукны сорап алмыйлар, яулап алырга кирәк икән! Илдә революция башланды.

Мылтык тавышларының яңгыравыгы Җаекка да килеп җитә, эшчеләрнең ил күгенә төшкән кан шәүләсе җаеклыларны да сискәндерә. Моңарчы яшерен түгәрәкләр рәвешендә яшәп яткан социал-демократлар һәм эсерлар, җанланып китеп, эшкә керешәләр: листовка-прокламацияләр басып тараталар, эшчеләрне эш ташларга чакыра башлыйлар. Менә яз җитә, һәм Уральск тарихында беренче мәртәбә маевка үткәрелә.

Эшчеләр, укучы яшьләр һәм шәһәрнең алдынгы интеллигенциясе билгеләнгән вакытка Зур Михайловская урамындагы кызлар гимназиясе янына җыелалар. Аннары халык, колонна булып, җаеклыларның ял итү, күңел ачу урыны — Ханская рощага таба юнәлә. Шәһәрне чыгуга, колонна өстендә ал байрак пәйда була һәм «Яшәсен Беренче май — хезмәт бәйрәме!» — дигән сүзләр кояшта ялтырап китә. Полиция килеп җитеп, демонстрацияне таратса да, халыкның бер өлеше, Урал елгасының аръягына чыгып, маевка үткәрә.

Габдулла Уральскидагы беренче демонстрация һәм беренче маевканың шаһиты булганмы? Анык мәгълүматлар тапмасак та, бу сорауга без уңай җавап бирә алабыз. Кечкенә шәһәрдәге һәр шылт иткәнгә дә колак торгыза торган үткенрәк шәкертләр, шул исәптән Габдулла мондый зур вакыйганы игътибарсыз калдыра ала алырмы соң! Җитмәсә, демонстрациянең башлану урыны — кызлар гимназиясе —

«Мотыйгыя» мәдрәсәсеннән артык ерак түгел, Галиәсгар Госманов өеннән бер кварталда, Габдулла укыган рус классы бинасының исә каршында гына. Егетнең демонстрацияне, ким дигәндә, полиция таратканчыга кадәр озатып баруы бик ихтимал.

Шунысы бәхәссез: моңарчы һәм моннан соң булган вакыйгалар, утка май сипкәндәй, ирек сөючән, бунтарь Габдуллага яңа дәрт, яңа көч, яңа куаныч китерәләр. Революцияне ул бәйрәм итеп, үз революциясе итеп каршы ала. Бераз соңрак, 17 октябрь манифесты игълан ителгәч, Җаекта күптән көтелгән татарча газета чыга башлагач, Габдулла революцияне шигырь белән тәбрик итәчәк:

Кайда китте цензурлык,
Коллык, тарлык, ким-хурлык?
Артка карасак борылып,
Ерак анлар калдыя.

Хәзергә әле аның «революционерлыгы», телдән әйткән кыю сүзләреннән тыш, күбрәк өс-башында, үзен тотышында, кылган гамәлләрендә күренә. Менә ул, кәләпүшне генә түгел, бәлки бүрек һәм фәсне атып бәрә дә, башына кепка киеп алып, һичкемнән курыкмыйча, Җаек урамында йөри башлый. Болай да була икән: берәр иптәше белән урам буйлап бара. Башында әлеге кепка, кулда кәкре башлы таяк, аякта читек-кәвеш булса да, балак тыштан чыгарылган. Берәр тәкъвә татарның каршыга килгәнен күрде исә, кесәсеннән папиросын чыгарып каба да шырпысын чыжлатып кабызып җибәрә. Иптәшенең тыярга тырышуына каршы «толчокчы ачудан буылсын әле» дип кенә куя икән.

Замандашлары тагын Габдулланың еш кына рус картузы, озын киндер күлмәк, киндер чалбар һәм аягына чабата киеп чыкканлыгы һәм хәтта шул кыяфәттә бакчаларга барганлыгы турында язалар. Биредә дә шуклык һәм, руслар әйтмешли, казлар котырту теләге юк түгел, әлбәттә. Әмма бусында Лев Толстой белән мавыгу, Толстойга охшарга тырышу күбрәк. Һәрхәлдә, ул даһи әдипнең ара-тирә ярлы крестьяннарга кул көче белән ярдәм иткәнен укып белгән кебек, озын киндер күлмәк киеп, ялан аяк хәлдә сука тартып барган Толстойның киң таралган рәсеме белән дә, һичшиксез, таныш булган.

Габдулладагы бунтарьлыкның уңай «программа»сы моңарчы да бар иде. Әмма кешенең хөрлеген чикли, сәләтенең ачылып китүенә киртә булып тора торган кара көчләрне ул күбрәк татар дөньясының үз эченнән күрә килде. Менә алар: Рәкыйп мулла һәм Гайнетдин кари кебек сөрсегән карашлы муллалар, Фәтхетдин һәм Нури кебек надан хәлфәләр, Мортаза Гобәйдуллин кебек үз байлыгына масайган купецлар, Хәсәнҗан Хөсәенов, Фатих Шәрипов кебек вак сәүдәгәрләр һәм мещаннар...

Революция башлану белән Габдулла татарлар тормышындагы күренешләрне бөтен Россиядәге хәл-әхвәл белән бәйләп карый, әшәкелекләрнең башын иҗтимагый-политик стройдан, патша хөкүмәтенең милли-колониаль политикасыннан, бюрократ чиновниклар «эшчәнлегеннән» эзли башлый. Бернәрсә дә кинәт кенә тумаган кебек, Габдулланың карашларындагы мондый сикереш, әлбәттә, электән әзерләнеп килгән. Бу уңай белән беркадәр чигенеш ясап китми булмас.

Үзләренең мөстәкыйльлекләрен сакларга омтылган татар мәдрәсәләре күп еллар власть кешеләренә борчу салып килгәннәр. Нәрсә укыталар анда? Шәкертләрне нинди рухта тәрбиялиләр? Панисламизм һәм сепаратизм кебек яман фикерләр таратып ятмыйлармы? Яшьләрне русларга каршы аякландырмыйлармы?

Мәдрәсәләргә мөнәсәбәттә мәгариф органнарында ике төркем, ике фикер көрәшә. Берәүләр, һич кичекмәстән, бу уку йортларын министерство контроле астына алырга, ана телендә укытуны туктатырга, министрлык тарафыннан расланган программа нигезендә дәрес бирүне кертергә кирәк, диләр. Икенчеләр исә, бу чараның хәвефле булачагын искәртеп, мәдрәсәләргә карата сыгылмалы политика үткәрергә чакыралар. Ике як та бер нәрсәдә берләшә: татарларның уку йортларын күздән ычкындырмаска. Беренче радикаль чара тормышка ашырылмаса да, мәдрәсәләр өстеннән күзәтчелек итү һаман көчәйтелә бара. Учебный округ попечительләреннән башлап городовойларга кадәр, бик күп рәсми кешеләр шушы эшкә тартылалар. «Мотыйгыя» мәдрәсәсенә инспекторларның килеп йөрүе турында безнең кулыбызда мәгълүмат юк (мондый күзәтү дә, әлбәттә, булган), полицейскийның исә атна саен диярлек мәдрәсәгә килеп йөрүе истәлекләрдән билгеле.

Озын мыеклы юан околодочный, үзен бик эре тотып, шәкертләр янына килеп керү белән, беренче булып Габдулла аңа каршы бара икән. Йөзенә татлы елмаю чыгарып һәм башын җүләргә салып, «Җантимер агай, Җантимер агай», ди-ди, тыңкыш тавыш белән сөйләшә башлый. Татарча, русчаны буташтыра, татар сүзләренең ахырына «ский» кушымчасы ялгап җибәрә, арага полицияне кимсетә торган татарча сүзләрне дә иплән кенә кыстырып куя. Шәкертләр тыела алмыйча көләләр икән.

Шунысы кызыклы: Тукайның соңрак язылган фельетоннарында без әлеге «Җантимер» сүзен еш кына очратабыз. Бу сүзне ул полицейский һәм жандармнарга карата куллана.

Габдулланың тагын рус-япон сугышы белән кызыксынганлыгы, сугыш хәрәкәтләрен күзәтеп барганы билгеле. Габдулланы Кырлайдан барып алып, Уральскига озаткан Бәдри абзыйның Камалетдин исемле улы күп еллар буе шагыйрь белән очрашкалап торган. Әнә шул Камалетдин аганың архивта саклана торган истәлеген укыганда, без бер кызыклы фактка тап булабыз. Очрашуларның берсендә («Рус-япон сугышы вакыты булса кирәк», диелә кульязмада) булачак шагыйрь аңа түбәндәгеләрне сөйләгән. Габдулла «русны мактап, японнарның җиңелгәнен әйтеп» русча шигырь язган икән дә, җаен туры китереп, «Уралец» газетасы редакторына тапшырган. «Моны кем язды?» дигән сорауга: «Бер шәкерт язды» дип җавап биргән. Редактор авторның үзе килергә тиешлеген әйткәч, Габдулла күпмедер вакыттан соң редакциягә барып чыккан. Аны кертми маташканнар: беренчедән, нинди дер бер малай, икенчедән, өс-башы шәптән түгел. Мәсьәлә ачыклангач, Габдулланы редактор янына кертеп җибәрәләр. Сөйләшү-аңлашу була. Ахырда редактор Габдуллага болай дигән: «Мондый шигырьләрне син һәр вакыт язып тор. Без сиңа һәр юлына биш тиен түләрбез».

Күп еллар үткәннән соң язылган истәлекләргә сак килү тиеш булса да, Камалетдин аганың бу фактны уйлап чыгару ихтималы юк дип, кистереп әйтергә мөмкин. Дөрес, без хәзергә истәлектә телгә алынган шигырьнең басылган яки басылмаган булуын да, яшь шагыйрьнең «Уралец»ка кабаттан шигырь бирүен яки бирмәвен дә белмибез. Чөнки бер генә китапханәдә дә газетаның тулы төпләмә юк. Әмма шунысы ачык: 1904 елда ук Габдулла чагыштырмача прогрессив юнәлешле «Уралец» газетасын укып барган һәм гомумән илдәге политик хәлләр белән кызыксынган.

Яшь шагыйрьнең рус телендә язган шигыре чынлап та патриотик рухта булганмы, моны хәзергә берничек тә раслап булмый. Әмма бу темага мөрәҗәгать итүе һәрьяклап игътибарга лаеклы.

Татарларның милләт булып формалашуы белән бәйле рәвештә, Япония бер заман укымышлы катлауларның игътибарын җәлеп итә. Чынлап та бит, кайчандыр Азия континентының бик күп мәмләкәтләреннән бер ягы белән дә аерылып тормаган, чагыштырмача кечкенә генә Япония XIX гасырның икенче яртысыннан башлап гаять кызу темп белән үсеп китә. «Япония, — дип яза академик Н. И. Конрад, — 1868 елгы революциядән соң Көнчыгышта мөстәкыйль капиталистик үсеш юлына кергән һәм бу юнәлештә гаять югары күтәрелгән бердәнбер ил. XX йөз башында инде ул империалистик мәмләкәтләрнең бик үк тату булмаган «гаилә»сенә кушылып китәр хәлгә ирешә. Беренче бөтен дөнья сугышыннан соң исә Япония политик яктан боларның тулы хокуклы итеп саналырлык партнерына әверелде».

Татар милләтенең экономика һәм культура ягыннан артта сөйрәлүенә ачынган XIX гасыр мәгърифәтчеләре кинәт алгы сафка сикергән Япониягә күз тегәләр дә сорау куялар: бу могҗизаның сәбәбе нәрсә? Һәм җавап та бирәләр: тырышлык һәм мәгърифәт, фән һәм техника. Мәгърифәтчеләрнең бу җаваплары яшь Тукайның да колагына керми калмаган, билгеле. Үзе әйтмешли, ярты сабый вакытында ук Галиәсгар Камал әсәрләренә мәхәббәт баглаган Габдулла 1900 елда басылып чыккан «Өч бәдбәхет» пьесасын, мәсәлән, кулга төшерә дә уңай персонаж авызыннан әйттерелгән түбәндәге сүзләрне укый: «Әле моннан ун ел электәрәк кенә японның исеме дә беленгәне юк иде. Ә хәзердә японнар мәгърифәт тәхсил кыйлып (гыйлем җыеп) [1], бөтен Европа гыйндендә (каршында) могтәбәр булдылар, һәрбер җирдә сәүдәгәрләре йөреп тора. Никадәр электриклар, никадәр телеграфлар ясадылар. Ул газеталарының очы-кырые юк. Безнең мөселманнар да мәгърифәт тәхсил кыйлырга тырышырга кирәк».

Әнә шул Япония 1904 елда тота да дәү Россиягә каршы сугыш ача. Тешләренең ныклыгын, тырнакларының үткенлеген күрсәтеп өлгергән булуына карамастан, бу эш күпләргә бүренең филгә ташлануы кебек кенә күренә. Рәсми патриотик шау-шу да әнә шул настроениеләрнең куәтләнүенә китергән. Яшь Тукай да шул шаукымга бирелеп, рус телендә патриотик шигырь язып ташлаган булса, бер дә гаҗәп түгел.

Ләкин бу ни хәл? Безнең шанлы гаскәребез бер дә уңышка ирешә алмый. Ул гына да түгел, Порт-Артурны калдырып чыгалар, бөтен бер армияне югалталар. Әнә бит мәгърифәт нишләтә! Дөрес, руста да мәгърифәт юк түгел. Күрәсең, без ул мәгърифәттән файдалана белмибез. Филнең кеп-кечкенә бер бүредән җиңелеп солых соравына кем гаепле? Күп сугышларда батырлык күрсәткән гади халыкны гаепли алмыйсың. Димәк, булдыксыз офицерлар, карак интендантлар, сатлык генераллар... Ул гына да түгел, гаеп министрларга, хәтта патшаның үзенә үк барып тоташмый микән әле? Күрәсең, мәмләкәтнең нигезендә үк ниндидер зур кимчелек бар.

Яшь Тукайның рус-япон сугышы тәэсирендә туган фикерләре нәкъ шул юнәлештә аккандырмы, әйтүе кыен. Әмма бу сугыш һәм Россиянең җиңелүе аны уйландырмый калмаган.

1905 елның 11 декабрендә басылып чыккан «Хөррият хакында» исемле шигырендә мондый строфа бар:

Тигез булды законда
Татар, урыс, япон да;

Ярар, «япон» сүзе бирелә рифма өчен алынган дип уйлыйк. Менә «Соры кортларга» (1906) исемле шигырe:

Һөҗүм кирәк ишаннарга — соры корт, гөмбә башларга;
Бетер, сындыр, кырып ташла мәгаль урра вә билбанзай!

[1] Аңлашылмаган сүзләрнең мәгънәләре җәяләр эчендә бирелде (автор).

Бу очракта да рифма таләбе беркадәр роль уйнасын ди. Тик шунысы бар: Япония белән кызыксынмаса, сугыш хәлләрен күзәтеп бармаган булса, белмим, «банзай» сүзе шагыйрьнең күңеленә һәм теленә килер иде микән?

Габдулланың рус-япон сугышы белән бәйле рәвештә Россиядәге политик хәлләр турында уйлана башлаганлыгын раслый торган аеруча кыйммәтле документ — «Мөхәрәбә вә государственная дума» исемле мәкалә. Ул «Война и дума» дигән брошюраның тәрҗемәсе булып, яртысы «Әлгасрел-җәдит» журналының 1906 елгы апрель һәм май саннарында басылып чыккан. Брошюрада һәм тәрҗемәсенең дөнья күргән кадәресендә сугышның асылы, аны китереп чыгарган сәбәпләр, сугышның Россия иҗтимагый-политик строеның черек-леген чагылдыруы большевистик позициядән торып аңлатылган.

Дөрес, Габдулланың «Война и дума» брошюрасына мөрәҗәгать итүе 1905 елның ахырына һәм 1906 елның башларына туры килә. Без исә аның 1905 елгы революцияне нинди мәгънәви багаж белән каршылавы турында сүз башлаган идек. Ләкин бит 1905—06 елларда шактый күп санда революцион эчтәлекле брошюралар чыгарылган. Шуларның шактый өлеше, Уральскига да килеп җитеп, һичшиксез, Тукай күзенә дә чалынган. Андыйлар арасыннан аның нәкъ менә рус-япон сугышына бәйле булганын сайлап алуын бу сугыш турында уйлануларының дәвамы итеп карарга кирәк.



1912 елда, ягъни яңа революцион күтәрелеш чорында, Тукай үзенең бер шигырен түбәндәге ике юллык белән башлаячак.

Без «бишенче» елны бер көнне уяндык таң белән,
Эшкә дәгъвәт итте безне кемдер изге нам белән.

Әйе, Тукайны 1905 елгы революция яшеннәренең гөрелтесе уятты. Менә ул беравык ис-акылын җыеп тора да, аңышып алып, эшкә җиң сызгана башлый. Яратып, баш-аягы белән чумып, алны-ялны белмичә эшли торган көннәре инде Габдулланың якынлашып килә. Сүз биредә «Фикер», «Әлгасрел-җәдит» һәм «Уклар» исемле газета-журналлардагы эшчәнлеге турында бара.

Кульязма стена газетасы һәм журнал чыгарганда яисә К. Мотыйгый язган әсәрләрне, мең бәла белән китап рәвешенә китереп, сату-тарату белән шөгыльләнгәндә, алар, ягъни Камил белән Габдулла, һәркөнне үк булмаса да, атнага бер яки ике мәртәбә чыга торган газета, айлык журнал турында күпме хыялландылар, авыз суын корытып, күпме сөйләделәр! К. Мотыйгый исә, характерына хас булганча, 1904 елның икенче яртысында рөхсәт алуга өмет әлегә юк дәрәҗәсендә чагында ук, журнал чыгаруга чын-чыннан хәзерлек эше башлый. Типография, татарча хәрефләр булдыру, берничә шәкертне, наборщиклык һөнәренә өйрәтү өчен, берәр якка җибәрү хәстәренә керешә.

Болар белән генә чикләнмичә, К. Мотыйгый шул вакытның күренекле шәхесләренә журналда язышырга үтенеп хатлар белән дә мөрәҗәгать иткән. Кульязма «Әлгасрел-җәдит»нең 8 декабрь санындагы мәкаләсендә ул андый кешеләрнең исемнәрен тезеп чыга да аларның журналга язарга вәгъдә биргәнлекләрен әйтә. Исемлектә «мөрәттип (хәреф җыючы) Габдулла Тукаев» та бар. Ни өчен мөрәттип? Бу сорауга без шул ук мәкаләдән җавап табабыз. «Габдулла Тукаев исә Мөхәммәт-Фатих әфәнде (Кәрими — И. Н.) матбагасына кидеп, мөрәттиплек үгрәнеп кәләчәге тугрысында мөгаһәдә (килешү) идеш-

те. Бер иптәше илә идарә хәрәҗәте (расходы, чыгымы) илә Оренбургта бер-ике ай кадәр дорып, матбага гыйлеме үгрәнеп кәләчәктер».

План Наполеонныкыннан бер дә ким түгел... Тик бер кечкенә генә нәрсә җитми: хөкүмәтнең рөхсәте. Камил җирле хөкүмәт учреждениеләренә йөреп карады — эш чыкмады. Петербургка прошение җибәрде — тискәре җавап килде.

1905 ел башларында тагын бер прошение китә. Шактый көттереп җавап килә. Рөхсәт юк булмаса да, бусы инде шактый өметле: газета яисә журнал чыгару өчен тиешле сума һәм материаль база (ягъни типография һ. б.) кирәк, әгәр шулар булса, бу мәсьәләгә яңадан кайтырга мөмкин, дигәннәр. К. Мотыйгый анда сугыла, монда сугыла, киңәш-табыш итә башлый. Көннәрдән-бер көнне «Уралец» газетасының редакторы (бу вакыт Л. Н. Ядринцев булса кирәк) аңа мондый киңәш биргән: нигә сезгә мәшәкать чигеп һәм расход тотып яңа матбага торгызырга? Сатып алыгыз «Уралец»ны матбагасы-ние белән. Бу киңәш Мотыйгыйның күңеленә хуш килгән. Менә безнең Камил, муеннан бурычка чумып, кардәш-ыруын, берме, икеме «меценат»ны янчыкларын чишәргә күндереп һәм, кайбер риваятьләргә караганда, хатынының приданын сатып, тиешле суманы туплый да типография хуҗасы һәм «Уралец»ның нашире булып ала. Хөкүмәт органнарына инде хәзер татарча газета-журнал чыгаруга рөхсәт бирүдән бүтән чара калмый.

«1905 елда (җәй көне булса кирәк — И. Н.), — дип яза Мотыйгый, — мин Уральскида матбага алып, татарча газеталар чыгарырга уйлагач, Габдулла әфәнде, үзенең үтенүе буенча, минем матбагама хәреф тезәргә (наборщиклыкка) керде. Матбагада иң әүвәл русча вә мөселманча хәрефләр тезәргә өйрәнде». «Үзенең үтенүе буенча» дигән сүзләрне моннан ярты ел гына элек Габдулланы «мөрәттип» дип атавы һәм типография эшләренә өйрәтер өчен Оренбургка җибәрергә ниятләнүе белән ничек яраштырырга? Бәлки хәзер Камилнең Габдуллага мөнәсәбәте үзгәргәндер һәм аның белән бергә эшләргә бик үк атлыгып тормыйдыр? Араларыннан кара мәче үткәләп китүне искә алып, шулай уйлар идек, әмма Тукай белән бергә «Мотыйгыя»дә укыган Ярулла Морадиның түбәндәге сүзләре бар: «Без (үзе һәм Габдулла — И. Н.) Камил әфәндене күргәч тә, сабырсызланып, «Әлгасрел-җәдит»не кайчан чыгарачагын сорый башладык. Камил әфәнде икемезгә дә һәйәәт тәхририясеннән (редколлегия) булмакымызны тәклиф итә һәм икемезгә дә «әдип әфәнделәр» дип эндәшә вә бездән яхшы үк нәрсәләр өмет иткәнлеген белдерә иде»[1].

Юк, К. Мотыйгый Габдулланы читкә тибәрергә теләмәгән. Ул, күрәсең, расход тотып читтә әзерләүгә караганда әзер наборщиклар чакыру дөресрәк булыр дигән фикергә килгән. Габдулланың талантын һәм каләм көчен күбрәк күргән саен егетне «дәрәҗәлерәк» эштә файдалану фикере ныгып барган.

Габдулла исә бүтәнчә уйлый. Камил, типография сатып алып, «Уралец»ның нашире булып алды. Габдуллага, шәкертлектән котылып, мөстәкыйль яшәргә җай чыгып тора түгелме? Нигә, мәсәлән, матбагага эшкә кермәскә? Дөрес, рус газетасында ул башкарырлык, бердәнбер эш (аңысы да беркадәр өйрәнгәннән соң) — хәреф җыю. Камил күзендә бу бик үк абруйлы эш саналмаса да, Габдуллага алай тоелмаган. Өстәвенә, матбугат эшенә, газетага якын буласың.

Әнә шул килеш көннәрдән-бер көнне Габдулла, хәреф җыючы итеп алуын сорап, К. Мотыйгыйга мөрәҗәгать итә. Яңа нашир ашыкмаска, бераз көтәргә киңәш биргән, бүтәнрәк эш тәкъдим итәчәген

[1] Я. Моради. Тукаев Уральскида. Әстерхан, 1913 ел.

әйткән булса кирәк. Әмма егетнең карары нык. Әгәр шулай икән, нигә Габдулланың үтенечен кире кагарга? Әйдә, үзе теләгәч керсен, өйрәнә торсын. Я. Муради моңа бер кызыклы деталь өсти: «Камил әфәнде Габдулла Тукаевны да матбагасына кабул иткән, шагыйремез мәрхүм Тукай ул вакытларда *вазифасыз* (ассызык минеке — И. Н.) гына рус малайлары арасында мөрәттиплеккә өйрәнергә бара икән». «Рус малайлары арасында» дигән сүзләренең эчтәлеген исә Александр Гладышев ачып бирә. 1904 елда ул, үсмерлектән яңа гына чыгып килгән чагында, «Уралец» типографиясенә хәреф җыярга өйрәнчек булып кергән. 1905 елда да әле Саша Гладышев — өйрәнчек. Әмма хәреф җыю һөнәрен яхшы үзләштергәнен искә алып булса кирәк, Габдулланы аңа беркетәләр. Алар арасындагы шәкертлек һәм остазлык мөнәсәбәте ике яклы була. Саша үзенең «шәкертенә» хәреф җыю серләрен өйрәтсә, Габдулла «остаз»ына әдәбият һәм поэзиядән күп кенә мәгълүмат биргән, политик мәсьәләләрдә дә Гладышевның үсешенә шактый булышлык иткән.

Яшь Тукай — бу чорда һаман әле мәдрәсә шәкерте. «Хөҗрә»дә яши, сайлабрак булса да, дәресләргә йөри. Әмма вакытының күбрәк өлешен типографиядә үткәрә. Эш хакы алмаса да, бүтән эшчеләр кебек үк, иртүк бара, төшкә кадәр баш күтәрми эшли, төшке чәйне эчкәч, тагын шунда йөгерә.

Габдулланы аеруча ашкындырып, күңелен нурландырып торган нәрсә, билгеле инде, татар телендә чыгачак газета һәм журнал була. Рөхсәт язуы килгәннән соң купкан шатлык дулкыннары инде ярларына керде. Хәзер яңа теләк өстенлек алды: шул газета һәм журналны тизрәк күрәсе, тотып карыйсы иде. Ә ул көннәр инде ерак түгел.

К. Мотыйгый Петербург, Казан, Оренбург калаларында була, татар хәрефләре һәм типография өчен кирәкле бүтән нәрсәләр юнәтү артыннан йөри, хәреф җыючылар белән сөйләшү алып бара.

Менә бер заман Казаннан хәрефләр кайта. Шуннан ук Сәйфи Насибуллин дигән наборщик һәм Гариф Кальтеев дигән печатник килеп төшәләр. Ул да булмый, 1905 елның истәлекле 27 ноябре җитә. Шушы көнне Камил белән Габдулла басу машинасыннан чыккан газетаның беренче санын кулларына алалар: «Фикер» дигән, «атнага бер чыга» дигән, «нашире һәм мөхәррире К. Мотыйгый-Төхфәтуллин» дигән. Куанычларын тел белән сөйләп, каләм белән язып аңлатырлык түгел.

Шул ук вакытларда «Әлгасрел-җәдит»не чыгаруга да кызу әзерлек бара. Хәер, бу журнал газетага кадәр үк үзенең тавышын биреп өлгерде.

Анысы болай була.

Рөхсәт язуы килгәнче үк, К. Мотыйгый танылган шәхесләргә хатлар яза башлаган. Ул, күрәсең, журналда язышырга вәгъдә бирүләрен генә түгел, бәлки берәр нәрсә язып җибәрүләрен дә үтенгән.

Хатларга җаваплар килә тора, материаллар туплана тора. Менә безнең Мотыйгый тота да шул материаллардан зур гына җыентык төзеп, «1906 нчы сәнә башында чыкмая башлаячак «Әлгасрел-җәдит» журналының мофассал (тулы) игъланы» дигән исем белән 1905 елның 15 сентябрендә Оренбургтагы Кәримов-Хөсәенев матбагасында 5000 данә итеп бастырып чыгара. Бу тиражның заманы өчен гадәттән тыш зур булганлыгын искә алсак, К. Мотыйгыйның мавыгучанлыгына, һәр эшне зурдан кубып эшләргә яратуына тагын бер кат ышанырбыз.

Камилнең формага зур әһәмият бирүен, һәрнәрсәнең шартын китерергә тырышуын белгәнгә, әлеге үтенеч хатын ул Габдуллага да тапшырган дип уйлыйсы килә. Кем белә, бәлки әле ул, еш очрашу-

ларына да, журнал турында күп сөйләшүләренә дә карамастан, хатны конвертлап, почта аша җибәргәндер.

Ничек булса да булган, әмма без К. Мотыйгыйның хат-мөрәҗәгатенә уңай җавап бирүчеләр арасында Г. Тукаев исемен дә күрәбез.

«Уральскида мәдрәсәи «Мотыйгыя»дән.

29 нчы август, 1905 нче сәнә.

Мөхтәрәм Мөхәммәт Камил әфәнде!

Чуктан бирү чикарылмасы мәэмүл (өмет ителгән) булуыннан «Әлгасрел-җәдит» журналының нашренә мәэзүн (рөхсәт алу) улдыныңызны ишедеп, фәүкылгадә (гадәттән тыш) мәсрүр (сөенү) вә мәмнүн (канәгать) улдык. Әгәр безем кебиләргә журналыңызның сәхифәләрендә урын бирелсә, бән бәкадәрельхаль, назмән вә нәсрән (тезмә һәм чәчмә рәвештә), журналыңызда язмакыми вәгъдә идарем вә шул вәгъдәми тәэкид (ныгыту) юлында, журналыңыз хакында ошбу әбъяте (бәетләр) гаҗизанәләреми тәхрир әйләдем. Журналыңызның бер күшәсендә (почмак) дәреш улынмасына өмит идарәем».

Бу сүзләрдән соң исемсез ике шигырь килә. Беренчесендә яшь шагыйрь югары, «купшы» стильдә милләтнең уянуына, яшьләрнең каләмгә ябышуына шатлык белдерә, мәгърифәткә дан җырлый, газета-журналларның файдасын аңлата, тырышлыкка, белемгә чакыра. «Чөнанча бездә Камилел-Мотыйгый...» дигән сүзләр белән башланган икенчесендә исә мәйданга киләчәк журналны күккә чөеп мактый: кандил бу ди, яктырткыч ди, күзге ди, кояш ди. Татар телендә беренче булып чыгачак бу журналның кадерен белергә, аңа язылырга, аны укырга чакыра. Болар — Габдулланың акка кара белән басылган беренче шигырьләре. «Игълан»ны әзерләү кухнясында кайнашуына карамастан, гәрәбә кебек тезелгән хәрефләрне, аслы-өсле урнашкан тип-тигез, туп-туры шигырь юлларын күрү Габдулланы дулкынландырмый калмаган, билгеле.

Менә 1905 ел бетеп, 1906 ел башлана. Башта атнасына бер тапкыр чыккан «Фикер» газетасы, атналык саннарын өчкә җиткереп, Россия киңлекләренә тарала тора, «Әлгасрел-җәдит»нең дә беренче саны, ниһаять, үзенең йөзен укучыга күрсәтә, ай үтүгә икенчесе дә очып чыгып китә, «Уклар» исемле сатирик журнал мәсьәләсе дә көн тәртибенә килеп баса. Габдулла бу вакытта үзенең иң рәхәт, иң бәхетле көннәрен кичергән дисәк тә, хата булмас. Дөрес, аның көннәре эшмәшәкать белән үтә, тын алырга да вакыты юк. Әмма теләп башкарган эш, яраткан хезмәт, никадәр авыр булмасын, ләззәт китерә.

«Фикер» газетасы чыга башлагач та, К. Мотыйгый Габдулланы айга сигез сум белән корректор итеп билгеләгән. Дөрес, Г. Кариев безгә бүтән төрлерәк мәгълүмат бирә: «Башта Тукай биш сум айлык белән ике ай дәвамында наборщик булып эшләде», — ди. К. Мотыйгыйның үз истәлегендә дә «Матбагада иң әүвәл русча вә мөселманча хәрефләр тезәргә өйрәнде» дигән сүзләр бар.

Замандашларының раславындагы мондый туры килмәүчелекне хәтер алдавына гына кайтарып калдыру дөрес булмас. Яңа гына туган «Фикер» газетасындагы хәлне бүгенге редакцияләр хәленә тиңләргә ярамый. Хәзер бит вазифалар анык билгеләнгән: редактор, җаваплы секретарь, бүлек мөдирләре, корректорлар һ. б. — һәркайсы үз эшен белә, һәркайсының вазифасы вакыт һәм эчтәлек ягыннан тәгаенләнгән.

«Фикер» редакциясенең штаты исә башта... бер кешедән торган. Нашире дә К. Мотыйгый, редакторы да. Җаваплы секретарь да үзе, «бүлек мөдире» дә. Беренче номерның корректурасын да үзе караган.

Рәсми рәвештә корректор итеп билгеләнгән Габдулланы эшне сәгатькә карап башлый, сәгатькә карап тәмамлый торган бүгенге «коллега»сы белән тиңләргә ярамый. Наборщик өлгерә алмый икән —

Габдулла хәреф кассасы янына барып баса. Конторщикка эш артып китә икән — ул аңа да барып булыша. «Фикер» тора-бара атнасына өч тапкыр чыга башлагач, «Әлгасрел-җәдит»тә дөньяга килгәч, Габдуллага, билгеле, эш тагын да арткан.

«Габдулла әфәнденең хезмәтләре, — дип яза К. Мотыйгый, — миңа бик ягымлы һәм дә үзе фәүкылгадә иҗтиһадлы булганга күрә, мин аның жалуньясын һәр ай саен арттыра бара идем. Шөйлә ки, иң әүвәл 8 сумга хезмәт итә башлап, соңыннан бик тиз айга 25 сум ала башлады».

Редакция һәм типография атмосферасында үзен никадәр генә рәхәт хис итмәсен, корректорлык вазифасын һәм бүтән эшләрне ничаклы теләп башкармасын, Габдулланың төп эше болар түгел. Аның төп эше,— үзе дә шулай санаган булса кирәк,— әдәби иҗат һәм публицистика.

Я. Морадиның әлеге китабында кызыклы белешмә бар: «Бер көн (1905 елның җәендә — И. Н.) Габдулла иптәш бөтенләй язу эшләренә бирелергә уйлады. Миннән 10 тиен акча сорап алды да, кәгазь вә карандаш сатып алып, мәшһүр Крыловның басняларын татарчага тәрҗемә итәргә тотынды». Күпмедер вакыттан соң Гурьевка кайтып киткән Морадига язган хатларының берсендә Габдулла «Крылов басняларын тәмам итүен, «Мәҗмугаи мөфидә» исеме илә Камил Мотыйгыйга нәшер өчен биреп, каләм хакына 25 тәңкә алырга муафыйк булганын бик куанып язган».

Габдулланың үзен иҗат эшенә багышларга карар итүе, истәлектә әйтелгәнчә, «ун тиенлек» эпизод рәвешендә генә булмаган, әлбәттә. Бу уй аңарда күптән өлгереп килгән. Без инде аның мәдрәсәи «Мотыйгыя» әдибе булып танылганын, шәһрәтенең мәдрәсәнең тышына да чыкканын күргән идек. К. Мотыйгыйның аңа зур өмет баглаганын, остазы Мотыйгулла хәзрәтнең дә хуплаганын белеп киткән идек. Әмма моңарчы әле шагыйрьлекне төп һөнәргә әйләндерүнең практик мөмкинлекләре егет өчен бик үк ачык түгел иде. Хәзер исә эш үзгәрде: «Фикер» газетасы чыга башлаячак, «Әлгасрел-җәдит» журналына рөхсәт алынган. Димәк, җиң сызганып язарга мөмкин. Крылов мәсәлләрен дә ул нәкъ менә «Әлгасрел-җәдит» өчен тәрҗемә итә башлаган. Һәм, чыннан да, соңрак алар нәкъ шушы журналда дөнья күрәләр. «Фикер» һәм «Әлгасрел-җәдит» чыга башлагач инде, буа ярылгандай була... 1906 елның июленә чаклы, ягъни сигез ай эчендә, язганнарына бер күз ташлыйк.

1905 елның ноябрь ахыры һәм декабрь ае: «Фикер» һәм «Нур» газеталарында басылган шигырьләре — 224 юл.

1906 ел. Январь, февраль, март, апрель, май, июнь айлары: «Әлгасрел-җәдит»нең һәр санында бер яисә ике, хәтта өчәр шигырь. «Фикер» газетасында алты шигъри әсәр. Арада 50—60 юлдан торганнары булган кебек, «Кечкенә генә көйле бер хикәя» исемле шигъри әсәр дә бар. Бөтенесе — 476 юл.

«Фикер»нең ярты еллык саннарыннан без биш исемдә мәкалә, фельетон һәм хикәяләрен табабыз. Кайберләре, озын булып, номердан номерга күчә барган. «Әлгасрел-җәдит» журналында, бер озын хикәядән кала, күләмле ике тәрҗемә урнаштырылган. Берсе — әлеге «Мөхәрәбә вә государственная дума» (апрель һәм май саннары). Икенчесе — А. Н. Бахның «Царь-Голод, экономические очерки» исемле әсәреннән баштагы дүрт бүлекнең тәрҗемәсе. Бусы журналның август, сентябрь һәм ноябрь саннарына кертелсә дә, эшләнеше, билгеле, елның беренче яртысына карый.

Югарыда Габдулланың Крылов мәсәлләрен татарчалаштырганлыгы турында әйтелгән иде. Ул бөек мәсәлченең барлыгы алтмыш биш мәсәлен чәчмә белән тәрҗемә иткән. Алар «Мәҗмугаи мөфидә»

(«Файдалы җыентык») исеме белән, «Әлгасрел-җәдит»тә 1906 ел дәвамында басыла һәм 1907 елга чыга.

Болар — имзасы куелган һәм Тукайныкы булуы шиккә алынмый торган әсәрләр. Андыйлардан кала, авторлары ачыкланмаган әллә ничаклы материал бар. Кемнәрнеке алар? Ихтимал булганнары икәү: Мотыйгый үзе һәм Габдулла. Беренчесенең күбрәк оештыру эшләре белән мәшгуль булганын искә алсак, күпчелек материалны Тукай язганлыгы турында уйларга туры килә.

Әгәр сигез ай эчендә басылып чыккан һәм авторлыгы шик тудырмый торган язмаларны гына бергә тупласаң да, уртача 10—12 табак күләмендә китап хасил булыр иде.

Күпме бу, әллә азмы? Әйтик, Бальзак масштабыннан чыгып карaганда, әлбәттә, артык күп түгел. Ә инде шул чорда кулына каләм алган күп кенә бүтән татар шагыйрьләре яисә язучыларының иҗат продукциясенә янәшә куеп карасак һәм Габдулланың шул вакыттагы эш һәм тормыш шартларын искә алсак, мәсьәлә бүтән сурәттә күз алдына килеп басар.

Ни әйтсәң дә, Габдулла «Мотыйгыя» шәкерте бит әле. Мәдрәсәдә «хөҗрә» биләп тора. Димәк, дәресләргә йөрүне бөтенләй үк ташлап бетереп булмый, мәдрәсәнең эчке тәртипләренә дә буйсынмый хәлең юк. Редакциядә корректор да ул, килгән материалларны төзәтү-редакцияләүгә дә тартыла башлый. Югарыда күргәнебезчә, бүтән төр эшләр дә башкарырга туры килә. Ә тәүлектә, билгеле ки, нибарысы 24 сәгать.

Инде килеп эш урыны мәсьәләсе. Язу-сызу белән мәдрәсәдә көндез шөгыльләнү турында сүз дә була алмый. Дөрес, шәкертләрнең күпчелеге каршында Габдулланың авторитеты зур. Әмма мондый шәкертләр дә бу кечкенә, ябык егетнең без белгән Тукай булып китәчәген, билгеле инде, башларына да китерә алмаганнар. Шуңа күрә «Шыпырт! Габдулла яза!» дигән команда астында торак тынып калмаган. Эреле-ваклы шәкертләр элеккечә үк мендәр сугышы оештыралар, шау-шулы уеннар уйныйлар, җырлап та җибәрәләр, талашу, кычкырышу да булып тора, кирәккә дә, кирәкмәскә дә Габдулла бүлмәсенә кереп бүлдерәләр, бимазалыйлар. Болары әле дус шәкертләр. Дошманнары да аз түгел. Туң миле бу шәкертләр Тукаевның тел камчысын оныта алмаулары һәм көнчелекләре аркасында интрига корганнар, үлән астыннан ут йөрткәннәр, вак-төяк әшәкелек эшләгәннәр.

Мәдрәсә түшәме астында Тукай нәрсәдер язган икән, алары торак тынып калгач, төнлә язылганнар. Шушы вакыттан калган гадәтедерме, шагыйрь моннан соңгы гомерендә дә күбрәк төнлә эшләгән.

Бәлки эш шартлары редакциядә әйбәт булгандыр?

1906 елның 4 январенда ясалган тентү беркетмәсеннән күренгәнчә, «Уралец» редакциясе өч бүлмәгә урнашкан булган. Беренчесендә — контора, икенчесендә — экспедиция эшләре, ә өченчесе — редактор кабинеты. Аста, подвалдагы 4 бүлмәдә, типография. Шуларның берсе — «Фикер» газетасының хәреф җыю бүлмәсе.

Күренә ки, редакциядә Габдулланың гына түгел, бәлки К. Мотыйгыйның да даими эш урыны булмаган. Дөрес, беркадәр соңрак, шул чакта конторщиклык вазифасын башкарган бер замандашының әйтүенә караганда, «Фикер» һәм «Әлгасрел-җәдит» өчен махсус бүлмә булдырылган. Тик анда да контора һәм экспедиция эшләре генә башкарылган. «Шуңа күрә, — дип яза замандашы, — Г. Тукай газета, журнал эшләрен кайда туры килсә, шунда эшләп йөрде». Төп эш урыны исә — «Фикер» газетасының подвалдагы хәреф җыю бүлмәсе. Кургаш тузаны катыш тынчу һава, шау-шу, ыгы-зыгы. Күршедә басу машинкасының дөпелдәгәне ишетелә. Габдулла бер почмакка сыенган

да аяк өсте генә гранка карый. Төзәтеп бетереп, хәреф җыючыга илтеп биргәч, бер читтә яткан кәгазьләрен алдына куеп, кызу-кызу язарга керешә. Бусы — номер өчен мәкалә яисә фельетон.

Замандашлары Габдулланың ара-тирә Төхфәтуллиннарның өендә эшләп утырганлыгы турында белешмә бирәләр. Билгеле инде, К. Мотыйгый тәкъдиме буенча булган бу. Нашир һәм редактор кеше Тукайны корректура карар өчен генә чакырмаган, әлбәттә. Ул аңа читтән килгән материалларны уку, ярардай булса, каләм тыгу, төзәткәләп җибәрү кебек эшләр тапшырган дип уйларга кирәк. Яисә Габдулла газета яки журнал өчен кирәк дип табылган үз мәкаләләрен язып утырган.

Әмма, истәлекләрдән аңлашылганча, шагыйрьнең Төхфәтуллиннар бүлмәсен файдалануы бөтенләй дә башка сәбәп белән булган, соңрак исә ул анда йомыш төшсә генә бара башлаган. Моның, әлбәттә, сәбәбе бар.

Бу вакытларда Төхфәтуллиннар ике катлы таш өйдә мул һәм иркен тормыш белән яшәгәннәр. Мотыйгулла хәзрәт, акыл иясе булачак, тышкы зиннәтләргә артык игътибар итмәсә дә, гаилә әгъзалары, шәһәрнең бай һәм зыялы рус гаиләләреннән күчергеч алып, яңача яшәргә, үзләрен заманча тотарга тырышалар. Иске гореф-гадәт һәм кагыйдәләрне атлап узу, сүздә һәм фикердә хөрлек, культурага, җыр-музыкага омтылу — болар барысы да яхшы. Тышкы яңаруга, әйтик, кием-салымга, ашау-эчүгә, кашык-чәнечке тотуга кирәгеннән артык игътибар бирүне дә бик үк хурлап булмый. Болары белән Габдулла килешер дә иде. Ә инде интеллигентный гаиләләргә охшарга тырышудан килә торган тәкәллеф һәм кылану, бүтәннәргә өстәнрәк карау һәм һавалану Габдулланың саруын кайнатмый калмаган, билгеле. Хәзрәт белән Камил аның талантын танысалар да, гаиләнең бүтән әгъзалары, әйтик, абыстай, Камилнең җәмәгате, Мотыйгулла мулланың үсмер уллары һәм кызлары өчен Габдулла — шәкертләрдән бер шәкерт кенә...

Типография почмагын һәм мәдрәсә торагының чаршау артын шагыйрь эшләү өчен артыграк күргән икән, бу бер дә гаҗәп түгел.

Хәзер инде, укучым, сигез ай эчендә җитештерелгән әлеге 10—12 басма табак продукция турында үзең әйтеп кара: азмы ул, әллә күпме?

Нәрсә турында һәм ничек язды соң Тукай шушы сигез ай эчендә? Бу сорауга җавап бирү өчен яшь шагыйрьнең Уральскидагы вакыйгаларда ни рәвешле катнашуы, илдәге хәлләрне ничек күзәтеп баруы, ничек бәяләве, җыеп әйткәндә, дөньяга карашының башлангыч чоры белән танышып китәргә кирәк.

1905 елның җәендә Габдулланың «Уралец» типографиясенә өйрәнчек булып кергәнлеге укучының хәтерендәдер. Уральскиның типография эшчеләре исә («Уральские войсковые ведомости» газетасының типографиясе дә шул исәптә) активлык һәм революцион вакыйгаларда катнашу ягыннан, депо эшчеләреннән кала, икенче урында торганнар. «Түгәрәкчелек» стадиясеннән чыгып, яңа гына оешма булып әверелгән социал-демократлар «Уралец» типографиясен листовка, революцион җыр һәм бүтән төр агитацион кәгазьләр басып чыгаруда нык кына файдаланганнар. Типографиядә партия әгъзалары да булган.

А. Гладышевның мәгълүматларына караганда, алар, ягъни Саша белән Габдулла, әнә шул прокламация һәм җырларны таратуда катнашканнар. Анисимов күләнә баралар икән дә, әлеге кәгазьләрне кармак салып утыручы мастеровойлар янына шыпырт кына куеп

китәләр икән. Хәтта шәһәрнең үзәк урамы Большая Михайловскаяда да таратып йөргәннәр.

Габдулла типографиянең бүтән рус эшчеләре белән дә аралашкан. Гладышевның әйтүенчә, эшчеләр бу татар егетен яратканнар, аңа, үз итеп, «интеллигентный татарин» дигән кушамат тагып куйганнар. Габдулланың аерым социал-демократлар белән дә таныш булганлыгы турында уйларга нигез бар. «Безне җыелышларга да үткәрәләр, — ди Гладышев, — ләкин без анда тулы тавыш белән файдаланмый идек әле».

Габдулланы листовка тарату кебек «бала-чага» эше генә канәгатьләндереп бетермәгән, билгеле. Аның зуррак эш башкарасы килә. Моның өчен исә күп белергә, мәмләкәттә барган вакыйгалардан хәбәрдар булырга кирәк. Һәм ул, «Уралец» белән генә чикләнмичә, редакциягә килә торган башкала газеталарын да җентекләп укып бара. Егетне бигрәк тә яшерен матбугат, төрле революцион брошюралар кызыксындырган. Шундый әдәбиятны табып алып укуы беркадәр соңрак «Война и дума» һәм «Царь-Голод»ны тәрҗемә итүе белән дә раслана.

Менә бер заман революциянең куәт ала баруыннан коты очкан патша тарихка «17 октябрь манифесты» дигән исем белән кергән документка кул куя. Анда сүз иреге, матбугат һәм җыелышлар иреге вәгъдә ителгән, закон чыгара торган дума чакырылачагы, конституция биреләчәге әйтелгән. Илдәге тәртипләрдән канәгать булмаган сыйныф, социаль катлау һәм партияләр тантана итәләр. Чөнки революциянең беренче зур җиңүе бу. Ә инде манифестның мәгънәсен аңлау һәм аңлатуда нигездә өч юнәлеш күзгә ташлана. Хөкүмәтнең тирәге булган карагруһчыл төркемнәр моңа самодержавиене саклап калу өчен чарасыздан эшләнгән адым итеп карыйлар. Либераль-буржуаз партияләр, манифестта буржуазия өчен уңайлыклар һәм ташламалар күреп, революцияне шушы дәрәҗәсендә туктату максаты белән, манифестны якларга, мактарга, конституцион иллюзияләр таратырга керешәләр. Революцион социал-демократлар исә, минуты, сәгате белән үк, манифестның коры кәгазь генә, революцион ялкынны сүндерүгә юнәлтелгән маневр гына икәнлеген халыкка аңлата башлыйлар, һөҗүмне дәвам иттерергә, самодержавиене аударырга чакыралар.

Яшь Тукайның, манифест турында ишеткәч һәм документның үзен укыгач, шатлыктан исереп йөрүе бер дә гаҗәпләндерми. Беренче карашка, безне икенче нәрсә — аның бу уңай белән беркатлылык күрсәтүе гаҗәпләндерә. Үзен тыңлап карыйк.

Күрең патша хәзрәтен,
Җуйды халык хәсрәтен,
Күргәч фитнә хәсрәтен,
Киңлек бирде бәдәвам.
(«Иттифак хакында».)

Чиновниклар безнең канны бик күп имде,
Имәлмәсләр, җитәр инде, җитәр инде;
Мазлумнарга якты нурлы көннәр килде.—
Азатлыкның кояшы тугды инде.
(«Дусларга бер сүз».)

Патша хәзрәтләре, күрәмсең, эреле-ваклы чиновникларның, полиция һәм жандармнарның башбаштаклыгын, халыкның ташып түгелергә җиткән ачуын күреп алган да, мәмләкәтне һәлакәттән коткарыр өчен, золымга чик куярга карар иткән. Менә тиздән дума җыелыр, конституция кабул ителер, шул нигездә халык, аеруча изелгән милләтләр, чын хокук, чын азатлык алыр, крестьяннар җирле булырлар. Хәзер исә, һич кичекмәстән, милләт эчендәге үзара талашларны читкә атып, бер җан, бер тән булып, эшкә башларга, искелеккә, на-

данлыкка каршы көрәшергә, мәгърифәт тармакларын үстерергә кирәк.

Тырышыйк, и хас вә гам [1],
Һәр көн үзгәрә заман,
Җитәр, йокламыйк һаман,—
Таңнар атты бәдәвам.



Сорау туа: ничек итеп Тукай шундый беркатлы иллюзиягә бирелә алды әле? Әйтерсең лә ул беркайчан да эшчеләр белән аралашмаган, социал-демократларның агымдагы хәлләр турындагы сүзләрен ишетмәгән һәм тыелган әдәбиятны тотып та карамаган!

Тирәнтенрәк уйлаганда, биредә гаҗәпләнерлек нәрсә юк. Мәгълүм булганча, ярым-йорты грамоталы эшче тарафыннан җиңел үзләштерелә торган социализм идеяләре интеллигенциягә башта, әлбәттә, авыр бирелә. Бөтен илгә, хәтта бөтен дөньяга танылган фикер иясе яки әдипнең, марксизм белән танышып та, бу тәгълиматны кабул итә алмавы да мөмкин. Ерак барасы да юк: Л. Н. Толстой. Авылдан авылга сөрелеп йөреп, промышленность үзәкләреннән ерак торган кечкенә Җаек каласының кадим мәдрәсәсендә ун ел яткан яшь Тукайдан шуннан артыгын көтәргә мөмкин идеме? Җитмәсә, ул — изелүче милләт вәкиле.

XIX йөзнең икенче яртысы һәм XX йөз башы татарларның уяну, милләт булып формалашу, милли азатлык өчен көрәш башлау чоры иде. Узган гасыр татар мәгърифәтчеләре, башка халыкларның мәгърифәтчеләре кебек үк, В. И. Ленин әйткәнчә, «...халыкның бер сыйныфын да аерым рәвештә игътибар үзәгенә алмадылар, гомумән халык турында гына түгел, хәтта гомумән милләт турында сөйләделәр» [2]. Татар милләте исә туып кына килә. Өстәвенә, ул хокуклары чикләнгән изелүче милләт. Әнә шул чорда, социаль мәсьәләләрдән дә бигрәк, милли мәсьәләнең калкыбрак торуы, милли аңның уянуы, милләткә мәхәббәт тойгыларының һәм, гомумән, милләт идеясенең игътибар үзәгенә басуы табигый хәл иде.

XIX гасыр мәгърифәтчеләренең әсәрләрен укып күзе ачылган яшь татар егетен күз алдына китерик. Менә бер заман ул үз-үзенә, тирә-ягына карый да күрә: бүтән милләтләр — француз яисә инглизчаннарны әйтәсе дә юк — мәсәлән, руслар, японнар, хәтта әрмәннәр, әнә кая киткәннәр! Ә без? Моннан йөз ел элек кайда булсак, шунда торып калганбыз түгелме? Наданлык, томаналык, фәкыйрьлек — котың очар! Һаман шул иске гореф-гадәт, иске кагыйдәләргә ябышып яту.

Егетебез кимсенә, хурлана, артта калуның сәбәпләре турында уйлана башлый, милләтне тәрәккый иттерү чараларын эзләргә керешә. 1905 елда бөтен халыклар өчен шундый милли хис белән шулай янган егетләрне меңәрләп санарга мөмкин иде инде. Һәркайсы дип әйтерлек сәләтенчә һәм мәеленчә нәрсәдер эшли, тапканын уртак казанга китереп сала... XIX гасырның икенче яртысында тернәкләнгән яңа эчтәлекле татар культурасы (шул исәптән, әдәбият) XX йөз башында сикереш ясаган икән, ул милли-азатлык хәрәкәте дулкыны сыртында бу югарылыкка күтәрелде дисәк тә, шаять хата булмас.

Әлеге меңнәрнең иң дәртле, иң ихлас күңелле, иң талантлыларыннан берсе Тукай булды.

Дәвамы бар

---

[1] Хас вә гам — югары һәм түбән катлаулар.
[2] В. И. Ленин. Әсәрләр. 2 том, 1955, 520 бит.

## Шәүкәт Галиев

### Үз итеп...

Бакчада туп тәгәрәтеп
Уйнап йөри шук бала.
Һәйкәл янына килә дә
Тынып кала, туктала.

Биектә торган кешене
Бик белә ул, бик таный,
Бик таныганга күрә дә
Үз итеп дәшеп карый.

Җавап булмагач, моңаеп
Карап тора ул аңа.
...Ленин бабай китап тоткан,
Ленин бабай уйлана.

Әнисе кызын юаткан,
Килеп күтәреп алган:
— Син китап укый башлагач,
Җавап бирер ул, балам!

### Онытмаган икән курай...

Әби аны
Сандыгыннан
Алып бирде:
— Бабаң китте —
Курай тынды,
Күптән инде...

Белә иде
Курай ул чак
Күп көйләрне:
«Зиләйлүк»не,
«Туган тел»не,
«Тәфтиләү»не.

Бер кан ла сез,
Бер лә, балам,
Сезнең сулыш,
Мә, җан өрче,
Терелтергә
Аны булыш!

...Өрәм дә бит,
Курай белми...
Оныткан шул,
Тын алмыйча,
Уйнамыйча
Күп яткан шул.

Әби көтә...
Аңа карап
Күңелем тулды...
Нәкъ шул чакта
Курайга да
Нидер булды —

Моңайган да,
Юаткан да
Сөйләшкән күк:
Мин әйтәсе
Сүзләр белән
Ул дәшкән күк!

Хәтерләде
«Зиләйлүк»не,
Белде, белде
«Тәфтиләү»не,
Онытмаган
«Туган тел»не!

Әй, сагынып,
Әй, тансыклап
Көйли курай —
Гүя бабаң
Үзе кайтты,
Диде бугай...

## Зәңгәр зебра

Зәңгәр зебра, зәңгәр зебра
Килә урамнан!
Зәңгәр зебраны малайлар
Уратып алган.

— Африкадан килгән микән?!
— Нигә ул зәңгәр?
— Зәңгәрләнерсең, шул чаклы
Юл үтсәң әгәр!

Зәңгәр зебра, зәңгәр зебра
Миһаһайлады,
Миһаһайдан абайлады
Малайлар аны:

Колын икән, зәңгәр зебра
Булмаган икән,
Зәңгәр рәшәткәгә генә
Буялган икән!

Буявы бетте колынның,
Юдык без аны.
«Зәңгәр» кушаматы гына
Ябышып калды!..

## Куян калачы

Әти кайтты
Урманнан,
Буш кайтмаган
Ул аннан —

Чытырманлы
Җирләрдән
Куян калач
Җибәргән!

Тәмләп кенә
Карачы,
Бигрәк тәмле
Калачы!

Төлке шуңа
Кызыгып
Йөри ди күз
Кыздырып...

* * *

Әткәй бара
Урманга.
Ни җибәрим
Куянга?

Кимергәне
Кишер дә,
Кишер кышын
Өшер лә...

Конфет-шикәр
Салыйм соң,
Рәхәтләнеп
Суырсын.

Бусы булсын
Истәлек,
Җибәрәмен
Пистолет!

Инде Куян
Калачын
Төлке талап
Карасын...

## Ышанма әле...

Тиен сикерә
Нарат башында,
Тын алмый торам
Карап мин шунда.

Тузганак койрык,
Җиңел-җиңелкәй,
Матур-матуркай,
Тиен-тиенкәй!

Чикләвек белән
Сыйлыйм, сыйлыймчы,
Атышып бергә
Уйныйм, уйныймчы!

Күреп туймадым,
Ник киттең үртәп,
Ник ышанмыйсың,
Ник син бик өркәк?!

Күрәм, яныма
Бер абзый баскан,
Йотардай булып
Күзләрен ачкан:

— Аһ, ди, кызганыч,
Тыелган сунар —
Тиеннәр түгел,
Китә бит сумнар!..

...Ерактарак йөр,
Тиен-тиенкәй,
Ышанма әле,
Җиңел-җиңелкәй!

## Кемнеке — аныкы...

1

Бабасы Бакыйны
Бакчага озата:
— Кемнеке — аныкы,
Әйбәт йөр, сынатма.
Чәчләрен бик тартма,
Кызларны елатма!

2

Бакый да бабасын
Авылга озата:
— Кемнеке — аныкы,
Әйбәт йөр, сынатма.
Чәчләрен бик тартма,
Кызларны елатма!

# ХАТЛАРДАН ЮЛЛАР

*Рафаэль Мостафин герой шагыйребез Муса Җәлил иҗатын өйрәнүчеләр сафына 60 нчы елларда килеп кушылган иде. Алар арасында ул бик тиз үз урынын тапты һәм сәләтле галим, тынгысыз эзләнүче булып танылды. Ул фәнни китапханәләрдә һәм архивларда эзләнде, Муса Җәлилне якыннан белгән, аның белән бергә яшәгән, бергә көрәшкән кешеләрнең язмышын ачыклады, шагыйрь эзләре буйлап меңнәрчә километр юл үтте, Муса Җәлилнең иҗатына, тормыш һәм көрәш юлына караган бай материал туплады.*

*Озакламый аның шул материалларга нигезләнеп язылган аерым мәкаләләре һәм очерклары басыла башлады. Аннары бер-бер артлы китаплары чыгарга тотынды: «Эзләнү дәвам итә» («Поиск продолжается». Рус телендә, Казан, 1965 ел. Бу китап шагыйрьнең дусты Г. Кашшаф белән бергә языла), «Батырлык поэзиясе» («Поэзия мужества». Рус телендә, «Знание» нәшрияты, Мәскәү, 1966 ел.), «Муса Җәлил эзләреннән» (Казан, 1968 ел.)... Аның бу китапларын әдәби җәмәгатьчелек тә, укучылар да җылы каршылады.*

*Ләкин Р. Мостафин эзләнүләрен алга таба дәвам иттерде. Ул М. Җәлил һәм җәлилчеләр язмышын ачыклауга төрле җирләрдә, төрле илләрдә яшәүче кешеләрне тарта алды. Нәтиҗәдә М. Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә багышланган яңа китаплар дөньяга чыкты. Галимнең 1971 елда «Детская литература» нәшриятында чыккан «Герой шагыйрь эзеннән» («По следам поэта-героя») исемле китабы аеруча зур яңгыраш тапты. 1973 елда аның тагын да тулыландырылган һәм баетылган варианты 100000 данә тираж белән Татарстан китап нәшриятында кабат басылды. Бер ел вакыт үткәч, «Өзелгән җыр эзеннән» («По следам оборванной песни») дигән исем астында һәм 220 000 данә тираж белән ул Мәскәүнең «Известия» нәшриятында чыкты.*

*Әлеге китаплары уңае белән, авторга илебезнең барлык почмакларыннан, хәтта чит илләрдән бик күп хатлар килгән. Ул хатларны төрле һөнәр, төрле профессия кешеләре — мәктәп балалары һәм комсомоллар, укытучылар һәм китапханә эшчеләре, күренекле язучылар һәм Җәлилнең көрәштәшләре язган. Алар Р. Мостафин китапларын укыганнан соң туган тәэсирләре белән уртаклашалар, авторга үзләренең теләкләрен һәм фикерләрен белдерәләр.*

*Журналыбызның бу санында укучыларга автор исеменә килгән кайбер хатларны һәм алардан аерым өзекләр[1] тәкъдим итәргә булдык. Хатлар һәм өзекләр хронология тәртибендә урнаштырылды.*

**Минем уемча, китабыгыз шагыйрь хакындагы барлык әсәрләргә караганда хакыйкатькә якынрак булып чыккан. Ул сезнең төп китабыгыз өчен әйбәт трамплин, яхшы җирлек булачак.**

**Тик шунысы кызганыч, китапларны бигрәк озак басабыз инде. Ул, кулдан-кулга йөреп, җыела, укыла, төзәтелә торгач күпме вакыт үтә. Кайбер нәрсәләр, чыннан да, искерә төшә. Шулай да бу нәрсә Шәрипов белән булган эпизодка[2] кагылмый диярлек. Ул шәп язылган. Әйдә, ничек язылган булса, шулай калсын.**

**Николай Лешкин.**
**Уфа, 30 июнь, 1971 ел.**

---

[1] Хатларны матбугатка Ф. Миңнуллин әзерләде.

[2] Сүз М. Җәлилнең немец төрмәсеннән Г. Шәрипов алып чыккан шигырьләре турында бара. Н. Лешкин — журналист, 1975 елда Уфада рус телендә басылган «Лица и маски» исемле китапның авторы.

Чын күңелдән котлыйм. Бернинди шөбһәсез, бу — Муса Җәлил турында язылган барлык китаплар арасында иң яхшысы, иң ышанычлысы. Китабыгыз диссертация якламый да гыйльми дәрәҗә бирергә лаек: анда Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең батырлыгы, беренче мәртәбә дөрес һәм эзлекле итеп, бөтен тулылыгы белән тасвирлана. Китап шик-шөбһәләр өчен бернинди урын калдырмый. Ул ышандыра, үлемсез героебызга булган мәхәббәтебезне арттыра.

Китабыгыз әлегә безнең кибетләрдә юк. Якын араларда җирле матбугат өчен аның турында рецензия язып карарга җыенам.

Бүләк өчен, дуслык хисләре өчен тагын бер тапкыр зур рәхмәт... М. Җәлил портреты ясалган экслибрис[1] җибәрәм. Авторы — Караганда графигы В. Тимофеев. Аның экслибрислары Лейпцигта күрсәтелде. Тагын Муса Җәлилнең Карагандада яшәүче шагыйрь һәм галим-минералог Спартак Әхмәтов тарафыннан тәрҗемә ителгән шигырьләрен җибәрәм. Укып карагыз әле... Фикерләрегезне әйтеп хат язарсыз.

**Әсхәт Хәмидуллин**[2].
**Караганда, 8 июль, 1971 ел.**

Хөрмәтле Рафаэль туган!

Мин Муса Җәлил язмышына кагылышлы материалларның кулга төшкәннәрен укып һәм бик кызыксынып күзәтеп барам. Әле менә Сезнең Мәскәүдә чыккан «По следам поэта-героя» исемле әсәрегезне кулга төшердем һәм йотлыгып укып чыктым. Шуның белән бергә, минем гаилә членнарыннан дә берничә кеше укып чыгарга өлгерде инде.

Бу хактагы материалларны кабат-кабат укуга карамастан, әсәрне ашкынып һәм ашыгып укыйсың. Алдагы сәхифәләрдә нинди булса да берәр яңа вакыйга турындагы хәбәрне белергә, Мусаларның әлегә чаклы ачылмаган батырлыклары турында ишетергә ашкынасың...

**Зур ихтирам һәм ихласлы сәлам белән**
**Сәйфи Кудаш.**
**Башкортстан, Йоматау, 28 сентябрь, 1971 ел.**

Сез соңгы елларда гел юлда булдыгыз, Муса Җәлил эзләре буйлап йөрдегез, иҗат иттегез. Иҗатыгыз белән «Казан утлары» журналы аша танышып тордык. Сез үз артыгыздан меңнәрчә укучыларны, Муса Җәлил тормышы белән бәйле вакыйгаларда катнашкан күп кешеләрне иярттегез. Без сезнең белән бергә яшәдек, бергә кайгырдык, бергә шатландык, хәтта «Муса Җәлил» теплоходында сәяхәт итеп тә йөрдек. Моның өчен чиксез зур рәхмәт!

Ниһаять, көтелгән китап безнең кулда. Анда бер Муса Җәлилнең генә түгел, ә аның белән бергә көрәшкән, бергә үлемне каршылаган иптәшләренең дә батырлыгы күрсәтелә.

Бу тәрҗемә түгел, ә татар язучысының бөек рус телендә язган үз әсәре. Укучы бусы өчен дә шатлана. Сез халык өчен әйтеп бетергесез зур эш башкардыгыз.

**Ирле-хатынлы Сафиуллин һәм Ихсановалар.**
**Пермь өлкәсе, 30 октябрь, 1971 ел.**

Рафаэль! Муса Җәлилнең судтагы рече (Р. Мостафин. По следам поэта-героя. Мәскәү, 1971 ел, 122 бит.) йомшаграк чыккан. М. Горькийның «Ана» романында Павел Власовның судтагы рече, Н. Островскийның «Корыч ничек чыныкты» романында Павел Корчагинның дуслары кабере янында биргән анты, А. Фадеевның «Яшь гвардия» романында краснодончыларның тантаналы вәгъдәләре кемнәрне генә дулкынландырмый да, кемнәрне генә көрәшкә рухландырмый. Муса Җәлилнең суд залындагы рече дә шундый булырга тиеш. Ул фашизмга үлем карары булып яңгырарга, ул шигырь белән тәгәлләнергә тиеш.

**Мидхәт Якупов.**
**Ташкент, 11 ноябрь, 1971 ел.**

---

[1] Экслибрис — нясенең исеме язылып китапка ябыштырылган ярлык.
[2] Ә. Хәмидуллин — Караганда телестудиясенең баш редакторы.

Борис Полевойдан соң[1] ни дә булса язу, хезмәтегезне, туккән көчегезне яңача бәяләү, сез язган китапның уңай яклары турында сүз әйтү кыен. Мин бары зур хезмәт тәмамлавыгыз, шәп китап язуыгыз белән чын күңелдән котларга гына телим.

Даугавпилста булуыгызны, Муса Җәлил узган авыр юллар буйлап йөрүегезне белгәч, 1941 елның 30 июнендә батыр полкташларым Петр Игашов һәм аның сугышчан дуслары күмелгән урында булуыгыз ачыклангач, миңа, нечектер, сезнең героегыз Муса Җәлил тагын да якын, кадерле, үз булып китте, сез үзегез дә якын кешегә әйләндегез.

**Запастагы гвардия майоры**
**Иван Шевченко.**
**Калининград, 14 декабрь, 1971 ел.**

Без, авыл комсомоллары, «По следам поэта-героя» дигән китабыгыз белән таныштык. Аны укыгач, Җәлил хакындагы элекке белгәннәребезгә күп яңа нәрсә өстәлде.

Якташыбыз Муса Җәлилнең искиткеч батырлыгы кемне генә канатландырмый да, кемне генә дулкынландырмый?! Без аның белән бик нык горурланабыз. Җәлилнең батырлыгы турындагы бу китабыгыз яшьләр йөрәгендә ватанга мәхәббәт уты кабыза.

Муса Җәлилне һәр җирдә яраталар һәм укыйлар. Аның үләр алдыннан язган шигырьләре безне чиксез дулкынландыра һәм батырлыкка рухландыра. Күпме көч бу кешедә, дип гаҗәпләнәбез.

Китабыгыз Муса Җәлил хакында язылганнарга күп яңалык өсти. Безне аның блокнотларының язмышы кызыксындыра. Тиздән алар хакында нинди дә булса яңа нәрсә белерсез, дип ышанабыз.

**Озерка авылы комсомоллары.**
**Оренбург өлкәсе, 5 сентябрь, 1972 ел.**

Рафаэль абый! Китабыгызны рәхәтләнеп кат-кат укыдым. Ул Җәлилгә, шулай ук сезнең тырышлыгыгызга булган хөрмәтемне тагын да көчәйтә төште. Мин герой шагыйрьнең рухи хәлен, аңардагы искиткеч патриотизм хисен сурәтләү һәм, ниһаять, кырыс һәм аек фактларны сайлый белү осталыгыгызга, хакыйкатькә, бары тик хакыйкатькә хөрмәт белән каравыгызга сокланам. Ләкин, мине гафу итегез, (Паньков сүзләренә таянып) әсир төшкәндә Җәлил кычкырган, дип язу кирәкмәс иде. Мин ышанам, тулысынча ышанам, Җәлил кебек зур ихтыяр көченә ия булган кеше кычкырмас, дошман каршында куркып калуын сиздермәс. Юк, ул түгел, башка кеше кычкырган.

Рафаэль абый! Моны китабыгызга кырыс бәя дип саный күрмәгез. Һич алай түгел! Мин Җәлилне һәм аның гүзәл әсәрләрен яратам, туган көненнән алып героик үлеменә кадәр булган бөтен биографиясен җентекләп өйрәндем, татар телендәге һәм русчага тәрҗемә ителгән шигырьләрен яттан беләм. Һәм шуңа да Җәлилне яраткан кеше белән тәэсирләремне уртаклашасым килә. Миң беләм, сез аны бик яратасыз, моңа китабыгызны укыгач төшендем.

**Гөлфия Хәсәнова.**
**Казагыстан, июнь, 1973 ел.**

Китабыгызны укып чыктым. Әсирлекнең авыр көннәрен кабат баштан кичергәндәй булдым. Листовкалар, яшерен җыелышлар, кулдан ясалган шигырь дәфтәрләре, ул шигырьләрне ничек тә саклап калырга тырышулар, качарга хәзерләнеп йөрүләр, йөзенә төкерергә, кыйнап ташларга теләсәң дә, дошман алдында елмаерга мәҗбүр булулар, ач килеш йокларга ятып, төштә икмәк күреп саташулар, кыйналулар, уникешәр сәгать буена эшләп йөрүләр — һәммәсе дә, һәммәсе дә таныш. Китапны мавыгып укыдым. Тәнкыйть характерындагы искәрмәләрем юк. Хәер, бераү бар икән.

Әсирлектә миңа немец коммунистларын яки күңелләре белән фашистларга каршы булган бик әйбәт гади кешеләрне очратырга туры килде. Китаптан күренгәнчә,

---

[1] Б. Полевойның «Правда» газетасында (1971 ел, 8 декабрь) басылган «Неизгладимые следы» исемле мәкаләсе күздә тотыла.

Муса белән аның иптәшләре дә андый кешеләрне очраталар. Ләкин сез алар хакында аз сөйлисез. Шундый кешеләр турында күбрәк белешегез, китабыгызның икенче басмасын чыгарганда аларга да урын бирегез. Немец дусларыбызның күңеле булыр.

Мин дә «Еллар аша» дигән кулъязмамны тәмамладым, анда әсирләр тормышына күп урын бирелә. Китап нәшриятта...

Яхшы китап язган һәм аны миңа укырга биргән өчен зур рәхмәт. Муса турында нинди дә булса яңа нәрсә тапсагыз, хәбәр итә күрегез, минем өчен бу бик кызык.

**Иван Савич.**
**Ворошиловград, 1973 ел.**

Китабыгызны алдым, ул яхшыра һәм тулылана төшкән. Аның 100 мең данә тираж белән чыгуы — күңелле хәл. Ләкин бу тираж да аз булачак. Ник дигәндә, М. Җәлилгә багышланган күп китаплар арасыннан ул — иң популяры. Ышанам, сезгә аның яңа басмасын чыгарырга туры киләчәк. Чөнки әсирлектә булган яңа кешеләр, яңа фактлар табылачак.

Шулай да совет әсирләренең немец коммунистлары һәм болгар студентлары белән булган бәйләнешләрен читләтеп узуыгыз бераз кәефне җибәрде. Болар бит расланган фактлар иде.

**Михаил Иконников.**
**Архангельск, 14 март, 1974 ел.**

Китабыгыз өчен зур рәхмәт!

Дөрес, аны яхшы кәгазьдә чыгармаганнар. Әмма ни генә булмасын, ул эти турындагы иң яхшы китап!

**Чулпан Җәлилова.**
**Мәскәү, 18 март, 1974 ел.**

Муса Җәлил — бөтен совет халкының мактанычы һәм горурлыгы. Үлемгә хөкем ителгәннән соң, шундый патриотик шигырьләр яза алган башка шагыйрь юк, минемчә. Сезнең Муса турындагы китабыгызны укыгач, күңелдә бөек Ватаныбыз һәм аның батыр халкы өчен горурлык хисе уяна.

**Владимир Новиков.**
**Казан, 21 март, 1974 ел.**

Бүген ахырга кадәр китабыңны укып чыктым. Ул ике атна буена юлдашым булды. Рәхмәт сиңа.

Хәтерлисеңме икән, минем әни дә шул ук Моабитта утыра бит. Һәм шунда аны ике мәртәбә үлемгә хөкем итәләр, Плетцензее төрмәсенә ябалар.

Китабың бик көчле язылган.

Җәзалау камерасын җентекләп тасвирлау. Мусаның әлеге тәмуг оясында яшәүгә булган өмете. Шундый авыр, йөрәкләр кысыла...

**Ингрид Георганс-Костова.**
**Берлин, 13 апрель, 1974 ел.**

Зур шатлыгым белән уртаклашам.

Кичә бездә Муса Җәлилгә багышланган әдәбият дәресе булды. Мин Җәлил турында сөйләгәндә, класста нинди тынлык хөкем сөргәнен белсәгез иде. Ул чагында мин кайда икәнемне дә онытгым, бөтем уем — мөмкин кадәр җан җылысы белән сөйләү иде. Һәм мин шуңа ирештем дә бугай.

Мин инде сүзне тәмамладым, ә класста ниндидер гадәттән тыш тынлык, беркем селкенми. Иң соңгы партада — укытучы. Классташларыма күтәрелеп караган идем, әллә нишләп киттем: һәммәсенең күзләрендә яшь.

Шуны белгәч, күршедәге унынчылар, директорга кереп, аларга да минем Муса Җәлил турында сөйләвемне үтенгәннәр. Анда да шул ук хәл кабатланды...

Моның өчен мин сезгә бурычлы. Сезнең белән хат алыша башлагач, мин Җәлилне тагын да ныграк ярата төштем. Шул хисне башкаларга да йоктырдым. Хәзер Муса Җәлил иҗаты белән танышырга теләүчеләрнең исәбе-хисабы юк.

**Вера Жадько.**
**Кустанай өлкәсе, 17 апрель, 1974 ел.**

Сезгә хәзер, мөгаен, хатлар күп киләдер һәм аларның һәркайсында «По следам поэта-героя» исемле китабыгызның геройлары хакында нинди дә булса яңа хәбәр буладыр. Кызганычка каршы, теләгем бик зур булса да, әлегә мин берни белән дә ярдәм итә алмыйм. Хикмәт бары шунда, китабыгызны укып чыккач, хат язмый кала алмадым.

Хезмәтегез өчен, шундый кеше булганыгыз өчен, сезгә чын күңелдән зур рәхмәт!

Мин эшләгән мәктәптә балаларның яртысына якыны — татарлар. Безнең мәктәпнең барлык укучылары, бигрәк тә өлкән классларда укучылар, Муса Җәлил шигырьләрен бик яраталар.

**Ирина Габиева.**
**Свердловск өлкәсе, 23 апрель, 1974 ел.**

Кадерле Рафаэль!

Җибәргән китапларыгыз өчен зур рәхмәт. Больницада яту сәбәпле, сезгә бик озак җавап яза алмадым...

Аның каравы, китабыгызның икенче басмасын зур игътибар һәм кызыксыну белән укып чыгу өчен биредә вакыт та, мөмкинлек тә җитәрлек булды. Миңа ул, беренче басма белән чагыштырганда, алга таба зур адым булып тоела. Яңа, кызыклы нәрсәләр күп, бик күп. Мәсәлән, беренче дәфтәр, өченче батальон тарихы турында (Атнашов һәм Бухаровның анда взвод командирлары булу фактын гына алыйк), гомумән, Н. И. Лешкинның яңа табышлары, архив материалларындагы мәгълүматлар һәм башка күп нәрсәләр... Кызганыч, иллюстрацияләр, чыннан да, начар чыккан. Берничә төгәлсезлек киткән: Цоссен янындагы урын Рансдорф дип түгел, ә Рангсдорф дип йөртелә, палачлар кеше җәзалаган өчен 30 марка түгел, ә 300 марка алганнар. Үз-үзеңә каршы килүгә бер мисал: 209 биттә «Аларны кем сатканын Муса белми иде», диелә. 179 биттә Муса үзе үк сатлык җанның исемен телгә ала.

Беренче басма белән чагыштырганда, бусында материал системалырак итеп бирелгән... Миңа калса, тагы ике бурычны үтәп чыгасыгыз кала: Җәлил турында балалар өчен документаль повесть язу һәм Муса һәм аның группасы турындагы барлык материалларны (үзегез туплаганнарын гына түгел) тәнкыйть күзе аша үткәреп фәнни хезмәт язу.

**Ялкынлы сәлам белән**
**Леон Небенцаль.**
**ГДР, Берлин, 2 май, 1974 ел.**

Кадерле Рафаэль!

...«Дружба народов»ка кушымта төсендә «По следам оборванной песни»ның чыгуы белән чын күңелдән котлыйм! Минемчә, яхшы басма һәм тиражы да — 220.000 — начар түгел. Димәк ки, борын салындырырга ярамый... Ни дисәң дә, әдәбият ул — китаплар...

Сездән ике данә «По следам...» ала алсам, шат булыр идем. Берсе — истәлек язуы белән (традиция буенча) Нурекны тәэсүчеләргә, икенчесе — үзем өчен.

Килештекме?

Өйгә яки редакция адресына җибәр.

Көтәм!

Сезгә иң изге теләкләр һәм уңышлар!

**Сергей Баруздин.**
**Мәскәү, 18 ноябрь, 1974 ел.**

«По следам поэта-героя» исемле китабыгызны куптән түгел укып чыктым. Китапның сызмаган, әллә нинди тамгалар, ничәмә-ничә төрле билгеләр куймаган, гарәп хәрефләре белән язмаган бер сау битен калдырмадым... Бер яктан караганда, бу — зур җинаять.

Икенче яктан караганда, бер дә алай түгел.

Китапны бик ихлас күңел белән, җентекләп укып барганда, офык буенча дәһшәтле һәм коточкыч, гадәттән тыш авыр һәм куркыныч Волхов фронты күренә. Җир үкереп яна... Сулар кайный... Кан дәрьясы ага... Җир өсте мәетләр, яралы солдатлар белән тулган. Шулар арасында, канга буялып, авыр яралы Муса ята... Явыз дошманга каршы тигезсез көрәштә һәлак булган ватандашларны күреп, йөрәк әрни, тын кысыла, тел тотлыга...

Алга таба да дәһшәтле һәм фаҗигале хәлләр гел арта бара. Әсирләр, концлагерьлар, төрмәләр, совет әсирләрен җәзалаучы палачлар... Сезнең китабыгызны укыганда, үзеңне шул вакыйгаларда катнашучы бер кеше итеп сизәсең. Шулай булгач, ничек аны сызгаламыйсың да, ничек аңа билгеләр салмыйсың?! Бу китапны салкын кан белән уку мөмкин түгел.

Мин Муса Җәлил һәм җәлилчеләр белән сезнең китабыгыз аша таныштым. Аларның шигырьләре һәм җырлары миңа бик нык тәэсир итте, күңелемә май шикелле сеңеп, җаныма балдай ягылды. Героик образлары җанлы рәвештә гомергә онытылмаслык булып күз алдымда калачак.

Гестапо дөяне энә күзеннән уздырган гадәттән тыш авыр шартларда Муса Җәлил һәм аның батыр йөрәкле иптәшләре фашизмга каршы көрәш алып баралар. Ахырдан шул көрәш юлында батырларча һәлак булалар.

Ләкин аларның эше эзсез югалмый. Алар салган шул эз, ахыр килеп, немец халкын социализмның туры, киң юлына алып чыга. Фашистлар хурлыклы рәвештә җиңелгәч, аның бер өлешендә яңа демократик республика — ГДР төзелә. Бу гүзәл җиңүдә Муса Җәлилнең һәм аның сугышчан иптәшләренең дә өлеше шактый.

**Хәмзә Юмангулов.**
**Ашхабад, 8 декабрь, 1974 ел.**

«По следам оборванной песни» исемле китабыгызны укып чыкканга ике айлап вакыт үтсә дә, һаман тынычланып җиткәнем юк. Күпме хезмәт салынган бу әсәргә!

Сез укучыны Волхов сазлыкларыннан башлап шагыйрьнең гомере өзелгән Плетцензее төрмәсенә кадәр алып киләсез, катлаулы язмышлы бик күп кешеләр белән очраштырасыз, үлемсез яңа геройлар белән таныштырасыз.

Әсәрдә гел дөреслек, бер генә җирендә дә күпертелгән, шомартылган урын юк. Үзем сугышның ачысын-төчесен шактый татыгангадырмы, сугыш темасына язылган бик күп китаплар укыганым бар. Әмма бер генә роман яки повестьның да күңелдә сезнең язмаларыгыз шикелле тирән эз калдырганы юк иде. Сез халыкның сөекле улы Муса Җәлилне — батыр йөрәкле, эчкерсез, намуслы, гомеренең ахырына кадәр туган иленә, халкына хезмәт иткән, дошманга нәфрәт белән янган, үлмәс шигырьләр калдырган герой шагыйрьне — миллионнарга ачып саласыз.

Безнең китапханәгә йөрүчеләрнең күпчелеге руслар. Муса Җәлилне белмәгән, аның «Моабит дәфтәре»ндәге шигырьләрен укымаган кеше юк диярлек.

Бөек Җиңүнең 30 еллыгы уңае белән, сезнең китаплар буенча укучылар конференциясе һәм герой шагыйрьгә багышланган әдәби кичә үткәрергә планлаштырабыз.

**Халидә Урманова.**
**Башкортстан, 26 декабрь, 1974 ел.**

Миңа элегрәк тә Муса Җәлил һәм аның «Моабит дәфтәре» турында укырга туры килгән иде. Ул чагында әле мин бик яшь идем. Хәзер менә, аның исемен ишетүгә, күңелдә хөрмәт һәм горурлык хисе уяна... Ул безнең өчен гомерен биргән, ә гомер бит — кешенең иң кадерле нәрсәсе. Муса Җәлил бик аз яшәгән, ә күпме эш эшләр-

гә өлгергән! Аның шигырьләренең һәр сүзе шагыйрьнең зур йөрәге турында сөйли. Сезнең китапта аның безгә килеп җитмәгән шигырьләре турында укыганда күңелләр сыкрап куя. Гитлерга да, чиксез корбаннар китергән сугышка да тагын бер кат ләгънәт укыйсы килә...

Гильотина хакында язылган урыннарны күз яшьсез укып булмый. Мондый вәхшилеккә исем юк...

**Наташа Немченко.**
**Кривой Рог, 29 декабрь, 1974 ел.**



Миңа Муса Җәлилнең батырлыгы турында элегрәк тә укырга туры килгәне бар. Тик алар аерым-аерым өзекләр генә иде. Ә сезнең китапта барысы хакында да тулы һәм эзлекле итеп сөйләнә. Мин шигырь укырга бик яратам, әмма Муса Җәлил шигырьләрен тыныч кан белән уку мөмкин түгел. Аның әсәрләрен укыган саен, мин аның ныклыгына һәм батырлыгына сокланам. Үлем карары чыгарылганнан соң да шигырь язу өчен нинди зур ихтыяр көченә ия булу кирәк!

Кызганычка каршы, бездә беркайдан да М. Җәлил шигырьләрен табып булмый. Сезгә зур үтенечем бар: аның шигырьләр җыентыгын табарга булышсагыз иде. Сезнең Язучылар союзында аның рус телендә чыккан шигырь китаплары бардыр?.. Түземсезлек белән җавап көтәм.

**Владимир Григорьев.**
**Омск өлкәсе, декабрь, 1974 ел.**

«По следам оборванной песни» (нинди әйбәт исем!) дигән китабыгыз төп геройның язмышы һәм зурлыгы белән генә түгел, ә бәлки искиткеч кайнарлык, үз-үзеңне, йөрәгеңне һәм акылыңны аямыйча язылган булуы белән дә сокландыра.

Трагик һәм бөек героегыз эзеннән йөргәндә ничек дулкынлануыгызны, сез кичергән сагыш һәм хисләрне бик ачык күз алдына китерәм. Миңа китапның композициясе дә яңа һәм оригиналь тоелды, урыны-урыны белән сез тасвирлап барасыз, ә кайчакта турыдан-туры укучыга мөрәҗәгать итәсез, уйланасыз, фактларны янәшә куеп карыйсыз, кайчак үз-үзегезне (алдагы китапларда әйтелгәннәргә өстәп) тулыландырасыз, кайчак бәхәсләшәсез яки раслыйсыз.

Тәэсир искиткеч, хакыйкатькә хыянәт иткән бер генә урын да юк.

**Мария Прилежаева.**
**Мәскәү, 13 февраль, 1975 ел.**

Китабыгыз өчен рәхмәт. Кызыклы һәм һәр яктан мактауга лаек ул китапны укучылар җылы каршылады, дигәнсез. Бу хәбәр мине бик шатландырды. Котлыйм.

**Борис Полевой.**
**Мәскәү, 5 март, 1975 ел.**

«Орбита» системасы буенча Муса Җәлилгә багышланган тапшыруны карадым (28 февраль, 1975 ел). Кирәкле һәм яхшы эшләнгән тапшыру. Муса Җәлилнең героик көрәше яшьләрне анабыз Ватанга чиксез бирелгәнлек рухында тәрбияләргә булыша. Безнең яшьләр көрәшче, коммунист, шагыйрь, Советлар иленең гражданины Муса Җәлил эзеннән баралар...

М. Җәлилгә багышланган тапшыруларда халык көйләрен һәм шагыйрь сүзләренә язылган җырларны да ишетәсе килә, бу — тапшыруларны һичшиксез баета төшәр иде.

**Ибраһим Чыңгыз.**
**Владивосток, 6 март, 1975 ел.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ФӘННИ КИҢӘШМӘ

13—14 ноябрьларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы конференц-залында хәзерге әдәбият фәне һәм тәнкыйтенең актуаль методологик мәсьәләләренә багышланган фәнни-теоретик киңәшмә булып үтте. Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, Татарстан язучылар союзы һәм Казан дәүләт университеты тарафыннан үткәрелгән бу киңәшмәдә, Казан галимнәреннән тыш, Мәскәү, Уфа, Алабуга һәм башка шәһәрләрдән килгән әдәбиятчылар катнашты. Филология фәннәре докторы, профессор И. Нигъмәтуллинаның «Системалылык ысулы һәм татар әдәбият фәне», филология фәннәре доктары, профессор Х. Госманның «Хәзерге әдәби процесста әдәбият фәне белән тәнкыйтьнең үзара хезмәттәшлеге», филология фәннәре докторы Г. Халитның «XX йөз башы татар әдәбиятының методлары һәм стильләрен өйрәнү мәсьәләләре», филология фәннәре кандидаты Р. Бикмөхәммәтовның «Хәзерге әдәбият фәнендә милли һәм гомумсовет әдәби закончалыкларны өйрәнү», филология фәннәре кандидаты А. Әхмәдуллинның «Хәзерге татар әдәбият фәне һәм тәнкыйтенең кайбер актуаль мәсьәләләре», филология фәннәре кандидаты Х. Курбатовның «Матур әдәбият телен структур-системалы өйрәнү», филология фәннәре кандидаты Ш. Абиловның «Урта гасыр татар әдәбиятының иҗат методын өйрәнү мәсьәләләре», филология фәннәре кандидаты Т. Галиуллинның «30 нчы еллар әдәбият фәне һәм тәнкыйтен өйрәнүнең кайбер методологик мәсьәләләре», филология фәннәре кандидаты Ф. Мусинның «Стиль мәсьәләләре», филология фәннәре кандидаты Р. Ганиеваның «Төрки әдәбиятларда иҗат методы мәсьәләләре», филология фәннәре кандидаты Ф. Хатиповның «Хәзерге тәнкыйтьтә әдәби әсәрне бәяләү критерийлары» дигән докладлары тыңлаучыларда зур кызыксыну уятты. Докладлар буенча фикер алышуларда филология фәннәре докторы Н. Юзиев, филология фәннәре кандидатлары Б. Гыйззәт, Ф. Сафиуллина, Х. Миңлегулов һәм башкалар катнашты.

## КӨН ТӘРТИБЕНДӘ — ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕ

Узган елның ноябрь аенда Татарстан язучылар союзы, Мәгариф министрлыгы һәм китап нәшрияты белән берлектә, татар мәктәпләре өчен чыгарылган әдәбият дәреслекләрен тикшерүгә багышланган зур сөйләшү уздырды. Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы укытучысы Ф. Ганиева, филология фәннәре кандидатлары М. Мәһдиев, Р. Мостафин, Х. Миңлегулов һәм Ш. Садретдиновлар гамәлдәге әдәбият дәреслекләре турында докладлар ясадылар. Фикер алышуларда филология фәннәре докторлары Г. Халит, И. Нуруллин, Х. Ярми, филология фәннәре кандидатлары Ф. Хатипов, Ф. Мусин, М. Җәләлиева, А. Әхмәдуллин, Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, Татарстан мәгариф министры урынбасары Р. Галиәхмәтов, министрлыкның дәреслекләр бүлеге хезмәткәре И. Әүхәдиев, Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Шәрәфетдинов, нәшриятның өлкән редакторы Н. Мәҗитова, әдәбият укытучылары Б. Хафизова һәм В. Хаҗиев иптәшләр катнаштылар. Алар докладларда кузгатылган мәсьәләләрне тагын да ачыклый һәм тирәнәйтә төшteләр, докладчыларның аерым фикерләре белән бәхәскә керделәр.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР КИҢӘШМӘСЕ

Казанда эшче авторларның беренче республика киңәшмәсе үткәрелде. Татарстан язучылар союзы, ВЛКСМ өлкә комитеты һәм профсоюзларның Татарстан өлкә советы тарафыннан оештырылган бу киңәшмәдә Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама һәм республикабызның башка промышленность үзәкләрендә яшәүче авторлар катнашты. Эшче авторлардан М. Газизов (Чаллы), Х. Хөснуллин (Чаллы), Э. Мостафин (Казан), М. Каюмов (Казан), Р. Хисмәтуллин (Түбән Кама), Р. Вәлиуллин (Лениногорск), А. Хәсәнов (Лениногорск), Р. Имаев (Түбән Кама), Сәетбатталов (Түбән Кама), Н. Гыйматдинова (Казан) һәм Р. Лотфуллиннарның (Чаллы) шигырьләре, хикәя, повестьлары, очерклары, тәнкыйть мәкаләләре тикшерелде. Алар танылган язучылар һәм артистлар белән очраштылар, төрле темаларга лекцияләр тыңладылар, промышленность предприятиеләрендә булдылар, шәһәрнең истәлекле урыннары белән таныштылар.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ, ӘДӘБИ ТҮГӘРӘКЛӘРДӘ

Татарстан язучылар союзы каршындагы проза секциясенең октябрь ахырында уздырылган утырышы М. Насыйбуллин иҗатын тикшерүгә багышланды. «Азат хатын» журналының җаваплы секретаре Г. Шәрәфетдинов утырышта катнашучыларны

М. Насыйбуллинның иҗат эшчәнлеге белән таныштырды. Фикер алышуда Ә. Еники, Ф. Хөсни, А. Расих, Б. Камалов, М. Мәһдиев, Х. Сарьян һәм башка язучылар катнашты. Алар яшь прозаикның әсәрләренә тәпле анализ ясадылар, файдалы киңәшләр, эшлекле тәкъдимнәр әйттеләр. М. Насыйбуллин каләмдәш дусларына иҗат планнары турында сөйләде.

*
* *

Шагыйрьләр секциясенең 26 ноябрьда уздырылган утырышында сүз яшь шагыйрь Г. Садә иҗаты турында барды. Утырышта Ә. Исхак, И. Юзеев, Р. Гатауллин, Роберт Әхмәтҗанов, Г. Рәхим, Р. Мингалимов һ. б. чыгыш ясады. Алар Г. Садә шигырьләренең уңай һәм кимчелекле якларын билгеләп үттеләр.

*
* *

«Казан утлары» журналы каршындагы яшь рецензентлар түгәрәгенең чираттагы утырышы бүгенге әдәбият турында фикер алышуга багышланган иде. Әдәби бәхәс төсендә барган сөйләшүдә түгәрәк членнарыннан Ф. Макаев, М. Вәлиев, М. Галиев, Т. Әйди, Р. Абдуллина, Н. Гамбәров, Р. Низамиев, Ә. Мәхмүдов, Ф. Низамова һ. б. катнашты. Алар бүгенге әдәбият турындагы кызыклы фикерләре һәм күзәтүләре белән уртаклаштылар. Бәхәскә йомгакны журналның тәнкыйть бүлеге мөдире Ф. Миңнуллин ясады.

*
* *

Шул ук түгәрәкнең 5 ноябрьда уздырылган икенче бер утырышында яшь тәнкыйтьчеләр күренекле язучыбыз Ә. Еники белән очраштылар. Ул яшьләргә бүгенге татар әдәбияты һәм үз иҗаты турында сөйләде, түгәрәк членнарының бик күп сорауларына җаваплар бирде.

*
* *

«Татарстан яшьләре» газетасы каршындагы «Яшьлек» әдәби берләшмәсенең чираттагы утырышында Н. Шакиров, Г. Гатауллин, Ф. Шәйдуллин, Х. Ильясов шигырьләре тикшерелде. Укылган әсәрләр турында фикер алышуда яшь тәнкыйтьче М. Вәлиев, шагыйрьләр Р. Вәлиев, Р. Миңнуллин, Г. Садә, Р. Хәйретдинов һ. б. катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАРГА БҮЛӘК

Авыл халкына культура хезмәте күрсәтүдәге уңышлары өчен, Татарстан язучылар союзына СССР Культура министрлыгы, культура хезмәткәрләре профсоюзы үзәк комитеты, авыл хуҗалыгы эшчеләре һәм хезмәткәрләре профсоюзы үзәк комитетының вымпелы һәм акчалата премия бирелде.

## ЯҢА КИТАПЛАР

Узган ел Мәскәүнең «Современник» нәшрияты төрле миллләт шагыйрьләренең Бөек Ватан сугышына багышланган шигырьләрен басып чыгарды. «Ради жизни на земле» дип исемләнгән бу җыентыкка татар шагыйрьләреннән М. Җәлил, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, С. Хәким, С. Баттал һәм З. Нури шигырьләре кергән. Анда шулай ук һәр авторның кыскача биографиясе һәм фоторәсеме бирелгән.

*
* *

Сухумидагы «Алашара» нәшрияты Абхазиянең халык шагыйре Дмитрий Гулианың «Безнең партия» дигән шигырен, илебездәге 43 милләт теленә тәрҗемә иттереп, аерым китап итеп чыгарды. Бу шигырьнең татарчасы шагыйрь Зәки Нури тәрҗемәсендә бирелгән:

**Табигатьнең чиксез зур көче бар —**
**Җир тетрәтә, таулар ишә ала.**
**Партиянең көче аннан да зур,**
**Ул көчтән тау хәтта үсә ала.**

**Табигатьтә туган яңа диңгез**
**Меңәр еллап шаулый-ярсый ала.**
**Ә Партия исә ел эчендә**
**Шундый диңгез тудыра-ясый ала.**

**Күктә балкый зур һәм нурлы кояш,**
**Матур итеп җирне яктырта ул.**
**Партиянең эше аннан да зур —**
**Күңелләрне ямьли, яхшырта ул.**

**Галәм чиксез — аның киңлекләрен**
**һичбер кем дә үлчи-иңли алмый.**
**Партияне сөю аннан зуррак —**
**Киң галәмгә күңел тиңли алмый.**

**Кояш белән һава — аерылгысыз,**
**Партия һәм халык — бердәм, бергә.**
**Кояш сүнсә, тормыш булмас иде,**
**Партиясез яшәп булмый җирдә.**

*
* *

Мәскәүнең «Наука» нәшриятында шәрык халыкларының әкиятләре, мифлары тупланган «Книга о судах и судьях...» дигән китап чыкты. Анда татар халкының да бер әкияте бар.

*
* *

Башкаладагы Политик әдәбият нәшрияты «Говорят погибшие герои» дигән җыентык чыгарды. Бөек Ватан сугышында һәлак булган батырлар истәлегенә багышланган бу китапта герой шагыйребез Муса Җәлилгә зур урын бирелгән.

## ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР, ОЧРАШУЛАР

Кырым өлкәсенең Ялта шәһәрендә «Язучылар — партиянең XXV съездына» дигән темага әдәби кичә үткәрелде. Кичәдә илебезнең төрле республика һәм өлкәләреннән

килгән әдипләр — И. Фоняков (Ленинград), Е. Карпенко (Киев), Җ. Әбдрәшев (Алма-Ата), М. Аврамчик (Минск), А. Кравцов (Харьков), В. Белоусов (Донецк), З. Нури (Казан), И. Данилов (Якутск), И. Осьмухин (Саранск), А. Балакаев (Элиста) — катнашты.

*
* *

Язучылардан Н. Дәүли, М. Маликова, Г. Сабитов һәм М. Галиев республикабызның Саба районында булып кайттылар. Алар, районның күп кенә авылларында булып, кыр батырлары һәм мәктәп укучылары белән очраштылар, матур әдәбият сөючеләрне үзләренең яңа әсәрләре белән таныштырдылар.

*
* *

Татарстан Культура министрлыгы, ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты, В. И. Ленин исемендәге китапханә һәм балаларның үзәк китапханәсе республикадагы балалар китапханәләре хезмәткәрләренең ике көнлек семинарын үткәрделәр. «Бала шәхесен тәрбияләүдә матур әдәбиятның роле» дигән темага багышланган бу семинарның бер утырышында балалар язучылары Ш. Галиев һәм Л. Ихсанова катнашты.

*
* *

Ташкентта яшәүче әдәбият галиме И. Зәбиров тугандаш Украинаның Львов һәм Запорожье өлкәләрендә йөреп кайтты. Ул әлеге өлкәләрнең бик күп промышленность предприятиеләрендә, мәктәпләрендә һәм пионер лагерьларында, колхоз һәм совхоз эшчеләре янында булды, аларга Муса Җәлил һәм аның батыр көрәштәшләре хакында сөйләде.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Узган елның октябрь аенда Әлмәт язучылары «Татнефть» берләшмәсе начальнигы урынбасары Үзбәк Саттаров белән очраштылар. Ул Татарстан нефтенең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге, алдагы бишьеллыкта нефтьчеләр алдына куела торган бурычлар турында сөйләде, язучыларны кызыксындырган сорауларга җаваплар бирде.

Утырышның икенче өлешендә Татарстан язучылар союзы каршындагы проза секциясенең җитәкчесе, танылган прозаик Атилла Расих үзенең иҗат тәҗрибәсе һәм иҗат планнары белән уртаклашты.

*
* *

Бүлек язучылары берничә тапкыр колхоз һәм совхоз эшчәннәре янында булып кайттылар. Елховой авылының культура сараенда уздырылган кичәдә Г. Афзал, Ю. Эминов, С. Сөләйманова, С. Кальметов һәм яшь шагыйрь Г. Кашапов катнашты. Алар үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, сорауларга җаваплар бирделәр. Кичәнең икенче өлешендә район культура йорты үзешчәннәре көче белән концерт куелды.

Шундый ук кичәләр районның Мәмәт, Кәләй, Нәдер һәм Яңа Кәшер авылларында да уздырылды.

*
* *

Яңа Кәшер урта мәктәбендә берничә ел буена әдәби-иҗат түгәрәге эшләп килә. Түгәрәк белән тел-әдәбият укытучысы, шагыйрә К. Булатова җитәкчелек итә. Күптән түгел Яңа Кәшер мәктәбе әдәбиятчылары Әлмәт шәһәренең 1 нче номерлы татар урта мәктәбе каршындагы әдәбият түгәрәге членнары янында кунакта булдылар. Алар тәҗрибә уртаклаштылар, әдәби кичәдә яңа шигырьләрен укыдылар.

## ТЕАТР ҖӘМГЫЯТЕ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Казанның Актерлар йортында Бөтенроссия театр җәмгыяте Татарстан бүлегенең XIII республика конференциясе булды. Анда бүлекнең идарә председателе, ТАССРның халык һәм РСФСРның атказанган артисткасы Р. Җиһаншина, ревизия комиссиясе председателе А. Юрусов отчет докладлары белән чыктылар. Фикер алышуларда Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының баш режиссеры, РСФСРның халык артисты Н. Даутов, балет солисты В. Яковлев, ТАССРның халык артисты П. Маслов, ТАССРның атказанган артисты Б. Роскин, сәхнә ветераннары советы председателе Ф. Саллави, Татарстан язучылары союзы идарәсенең председателе Г. Ахунов, Бөтенроссия театр җәмгыяте идарәсе члены В. Серков һ. б. катнашты.

Конференция бүлек идарәсенең һәм ревизия комиссиясенең яңа составын сайлады.

## КОТЛЫЙБЫЗ

Совет театр сәнгатен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен СССР Верховный Советы Президиумы Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисты **Фуад Ибраһим улы Халитовка СССРның халык артисты** дигән мактаулы исем бирде.

*
* *

Сочида «Кызыл канәфер» дип исемләнгән халыкара җыр фестивале тәмамланды. Чили патриоты Виктор Хара истәлегенә багышлап уздырылган бу фестивальдә якташыбыз Р. Ибраһимов зур уңыш казанды. Португалия җырчысы Луиза Башту белән бергә, ул беренче премиягә лаек булды.

*
* *

Фәрит Яруллин истәлегенә багышланган симфоник поэмасы өчен, композитор Фасил Әхмәтовка РСФСРның Дәүләт премиясе бирелде.

## ТЕАТР ҺӘМ БАЛАЛАР

23 ноябрьдан 30 ноябрьга кадәр республикада «Театр һәм балалар» атналыгы уздырылды. В. И. Качалов исемендәге Зур драма театры бинасында Бөтенроссия «Театр һәм балалар» атналыгын ачу тантанасы булды. ТАССР культура министры Ә. С. Миндубаев, ТАССР мәгариф министры урынбасары З. Е. Михайлова, ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре Р. З. Баһаветдинова Бөтенроссия «Театр һәм балалар» атналыгының яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләүдәге роле турында сөйләделәр, атналыкны оештыручыларга һәм анда катнашучыларга зур уңышлар теләделәр. Шул ук көнне республикабыз театрларында «Ачык ишекләр көне» үткәрелде. Якшәмбе көнне Казанның Актерлар йортында «Яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләүдә театрның роле» дигән темага ата-аналар өчен конференция үткәрелде.

Атналык көннәрендә нәни тамашачылар артистлар, режиссерлар, драматурглар белән очраштылар. Һәр театр бәйрәмгә яңа спектакльләр әзерләде.

*

* *

Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры тамашачыларга Р. Щедринның «Канатлы ат» исемле балетын күрсәтә башлады. Әсәрне сәхнәгә балетмейстер Л. Исакова куйган. Декорацияләрне А. Кноблок ясаган. Дирижеры — Г. Арсенин.

*

* *

Казан курчак театрының рус труппасы сәхнәгә Н. Фәттахнең «Кызлар тавының серләре» исемле әсәре буенча эшләнгән яңа спектакль чыгарды. Спектакльнең режиссеры — Р. Батуллин, художнигы — В. Губская. Көйләрне композитор С. Садыйкова язган. Әсәрне рус теленә Ә. Хөсәенов тәрҗемә иткән.

*

* *

Атналык көннәрендә В. И. Качалов исемендәге Зур драма театры Д. Родари әсәре буенча эшләнгән «Король чәчәкләре», һинд әкиятләренә нигезләнеп куелган «Чанду маҗаралары» һәм В. Розов әсәре буенча эшләнгән «Хәерле сәгатьтә» исемле спектакльләр күрсәтте.

*

* *

Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә бу көннәрдә «Тапкыр егет» һәм «Кол Гали» дигән спектакльләр барды. Театр артистлары шулай ук Питрәч районы балаларына культура хезмәте күрсәттеләр.

## БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР

14 ноябрьда Казан дәүләт консерваториясенең актлар залында дирижер Равил Мартынов җитәкчелегендә ТАССР Дәүләт симфоник оркестрының концерты булды. Анда СССР халык артисты, СССР Дәүләт премияләре лауреаты композитор Нәҗип Җиһановның 6 нчы симфониясе беренче тапкыр башкарылды.


## АРТИСТНЫ ИСКӘ АЛУ


Казанның Актерлар йортында җырчы Газиз Әлмөхәммәтовның тууына 80 ел тулуга багышланган кичә уздырылды. Журналист Ш. Рахманкулов тамашачыларны артистның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштырды. Танылган музыкант И. Һилалов, Татарстанның атказанган артисткасы С. Садыйкова, композитор З. Хәбибуллин Газиз Әлмөхәммәтов турында истәлекләр сөйләделәр. Соңыннан сәнгать осталары көче белән концерт бирелде.

# ЯШӘ, ПАРТИЯ

БАТУ МУЛЮКОВ көе

ӘНВӘР ДАВЫДОВ сүзләре






Богаулы кулларда өрнеде яралар,
Өметләр янды теләкләрдә;
Нәләт богауны өзәргә, Партия,
Көч бирдең безнең йөрәкләргә.
Миллионнар уен,
Өметен, теләген
Бергә тупладың,
Безнең Партия.
Халык акылы,
Көче, йөрәге,
Заман вөҗданы —
Безнең Партия.
Яшә, Партия!

Азатлык нурлары балкытты Ватанны,
Көн килде барлык халыкларга;
Илне гөлбакча итәргә, Партия,
Зирәклек бирдең акылларга.
Миллионнар уен,
Өметен, теләген
Бергә тупладың,
Безнең Партия.
Халык акылы,
Көче, йөрәге,
Заман вөҗданы —
Безнең Партия.
Яшә, Партия!

## *Хөрмәтле укучыбыз игътибарына*

Журналыбызның өченче саны Сибгат Хәким шигырьләре белән ачыла. Шагыйрь иҗатына хас табигать, сугыш һәм тыныч тормыш, халкыбыз тарихы, ил картлары, хезмәт кешеләре турында уйлануларын сез шигырьләрдә дә күрерсез.

Бу санда Атилла Расихның «Айлы төннәр» романы басылып бетәчәк.

Габдулла Тукайның 90 еллыгын билгеләп үтәр көннәр якынлашып килә. Шул уңай белән Ибраһим Нуруллинның «Тукай» әсәреннән өзекләр бастыруны дәвам итәбез.

Марсель Зарипов очеркы «Уракчы егетләр» дип атала. Әмма ул колхоз батырлары түгел, Түбән Кама химикларының егетлекләре турында сөйли.

Журналның бу санында хатын-кызлар иҗатына күп урын бирелгән. Сез Ләбибә Ихсанова, Кояш Тимбикова хикәяләре, Мәдинә Маликова очеркы, Салисә Гәрәева, Венера Рәхмәтуллина шигырьләре һәм Гөлшат Зәйнашева рецензиясе белән танышырсыз

Тәнкыйть бүлегендә Рафаэль Мостафинның әдәбият турында уйланулары, яңа китапларга рецензияләр басыла.

Тарихи фактлары белән башкорт язучысы Йосыф Гәрәйнең «Каләм», «Нур», «Ашкадар» дигән мәкаләсе кызыклы гына.

Һәр сандагыча, бу юлы да әдәбият һәм сәнгать яңалыклары бирелә.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210